ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

4.2005



# КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ



*Б. Проломная (хәзерге Бауман) урамы*



*Кабан күле*

XX гасыр башында алынган фотосурәтләр.
*Абдулла Дубин коллекциясеннән.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2005

4

(990)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


*Бу санда*


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Роберт ӘХМӘТҖАН. Садә авазлар. *Шигырьләр.* ... 5
Рөстәм МИНГАЛИМ. Безне ватып ага вакыт. *Шигырьләр.* ... 110

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Зөлфәт ХӘКИМ. Телсез күке. *Ике пәрдәле драма.* ... 12

**ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ—ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ**

Олег ШЕСТИНСКИЙ. Татар изүе татлы. *Хикәя.* ... 114

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Камил ТАНГАЛЫЧЕВ. Тел белгән сихри биләүдә. *Шигырьләр.* ... 119
Айрат СУФИЯНОВ. Өмет калыр. *Шигырьләр.* ... 124

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Сәгыйдулла ХАФИЗОВ. Кайда безнең рыцарьлар? ... 127

**ИЛБАРИС НАДИРОВКА 80 ЯШЬ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Шигъри җанлы галим. ... 136
Илбарис НАДИРОВ. Игелекле эшнең иртә-киче юк. ... 137

**РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНГА 70 ЯШЬ**

Марсель ГАЛИЕВ. Гомер учагы. ... 146

**"ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ" БИТЛӘРЕННӘН**

Гомәр САБИРҖАНОВ. Асылларның асылы. ... 157

**ХӘТЕР**

Нәкыя ГЫЙЛӘҖЕВА. Газизебез бар иде. ... 162

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ... 168

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Марат ЗАКИР. Давыллы дәвер шагыйре (Әбрар Сәгыйдинең тууына 110 ел). ... 174
Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Якты һәм җылы бөркелә... (Мәҗит Рафиковның тууына 80 ел). ... 176

**ЮМОР-САТИРА**

Тәлгат НӘҖМИЕВ. Саба мәзәкләре. ... 178

**LATİN IMLASİNDA UQU KÜNEKMƏLƏRE**

"Yazdan ayırıp bulmıy Tuqaynı". ... 183

"Казан утлары" архивыннан. ... 186
Берлекнең яңа әгъзалары. ... 188
Иҗтимагый- мәдәни тормышыбыздан. ... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": стихи Роб. АХМЕТЗЯНОВА, Р. МИНГАЛИМОВА.
"Драматургия": драма З. ХАКИМА "Немая кукушка".
"Дружба литератур—дружба народов": рассказ О. ШЕСТИНСКОГО "Сладкое татарское иго".
"Новые имена": стихи К. ТАНГАЛЫЧЕВА, А. СУФИЯНОВА.
Дискуссия "Герой нашего времени": статья С. ХАФИЗОВА "Где наши рыцари?"
"К 80-летию И. Надирова": Р. ФАЙЗУЛЛИН. "Ученый с поэтическим мышлением": статья И. НАДИРОВА к 10-летию фонда Ахметвали Менгера.
"К 70-летию Роб. Ахметзянова": эссе М. ГАЛИЕВА о поэте.
"Страницы из "Татарской энциклопедии": статья Г. САБИРЗЯНОВА.
"Память": статья Н. ГИЛЯЗОВОЙ о творчестве писателя Г. Мухамметшина.
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
В номере отмечаются 110-летие А. Сагиди, 80-летие М. Рафикова.
"Юмор-сатира": Т. НАЗМИЕВ. "Забавные истории".
Навыки чтения на основе латинской графики.
Из архива журнала.
Новые члены Союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина художника И. АХМАДИЕВА "Тафтиляу", поэт М. Закир.

## IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": verses by R. AHMETZYANOV, R. MINGALIMOV.
"Dramatic art": drama by Z. HAKIM "Mute cuckoo".
"Literature Friendship is Peoples' friendship": story by O. SHESTINSKY "Sweet Tatar opression".
"New names»: verses by K. TANGALYCHEV, A. SUFIYANOV.
Discussion «Hero of our time": article by S. HAFIZOV "Where are our knights?"
"To 80th anniversary of I. Nadirov": R. FAYZULLIN. "Scientist with poetic thinking"; Article by I. NADIROV to 10th anniversary of Ahmetvali Mengera's fund .
"To 70th anniversary of R. Ahmetzyanov": essay by M. GALIEV about the poet.
"Pages from "Tatar encyclopedia": article by G. SABIRZYANOV.
"Memory": article by N. GILYAZOVA about creativity of writer G. Muhametshin.
"Science": A. TIMERGALIN. "Dictionary of nation".
In this magazine 110th anniversary of A. Sagidi, 80th anniversary of M. Rafikov are celebrated.
"Humour-satire": T. NAZMIEV. "Funny stories".
Skills of reading on the basis of latin alphabet.
From archive of magazine.
New members of Union of writers.
Diary of social-cultural life.
On our covers: picture by artist I. AHMADIEV "Taftilau", Poet M. Zakir.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.03.2005 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7011. Заказ А–196.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.



**Роберт Әхмәтҗан**

## САДӘ АВАЗЛАР

### Бакый ага Сөембикәсе

*"Мин гомерем буе җырладым..."*
Бакый Урманче

**Ак дөньяда, өстәп бакыйлыгын,**
**Бакый ага сынга җан өргән...**
**Могҗизамы,—**
**тормыш суты ташып,**
**агач тамырлардан йөгергән!**
**Күзен ачып**
**йөреп китәсе бар,—**
**Ул терелгән, оста, терелгән...**
**Сөембикә булып өлгергән!**

**Өтергеңне куймый җырлый идең,**
**Бакый ага,**
**җырла тагын бер,—**
**Җанкисәгең Сөембикәңә дә**
**Үзенең җырын,**
**чорын сагындыр!**

**Төрбәсеннән торсын әле ханнар,**
**Сафа Гәрәй торып утырсын!..**
**Гүрдән торып, алар ак дөньяны**
**Яшәү гаме белән тутырсын!**

**Шатлансыннар күкләр, газиз туфрак,—**
**Җырласыннар бөтен катламда...**
**Татар рухы җирдә ятар түгел,—**
**И, милләтем итсен тантана!**

Сөен, бикә!
Син яңадан тудың!
Чорың—ерак,—
Сөен-сөенмә...

Күңелләрдә ап-ак киемнән син.
Тик карадан...
берүк
киенмә!

## Көзге якты дөнья уртасында

Ага суда тезелеп сары яфрак,
Калганнары тора талда калтырап:
"Җитәсе бит бу хәл безгә дә...
Без язларын мендек зәңгәр күккә,
Килгән кебек идек мәңгелеккә,
Килер бу мәл, дуслар, сезгә дә,
Көзгә дә..."

Төялеп лә китә матурлыклар,
Ә язларын кире кайтырлыклар
Көзге суга төшә капланып:
"Без кайтырбыз язын бөре булып,
Бүгенгедән эре, тере булып,
Тик кышларын үтик сакланып,
Шатланып!"

Көзге матур дөнья уртасында
Китәм, диеп, кайчак куркасың да,
Йөрәк-яфрак тора калтырап...
Әллә нигә бөтен фасыллардан
Гүя бөре, әле ачылмаган,—
Көз дөньясын сөям катырак,—
Яктырак!

Яшәтә бит безне өмет кенә,
Агымсуда без бит күбек кенә,—
Көтә көзге яфрак хәлләре.
Югыйсә бит кояш яктысында,
Табигатьнең юлым яртысында
Шәм кабызып куйган мәлләре:
Балкып яна яшәү гамьнәре!

## Соңгы яфрак

(элегия)

I

...Утыра ул карап тәрәзәдән
Көннәр буе—бөкре, чал карчык.
Ни соң күзли сүнә язган караш,
Кайда калган Яшьлек адашып?

Урамда көз.
Көз, дип, саргайган йөз,—
И бу көзе фани заманның!..
Өзелеп төшәр чагы җиткән ласа
Соңгы яфраккае чаганның...

Шул урамнан әллә эзлиме ул
Яшьлегенең ерак шәүләсен?
Искән җилдәй шаулап үткән гомер.
Табалганмы шуның мәгънәсен?..

II

Көзнең соңы кергәндә
кырау ятты үләнгә...
Оча соңгы яфраклар,
салкын җиргә кунаклый:
яфрак тамырны каплый,
яфрак
тамырны
саклый!

Табигать үзен аклый,—
җәй гомерен йомгаклый...
җәем инде ерактыр,—
килеп
киткән
кунактыр...

Мин дә китмәм еракка:
охшап соңгы яфракка,
бер
төшәрмен
туфракка...

## Беренче кар

...Беренче кар әле безнең, беренче кар...
Туйдан чыктык ак иртәдә—беренче пар:
Каеннарда җем-җем итә ап-ак чуклар...
Без яшь чаклар әле бит бу,
без яшь чаклар!..

Аяк асты гүя йомшак ап-ак шафран,
Яфракларны очмасын дип ак кар япкан.
Җитәкләшеп килеп чыктык таң каршына,
Аң-таң булып,
яңа гына, балачактан!..

Балачаклар кемнән дә ул калачак ла,
Беренче кар... әле ишеп явачак ла!..
Ява—эри, ява—эри, гүя шикәр...
Ә шулай да...
мәңге истә калачак ла
Беренче кар...

**Кайда соң сез шул ак таңның пакь сүзләре,**
**Эзләп йөрим—**
**кайда безнең беренче кар,**
**беренче кар?!**
**...Беренче кар өсләрендә—кош эзләре,**
**Туй итәләр безнең өчен**
**чәүкәләр дә вә чыпчыклар:**
**Беренче кар!..**

## Уяну

*Мөтәдусларга*

**Янус кеби гаҗәп дусларым сез,**
**мин идем бит сезгә тартылган...**
**Антларыгыз, бөтен хакларыгыз,**
**"ахирәт дус" дигән чакларыгыз,**
**кубуга ук табын артыннан,**
**төтен булып оча, тарала...**
**миражга тиң ялган хыяллар да**
**очкан-киткән җилгә... кай ара?..**

**Мәкер-хәйлә белмәс нарасыйдай,**
**елышканмын сезгә табарак;**
**"диңгез" дисәм—аквариум икән,**
**"көймә" дисәм—ярык тагарак,**
**"шәмдәл" дисәм—тычкан уты гына,—**
**юлны таптым капшап-кармалап...**

**Йә, хушыгыз,—сезгә үчем дә юк,**
**тик хаклыкны белдем яңарак.**
**Соң булса да уң булсын, дип китим**
**кояшлырак якка табарак!**
**Сездә калсын**
**ярык тагарак...**

## Сабырлык хакында

**"Сабырлыкның төбе—сары алтын"—**
**шулай дигән минем сабыр халкым,—**
**уйларымда дөрләсә дә ялкын,**
**сер бирмәскә иде исәбем...**
**Уйламаган-көтмәгәндә генә,**
**максатыма җитмәгәндә генә**
**тормыш төртте утлы кисәвен...**
**Сабыр итү иде исәбем!..**

**Бу—дәфтәрнең башлануы гына,**
**саф хисләрнең расلануы гына,**
**җыр туфрагы ашлануы гына**
**илтер микән көткән максатка?**
**Максатыңа фәлән чакырым гына,—**
**сабырлык шул килми чакырып кына,—**
**сабыр итеп булмас, ахыры, миңа...**
**өр-яңа бер гомер башлап та!**

## Шагыйрь

Сүз мәгънәсен эзли җирдән, күктән, йә таштан,
Сүз газабында көя, яна ул тоташтан!
Сүзләрдән генә торса да гәрчә гомер биштәре,—
Таба алмый асылын—туу үлемгә тоташкан!

Инде ачылып китсә дә Иҗатының офыклары,
Чүмечләп эчсә дә гөрләгән суларны,
Ятып чөмерергәдер болытлары белән—дәрьясын,—
Басмыйдыр сусынын дөнья ярсулары?!

Өч көнлек дөньяда—гомерлек мосафир,
Һәр яфрак, агачның сорап ул исемен,
Кояшлы аланны кичкәндә, сизми дә
Килеп үк җиткәнен гомере киченең...

Хуш, Кояш, тапшырдым, минем дә баешым,
Син таңда туарсың офыкта яңадан...
Ишетелер шикелле җиһанда тавышым
Минем дә яңадан,
Өр-яңа тугандай анадан...

## Иске көйгә

Юк инде, алмый безне һичнинди модалар,
язабыз тик үткәннәргә мәдхия-одалар;

Гашыйклар рухына багышлап шигъри намазны,
тотабыз йөрәктә яшьлектән килгән тонык авазны...

И иркә, садә авазлар киләдер ерак бакчалардан!
Яшьлек бакчалары! Бер тылсым юк инде аны ача
торган.

Андый бакчалар юктыр шул Бабилдә* дә Икесуда,
эзләсәң дә юктыр кыйтгалардан, дүрт шәм тотып
ике кулга.

И илаһи гомер! Булсачы әгәр шундый иркең генә:
шул бакчаңда кунак булып килим бары бер көн генә!

И яшьлек, син бәһасез энҗеләрдән торган таҗсың!
Мә, елларым тавын ал, шуның бөртегенә!..

* * *

Үкен, үкен—
инде үтте ул көн,
очты җилгә төтен—
очкан гомер...

*Бабил – Вавилон – бирелә дөньядагы җиде могҗизаның берсе саналган Семирамидадагы асылмалы бакчага ишарә ителә.

**Тәңгәл икән барысы—
бергә-бер...
Очкан төтен,
җилгә очкан гомер—
моңлы төшем белән
бермә-бер!**

**Ни калдырдың?..
И ул гүзәллекләр,
ул киңлекләр—
билдән ак чәчәк!
Ике кулда чайпалдырып савыт,
ак сөлгесен иң өстенә салып,
ни китерә
көткән Киләчәк?..**

**Ни китерә?
Йә, әйт.
Дүрт күз белән аны
күтәп алып,—
әллә язмыш балы,
әллә... агу—
күпме икән аңа
бирәчәк?..**

## Күләгәләр

**Һәркемнең бар үзенең күләгәсе—
йөргән чакта җирдә гәүдәсе;
кай ишектән керсә, шымчы кебек,
шул тишектән керә—шәүләсе!**

**Тик күләгә—бездән "акыллырак"—
якынаймый башлап Кояшка:
Кояш алдан булса—артка поса,
арттан бәрсә Кояш—ул башта!**

**Көн кыскара, ә ул—озыная,
нәфесе зур—Кояш төшәме—
урамнарга озын сузылып ятып,
бездән соң да яшәү исәбе...**

**Юк, без инде күләгәләр түгел,
күчермәләр түгел—
нөсхәләр!
Күләгәләр—юан...
Ә без—күңел кебек,
йөрәк кылы кебек нечкәләр!**

*Идрис — фәрештә.

**Күләгәләр булмадык без җирдә,**
**шәүләләр дә булмыйк**
**гомергә.**
**Беренчеләр бит без!**
**Күләгәләр... әйдә, йөри бирсен**
**акыл җыеп**
**кичке эңгердә!..**

## Заман ахыры

**Күкләр чиксез**
**Вә догалы:**
**Фәрештәләр**
**Мадригилы!**

**Мәшрикъ яктан**
**Исә җилләр,**
**Пыскып ята**
**Янган илләр...**

**И, Исрафил**
**Өрде сурын:**
**Җәһәннәмдә**
**Сезнең урын!..**

**Җанда өмет:**
**Килә Идрис*...**
**"Бу—мин!"—диеп**
**Көлә... Иблис.**

**Илерә адәм**
**Утлы ярда...**
**Чаба, кешнәп,**
**Атсыз**
**арба!..**

⁂



## Зөлфәт Хәким

# ТЕЛСЕЗ КҮКЕ*

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМА

Үлүченең көне җитмәсә, үтерүченең кулы җитмәс.
*Татар халык мәкале*

Кылыч җимергән нәрсәне каләм төзәтә ала.
*У. К. Кекконен*

Всякая национальность есть богатство единого
братски объединенного человечества, а не препятствие на его пути.
*Н. А. Бердяев*

Әҗәлдән котылып булмаса да, чигереп була.
*Татар халык әйтеме*

Нация не может погибнуть, кроме как от самоубийства.
*Р. У. Эмерсон*

... Кара урманнарда ике алмагач,
Алмалары саен бал тама;
Ике күзләремдә сиксән керфек,
Керфекләре саен кан тама.
*Татар халык җыры*

*Мин күптән инде "Телсез Күке" турында сөйләргә җыенам. Гәрчә ул вакыйга миндә озак еллар яшәсә дә, моңарчы аны сезләргә бәян итәр өчен, күрәсең, миндә эчке өлгерү җитенкерәмәгәндер. Бәлки Вакыттан тагын нинди дә булса яңалыклар, кичерешләр, төзәтмәләр эстәгәнмендер.*

*Соңгы еллар төрле үзгәрешләр вә өстәмәләр кертте. Инсаният дөньясына да, шул ук вакытта һәрбер аерым кеше яшәешенә дә. Әлбәттә, минем бәянемә дә. Чөнки әсәремдәге кайбер кешеләр бүген дә исән һәм мин аларга озын гомер телим, алдагы елларда да исән-сау булсыннар, ярабби.*

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) — *язучы, драматург; «Агымсуда ни булмас», «Мин төш күрдем», 3 томлык сайланма әсәрләр һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

*Бу әсәр узган ел үткәрелгән «Яңа татар пьесасы» конкурсында беренче урынга лаек булды.

*Югыйсә туган-тумачам, дус-ишем, таныш-белешем хакында түгел бу вакыйга, ләкин, ни гажәп: ул кешеләрнең язмышына һич кенә дә битараф кала алмыйм, бу минем хәлемнән килми. Алай гына да түгел, вөҗүдемдә бер сәер тойгым бар—гүя аларның үткәннәрен үзем дә күрдем вә кичердем.*

*Теп-тигез генә сөйләп бирермен дип ышандыра алмыйм. Чөнки Телсез Күке турында мәңге сөйләп һәм мәңге җырлап туймаслык.*

*Аллага тапшырып, бәянемне башлыйм.*

**Катнашалар:**

Зәйнуллин Зариф Хәбибрахман улы—Чулман буе татары.
Галиәкбәр улы Зыятдин (бабасы Якуб)—Финляндия татары.
Кәшифә—Зарифның сөйгәне, соныннан хатыны.
Хәбиб—Финляндия татары, яшь егет.
Назимә—Зарифның оныгы.
Зимин Федор Семенович—НКВДның Особый отдел офицеры.
Лебедев Анатолий Евсеевич—өлкән лейтенант, рота командиры.
Шаталов Иван—рядовой, урыс.
Рассуханов Аслан—рядовой, чечен.
Севрюгин Михаил—рядовой, урыс.
Яхно Сергей—рядовой, яртылаш украин.
Зиновьев—25-27 яшьләрдәге ир-егет.
Солдатлар, тоткыннар, хәрби әсирләр һ. б.
Конвоирлар, надзирательләр.
Телевидение хезмәткәрләре: корреспондент кыз, оператор егет.

# БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Алты йорттан һәм төрле каралты-курадан торган урман хуҗалыгы. Ин иске йортта "Телсез Күке" кушаматлы Зариф карт яши. Аның өй эче ярымкараңгы. Бөтенләй буш өй дисән ялгыш булыр. Тимер карават, иске аклы-каралы телевизор, кыршылып беткән шкаф, өстәл, урындык кебек җиһазлар монда әле кеше яшәрлек икәнне күрсәтә. Бөтен нәрсә тәртипсез рәвештә калган. Өстәл күчкән, урындык ауган, кием-салым төрле почмакка чәчелгән. Чүпрәк сумка күтәреп Зариф кайтып керә. Баскан урынында катып, ул бик озак өй эченә карап тора. Сумкасын стенадагы калакка элеп куйгач, ин беренче чиратта, барып шкафтагы тартманы ачып карый. Аның төбеннән бер документ кисәге ала. Беркавым ана карап торганнан сон кире урынына куя. Ашыкмыйча гына бүлмәсен тәртипкә китерә башлый. Өстәлне стенага таба күчерә, ауган урындыкны торгыза, аунап яткан күлмәкләрен җыеп карават башындагы сандык өстенә ташлый. Шкаф тартмаларын кат-кат ачып карый—андагы вак-төякне барлый. Тышта урман хуҗалыгының этләре аза кубып өрергә тотыналар. Йорт каршына җинел машина килеп туктый. Ләкин Зариф моңа игътибар бирми, өйнен бер почмагыннан икенчесенә әрле-бирле йөри. Кинәт өй ишеге ачыла һәм бусагада пөхтә кыяфәтле, кара кәчтүмле, ак күлмәкле, галстуклы ир-егет пәйда була. Култык астына күн папка кыстырган. Егерме бишегерме җиде яшьләрдәге бу кешегә үзенең ыспай киеме бигүк ятыш булмаса да, аның муенындагы галстугы ничектер бер табигый элемент рәвешендә түше буйлап корсагына таба сузылып төшкән.

Көтелмәгән кунак *(актерларча куелган тавыш белән).* Добрый день! Здравствуйте!

(Хәерле көн! Исәнмесез!)

*(Аның тигез итеп янга таралган сары чәченә, елтыравыклы зәңгәр күзләренә һәм авыз чите белән елмаюына карагач, бу исәнләшүдә дикторларга хас коры сәламләү һәм ясалма ягымлылык кына түгел, ә берникадәр ихласлык та барлыгы, исәнләшүендә, ничек кенә булмасын, барлык вөҗүде катнашуы абайлана. Шулай булгач, теләсә нинди халәттә мондый сәламләүгә җавап бирмәү мөмкин түгел.)*

Зариф *(бүлмә уртасында басып торган килеш).* Исәнме.

{Здравствуй.}

*(Инде әллә кайчаннан бирле сөйләшмәү сәбәпле, тавышы карлыгып чыга. Дымлы күзләрен ишек катындагы кешегә төбәп аның кем икәнен чамаларга тырыша.)*

Кунак *(хуҗаның каты күз карашыннан уңайсызланып ишек катында тора).* Вы встревожены? Сейчас все поймете.

{Сез каушадыгыз, ахрысы? Хәзер мин сезгә барысын да аңлатам.}

*(Картка таба атлый.)*

Зариф. Син кем?

{Ты кто?}

Кунак *(үтә дә итагатьле тавыш белән).* Прошу прощения, я по-татарски не понимаю.

{Гафу итегез, мин татарча аңламыйм.}

Зариф *(фәкать кирелөнү өчен генә).* А я по-русски не понимаю.

{Ә мин урысча аңламыйм.}

Кунак. Прошу вас, не волнуйтесь... и не бойтесь меня.

{Зинһар каушамагыз... курыкмагыз миннән.}

Зариф *(татарча акцент белән сөйләшә).* Я тебя не боюсь!

{Мин синнән курыкмыйм!}

Кунак. И не сердитесь, пожалуйста. Зря вы горячитесь... Я из милиции. Капитан Зиновьев... Вот удостоверение...

{Зинһар, ачуланмагыз, тынычланыгыз. Мин—милициядән. Капитан Зиновьев... Менә таныклыгым.}

*(Куен кесәсеннән алып документын күрсәтә.)*

Зариф *(таныклыкка бөтенләй күз салмый, Зиновьевның үзенә текәлеп карап тора).* Зачем приехал?

{Ник килден?}

Зиновьев. По поводу ограбления.

{Талау буенча.}

Зариф. Какого ограбления?

{Нинди талау буенча?}

Зиновьев. В связи с ограблением вашего дома.

{Йортыгызны басканнар бит.}

Зариф. Никакого ограбления нет.

{Бернинди талау юк монда.}

Зиновьев. Зариф абы, зачем вы упрямитесь?

{Зариф абый, ник киреләнәсез инде?}

Зариф. Откуда знаешь про ограбление? Я никому не сообщал.

{Йортымны басканнарын каян белдең? Мин бит беркемгә дә хәбәр итмәдем.}

Зиновьев. Вас ограбили. И не один раз. Ваш дом уже несколько раз грабили.

{Сезне талаганнар. Һәм инде бер генә тапкыр түгел. Йортыгызны инде берничә мәртәбә басканнар.}

Зариф. Мне наплевать. У меня нечего воровать. У меня ничего нет. Если хотят, пусть грабят. Я никому не буду сообщать.

{Ә мин төкерәм. Минем урларлык малмөлкәтем юк. Минем бернәрсәм юк. Телиләр икән, тагын таласыннар. Барыбер беркемгә дә хәбәр итмәячәкмен.}

*(Караватка утыра.)*

Зиновьев. Разрешите присесть.

{Утырырга рөхсәт итегез.}

*(Урындыкка утырып Зарифны жентекләп күзәтә.)* Да, вы человек гордый. Нелюдимые они все гордые. Сообщать о своих неприятностях вам несвойственно. В этот раз, я подождал две недели и... Думаю, может, старик все же заявит в милицию, но понял, что от вас этого не дождешься. Ну так вот, подождал я две недели, и решил сам приехать.

{Әйе, сез горур кеше. Аралашмаучы кешеләр алар, гадәттә, горур булалар. Сезнең кебекләр кайгы-хәсрәтләре белән беркайчан уртаклашмыйлар. Бу юлысы мин ике атна көттем дә... Мин инде сез үзегез милициягә гариза язарсыз дип уйлаган идем, әмма дә ләкин аңладым: сез андый кеше түгел. Шулай итеп, ике атна көттем дә, менә, үзем килергә булдым.}

Зариф *(аптыраган кыяфәт белән).* Какие две недели?

{Ике атна?}

Зиновьев *(үтә житди булырга тырышып).* Вас последний раз две недели назад ограбили, так?

(Соңгы тапкыр сезнең йортны моннан ике атна элек таладылар, шулай бит?)

Зариф *(тоңык кына тавыш белән).* В последний раз меня сегодня ограбили. Я ходил в Субай, в магазин за сахаром. Прихожу—все перевернуто.

(Соңгы тапкыр мине бүген таладылар. Субай кибетенә шикәргә дип барган идем. Кайтуыма өйнең асты өскә килгән.)

Зиновьев *(гажәпләнү төсе белән).* Надо же! Значит, я как раз вовремя! Просто поразительно! Ужас какой! Я-то думаю, две недели уже прошло, не заявляет, дай сам съезжу... Еще и сегодня грабанули?! Вот те на!

(Карале син аны! Димәк, мин нәкъ вакытында килгәнмен! Гажәп, гажәп! Коточкыч! Ә мин бит ике атна узды, үзе хәбәр бирми, туктале, барып кайтыйм әле дип килдем... Димәк, әле бүген дә кергәннәр?! Менә сиңа, мә!)

Зариф. А про то ограбление откуда узнал?

(Ә тегеләре турында каян ишеттең?)

Зиновьев *(папкасында актарына).* Субаевские рассказали: как вас постоянно грабят, а вы за помощью не обращаетесь. Мне вот интересно стало...

(Субайда сөйләделәр: гел йортыгызны басулары турында да, беркемнән ярдәм сорамавыгыз хакында да. Миңа ничектер кызык, сәер тоелды...)

*(Зарифка текәлә.)* А почему вы в милицию не сообщите?

(Нишләп милициягә мөрәжәгать итмисез?)

Зариф *(авыз чите белән генә көлемсерәп куя).* Какой толк от этого! Вы все равно порядок не сможете навести.

(Сезгә мөрәҗәгать итүдән ни мәгънә! Сез барыбер беркайчан да тәртип урнаштыра алмаячаксыз.)

Зиновьев *(бераз усал булып кыланып).* Ну, конечно, если все будут молчать как вы... Я имею ввиду про преступления...

(Монда без генә гаепле түгел. Менә сезнең кебекләр дәшми яталар да... Җинаятьләр турында дип әйтүем... Сез мөрәҗәгать итмәгәч, кемне кайда эзләргә тиеш без?)

Зариф *(тыныч кына һәм шул ук вакытта нык тәэсир итәрлек тавыш белән).* Меня в счет уже не надо брать, мне жить недолго осталось.

(Мине санга алмагыз инде сез, миңа яшәргә күп калмады.)

Зиновьев *(ягымлы булырга тырышып).* Не спеши помирать, абы.

(Үләргә ашыкма әле, абый.)

Зариф *(эчке куәте сизелерлек иттереп).* Вор, который забирается в мой дом, он жалок и ничтожен, и, наверняка, не проживет столько, сколько прожил я. Мой дом грабят, а ведь ценного у меня ничего нету. Кое-что уже, правда, утащили.

(Минем өйне баскан карак—вак һәм мескен кеше. Ул мин яшәгән кадәр гомер яши алмас, мөгаен. Талыйлар да талыйлар, ә бит минем аларны кызыктырырдай кыйммәтле әйберем юк. Дөрес, алай да кайбер нәрсәләрне алып чыгып киткәннәр.)

*(Иске тумбочка өстендә торган телевизорга ишарәләп.)* Телевизор оставляют, потому что—черно-белый. Наверно, думают, что не показывает.

(Телевизорга кагылмыйлар, чөнки—аклы-каралы. Күрсәтми дип уйлыйлармы.)

Зиновьев *(күзләрен чекрәйтеп).* А что украли?

(Ә нәрсәләрегезне урлаганнар?)

Зариф *(бернинди борчылусыз һәм һич кенә дә уфтанмыйча).* В прошлом году два раза грабили... Тогда дубленку, валенки, радиоприемник и еще кое-чего из барахла. Новое ведро, топор, помнится, уперли. Две недели назад из сарая две лопаты унесли, а из дома новую кастрюлю эмалированную и новую кожаную фуражку.

(Былтыр ике тапкыр кергәннәр иде... Аларында туныны, киез итекләремне, радиоалгычны, тагын вак-төякне урладылар. Яңа чиләк, балта юкка чыкты. Ике атна элек сарайдан көрәкләрне алганнар, өйдән эмаль кәстрүлне, яңа күн фуражкамны чәлдергәннәр.)

*(Кашларын нык җыерып.)* Вот фуражку жалко, потому что мне ее моя любимая внучка подарила.

(Менә, фуражкам жалке—аны миңа ми-

нем яраткан оныкам бүләк иткән иде.}

Зиновьев. А в этот раз?
{Ә бу юлысы?}

Зариф *(як-ягына каранып)*. Никак не пойму. В этот раз, вроде бы порылись и все. Ну, ведь брать-то уже больше нечего.
{Һич аңлый алмыйм. Бу юлы актарынганнар гына шикелле. Монда алыр нәрсә юк бит инде хәзер.}

Зиновьев *(папкасыннан кәгазьләр алып)*. Заявление писать будете?
{Гариза язасызмы?}

Зариф. Нет.
{Юк.}

Зиновьев. А кого подозреваете?
{Кемнән шикләнәсез?}

Зариф. Я вообще никого ни в чем не подозреваю. Я не такой человек. Думаю, один из самых плохих качеств—это подозревать.
{Мин беркемнән дә шикләнмим. Мин андый кеше түгел. Уйлавымча, шикчеллек—иң әшәке сыйфатларның берсе.}

Зиновьев *(бераз кырысланып)*. Но в данном конкретном случае можно и нужно подумать—кто бы мог это сделать.
{Шулай да ачыкларга кирәк: кем эше икән бу.}

Зариф. Не знаю.
{Белмим.}

Зиновьев. Кто-то из посторонних или из местных?
{Чит кешеләр керә микән, әллә шушы тирәдәгеләрме?}

Зариф. Отсюда недалеко есть Серебряное озеро. Там лечебная вода. Туда много всякого народу ездит...
{Моннан ерак түгел шифалы сулы Көмеш күл бар. Анда халык күп йөри.}

Зиновьев *(нәрсәнедер исенә төшергән кыяфәт белән)*. Да, да, да, да.
{Әйе, әйе, әйе, әйе.}

Зариф. А дорога из города как раз мимо нашего лесного хозяйства проходит. Вот и наведываются сюда. Раз дома нет хозяина, значит, можно зайти, порыться.
{Шәһәрдән Көмеш күлгә юл нәкъ безнең урман хуҗалыгы аша үтә. Юл өсте булгач, хуҗа өйдә юклыкны белгәч керәләр дә актарыналар инде.}

Зиновьев. Здесь шесть хозяйств. Других не грабят?
{Монда алты йорт. Башкаларны таламыйлармы соң?}

Зариф. Не знаю. У них постоянно кто-нибудь дома есть. Наверно, к ним не залезают.
{Белмим. Аларның бит гел кемнәре дә булса өйдә кала. Өйләрендә гел кеше булгач аларга кермиләрдер.}

Зиновьев. А вы совсем один живете?
{Сез бөтенләй берүзегез генә яшисезме?}

Зариф. Да.
{Әйе.}

Зиновьев. Здесь вроде собаки сильно лают, когда посторонний в лесхозе появляется.
{Монда чит кеше килгәч этләр каты өрә түгелме?}

Зариф *(куәтле тавыш белән)*. Вор он ни бога, ни черта ни боится. Разве же он побоится какой-то собаки!
{Алладан да шайтаннан да курыкмаган карак эттән генә өркеми инде ул!}

Зиновьев. Ну, а соседи, что, невнимательные такие? Говорите же, что кто-нибудь да у них дома остается.
{Ә күршеләр нишләп алай игътибарсыз икән соң? Аларның кеме булса гел өйдә кала дисез бит.}

Зариф *(сөйләшүдән туя башлый)*. Я прожил много лет, и сам на свои вопросы ответить ни могу. А ты меня про соседей спрашиваешь.
{Мин бу дөньяда күптәннән яшим, тик шулай да үземнең сорауларыма да җавап бирә алганым юк әле. Ә син миннән күршеләр хакында сорыйсың.}

Зиновьев *(тәрәзә ягына күз салып)*. Да, хоть и лес, хоть и лесное хозяйство, но все же очень неспокойно у

вас здесь. Это Серебряное озеро кишит всяким сбродом—там и бандиты, там и наркота, там все... Здесь опасно.

(Әйе, урман булса да монда бигүк тыныч түгел икән. Ул Көмеш күл тирәсендә нинди генә әтрәгәләм чуалмый—анда бандиты да, наркотасы да, анда барысы да бар... Куркыныч монда, куркыныч.)

Зариф. А где не опасно?

(Ә кайда куркыныч түгел?)

Зиновьев. Впрочем, да.

(Шулай шул.)

Зариф. В этом мире везде опасно.

(Бу дөньяның һәр тарафында куркыныч.)

Зиновьев. Почему в Челны не поедете жить, к сыну?

(Нишләп сон сез Чаллыга, улыгыз янына яшәргә күчмисез?)

Зариф *(Зиновьевка карап тора).* Про сына тоже узнал?

(Улым турында да белештенмени?)

Зиновьев *(унайсызланган булып кылана).* Да, я на всякий случай коекакую информацию взял о вас.

(Әйе, бәлки кирәге чыгар дип мин сезнең хакта бераз мәгълүматлар алдым.)

Зариф *(канәгатьлектән тавышы көрәя).* У меня прекрасный сын. У него отличная семья. Невеста хорошая. Внучку же я больше всего на свете люблю. Они меня умоляют, чтобы я переехал к ним жить.

(Улым шәп егет минем. Гаиләсе дә искиткеч әйбәт. Киленнән дә уңдык. Ә оныкам исә минем өчен бүгенге көндә иң кадерлеселәр. Алар инде мине кайчаннан бирле үзләре янына күчәргә үгетлиләр.)

Зиновьев *(аптырап).* Так в чем же дело?

(Шулай булгач, ник аларда яшәмисез?)

Зариф *(чак кына ишетелерлек итеп).* Не могу. Я здесь родился, здесь жизнь прожил. Отсюда и до Субайского кладбища недалеко.

(Китәсем килми. Мин монда тудым, шушында гомер кичердем. Моннан Субай зиратына да ара якын.)

Зиновьев. Ну, вы опять...

(Ну, сез инде тагын...)

Зариф. Там моя жена Кашифа похоронена. Я каждый день на ее могилу хожу.

(Анда минем хатыным Кәшифә күмелгән. Мин бит көн саен аның кабере янына барам.)

Зиновьев. Ну, ведь из Челнов на это кладбище можно иногда приезжать.

(Ул зиратка Чаллыдан да килеп йөрергә мөмкин.)

Зариф. А я каждый день к ней хожу.

(Мин бит көн саен барам аның янына.)

Зиновьев. Понятно. Когда в Субае спрашивал, все вас называют то "Күке Зариф", то "Телсез күке". Күке—это кукушка?

(Анлашылды. Субай кешеләре сезне "Күке Зариф" дип атыйлар, "Телсез күке" диючеләр дә бар. "Күке"—кукушкамы ул?)

Зариф. Да.

(Әйе.)

Зиновьев. Телсез—это немой. То есть "Немая кукушка"?

(Телсез, димәк—тавышсыз. Авазсыз. "Телсез күке" дигән сүзме?)

Зариф *(ачуы килә башлый).* Да, да, да. Больно уж ты любопытный.

(Әйе, әйе, әйе. Артык кызыксынучан булып чыктың әле син.)

Зиновьев *(читенсенгән булып).* Видимо. Профессиональная привычка. А почему кукушкой прозвали?

(Бәлки шулайдыр. Һөнәри гадәттер инде. Ә нигә күке дип атыйлар?)

Зариф. Это кличка нашего рода. А меня немой кукушкой прозвали, потому что у меня часто приступы бывают. Тогда у меня язык отнимается. Говорить не могу. Поэтому "Немая Кукушка".

(Нәселебезнең кушаматы ул. Ә телсез күке дип өянәкләрем аркасында атыйлар. Өянәкләрем вакытында мин тотлыгам. Кайвакыт телсез калам. Шуна күрә—"телсез Күке" диләр.)

Зиновьев *(зур кызыксыну белән).* Ну, почему все-таки кукушка?

(Ә шулай да, ни өчен—күке диләр?)

Зариф *(усал тавыш белән)*. Ты не те вопросы задаешь, капитан.

{Син, капитан, сорауларны артык күп бирәсең түгелме.}

Зиновьев *(картның ачулы кыяфәтеннән бераз каушый)*. Прошу прощения. Тогда давайте, по делу. Значит, по факту ограбления не хотите писать заявление?

{Гафу үтенәм. Төп эшемә әйләнеп кайтам. Өегезне басу буенча гариза язарга ниятегез юк инде алайса?}

Зариф *(коры гына)*. Нет, не вижу надобности.

{Кирәкми дип саныйм.}

Зиновьев *(ялагай тавыш белән)*. Можно, все-таки, еще вопрос, не совсем относящийся к моему визиту?

{Шулай да, килүемнең сәбәбенә кагылмаган тагын бер сорау бирергә рөхсәт итәсезме?}

Зариф *(башын читкә борып сөйләшәсе килмәгәнне күрсәтмәкче була)*. Спрашивай.

{Сора.}

Зиновьев. Я слышал, вы были участником советско-финской войны 1939-1940 годов.

{Сез 1939-1940 еллардагы сәвит—фин сугышында катнашкансыз дип ишеттем.}

Зариф *(тоныќ кына тавыш белән)*. Да.

{Катнаштым.}

Зиновьев. Участвовали в Великой Отечественной войне, из рядового стали офицером и полным кавалером орденов славы? Это правда?

{Бөек Ватан сугышында да катнашкансыз, рядовойдан офицер булгансыз, Дан орденнарының тулы кавалеры икәнсез, шулаймы?}

Зариф *(тавышын күтәреп)*. Правда.

{Шулай.}

Зиновьев. А где все это?

{Кая соң алар?}

Зариф *(нәфрәтләнеп)*. Что, это? Ордена?

{Нәрсә ул—"алар"? Орденнармы?}

Зиновьев. Куда все подевалось? Вы ведь даже ветераном войны не числитесь нигде. Вы ведь к тому же и ранения имеете?

{Кая югалды алар? Сез бит хәтта сугыш ветераны булып та беркайда исәптә тормыйсыз. Сез бит сугыштан каты яраланып, контузияләнеп тә кайткансыз.}

Зариф *(кыза башлый)*. Да, ты все правильно разузнал. К тому же я и в советских лагерях сроки мотал.

{Әйе. Син барысын бик дөрес, төгәл белешкәнсең. Мин әле сәвит төрмәләрендә дә утырдым.}

Зиновьев. Ну, ведь вы можете теперь восстановиться!

{Сез бит хәзер үзегезнең хокукларыгызны кире кайтара аласыз.}

Зариф *(жикереп)*. Что я могу восстановить?!

{Нинди хокукларымны кайтара алам мин?!}

Зиновьев. Права участника двух войн, инвалида... права на льготы... Возможно, и реабилитацию получите. Вы же, все-таки, герой!

{Сугыш ветераны, сугыш инвалиды буларак... льготаларга хокукларыгыз бар сезнең. Реабилитация алуыгыз да ихтимал. Сез бит—полный кавалер орденов славы! Сез бит—герой! Үзегезгә тиешле нәрсәләрне торгызырга кирәк!}

Зариф *(кырыс тавыш белән)*. Ты молод еще. В человеке человека надо восстановить. А не побрякушками обвешиваться. И реабилитировать должен каждый человек сам себя. А начинать нужно с прощения. Самому просить прощения и прощать.

{Яшь әле син. Кешедә иң элек кешенең үзен торгызырга кирәк. Ялтыравыклы шылтыравыклар асып куеп кына кешене күтәрү мөмкин түгел. Реабилитацияне дә кеше үзенә карата үзе хәл итәргә тиеш. Ярлыкаудан башларга кирәк барысын да. Үзенә дә тәүбә итәргә. Башкаларны да кичерү, гафу итү мәслихәт.}

Зиновьев *(саклык белән генә сорый)*. А ордена славы у вас украли?

{Ә сезнең Дан орденнарын әллә урладылармы?}

З а р и ф *(битарафлык белән).* Нет, их у меня не украли. Да, я даже участником войны сегодня не числюсь. Ну, разве это важно? Мне ничего не нужно. Я скоро к моей Кашифе уйду, в мир иной.

(Юк, орденнарымны урламадылар. Әйе, мин бүген хәтта сугыш ветераны булып та исәпләнмим. Моның әһәмияте бармыни соң? Мина берни кирәкми. Тиздән мин Кәшифәм янына китәм—теге дөньяга.)

З и н о в ь е в *(нык гаҗәпләнә һәм кызыксынудан туктый алмый).* Неужели в этом мире уже больше ничто вам не мило?

(Инде сезнең өчен дөньяның яме тәмам югалдымыни?)

З а р и ф *(тавышын йомшартып).* Внучку я безумно люблю. Она на Кашифу очень похожа. Ради нее я еще в этом мире немного побуду.

(Оныкамны мин үлеп яратам. Кәшифәгә шундый охшаган ул. Шул кызчык хакына мин әле бу дөньяда бераз яшәргә риза.)

*(Тагын кинәт усаллана.)* А все остальное для меня уже померкло.

(Ә калганы минем өчен инде тоныкланды.)

З и н о в ь е в. Ну а если восстановить все, может, интереснее стало бы жить?

(Әгәр үзегезгә тиешле нәрсәләрне кайтарсалар, бәлки яшәүнең яме артыр иде?)

З а р и ф. Ты опять про льготы и ордена?.. Ничего этого мне не нужно. Вот если бы я узнал, что человек один в те далекие годы не умер в сталинском бараке, мне было бы намного легче. Если бы мне сообщили, что он вернулся на родину и сегодня жив-здоров, я бы просто был счастлив. А если бы еще мне сказали, что этот человек простил и прощает меня, то жизнь земную я счел бы законченной и небысмысленной.

(Янә льготаларга, орденнарга киная ясавыңмы бу?.. Мина боларның кирәге юк. Әгәр дә моннан күп еллар элек бер кешенең лагерь барагында үлмәгәнен белсәм, мина күпкә җиңелрәк булыр иде. Әгәренки мина әйтсаләр: "Ул исән, ул туган иленә кайтты, бүген дә исән-сау!—дисаләр мин үземне бәхетле итеп тояр идем. Ә инде ул кеше мине гафу иткән һәм бүген дә гафу итә дисаләр, мин бу дөньядагы гомерем заяга узмады дип, яшәвемнең мәгънәсе бар, дип кычкырыр идем.)

З и н о в ь е в *(алгарак сузылып).* Кто этот человек?

(Кем ул?)

З а р и ф *(жикереп).* Ты мне надоел!

(Мин синнән туйдым!)

З и н о в ь е в *(сискәнеп куя).* Простите, пожалуйста.

(Зинһар, гафу итегез.)

*(Кәгазьләрен кире папкасына тутыра.)* Действительно, я кажется утомил вас.

(Чынлап та, мин сезне алҗыттым, ахрысы.)

*(Урыныннан кузгала.)* Я пойду.

(Мина китәргә вакыт.)

З а р и ф *(коры гына).* Иди. И не сердись на меня.

(Бар. Мина үпкәләмә.)

З и н о в ь е в *(ясалма ягымлылык белән елмая).* Ну, что вы! Чудной вы человек, Зариф абы.

(Юк инде, Зариф абый, сез нәрсә! Бигрәк сәер кеше сез.)

З а р и ф. Какой есть...

(Менә шундый инде мин...)

З и н о в ь е в *(картның тынычланганын сизеп сорарга җөрьәт итә).* А припадки у вас... Вы немеете когда у вас неприятности и сильно огорчены?

(Өянәкләрегез... Сез нык дулкынланганда, артык каты хәсрәтләнгәндә телсез каласызмы?)

З а р и ф *(Зиновьевның күзләренә карап).* Да.

(Әйе.)

З и н о в ь е в *(аның күз карашыннан качыр өчен як-ягына карап).* Мне кажется, что ограбив ваш дом, нельзя вызвать в вас припадок.

(Өегезне басып кына сездә өянәк кузгату мөмкин түгелдер.)

З а р и ф *(һаман Зиновьевка текәлеп карап тора).* Нет, это не может быть причиной моего потрясения.

(Юк, талап кына мине тетрәндерү мөмкин түгел.)

З и н о в ь е в *(кинәт картның күзләренә карый).* А что может вас сильно потрясти?

{Ә нәрсә белән сезне каты тетрәндерү мөмкин?}

З а р и ф *(яман усал тавыш белән).* Молодой человек! А вот твои расспросы действительно могут меня из себя вывести!

{Ә менә синең төпченеп сораштыруларың канымны нык кыздыра.}

З и н о в ь е в *(картның каты нәфрәтләнүеннән шүрли).* Простите. Я хотел, наоборот, помочь вам хоть как-нибудь.

{Гафу үтенәм. Минем, киресенчә, сезгә ничек тә булса ярдәм итәсем килә.}

З а р и ф *(кызуы арттырып).* Ты не похож на человека, способного помочь такому, как я.

{Син бер дә миңа ярдәм итәрдәй кешегә охшамагансың.}

З и н о в ь е в *(картны юмалау нияте белән).* Вы зря так... Не надо меня обижать.

{Алай димәгез инде... Кимсетмәгез мине. Үпкәләтәсез бит.}

З а р и ф *(жикереп).* А ты разве баба, чтобы обижаться?!

{Син хатын-кыз мәллә—үпкәләргә?!}

З и н о в ь е в *(үзен кулга ала һәм тыныч кына тавыш белән).* Вы же меня совсем не знаете.

{Сез бит мине бөтенләй белмисез.}

З а р и ф *(кычкырып диярлек).* А зачем мне тебя знать!

{Сине белүемдә хаҗәт бармы! Сине белү заруримы!}

З и н о в ь е в *(курка һәм ишекне ача).* Ну что ж, по факту ограбления все равно можем к вам явиться в любое время. Может быть, я сам. А может, другой наш сотрудник. Вы хорошенько посмотрели—что в этот раз унесли? Из документов ничего не пропало?

{Ярар алайса. Өегезне талау эше буенча без әле килеп чыгарбыз. Үзем булмасам, безнең бүлектән берәр башка кеше килер. Бу юлысы нәрсәләрегез югалды—сез дикъкать белән карадыгызмы? Документлар урынындамы?}

З а р и ф *(кычкыра).* Ничего не пропало! И вообще, меня никто никогда не грабил! Понял?!

{Бернәрсә дә югалмады! Мине беркем дә таламады! Минем өемне беркайчан да басканнары юк! Аңладыңмы?!}

З и н о в ь е в. Понял. До свидания! Всего доброго!

{Аңладым. Сау булыгыз!}

З а р и ф *(кычкырып).* Хуш! Прощай!

{Иди! Прощай!}

*(Зиновьев чыгып китә.)*

Музыка. З а р и ф тынычлана алмый, бүлмә буйлап ары-бире йөри.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

90-нчы еллар. Санкт-Петербург каласы. Татарларның Сабантуй бәйрәме. Музыка. Жырбию. Тантаналы ыгы-зыгы.

К о р р е с п о н д е н т к ы з *(видеокамерага карап сөйли).* Хөрмәтле телевизор караучылар! Мөхтәрәм милләттәшләребез! Иң күнелле, иң затлы бәйрәмнәребезнең берсе—Сабантуй—Русиянең икенче башкаласы дип саналган Санкт-Петербург каласында аеруча күтәренке рух вә илһам белән уздырыла дисәм бер дә ялгыш һәм арттырып әйтү булмас, мөгаен. Санкт-Петербургның үзендә яшәүче татарлар өчен генә түгел, башка милләт культурасын ихтирам итүче барлык кешеләрнең, әлбәттә инде, илнең төрле төбәкләреннән, хәтта чит илләрдән килгән кан кардәшләребезнең олуг бәйрәме бу! *(Корреспондентның тавышы ерагая. Жыр яңгырый.)*

Назимә матур күлмәктән, иненә жинел сумка асып салмак кына атлый. Кәефе начар булмаса да, йөзендә сагыш бар. Каядыр читтәрәк көрәш ярышына комментарий бара. Бәйрәмнең икенче тарафыннан ат чабышына чакыру яңгырый. Кайсыдыр яктан урыс телендәге игъланнар да ишетелә. Барлык тавышлар бер сабантуй авазына әверелеп һавада яңгырап тора. Назимә борчылып як-ягына

карана. Аны жәйге жинел кәчтүм кигән бер егет күзәтә. Назимә моны абайлап ала да, анын зыялы икәнен чамалап, шундук мөрәҗәгать итә.

Назимә *(тавышындагы каушау төсләрен җыңә алмый)*. Извините... Можно вас спросить?

(Гафу итегез... Сездән сорарга мөмкинме?)

Егет *(елмаеп)*. Син татар кызы бугай?

Назимә *(аптырап кала)*. Әйе.

Егет *(ягымлы тавыш белән)*. Алайса, зинһар татар телендә әйт сүзеңне.

Назимә *(ниһаять үзен кулга ала)*. Гафу итегез. Мин сездән сорамакчы идем... Монда берәр ничек телефоннан шалтырата торган урын юк микән?

Егет *(ваемсыз гына)*. Бар, нишләп булмасын.

Назимә *(ялварулы тавыш белән)*. Зинһар, әйтегез.

Егет. Минем телефоннан шалтырат. *(Мобильный телефонын кесәсеннән чыгарып бирә.)*

Назимә *(каушый)*. Чын әйтәсезме... *(Телефонны ала, кнопкаларга карап тора.)*

Егет *(җитдиләнеп)*. Бир, үзем жыям номерны. Син әйтеп тор. *(Телефонны ала.)* Кая шалтыратасын?

Назимә. Монда, Петербургтагы бер кызга. Шунын мобильнигына. *(Номерны әйтә.)*

Егет *(номерны жыя)*. Мә, сөйләш. *(Үзе шундук кызның сөйләшкәнен ишетмәс өчен читкә китә.)*

Назимә *(телефонны ала)*. Алло! Ирина! Это опять я—Назимә из Казани. Мы договаривались созвониться. Здравствуйте!

(Алло! Ирина! Бу тагын мин әле—Назимә, Казаннан. Без шалтыратышырга сөйләшкән идек. Исәнмесез!)

Ирина *(телефоннан)*. Здравствуйте! Родители из Ростова не скоро приедут.

(Исәнмесез! Әти белән әнием Ростовтан әле тиз генә кайтмаячаклар.)

Назимә *(нык дулкынлана)*. Знаете, Ира, думаю, с твоими родителями мне встречаться нет необходимости. Мне бы с Анатолием Евсеевичем повидаться и поговорить.

(Беләсезме, Ира, сезнен әти-әниегез белән минем очрашунын кирәге юктыр дип уйлыйм. Мина Анатолий Евсеевич белән күрешеп сөйләшергә иде.)

Ирина. Назима, милая, боюсь, не получится.

(Назимә, кадерлем, гафу итегез, ләкин очраша алмассыз дип уйлыйм.)

Назимә *(менә-менә елап җибәрергә тора)*. Почему?

(Нишләп?)

Ирина. Думаю, вам будет бесполезно с моим дедом встречаться, так как он в очень плохом состоянии.

(Минем бабамның хәле инде бик авыр, шул сәбәпле анын белән очрашунын бернинди файдасы булмас.)

Назимә. Он в больнице?

(Ул хастаханәдәме?)

Ирина. Да.

(Әйе.)

Назимә *(тавышы калтырый башлый)*. А мне нельзя к нему в больницу сходить?

(Ә мина анын янына хастаханәгә барырга ярыймы?)

Ирина. А зачем? Он вашего деда Зарифа не помнит. И того финского солдата тоже не помнит. Откуда ему помнить про какого-то финского пленного. Откуда он знает что с этим финном произошло, что с ним сделали, как убили, и убили ли вообще. Он даже не помнит уже, что, когда и как с ним самим случилось. Неужели вы мне не верите! У него памяти-то уже нет. Я ведь долго расспрашивала про вашего деда, но он никого и ничего не помнит. Ну раз так, то зачем вам приходить к нему и тормошить его память.

{Ник? Ул сезнең бабагыз Зарифны хәтерләми. Теге әсир фин солдатын да онытткан. Ничек инде шушы яшендә нindидер әсир финны исендә тотсын ул. Әсир финны нишләткәннәрен, ничек үтергәннәрен... әле үтергәннәрме-юкмы, билгеле түгел—моны кайлардан белсен инде ул. Сез мина ышанмыйсыз бугай! Аның бит инде хәтере бөтенләй юк. Мин бик озак сораштырдым сезнең бабагыз турында, ләкин ул беркемне, бернәрсәне хәтерләми. Шулай булгач, янына барып йөдәтмәгез инде. Сәламәтлеге бик начар бабайның.}

Н а з и м ә. Да, вы правы. Но у меня все же к вам одна просьба есть.

{Сез хаклы. Шулай да минем сезгә бер үтенечем бар.}

И р и н а. Слушаю.

{Тыңлыйм.}

Н а з и м ә. Мой дед Зайнуллин Зариф просит у него прощения.

{Минем бабам Зайнуллин Зариф аңардан гафу үтенә. Ярлыкавын сорый.}

*(Елый.)* Он считает себя виноватым перед вашим дедом Лебедевым Анатолием Евсеевичем и просит простить великодушно. А за что, за какие грехи они сами, наверно, знают.

{Сезнең бабагыз Лебедев Анатолий Евсеевич алдында ул үзен гаепле дип саный һәм ярлыкавын үтенә. Нәрсә өчен, нинди гөнаһлар өчен, мөгаен, үзләре генә беләләрдер.}

И р и н а. Хорошо, Назима, вы только успокойтесь, ради бога, не плачьте. Знаете что, приходите ко мне ночевать. Что это вы там будете в гостинице лежать. Гостиница есть гостиница. У меня в любом случае уютнее будет.

{Ярар, Назимә. Алла хакы өчен, еламагыз, тынычланыгыз. Беләсезме нәрсә... сез кунарга безгә килегез. Кунакханәдә кукыраеп ятканчы. Кунакханә кунакханә инде ул. Миндә барыбер ямьлерәк, унайрак булыр.}

Н а з и м ә *(һаман елый)*. Нет, спасибо. Я вечерним поездом в Казань возвращаюсь.

{Юк, рәхмәт. Мин кичке поезд белән Казанга кайтып китәм.}

И р и н а. Не плачьте, пожалуйста. Ну, успокойся, ради бога.

{Зинһар, елама. Тынычлан, Алла хакы өчен.}

Н а з и м ә *(кулъяулыгы белән күз яшьләрен сөртә)*. Извините, пожалуйста, за беспокойство.

{Борчыганым өчен гафу итегез инде мине.}

И р и н а. Ничего, ничего. Вы сами на меня не сердитесь. Дед, ей-богу лежит почти в беспамятстве.

{Ник гафу үтенәсез. Сез үзегез мина үпкәли күрмәгез. Чынлап та бабам һушсыз, аңсыз ята.}

Н а з и м ә. Да, я верю вам.

{Мин сезгә ышанам.}

И р и н а. Вы, значит, вечером уже уезжаете?

{Димәк, сез кич белән кайтып китәсез инде?}

Н а з и м ә. Да.

{Әйе.}

И р и н а. Ну что ж, доброго пути! Счастливо доехать вам.

{Ярар алайса, хәерле юл! Исән-сау кайтып житегез.}

Н а з и м ә. Спасибо. До свидания!

{Рәхмәт. Сау булыгыз!}

И р и н а. До свидания! *(Назимә елый.)*

{Сау булыгыз!}

Е г е т *(килә)*. Авыр әңгәмә булды мәллә?

Н а з и м ә *(телефонны егеткә биреп)*. Юк ла, үзем шундый елак мин. Күнелем тулды. *(Битен кулъяулыгы белән сөртә.)*

Е г е т *(борчылып)*. Мин берәр ничек ярдәм итә алмыймммы?

Н а з и м ә. Ярдәм иттегез бит инде. Рәхмәт. *(Йөзеннән газап төсе һаман китми.)*

Е г е т. Проблемагызны хәл итә алмыйммы соң?

Н а з и м ә. Юк.

Корреспондент микрофонын алга сузып килеп житә. Оператор шундук Хәбир белән Назимәне төшерә башлый. Назимә борчылып чәчләрен төзәткәли.

К о р р е с п о н д е н т к ы з *(операторга)*. Тукта төшерми тор. *(Хәбир белән*

*Назимәгә.)* Сездән интервью алырга мөмкинме? *(Үзе беркемгә тын да алырга ирек бирми интервьюга әзерләнә башлый.)* Сез менә мондарак басыгыз... Ә сез... менә сезне төшергәндә теге пейзаж күренебрәк торсын... Туктагыз әле, сез якынрак басыгыз, әнә теге колганы да күрсәтик. Шулай гына торыгыз. Башта мин камерага берничә сүз әйтәм, шуннан соң сезгә сораулар бирермен.

Егет. Ярар.

Назимә *(егеттән сорый).* Минем күзләрем шешенгәндер бит... елагач? *(Сумкасыннан көзге алып карый, чәчен төзәткәли.)*

Егет *(ягымлы елмаеп).* Юк, юк, бик гүзәл. Син әле яна гына йокыдан уянган сабый бала кебек гүзәл.

Корреспондент кыз *(яңгыравыклы тавыш белән кызу-кызу сөйли).* Хәерле көн, хөрмәтле телевизор караучылар! Исәнмесез, газиз милләттәшләребез! Санкт-Петербург каласында Сабантуй бәйрәме гөрли. Бәйрәмнәрегез мөбәрәк булсын! Сабантуйда катнашучылар белән сөйләшеп аласыбыз килә. *(Назимәгә таба борылып мөрәҗәгать итә.)* Гафу итегез, сезнең исемегез ничек?

Назимә *(чак кына ишетелерлек итеп).* Назимә.

Корреспондент. Сез Санкт-Петербургның үзендә яшисезме?

Назимә. Юк, мин Казаннан, Татарстанның башкаласыннан килдем.

Корреспондент. Махсус Сабантуй бәйрәменә мәллә?

Назимә *(әле һаман тынычлана алмый).* Юк, бер бик мөһим эш белән килгән идем. Менә, Сабантуйга туры килдем.

Корреспондент. Әлбәттә, сез моңа бик шаттыр?

Назимә. Әйе.

Корреспондент. Бәйрәм ошыймы?

Назимә *(елмаерга тырышып).* Бәйрәм бәйрәм инде. Бик күңелле, бик күркәм.

Корреспондент. Казан сабантуе көчлерәкме, әллә мондагысымы? Аерма бармы?

Назимә *(тавышы бераз ныгая).* Сабантуй һәркайда сабантуй инде ул. Иң мөһиме кешенең үз күңелендә бәйрәм булырга тиеш, минемчә.

Корреспондент. Казанда эшлисезме, укыйсызмы?

Назимә. Укыйм. Педагогия институтында, татар теле бүлегендә.

Корреспондент. Сер булмаса, нинди җилләр сезне бу калага алып килде?

Назимә *(бик моңсу тавыш белән).* Бабамның сугыштагы иптәшен эзләп килгән идем. Кызганыч, ул инде бик карт һәм хастаханәдә авыр хәлдә ята.

Корреспондент. Алай икән. Әңгәмәгез өчен рәхмәт. *(Егеткә мөрәҗәгать итә.)* Күренеп тора ки, сез Санкт-Петербург егете.

Егет *(якты елмаеп).* Ялгышасыз. Мин Финляндиядән килдем. Хельсинкидан.

Корреспондент. Финляндиядән?! *(Тагын ниндидер сорау бирмәкче була, ләкин житешми—егет сүз ала.)*

Егет. Әйе. Мин шунда туып үстем.

Корреспондент *(бик гаҗәпләнә).* Шулаймыни-и-и?! Фин татары!

Егет *(үпкаләмичә генә битәрләп ала).* Нишләп сез барыгыз да фин татары дисез?! Финляндиядә яшәүче татар. Һәрхалдә Финляндия татары дип әйтегез.

Корреспондент *(үзен бик тә гаепле сизеп).* Гафу итегез, гафу итегез. Исемегез ничек?

Егет. Хәбиб атлы.

Корреспондент. Хәбиб әфәнде, сез Сабантуй кунагы гынамы, әллә шулай ук башка эшләр белән дә килдегезме?

Егет. Бизнес буенча мина еш килергә туры килә. Петербургка да, Мәскәүгә дә, Татарстанга да. Бу юлысы да Петербургтагы кайбер эшләремне Сабантуй вакытына махсус туры китердем. Иң яраткан, күңелемә иң хуш килгән бәйрәм бу минем. Хәер, һәр татар кешесе өчен шулайдыр инде. *(Назимә егетнең Финляндия татары икәнне ишеткәч сискәнеп китә. Башта бик сөенә, аннары башына килгән ниятен кире кагып, телен тыярга карар кыла.)*

Корреспондент. Финляндиянең үзендә татарлар, әлбәттә, шулай ук Сабантуй бәйрәмен уздыралардыр?

Егет *(горур тавыш белән).* Әлбәттә.

Корреспондент *(камерага карап).* Менә, хөрмәтле телевизор караучылар, Финляндиядә туып үскән кан кардәшебез туган телебездә ничек камил сөйләшә. Бу—һичшиксез безнең милли бәйрәмебезгә аерым бер ямь өсти. *(Егет ягына борыла.)* Әле озак буласызмы Санкт-Петербургта?

Егет. Юк, мин инде Сабантуйга кадәр үк эшләремне тәгәлләдем. Иртәгә Хельсинкига юнәләм.

Корреспондент. Сез Татарстанның үзендә генә түгел, татар яшәгән башка төбәкләрдә дә еш буласыздыр. Татар халкы турында, аның бүгенге халәте хакында нәрсә әйтә аласыз?

Егет *(житди кыяфәт белән).* О-о-о, сез бик зур сорау бирдегез. Мин татар халкының гап-гади бер вәкиле, шуңа күрә мин барлык милләт хакында сүз әйтергә үземне компетентлы һәм вәкаләтле түгелдер дип саныйм.

Корреспондент *(кин иттереп елмая).* Рәхмәт! Сез Хельсинки егете Хәбиб һәм Казан кызы Назимә шушы Санкт-Петербург Сабантуенда таныштыгызмы?

Егет *(сораудан канәгать булып елмая).* Әйе.

Корреспондент. Менә бит! Шушындый бөек бәйрәмдә нинди матур очрашу-кавышулар насыйп була кайберәүләргә. Әңгәмәгез өчен рәхмәт! Сау булыгыз! *(Камера экранына карап.)* Мөхтәрәм милләттәшләр! Бәйрәм дәвам итә. Яшәү дәвам итә. Әйдәгез, барып ат чабышына күз салыйк. *(Китәргә җыеналар.)*

Егет. Сау булыгыз!

Назимә. Сау булыгыз! *(Корреспондент һәм оператор күздән югалалар.)*

Егет *(Назимәгә карап тора).* Менә, корреспондент ярдәмендә таныштык та бугай инде. *(Көлә.)*

Назимә *(кинәт шатланып көлеп җибәрә).* Әйе, бер-беребез турында инде кайбер мәгълүматларны хәзер беләбез. *(Аларның икесен дә аңлатып булмый торган күтәренкелек, шатлык һәм илһам биләп ала. Рәхәтләнеп көләләр.)*

Егет *(кызга туп-туры карап).* Димәк, син—Назимә?

Назимә *(ояла).* Әйе. Ә сез, димәк,—Хәбиб?

Хәбиб. Әйе. *(Көлә.)* Күңелле килеп чыкты.

Назимә. Сез чынлап та фин татарымы?

Хәбиб *(бернинди ачусыз, ләкин житди кыяфәт белән).* Мин фин татары түгел. Мин Финляндия татары.

Назимә *(каушаулы тавыш белән).* Гафу итегез.

Хәбиб *(кызның каушавын күреп тиз генә аны тынычландырырга тели).* Гафу үтенерлек нәрсә юк әлегә. Борчылма бер дә.

Назимә. Сез инде минем белән "син" дип сөйләшә дә башладыгызмыни?

Хәбиб. Бездә кешегә "сез" дип эндәшмиләр. Татарлар элек-электән бербергенә "син" дип мөрәҗәгать иткәннәр. Русиядә генә ул, имеш, ихтирам йөзеннән, "сез" дип сөйләшәләр. "Син" дип мөрәҗәгать итү яхшырак, якынрак бит инде, шулаймы?

Назимә. Килешәм. Гаҗәп! Минем беренче мәртәбә фин татарын... гафу... Финляндиядә яшәүче татарны очратуым. Андагы татарлар турында ишетеп кенә белә идем.

Хәбиб *(шатлыгы бөтен кыяфәтенә чыга).* Минем дә бүгенге көнем могҗизалы булып чыкты—беренче мәртәбә мондый гүзәл Казан кызын очратуым.

Назимә *(сынаулы караш һәм серле тавыш белән).* Чибәр татар кызларын күп күргәнсездер инде—Татарстанда да, башка тарафларда да. Казанда булганыгыз бардыр бит?

Хәбиб *(ихлас күңелдән әйтә).* Бар. Казан кызларын да күргәнем бар. Ләкин синең кебек гүзәлне беренче тапкыр күрүем.

Назимә *(кинәт житдиләнә).* Үләм! Битем яна. *(Кул арты белән яңакларына кагыла.)*

Хәбиб *(як-ягына, күккә карап ала, аннары кызга карап елмая).* Бик эссе бүген.

Назимә *(ни әйтергә белми).* Сез... син татарча әйбәт сөйләшәсез.

Хәбиб *(горур тавыш белән)* Татар бит мин! *(Кызга сокланып карап тора.)*

Назимә *(күзләрен яшереп).* Ник алай текәлеп карыйсың?

Хәбиб *(елмаеп).* Татар бит мин! *(Көлә.)*

Назимә. Анда, Финляндиядә барыгыз да шулай яхшы сөйләшәсезме татарча?

Хәбиб. Тырышабыз. Карале, Назимә, Петербургка ни йомыш белән килгәнеңне ишеттем шикелле, әмма аңламый калдым?

Назимә *(кыяфәте тагын сагышлана).* Бабамның полкташын эзләп килгәнием. Фин сугышында аларның рота командиры Ленинград кешесе булган—Лебедев Анатолий Евсеевич. Бабам шуны табарга кушкан иде.

Хәбиб. Таптыңмы соң?

Назимә. Оныгы Иринаны гына табып очрата алдым. Ә бабасы инде урын өстендә.

Хәбиб. Алай икән.

Назимә. Сезнең ата-аналарыгыз да Финляндиянекеме?

Хәбиб. Хәтта бабам да Финляндиядә туган.

Назимә *(каядыр бер ноктага карап).* Ә совет-фин сугышында Финляндия татарлары сугышканмы?

Хәбиб *(тавышында горурлык яңгырый).* Әлбәттә. Ничек инде Туган ил өчен сугышмыйсың?!

Назимә *(уйчан кыяфәт белән).* Сезнең Туган ил—Финляндия бит инде ул?

Хәбиб. Шулай. *(Тизрәк бу житдилектән һәм сагышлы тоннан арыныр өчен тавышын күтәрә һәм ягымлылыгы шундук йөзенә чыга.)* Минем бер тәкъдимем бар: әйдә бу темага сөйләшмик. Бүген бәйрәм. Барлык татарларның бәйрәме.

Назимә *(гафу үтенгән сыман).* Әй, минем кәефем арыганнан бозылды, шуңа күрә сөйләшүемнең атасы-анасы юк.

Хәбиб *(кинәт).* Синең ашыйсың киләме?

Назимә. Бераз килә.

Хәбиб *(ягымлы итеп елмая).* Кызлар "бераз килә" дисә, ул инде чынлап та килә дигән сүз. Әйдә, берәр жирдә берәрнәрсә алып утырып ашыйк.

Назимә *(елмаерга тырыша).* Әйдә. *(Китәләр. Музыка яңгырый. Жыр ишетелә.)*

Музыка һәм шатлыклы авазлар фонында Сабантуй күренешләре.

Бераздан Хәбиб белән Назимә пәйда булалар.

Хәбиб. Бәлки тагын берәр көн Санкт-Петербургта буласыңдыр?

Назимә. Юк, Хәбиб, миңа Казанга кайтырга кирәк.

Хәбиб. Минем сиңе жибәрәсем килми.

Назимә. Үзең дә иртәгә Хельсинкига кайтып китәсең инде. *(Музыка. Бер-берсенә бик озак карап торалар.)*

Хәбиб *(визиткаларын бирә.)* Менә минем адресларым. Менә телефон номерларым. Мөмкинлеген булса шалтырат. Хат язсаң да була. Синең телефоның бардыр бит?

Назимә. Мин бит Казанның үзенеке түгел. Казанга Чаллыдан килдем мин. Чаллыда телефоным бар, ә Казанда бер әбидә фатирда торам. Биримме соң адресларымны, Чаллыдагы телефонымны?

Хәбиб *(сөенеп).* Әлбәттә. Ник аны сорап торасың!

Назимә *(кабаланып сумкасыннан блокнот белән авторучка ала һәм тизтиз Казандагы һәм Чаллыдагы адресын, Чаллыдагы телефон номерын язып бирә.)* Менә, яздым. Мин әле бер ярты ай чамасы Казанда булам, аннары Чаллыга кайтып китәм.

Хәбиб *(кыздан күзләрен алмый).* Бер дә аерылышасы килми.

Назимә. Минем дә. *(Үзен кая куярга белми.)* Уф, битем яна!

Хәбиб. Эссе бит.

Назимә. Шалтыратыгыз... Шалтырат.

Хәбиб. Син дә. Без хәзер бер-беребезне беләбез, без инде бер-беребезне тиз табачакбыз.

Назимә. Тик... онытырсың син мине.

Хәбиб *(нәрсәнедер исенә төшергән сыман талпынып).* Ә мин тиздән тотам да, Казанга килеп төшәм! Син Чаллыңа кайтып киткәнче үк. Бәлки шуннан Чаллыга бергә кайтырбыз.

Назимә. Уф, тагын битем яна.

Хәбиб. Көне бик эссе.

Назимә *(чак кына ишетелерлек итеп).* Миңа кузгалырга кирәк.

Хәбиб *(шулай ук чак кына ишетлерлек тавыш белән).* Мин сине озатып куям. *(Китәләр.)*

Музыка. Сабантуй тавышлары беркавым гөрләп тора да, сәхнә караңгылана. Төрле утлар балкый. Самолет утлары да жемелди. Өстән шәһәрне күзәткән күренешләр дә балкып ала. Төнге кала күренешләре. Төрлетөрле музыка яңгырап ала. Төрле телдә сөйләшкән тавышлар ишетелә. Телефоннан сөйләшкән тавышлар берсен-берсе каплап яңгырый. Бу тавышлар отыры кими. Эфирда Хәбиб белән Назимәнең телефоннан сөйләшүләре ишетелә.

Хәбиб *(телефон буенча Хельсинкидан).* Алло! Назимә! Исәнме? Бу—мин—Хәбиб Хельсинкидан шалтыратам.

Назимә. Исәнме! Ничек таптың институт номерын?

Хәбиб. Аның бер авырлыгы да юк. Кайсы телефонга чакырдылар соң сине?

Назимә. Декан бүлмәсендәгенә. Минем институтта икәнемне каян белдең?

Хәбиб. Күнелем сиздә.

Назимә. Үзең әйбәт кенә кайтып життеңме?

Хәбиб. Аллага шөкер. Петербургта хушлашканыбызга нибары ике көн узды, ә минем өчен егерме ел узган сыман булды инде. Син минем күз алдымнан һич кенә дә китмисең.

Назимә. Шулаймы... Ә мин сине бүген төшемдә күрдем.

Хәбиб. Ничек итеп?

Назимә. Бик матур итеп. Монда мин иркенләп сөйләшә алмыйм.

Хәбиб. Ник?

Назимә. Кеше күп.

Хәбиб. Тиздән Казанга киләм. Очрашабызмы?

Назимә. Әлбәттә. Мин әле йә бүген, йә иртәгә иптәш кызымның телефоныннан сиңа шалтыратырмын.

Хәбиб. Ярар. *(Музыка көчәя.)*

Музыканың тавышы кимегәч эфирда тагын егет белән кызның сөйләшкәннәре ишетелә.

Назимә. Казанда коеп яңгыр ява. Кешеләр тегендә-монда чабыша.

Хәбиб. Бездә кичә яуды яңгыр.

Назимә. Шул сезнең яңгыр килеп житкәндер инде монда.

Хәбиб. Әйе. Жил иссә дә, яңгыр яуса да, Кояш елмайса да—болар барысы да безнең тарафтан, минем теләгем белән синең Казаныңа жибәрелә *(Көләләр.)*

Назимә. Безнең бер районда давыл булып узды—агачлар ауган, берничә йорт жимерелгән... Анысын да син жибәрдеңме?

Хәбиб. Юк, юк, анысын мин түгел. Анысын башка кеше юллагандыр. *(Көләләр.)*

Назимә. Мин сине тагын төшемдә күрдем.

Хәбиб. Ничек итеп?

Назимә. Әйтмим.

Хәбиб. Ә мин сине бик сагындым. Шундый күрәсем килә.

Назимә. Чын әйтәсеңме?

Хәбиб. Шушындый ерак арадан ялган сөйлиләр ди мени?

Назимә. Минем бөтен битем яна... Ут кабынамы инде!

Хәбиб. Эсседер.

Назимә. Коеп яңгыр ява дидем бит. *(Музыка көчәя.)*

Вакыт-вакыт эфирда бер-бер артлы һәм берсен-берсе бүлә-бүлә яңгырап куя:

—Мин сине сагындым!
—Мин дә сине сагындым!

Музыка.

—Бүген Казанда көн якты.
—Бездә дә чалт аяз көн.

Музыка.

—Бүген төшеңдә күрдеңме мине?
—Әйтмим әле менә!

Музыка.

—Хельсинкига кунакка кил!
—Син бит үзең тиздән Казанга киләм дидең.
—Әйе, килеп бөтен Татарстанны айкап йөрисе бар әле.

Музыка.

Хәбиб. Петербург сабантуендагы очрашуыбызның һәр мизгеле хәтеремдә, һәр сызыгы, һәр чагылышы күз алдымда, һәр хәрәкәтең һәм балкышың күңелемдә.

Назимә. Кичә озак шалтыратмый торгач мин бик борчылдым. Көне буе үземне кая куярга белмәдем.

Музыка.

Хәбиб. Мин сине шундый сагындым!

Назимә. Андый жыр бар. Беләсеңме?

Хәбиб Беләм. *(Жырлап күрсәтә.)* Мин сине шундый сагынды-ы-ым.

Назимә. Сизәсең микә-ә-ән шу-у-уны-ы-ы... *(Көлешәләр.)*

Алар телефоннан сөйләшкәндә эфирда шулай ук татар, фин, рус телләрендә Хельсинкидагы, Мәскәүдәге, Казандагы дикторларның вакытны, һава торышын һәм башка төрле көн саен кирәк мәгълүматларны әйткән авазлары ара-тирә яңгырап куя.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Зариф өе. Тагын бүлмәсенен асты өскә килгән. Шкафынын тартмалары ачык. Зариф башын куллары белән кысып караватта утыра. Ыңгыраша. Аның өянәге купкан һәм телсез калган. Сикереп торып шкаф тартмаларын актара. Янә караватына барып утыра да ыңгырашып башын куллары белән кыса. Көтмәгәндә өйнен бер почмагында 1939 нчы елгы хәрби форма кигән фин солдаты пәйда була. Ул әкрен генә Зариф утырган якка карап өйнен бер почмагыннан икенчесенә атлый. Зариф башын күтәреп ана карап тора. Ул өендәге өрәктән һич кенә дә курыкмый. Гомумән бу күренеш аны аптырашта калдырмый—ул аны тып-тын гына күзәтә.

Фин *(авыз чите белән генә елмаеп).* Ничек фин солдаты монда килеп чыккан дип аптырама, Зариф. Мин инде хәзер кайда телим, шунда йөрим.

Зариф *(чыраена газап чыгарып).* Ы-ы-ы-ы-и-и-и...

Фин *(елмая).* Алай нык кайгырма, Зариф. Күз чыгып, баш бетмәгән.

Зариф *(нидер әйтмәкче булып ыңгыраша).* А-а-а-ы-ы-ы-и-и-у-у-у-ы-ы-ы...

Фин *(житдиләнеп).* Нәрсә булды сон сина? Тагын телен югалдымыни?

Зариф. А-а-а-и-и-и-е-е-е-ы-ы...

Фин. Үтәр, үтәр, анысы да үтәр.

Зариф. М-м-м-м...

Фин. Бу дөньяда барысы да, бөтенесе дә үтә. Бу дөньяда һәр нәрсәнен чиге, азагы бар.

Зариф. Ы-ы-ы-и-и-и-о-о-о-ы-ы-ы...

Фин. Кайгырма! Ул документның кемгә кирәге бар инде хәзер?!

Зариф. М-м-м-м...

Фин *(елмая).* Их, Телсез Күке, Телсез Күке! Хәтерлисенме, син мине теге вакытта яклаганда минем хакта “телсез күке” бит ул дигән идең.

Зариф *(авызын кыйшайтып елмаерга тырыша).* А-а-а-а-и-и-и-ы-ы...

Фин *(кайгылы тавыш белән).* Их, Зариф, Зариф, нигә һаман үзеңдә җан газабын асрыйсың?!

Зариф. Ы-ы-ы-а-а-а... *(Фин солдаты әкрен генә, гүя йөзеп, өйнен стенасы аша юкка чыга. Зариф өрәк югалган тарафка карап тора да, тагын куллары белән башын кысып ыңгыраша.)*

Зиновьев керә.

Зиновьев *(акцент белән татарча исәнләшә).* Исәнмесез! *(Зариф аңа төссезләнгән күзләре белән карап тора.)* Что?! Опять?!

(Нәрсә?! Тагынмы?!)

*(Түргә уза, бүлмә буйлап йөренә, як-ягына карана.)* В этот раз что украли?

(Бу юлысы нәрсәнне урлаганнар?)

Зариф. М-м-м-м... *(Калтырана.)*

Зиновьев *(картка игътибар белән карап тора).* Понятно. Язык отнялся. Очередной приступ. Скорую вызвать?

(Аңлашылды. Телен югалган. Чираттагы өянәк. Ашыгыч ярдәм машинасын чакыртыйкмы?)

Зариф *(“Юк” дигәнне аңлатып баш чайкый).* Э-э-э-э-э...

Зиновьев. Давай, я тебя сам в больницу повезу. Устрою в хорошее отделение, к хорошему врачу.

Зариф *(ыңгырашып баш чайкый).* Ы-ы-ы-ы...

Зиновьев. Что-то очень нужное украли в этот раз?

(Бу юлысы берәр бик кадерле әйберенне урлаганнар маллә?)

Зариф *(“Әйе” дигәнне аңлатып баш кага).* А-а-а-и-и-и-ы-ы-ы...

Зиновьев *(як-ягына каранып).* Что именно?

(Нәрсәнне?)

*(Зариф дәшми.)*

Заявление будешь писать?

(Гариза язасынмы?)

*(Зариф баш чайкый.)*

Что же тебя так потрясло?

(Нәрсә сине шушы кадәр тетрәндерде?)

*(Элек телевизор торган тумбочкага карап тора.)* У тебя телевизор был. Старый, черно-белый. Утащили?

(Синен иске, аклы-каралы телевизорың бар иде. Урлаганнармы?)

*(Зариф баш кага.)*

Очень жалко?

(Бик кызганасынмы?)

*(Зариф баш чайкый.)*

Ну да, из-за телевизора ты болеть не будешь, не такой ты человек. Что же еще украли у тебя?

{Хәер, син телевизор аркасында чирли торган кеше түгел. Тагын нәрсәнне алганнар соң синен?}

*(Зариф дәшми.)*

Может быть, тебе стало известно— кто тебя грабит?

{Әллә каракларнын кемнәр икәнен белдеңме?}

*(Зариф башын чайкый.)*

Ох-ох-ох... *(Урындыкка утыра.)* Жаль, что нельзя с тобой поговорить. Надолго это у тебя?

{Ох-ох-ох... Синең белән хәзер сөйләшеп булмый—шунысы начар. Озакка сузыламы синең бу халәтең?}

*(Зариф дәшми.)*

Приступ надолго, что ли, посещает? Немеешь надолго?

{Өянәгең озакка кубамы? Күпме вакыт телсез йөрисен?}

*(Зариф дәшми. Төссез күзләре белән Зиновьевка карап утыра, бераз калтырана.)*

Лекарства-то есть хоть какие-нибудь?

{Даруларың бармы соң синең?}

*(Зариф башын чайкый.)*

А нужны какие-нибудь лекарства?

{Берәр төрле дару-мазар кирәкмиме соң?}

*(Зариф башын чайкый.)*

Странный ты старик! Странный, странный, очень странный!

{Сәер карт син, сәер! Бигрәк сәер!}

*(Зиновьев урындыкка утырып папкасын актарырга тотына.)*

Бүлмәдә тагын 1939 нчы елгы фин солдаты пәйда була. Ул стена аша үтеп керә һәм, йөзгән сыман, әкрен генә, Зариф ягына карап, өйнең бер почмагыннан икенчесенә юнәлә. Бу өрәкне Зиновьев күрми, ул Зарифка гына күренә.

Ф и н. Һәй, Зариф, һаман тынгылык бирмиләр үзенә, әйеме. *(Зариф ана карап тора, ә Зиновьев исә өрәкне күрми дә ишетми дә.)*

З и н о в ь е в. Скучно будет без телевизора-то.

{Телевизорсыз ямансурак булыр шул.}

*(Зариф аңа игътибар итми, әкрен генә атлаучы өрәккә карап тора.)*

Ф и н *(Зиновьевка кашларын җыерып карый).* Зариф, нәрсә мыгырдый ул?

З и н о в ь е в *(кыяфәтен усалландырып).* Ну, сволочи, даже старый телевизор унесли! Ты из-за телевизора, может быть, все-таки, так сильно расстроился?

{Ну, кабахәтләр, инде иске телевизорны да алып киткәннәр! Ә шулай да син бәлки телевизор аркасында болай кайгыга төшкәнсеңдер?}

З а р и ф *(Зиновьевка шактый вакыт карап тора).* Ы-ы-ы... *("Юк" дигәнне аңлатып башын чайкый. Тагын өрәккә карап ката.)*

Ф и н *(Зиновьевка ачулы караш белән карый).* Зариф, нәрсә быкырдый бу сәер кеше? Мин урысча аңламыйм бит.

З и н о в ь е в. Зариф абы, все же протокол необходимо составить.

{Зариф абый, шулай да протокол төземичә ярамый.}

*(Зариф "кирәкми" дигәнне аңлатып баш чайкый.)* Ну, что ты такой упрямый!

{Ник һаман киреләнәсең соң син!}

Ф и н. Нишләп сиңа бәйләнә ул, Зариф? Ник җавап бирмисең? *(Зариф ыңгырашып куя.)* Әй, син телсез калдың бит әле, онытып җибәргәнмен. Үтәр, үтәр. Өянәгең дә үтәр, телең дә кайтыр, Алла боерса. Ә бу кешегә телевизор өчен кайгырам дип әйт тә инде, шул ялган белән котыл. Нәрсә, төпченеп утыра ул! *(Ачуланып.)* Чыгарып җибәр үзен тизрәк!

З и н о в ь е в. Ну, тебя же и впредь будут вот так грабить. Они появляются только тогда, когда тебя дома нет, да?

{Сине бит алга таба да гел шушылай талаячаклар. Алар син өйдә булмаганда гына киләләр, шулаймы?}

*(Зариф ана карап тора.)*

Ф и н *(нәфрәтләнеп).* Нәрсә кирәк ана?

З и н о в ь е в. Я хотел спросить, когда ты дома, воры не появлялись? Подозрительных людей не замечал в лесхозе, около дома?

{Син өйдә чакта каракларның күренгәне юкмы, дип сорамакчы идем мин. Урман

хуҗалыгында, үзеннен йортын тирәсендә шикле кешеләрне абайлаганын юкмы?)

*(Зариф башын чайкый.)*

Фин *(Зиновьевка ымлап)*. Зариф, игътибар белән кара әле, кемгә охшаган ул? *(Зариф Зиновьевны жентекләп күзәтә.)*

Зиновьев *(картнын күз карашыннан бераз югалып кала)*. Что ты, Зариф абы, на меня так смотришь?

(Син нишләп, Зариф абый, мина алай карыйсын?)

Фин. Кара, кара. Берәр кешене хәтерләтмиме ул сина?

Зиновьев *(кәгазьләрен папкасына тутыра)*. Ну, что ж, мне кажется, что ты не нуждаешься в помощи и не горишь желанием помочь милиции.

(Ярар алайса, анлавымча, син ярдәмгә мохтаж түгелсен, үзен дә милициягә ярдәм итәргә атлыгып тормыйсын.)

Фин *(таләпчән тавыш белән)*. Зариф, куып чыгар син аны! Юньле кешегә охшамаган. Ярый, үзенә кара, киттем мин. Озак чирләмә, Зариф, тизрәк терел. Сау бул! *(Стена аша чыгып югала. Зариф ул киткән тарафка карап тора.)*

Зиновьев *(торып бүлмә буйлап атлый)*. У лесничего телефон есть. В случае надобности можешь позвонить вот по этому телефону.

(Урман хуҗалыгы житәкчесенен телефоны бар бит. Кирәк чакта менә бу номер буенча шалтырата аласын.)

*(Телефон номеры язылган кәгазь кисәген өстәлгә куя. Зариф Зиновьевка карап тора. Зиновьев анын кыза башлавын чамалый. Зариф кинәт сикереп тора да барып ишекне ача. Зиновьев анын ни теләгәнен анлый һәм ишеккә таба юнәлә. Ишек катында туктап картка карый.)* Я же тебе добра желаю. Хочу помочь.

(Мин бит сина яхшылык кына телим. Ярдәм итәсем килә минем сина.)

*(Зариф Зиновьевны этеп чыгарып жибәрә һәм ишекне шапылдатып яба.)*

Авыр музыка. Зариф өйнен түренә атлый.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Яр Чаллы шәһәре. Вокзал. Ике авыр сумка күтәреп Назимә басып тора. Сумкаларын жиргә куя. Сәгатенә карап ала. Ыгы-зыгы. Шау-шу. Кеше авазлары, автобус тавышлары аша төрле яктагы киосклардан чуар музыка янгырый. Дикторлар бер-бер артлы игъланнарын әйтеп торалар.

—С первой платформы отправляется автобус "Набережные Челны—Казань" рейсом на 08.30. Тугызынчы яртыдагы "Яр-Чаллы—Казан" автобусы дүртенче платформадан кузгала.

—Готовится посадка на автобус "Набережные Челны—Заинск" рейсом на 09.00. Платформа—шестая. Сәгать тугызда китәчәк "Яр Чаллы—Заинск" автобусына алтынчы платформада утырту башлана.

—Водитель Мензилинского автобуса, зайдите в диспетчерскую! Водитель Мензилинского автобуса, срочно зайдите в диспетчерскую!

—Объявляется посадка на автобус, следующий рейсом "Азнакаево". Отправка в 09.15, с пятой платформы. Унынчы унбиш минутта кузгалачак Азнакай автобусына утырту башлана. Бишенче платформа.

—Водитель Мензелинского автобуса, не слышите, что ли! Зайдите в диспетчерскую! По-русски не понимаете, что ли?! *(Диспетчерскида үзара сөйләшкәннәре тышка ишетелеп тора.)* Гуля, скажи по-татарски, а то заколебал.

—*(Чәрелдәвек тавыш белән Гуля кычкыра.)* Минзәлә водителе, ишетмисен, что ли, диспетчерскигә кер!

Назимә диспетчер тавышы килгән якка карап куя да, сумкаларын алып, читкәрәк барып баса. Беркавым торганнан сон ул ерактарак зур портфель тоткан бер кешене күрә һәм тан кала.

Назимә *(үзалдына)*. Әллә саташам инде... Күземә генә күренәме... Ул бит инде бу, ул! *(Теге кеше бу якка таба килә башлагач Назимә дә ана таба атлый.)* Әйе, нәкъ үзе! *(Капма-каршылыклы

*хисләр кичерә, нишләргә белми—сөенергәме, көенергәме. Ләкин һичшиксез куану, шатлык өстенлек ала. Ул тирәякны яңгыратып кычкыра.)* Хәбиб! *(Хәбиб үзенә эндәшкәннәрен ишетеп якъягына карый һәм шундук Назимәне абайлап ала.)* Хәбиб!

Хәбиб *(Назимәне күреп ала һәм аның янына йөгерә).* Назимә?!

Назимә *(шатлык катыш каушау белән).* Хәбиб синме бу?

Хәбиб *(шулай ук аптырашта кала, шуңа да карамастан чиксез шат).* Мин. Ә бу—синме?

Назимә *(ни уйларга да белми).* Ник, күрмисеңмени? Син... ничек монда килеп эләктең?

Хәбиб *(чиксез куанып).* Хәзер мин сиңа барысын да аңлатам. Иң элек сиңа карап торыйм әле. *(Назимәгә карап тора.)*

Назимә *(оялып).* Әй, бик жентекләп карама әле.

Хәбиб. Ник, ярамый мәллә?

Назимә. Кыяфәтем өчен оялам. Йокым туймады бүген.

Хәбиб *(ихлас күңелдән).* Син тагын да чибәррәк хәзер.

Назимә *(гаҗәпләнеп һәм аңларга тырышып).* Өченче көн Хельсинкидан шалтыратканда шулай тиз арада Чаллыга килеп чыгасыңны әйтмәгән идең.

Хәбиб *(Назимәне сокланып күзәтә).* Син дә бит бүген Чаллыда буласыңны хәбәр итмәдең.

Назимә. Әйе шул.

Хәбиб *(шатлыгын бөтен кыяфәтеннән күрсәтеп).* Карале, тагын нинди могҗизалы көн! Тагын сине очраттым!

Назимә *(сынаулы караш белән карап).* Син мине күрергә дип махсус килмәгәнсеңдер бит?

Хәбиб. Минем ике төп эшем бар бу килүемдә. Берсе Зыятдин бабамның әманәтен үтәү, икенчесе, әлбәттә, синең белән очрашу. *(Кызга карап туя алмый.)* Бик сагындым мин сине.

Назимә *(үпкәле тавыш белән).* Син бит мине Казанда булырга тиеш дип уйлагансыңдыр. *(Бераз тынычланып.)* Иптәш кызларымнан шалтыратып сорадыңмы?

Хәбиб. Дөресен әйтәм, шалтыратып белешеп тормадым. Беренчедән, мин иң элек мондагы эшемне тәмамласам яхшырак булыр дидем. Аннан соң Казанда иркенләп синең белән бергә булырбыз дип өметләндем. Икенчедән, алдан кисәтмичә генә килеп чыгуым сиңа берникадәр сюрприз булыр дип тә уйладым. Ә син үзең телефоннан сөйләшкәндә ник әйтмәдең Чаллыга кайтып китәсеңне?

Назимә. Кичекмәстән кайтырга кирәк булды. Әни чакырды: бабаң авырый, кайт тизрәк, диде. *(Тәмам төшенкелеккә бирелә.)* Мин сине бүген дә төшемдә күрдем.

Хәбиб. Очрашасы булганга күргәнсең бу юлы. *(Кызның пошамангa калуына борчыла башлый.)* Нишләп кәефең төште? Син шат түгел мәллә?

Назимә *(Хәбибкә карап, аның ничек монда килеп чыгуы турында уйланып бимазалана).* Шат. Ләкин, әллә ничек килеп чыкты.

Хәбиб. Тормыш гел минутлап-секундлап төгәл бармый инде ул. Көтелмәгән мизгелләр дә килеп чыга. Безнең беренче очрашуыбыз да әллә ничек килеп чыкты бит.

Назимә. Әйе шул.

Хәбиб *(ихлас күңелдән).* Мин сине шундый сагындым.

Назимә *(кыюсыз тавыш белән).* Мин дә.

Хәбиб. Синең автобусың ничәдә китә соң?

Назимә. Сәгать унда.

Хәбиб. Минеке ничәдә икән?

Назимә. Син соң хәзер кая юл тотасың?

Хәбиб. Назимә, миңа бит Субай дигән авылга барырга кирәк.

Назимә *(тагын да ныграк гаҗәпләнеп Субайга?!).*

Хәбиб. Әйе. Билетны кайсы кассадан алырга икән?

Назимә *(аптырашта калып).* Субай автобусының үзендә кондуктор сата билетны. Ник анда барырга булдың соң син?

Хәбиб. Безнең нәсел чыгышы белән шуннан бит.

Назимә *(шаккатып).* Чын әйтәсеңме?!

Хәбиб. Әйе. Башта инде, әлбәттә сине Казанга озатып җибәрәм. Ә Субайга ничәдә китә икән автобус?

Назимә *(чиксез гаҗәпләнеп).* Ике сәгать саен йөреп тора.

Хәбиб *(якты елмаеп Назимәгә карап туймый).* Их, Назимә, Назимә! Карале син очрашуыбызны! *(Житдиләнә.)* Син генә шат түгел бугай.

Назимә *(үзен кая куярга белми).* Шат мин, шат. Тик... мин тәмам юга-

лып калдым әле... Мина әйтмичә килеп төшүен... Казанга түгел, Чаллыга...

Хәбиб. Сон, анлаттым бит инде. Хәзер сине Казанга озатып жибәргәч, Субайга барып кайткач, туп-туры Казанга китәм—әлбәттә, иртәгә инде. Каршы булмасаң, туп-туры синен янына киләм. Кунакханә мәсьәләсен хәл итеп куячаклар анда. Син мина Казанны күрсәтерсең. Казан турында минем сине сөйләтәсем килә. Яме. Субайга автобус кайсы төштән китә сон?

Назимә *(саклык белән генә әйтә)*. Борчылма. Мин дә бит Субайга кайтам.

Хәбиб. Нәрсә диден? *(Ышанмый тора.)*

Назимә *(үзен кулга алып һәм кыюрак тавыш белән)*. Минем Казанга барышым түгел. Мин хәзер Субайга кайтып барам.

Хәбиб *(илһамланып)*. Чын әйтәсенме?

Назимә. Бабам чирли, шунын янына кайтып килергә кирәк.

Хәбиб. Бабаң шундамыни?

Назимә. Шунда.

Хәбиб. Димәк, бергә барабыз Субайга?!

Назимә. Шулай килеп чыга инде.

Хәбиб *(бәхетле икәнен яшерми)*. Карале, ә, могжиза өстенә могжиза!

Назимә *(сынаулы караш белән карап тора)*. Шикләнә башладым әле мин синнән.

Хәбиб. Ник?

Назимә. Егетләргә бик ышанырга ярамый ул.

Хәбиб. Назимә, бәгърем, син ташла әле мондый уй-хисләренне!

Назимә. Ә хәзер Субайга кемнәргә барасын?

Хәбиб. Минем атам ягыннан бабайнын бабасы шул авылдан. Гәрчә анда инде бер туганнарыбыз булмаса да, юлга мин бабамнын васыятен үтәргә дип чыктым. Әманәт дип атасан да ялгыш булмас. Бабамнын бабасы яшәгән нигезне, һич тә булмаса шул нигез урынын табып баш иярга тиешмен. Димәк, синең бабаң Субайда яши?

Назимә. Субайдан ерак түгел.

Хәбиб. Нык авырыймы?

Назимә. Менә, баргач күрәм инде. Син Субайда кунасынмы?

Хәбиб. Күз күрер. Барып житик әле. Аннары, мина әле Субайдан да арырак бер жиргә барып кайтырга туры киләчәк. Автобус Субайдан сон кая бара?

Назимә. Кире Чаллыга китә. Ә син Субайдан ары тагын кая барырга җыенасың?

Хәбиб. Урманга. Анысы да мәрхүм бабамнын гозере.

Назимә *(сискәнеп)*. Нинди урманга?

Хәбиб. Урман хужалыгына. Ничек атала әле ул урман? Бәрәкәт урманы дипме?

Назимә *(сагаеп)*. Әйе. Ә син... каян беләсен?

Хәбиб. Бабам сөйләде. Субайдан ерак түгел бит ул?

Назимә. Бер чакрымнан да кимрәк. Субай авылына терәлеп тора диярлек.

Хәбиб. Күке тавышлары да авылга ишетелеп торамы?

Назимә. Әйе, ишетелеп тора.

Хәбиб. Күкеләр һаман күпме анда?

Назимә *(каушый)*. Элек күбрәк булган.

Хәбиб. Урман хужалыгы һаман да бармы сон?

Назимә. Бар. Кая китсен ул. Сина урман хужалыгы ник кирәк сон?

Хәбиб. Субайнын үзендә туган-тумачабыз булмаса да, ул тирәдә бер туганыбыз бар безнен. Мәрхүм бабам аны да эзләп табарга кушты. Тик менә мина мәгълүм түгел—исәнме ул, юкмы. Исән булган сурәттә һаман да шул урманда яши микән, әллә башка тарафлардамы?..

Назимә *(киеренкелек белән)*. Кем сон ул?

Хәбиб. Бәлки ишеткәнен бардыр: Күке Зарифы.

Назимә *(котсыз калып)*. Күке Зарифы?!

Хәбиб. Әйе.

Назимә *(нык дулкынланып)*. Исән ул!

Хәбиб. Син аны беләсен алайса?!

Назимә *(кычкырып диярлек)*. Беләм!

Хәбиб. Кайда яши ул?

Назимә. Шунда. Лесхозда.

Хәбиб. Кайда? Мин урыс сүзләрен анламыйм.

Назимә. Шунда инде... Урман хужалыгында. Бәрәкәт урманында.

Хәбиб. Димәк, исән?!

Назимә. Исән!

Хәбиб. Син бик нык каушадын. Һаман мина үпкәлисен бугай, әйеме?

Назимә *(нишләрә белми—сөенергәме, көенергәме)*. Юк, Хәбиб, үпкәләмим. Киресенчә, менә болай

көтмәгәндә килеп чыгуың бәлки яхшырактыр да.

Хәбиб. Нишләп Зариф бабайны телгә алгач, ник каушадың?

Назимә. Чөнки Күке Зарифы—минем бабам. Мин хәзер шуның янына кайтып барам.

Хәбиб *(канатланып)*. Менә сиңа мә! Син—Зариф бабайның оныгы?!

Назимә. Әйе, әйе.

Хәбиб. Төш дисәң, төш түгел бу! Әкияткә дә охшамаган!

Хәбиб. Син миңа үпкәләмә генә, зинһар.

Назимә. Юк. Ни өчен? *(Тынычлана башлый.)*

Хәбиб. Бәлки бабаңны кушаматы белән атаганым өчен ачуың чыккандыр?

Назимә. Юк ла. Кушаматның нәрсәсе бар инде аның. Тик аны хәзер "Күке" дип кенә түгел, "Телсез Күке" дип тә атыйлар.

Хәбиб. Ник?

Назимә. Соңгы вакытта аның коточкыч өянәкләре кузгала. Тотлыга башлый. Торымнан-торымга телсез кала. Бөтенләй сөйләшә алмый. *(Күз яшьләрен көчкә тыеп тора.)* Өстәвенә шушы көннәрдә тагын бер күңелсез вакыйга булды. Өенә тагын караклар кергән. Субай зыяратына, Кәшифә әбинең каберенә дип чыгып киткән. Кайтуына өенең астын өскә китергәннәр.

Хәбиб. Кәшифә—синең әбиеңме?

Назимә. Әйе.

Хәбиб. Кәшифә әби исән түгел икән...

Назимә. Син аның турында ишеткәнең бар мәллә?

Хәбиб. Бар. Мин сиңа барысын да сөйләрмен.

Назимә. Бабай көн саен аның кабере янына бара. Алар шул кадәр берберсен яратканнар. Андый мәхәббәт китапларда гына була торгандыр.

Хәбиб. Каян белдең өен басканнарын, чирләвен?

Назимә. Хуҗалык җитәкчесенең телефоны бар. Шул шалтыратты. Хәле авыр чакта бабай врачлар да чакыртмый, әти-әнигә дә кайтыгыз дими, бары тик мине генә чакыра. Назимә кайтса терeләм мин ди ул. Һәм чынлап та шулай. Мин кайтып бераз аның белән утыргач аның өянәге бетә, теле ачыла башлый, берничә минуттан теле бөтенләй рәтләнә, сөйләшә башлый. Әти белән әни дә кайтырлар иде дә... Әти Красноярскида командировкада. Әнине эшеннән җибәрмәделәр. Менә, үзем генә кайтам.

Хәбиб. Әле синең кеше дәвалау сәләтең дә бар икән.

Назимә. Мин бабамны гына дәвалый алам. Мине бик нык ярата ул. Кәшифә әбиемә охшаганмын мин. Шушы хәтле охшасаң да охшарсың икән дип шакката. Әбием яшь чакта җырлаган җырларны җырлатып ардырып бетерә.

Хәбиб. Үзе генә яшиме?

Назимә. Берүзе.

Хәбиб. Карт кешегә ялгыз яшәү... бигрәк тә урманда... бигүк дөрес түгелдер инде.

Назимә. Калага китәсе килми аның. Әти белән әни ялыналар. Мин ялынам—юк, китми урманыннан. Инде караклар бер ун тапкыр басканнардыр йортын.

Хәбиб. Ничә хуҗалык соң анда?

Назимә. Алты-җиде бугай.

Хәбиб. Ә караклар каян килә?

Назимә. Каладан. "Көмеш Күл" дигән шифалы сулы бер күл бар—шунда йөри шәһәр халкы. Юл нәкъ шул бабай торган тирәдән уза. Аның инде урлар нәрсәсе дә калмады. Бу юлысы иске телевизорын алып чыгып киткәннәр. Аклы-каралы телевизор. Юньләп күрсәтми дә иде инде.

Хәбиб. Ай-яй, начар икән.

Назимә. Туктале, минем бабай ник кирәк булды соң сиңа?! Шуны сорамыйм да.

Хәбиб. Ашыкма, Назимә, барысын да сөйләрмен. Зариф бабай турында, мәрхүмә Кәшифә әби турында да кайчан кемнән ишеткәнемне сөйләрмен. Тагын әллә нәрсәләр беләм әле мин. Ашыктырма. Минем хисләрем ташый. Шуна күрә, ашыктырма. *(Ул чыннан да каушый. Ләкин Назимәне очрату шатлыгы барыбер өстенлек ала.)*

Назимә. Чыннан да, могҗиза өстенә могҗиза! *(Назимә дә Хәбибне очратуына чиксез шат икәнен аңлый башлый—кәефе бераз күтәрелә.)* Мин дә сиңа автобуста барганда бабам белән әбиемнең яшь чакларын, ничек бер-берсен яратканнарын сөйләрмен.

Хәбиб. Ярар.

Назимә *(сискәнеп.)* Әй, әнә бит безнең автобус! Әйдә, тизрәк! *(Сумкаларын күтәрә.)*

Хәбиб *(кызның кулыннан сумкаларын тартып ала)*. Мин күтәрим. Киттек! *(Автобуска таба юнәләләр.)*

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Утызынчы еллар ахыры. Зариф белән Кәшифәнен яшь чаклары. Алар икесе дә бәхетле. Аланда көлешә-көлешә куышып йөриләр.

Зариф *(Кәшифәне куып тота да кочакламакчы була).* Тоттым бит!

Кәшифә *(ычкынмакчы булып бәргәләнә).* Җибәр! Кулын кул түгел. Көрәк хәтле. *(Якында гына кәккүк кычкыра башлый.)* Тс-с-с. Кәккүк кычкыра. *(Туктап тыңлыйлар.)*

Зариф *(кәккүк тавышын саный).* Бер, ике, өч, дүрт...

Кәшифә *(кулы белән егетнең авызын томалый).* Санама.

Зариф. Ник? *(Кәшифәнен кулын ике куллап, кош тоткандай, саклык белән назлый.)*

Кәшифә. Куркам.

Зариф. Нәрсәдән?

Кәшифә. Саннардан гомумән куркам мин.

Зариф *(елмаеп).* Гомумән куркак син.

Кәшифә. Әйе шул. *(Житди кыяфәт белән.)* Миңа кайтырга кирәк.

Зариф *(канәгатьсезлек белдереп).* Иртә бит әле.

Кәшифә. Синең белән урманда йөргәнемне белсә, әти мине бәреп үтерә.

Зариф. Син саннардан түгел, әтиеңнән куркасың.

Кәшифә. Әти бит ул.

Зариф *(бераз ачуланып).* Урманда йөрми, кайда йөрик тагын?! Авылыгызга килергә кушмыйсың бит миңа. Шпион шикелле урман авызыннан сезнең Субай авылын күзәтеп, борма-борма юлдан кайчан минем Кәшифәм килер икән дип зарыгып көтеп ятам.

Кәшифә *(үчекләп).* Читен булса көтмә!

Зариф. Ник авылыгызга килүемнән куркасың?

Кәшифә *(башын аска иеп).* Оялам.

Зариф. Бер-беребезне яраткач, аны кешеләр сизсә дә берни юк инде.

Кәшифә *(житди кыяфәт белән).* Миңа беркөнне әти әйтә: "Кызый, сине лесник малае белән күргәннәр,"—ди. "Нинди лесник?"—дип әйтеп ташладым. "Башыңны җүләргә салма, бездә лесник берәү генә—Күке Хәбибрахманы,—ди.— Шуның башкисәр малае белән урманда икегезне күргәннәр,—ди. Смотри!"—дип йодрык селкеп янады. Жир тишегенә керер китәрдәй булдым.

Зариф *(кашларын җыерып).* Башкисәр булырлык нишләгән әле мин?!

Кәшифә. Авылыбызга килгән саен берәрсе белән сугышып китәсең бит.

Зариф. Егетләрегез шундый бәйләнчек булгач...

Кәшифә. Дөресен әйткәндә, авылыбызга килүеңә мин шуңа күрә каршы да.

Зариф. Нәрсәгә күрә?

Кәшифә. Авылыбыз егетләре сине дошман иткәнгә.

Зариф. Син—Субай авылының иң чибәр кызы. Шуңа көнләшеп гел мине кыйнамакчы булалар алар.

Кәшифә. Ана түгелләр. Син үзең кыргый. Алар белән рәтләп сөйләшә дә алмыйсың. *(Көлә.)* Урман кешесе—урман кешесе инде ул.

Зариф. Көл әйдә, көл.

Кәшифә *(серле итеп елмая).* Минем синнән күптән сорыйсым килә...

Зариф. Нәрсә сорыйсың килә?

Кәшифә. Нишләп сезнең кушаматыгыз "күке"?

Зариф *(коры гына).* Белмим. Урманда яшәгәнгәдер.

Кәшифә. Кызык... Күке Хәбибрахманы... Күке Зарифы! *(Үчекли.)* Әй, Күке Зарифы-ы-ы, ишетәсенме?! Ачуың киләме?

Зариф. Юк. Нишләп минем ачуым килсен. Субайда акылга тулы кеше юк бит анда. Субай кешесенә мин бераз скидкә ясыйм, ачуланмыйм да, үпкәләмим дә. *(Рәхәтләнеп көлә.)*

Кәшифә. Аһ, әле син шулаймы?! Димәк мин дә тулы түгел?! *(Зарифны егарга тырыша.)*

Зариф *(көлә).* Соң, акылга зәгыйфь булмасаң, урман хәтле урманга килеп йөрер идеңмени?!

Кәшифә *(Зарифны ныграк жилтерәтергә тотына).* Аһ, оятсыз! Нәрсә дип торган була бит! Моннан соң эземне дә атламыйм!

Зариф *(көлүдән туктый).* Алайса мин үләм. *(Кыяфәте житдиләнә. Кәшифәне иңнәреннән коча.)* Минем һәр көнем сине генә уйлап үтә, жанкисәгем!

Кәшифә *(Зарифның күзләренә ка-*

*рап тора).* Мин дә бит гел сине генә уйлап йөрим, тиле булсаң да.

Зариф *(Кәшифәне тәмам кочагына ала).* Синнән башка бу дөньяның бер генә дә яме булмас иде.

Кәшифә. Көн туса минем ике күзем сезнең урман ягында инде. Әйтерсең лә минем өчен бөтен яшәүнең мәгънәсе шул тарафларда. *(Зарифның куенынннан шуышып чыга.)*

Зариф. Әле син белмисеңдер...

Кәшифә. Нәрсәне?

Зариф *(горур һәм шул ук вакытта шөбһәле тавыш белән).* Мине тиздән армиягә алачаклар.

Кәшифә *(кинәт моңсуланып).* Ишеттем инде.

Зариф. Каян ишеттең?

Кәшифә. Авылда сөйләштеләр. Авылыбыздан китәсе егетләрне атаганнан соң сине дә әйттеләр. Шунда йөрәгем жу итте. Минем әле моңарчы ышанасым килмәде. Үзең бу хакта әйтмәгәч, бәлки китмәссең дип ышанып йөрдем. Димәк, армиягә алачаклар, дөрестән дә?

Зариф. Әйе.

Кәшифә *(сөмсере коела).* Бик ямансу булачак икән. *(Шаярырга тырыша, ләкин бик моңсу килеп чыга.)* Урманда бер күке кимиячәк. Күкеләрнең берсе кычкырмый торачак икән урманнан авылыбыз ягына.

Зариф *(башын читкә борып).* Сиңа кызык...

Кәшифә *(кинәт елап җибәрә).* Аптыраганнан шаярам мин, Зариф. Мин инде үземне кая куярга белмим. Өйдәгеләр дә нык борчылуымның сәбәбенә төшенделәр, ахрысы. Куркам мин, никтер!

Зариф. Нәрсәдән куркасың?

Кәшифә. Син барасы армиядән куркам! Җибәрәсем килми анда сине!

Зариф. Кирәк бит, кирәк. Егет кеше солдат булырга тиеш ул.

Кәшифә. Синсез бик ямансу булачак. Мин сине шундый сагыначакмын.

Зариф. Сагынып туйгач мине онытмассыңмы соң?

Кәшифә *(елаудан туктый).* Тиле. Сине онытырлыкмы соң. Мин сине өзелеп сагынып, зарыгып көтәчәкмен.

Зариф. Хат язачаксыңмы?

Кәшифә. Әлбәттә. Ә син?

Зариф. Мин дә вакыт булган саен, җай чыккан саен сиңа хат язачакмын. Мин сине инде киткәнче үк сагынырга өлгердем.

Кәшифә. Мин дә инде аерылышканчы ук күңелемдә сиңа бер хат яза башладым.

Зариф. Мин матур яза белмим инде, гаеп итмәссең. *(Елмая.)*

Кәшифә. Ничек язсаң да, ничек әйтсәң дә—минем өчен барысы да матур.

Зариф. Рәхмәт. *(Кәккүк кычкыра башлый.)*

Кәшифә *(саный башлый).* Бер... ике... өч... дүрт... биш.

Зариф *(кулы белән кызның авызын каплый).* Санамыйк.

Кәшифә *(егетнең кулын үзенең битенә тигезә).* Ярар, санамыйк.

Зариф. Кәшифә!

Кәшифә. Ә?

Зариф. Теге җырны җырла әле.

Кәшифә *(җырлый).*

"Саннар".

Күбрәк сана, кәккүк, күбрәк сана,
Санга сугып санар саннарны,
Гомер дисбесенең төймәләрен -
Икәү бергә узар елларны.

Күп санама, кәккүк, күп санама
Башка төшәр хәсрәт саннарын;
Өметләрем инде бер өзелсә
Сине бүтән тыңлый алмамын.

Саный кәккүк үзе белгән көйгә
Айлы төнне, алсу таңнарны;
Ә йөрәкләр үз көенә тибә
Санламыйча сансыз саннарны.

*(Кәккүк кычкыруын дәвам итә.)*

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Зариф карт самавыр куеп йөри. Назимә белән Хәбиб килеп керәләр. Зариф аларга карап тора. Назимәне күреп елмая.

Назимә *(карт янына йөгереп килә).* Бабай! Мин кайттым! *(Бабасын елыйелый кочаклый.)* Тагын чирләденмени?

Зариф. А-а-а-ы-ы-и-и-ы-ы...

Назимә. Тагын өенне бастыларммы?

Зариф *(шатлыктан күзләре*

*яшьләнә, кызының чәчләрен сыпыра).* К...к...к...ы-ы-ы...

Назимә. Кызым дип әйтмәкче буласың, бeләм.

Зариф *("Әйе" дигәнне аңлатып баш кага).* К...к...к-ы-ы-ы...

Назимә. Бабай, тереләә башларга кирәк. *(Елмаерга тырыша.)* Болай ярамый.

Зариф *(авызын кыйшайтып елмаймакчы була).* А-а-а-ы-ы-и-и...

Назимә. Син бит һәрвакыт мин кайткач терeләсең. *(Зариф "Әйе" дигәнне аңлатып баш кага.)* Синең бит мин янында булганда телең ачыла, сөйләшә башлыйсың.

Зариф *(Назимәне иңеннән кочып караватка утырта. Үзе янәшә утыра да кызыннан күзләрен алмыйча карап тора. Шатлыгы бөтен кыяфәтенә чыга).* К...к...кы-ы-ызы-ы-ым...

Назимә *(чиксез шатланып).* Миңа бит, бер сүзне инде әйттең. Самавыр куйдың мәллә, бабай?

Зариф. А-а-а-и-и-ие-е-е.

Назимә. Бик әйбәт. Без сиңа күчтәнәчләр алып кайттык. *(Йөгереп барып сумкаларны актара, төрле төргәкләр чыгара. Бу вакытта Хәбиб нишләргә белми аптырап тора. Ул һаман ишек катыннан китми.)*

Зариф *(Хәбибкә таба атлый).* М-м-м... с-с-с-ине-е... ты-ты-тыа-а-аныйм.

Хәбиб *(Зарифка таба атлый һәм ике кулы белән картның калтыранган кулын тотып күрешә).* Исәнме, Зариф ага!

Зариф *(егетне җентекләп күзәтә).* Ат...т...т...тынны-ы-ы оныт-т-тым.

Назимә. Бабай, юк, юк, сиңа таныш кеше түгел бу.

Зариф. К...к...айда к...к...күрдем...

Хәбиб *(каушый һәм картны җентекләп күзәтергә тырыша, ниндидер таныш сызыклар, сыйфатлар эзләгән сыман карый).* Юк, бабай, без синең белән таныш түгел.

Назимә. Бабай! Син утырып кына тор әле. Хәзер чәй әзерлим. *(Самавыр белән мәж килә.)* Ничә чәйник алып кайтып бирдем инде үзеңә. Тефаль да, немесныкен дә. Юк, самавырдан башка бернәрсәне танырга теләми. Хәер, аның инде бөтен чәйникләрен урлап бетерделәр бугай.

Зариф *(урындыкка утыра, егетне һаман җентекләп күзәтә).* М-м-мин с-с-сине б..б...беләм... Оныт-т-т-тым гына. *(Аның һәрбер әйткән сүзе газап белән, авырлык белән чыга.)*

Назимә *(табын әзерли-әзерли).* Бабай, бераз тынычлан. Мин сиңе ашатам-эчертәм башта. Аннары ул егетнең кем икәнен салмак кына аңлатырмын. Йә үзе аңлатыр.

Зариф *(кызына мөрәҗәгать итә).* К-к-кияү т-т-т-түгелдер бит?

Назимә *(оялып).* Юк.

Хәбиб. Чыннан да, сонрак кем икәнемне аңлатырмын. Ерактан килдем мин. Хәбиб атлы булам.

Зариф *(хәтерендә казынып йөзен чыта).* Н-н-н-нишләп соң йөзең т-т-таныш? Мин б-б-б-беләм б-б-бит сине.

Хәбиб *(дулкынлануын яшерер өчен башын читкә бора).* Мин дә беләм сине, Зариф ага. Мин синең янына махсус килдем.

Зариф. М-м-м-милициядән т-т-түгелме?

Хәбиб. Юк, милициядән түгел.

Назимә. Өенне баскач милиция килдеме соң?

Зариф. Әйе.

Назимә *(килеп бабасының аркасыннан кага).* Бабай, маладис, кечкә тәмам телең ачылып китәчәк. Мин сиңа шундый шәп дарулар алып кайттым— төрле үләннәрдән, берниндн химиясез.

Хәбиб. Өенне талаганга бик каты авырып киттеңме?

Зариф *(газаплы тавыш белән).* Әй, б...б...балала-а-а-ар... М-м-миндә б-б-бер ды-ды-дыкуминт сак-к-к-клана иде... Шуны урлаганнар.

Назимә. Кайсы документыңны урладылар, бабай?

Зариф. Фе-фе-еин-е-е-е-я-я.

Хәбиб. Нәрсә дисең, бабай?

Зариф Фе-фен..нән-дия...

Хәбиб. Финляндия?

Зариф *(башын кага).* Т...т...тарыныкы.

Хәбиб. Финляндия татарыныкы?

Зариф *(тиз аңлауларына куанып елмая).* А-а-а-и-и-и-е-е-е.

Хәбиб. Бик кадерле документ идемени?

Зариф. Әйе.

Назимә *(пышылдап).* Хәбиб, әлегә кем икәнеңне әйтми тор. Нык каушавы ихтимал. Соңрак, яме.

Хәбиб. Ярар.

Назимә *(кычкырыбрак бабасына мөрәҗәгать итә).* Бабай, Хәбиб вакыты җиткәч үзе сөйләр: кем икәнен дә, ник

килгәнен дә, яме. Төпченми тор, зинһар.

Зариф. Ярар. Ашыкт...т...т...ы-ы-ырмыйм. Үзе ашык...к...к..ма-а-а-аыса...

Хәбиб. Мин беркая да ашыкмыйм. Мин сине күрергә, синең белән сөйләшергә дип махсус килдем.

Зариф *(авырлык белән аңлата)*. Аның ды-ды-ды а-а-к...к...к-у-у-ументы м...м...и-и-индә... чакта әле к...к...кү-ү-үүнелем...м...м...мдә өмет бы-бы-быа-а-ар иде... М...м...мин сезгә ял ит...т...ткәч, т...т...телем рәт...т...тләнгәчрәк бы-бы-быа-а-арысы-ы-ын ды-ды-да-а-а сө-ө-өйли-и-им.

Музыка. Назимәнең тагын күз яшьләре тәгәри. Хәбибнең дә күңеле тула. Ул Зарифны иненнән коча да, башын читкә борып, күңеле тулганны күрсәтмәскә тырыша.

Музыка.

## ЖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Зарифның сөйләгәне эфирда яңгырый.

Зариф:

—Армиягә китәр көн дә килеп житте. Китәргә берничә көн кала урманда һәр таныш агач белән, үзем утырткан һәрбер үсенте белән хушлашып йөрдем. Мең тавышлы һәм мең шифалы урман авазын тыңлап туймадым. Чит жирләрдә колагымда яңгырап туган якны күңелемдә булса да якынайтып торыр бу сихри авазлар дип уйладым. Субайдан да ике егетне алдылар армиягә. Минем аларның икесе белән дә сугышканым бар иде. Ә менә солдатка китә башлагач бернинди үзара дошманлык, бернинди үпкә-нәфрәт калмаган иде беребездә дә. Кәшифә мине озата барганга алар фәкать якты көнләшү белән безнең өчен куанып кына карадылар. Кәшифә дә мине озата баруына, миңа карата булган хисләрен яшермәве белән хәтта горурлана да иде шикелле. Чөнки ул инде ата-анасыннан да, авылдашларыннан да мине яратуын яшерми иде. Аның янәшә булуы еракка һәм озакка китүемне күпмедер вакытка бөтенләй оныттырды.

Инде минем туган-тумачам һәм Субай егетләрен озатучылар ерактан кульяулыклар болгап калганда Кәшифә әле һаман минем белән янәшә атлады. Без башкалардан арттарак калып бардык. Әйтәсе сүзләр, житкерәсе хисләр шулкадәр күп иде ки, алар барысы да буылып, бер төенгә тупланды да, без берберебезгә бер аваз да сала алмый шактый вакыт тып-тын бардык.

Кәшифә *(кульяулык бирә)*. Сакла, яме.

Зариф. Ярар *(Кульяулыкны кесәсенә тыга.)*

Кәшифә *(үпкәле тавыш белән)*. Ник фоторәсемемне сорамыйсың?

Зариф. Бармыни?

Кәшифә. Инде онытткан да. Мин сиңа вәгъдә биргән идем бит рәсемемне бүләк итәм дип. *(Кулындагы төргәгеннән саклык белән генә рәсемен алып Зарифка бирә.)*

Зариф *(шатлыгы йөзен балкыта)*. Рәхмәт, Кәшифә!

Кәшифә. Әле тагын бер әйбер бирәм мин сиңа. *(Төргәгеннән пәке алып бирә.)*

Зариф. Бусы да миңамы?

Кәшифә. Сиңа булмый, кемгә булсын инде.

Зариф *(пәкене чалбар кесәсенә тыгып куя)*. Рәхмәт яусын! *(Кызны кысып кочаклый.)*

Кәшифә. Ул хәтле каты кысма, тиле! Барып житү белән хат яз. *(Юлдан атлыйлар.)*

Зариф. Язырмын. Син мине көт кенә.

Кәшифә. Мин сине инде менә хәзер үк көтә башладым.

Зариф. Көткәндә вакыт озак бара инде ул.

Кәшифә. Армиядә сезне тик тотмаслар, анда бигүк сагышланып утырырга вакыт та булмас.

Зариф. Әйе, солдатка тынгылык юктыр инде ул.

Кәшифә. Ә мин быел педучилищега керергә жыенам.

Зариф. Миңа бу турыда әйтмәгән иден.

Кәшифә. Әллә ничә тапкыр әйтергә жыендым. Монарчы икеләнеп йөргәнгә әйтергә ашыкмадым. Хәзер инде, син дә армиягә киткәч, һичшиксез укырга кереп карыйм. Вакыт та бәлки тизрәк узар

Аннары, минем укытучы буласым килә. Шундый хыялым бар.

Зариф. Укуга чумып мине онытмассынмы соң син?

Кәшифә. Менә карыйбыз инде, нәрсә кыйммәтрәк—укумы, синме. *(Көлә.)*

Зариф *(шелтәле тавыш белән)*. Синең шул көлү булыр инде!

Кәшифә *(кинәт моңсулана)*. Син исән-сау әйләнеп кенә кайт, Зариф. Синең армиягә китүең бәлки синен белән минем өчен әһәмиятледер.

Зариф. Ник алай дисен?

Кәшифә. Бер-беребезнең кадерен белергә, ныграк яратырга аерылышып тору бәлки кирәктер дә. *(Тагын кинәт көлә башлый.)* Субай халкы да бераз ял итәр үзеннән. Урманнан Күке Зарифы килми башлагач авылыбызда сугышучы да юк, дип сөенерләр. *(Кычкырып көлә.)*

Зариф *(шелтәләсә дә елмая)*. Һаман көләсең син миннән.

Кәшифә *(тагын да кычкырыбрак көлә)*. Көлми нишлим соң! *(Көлә-көлә истерикага бирелә. Көлүе кинәт елауга күчә. Ул сулкылдап-сулкылдап елый башлый.)* Белсән иде, сине ничекләр җибәрәсем килмәгәнне. Мин бит инде әллә ничә көн әти-әнидән качып елыйм да елыйм. *(Туктыйлар.)*

Зариф *(кочаклап юата)*. Кәшифә, акыллым, болай ук кирәкми. Елау ярый, ләкин болай ук түгел.

Кәшифә *(сулкылдый-сулкылдый)*. Мин бит һәрвакыт үземнен борчылуымны, газабымны киметер өчен синнән көлгән булам.

Зариф *(юмалап)*. Көл, көл миннән. Чынлап та көлерлек бит. Авылыгызга синең янына барган саен егетләрегез белән сугышып кайта идем бит. Берсендә бөтенләй билдән тиң шәрәтән кайтып киттем. Чөнки күлмәгемне кыярлек түгел иде—ертылып чүпрәк кисәгенә әверелгән иде. *(Икесе дә көлә башлыйлар.)*

Кәшифә *(күз яшьләре аша көлеп)*. Инешкә төшеп сине юындырдым әле мин анда.

Зариф. Әйе шул. *(Рәхәтләнеп көләләр.)*

Кәшифә *(көлүдән туктап)*. Канга баткан иден бит син анда.

Зариф. Булса ни. Аның каравы син мине мамыктай кулларың белән инештә юындырдың. *(Кәшифәнең тагын күз яшьләре ага башлый. Зариф аның ничек булса да тагын күнелен күтәрергә тырыша.)* Хәтерлисенме, безнен кушаматыбыз белән кызыксынган иден?

Кәшифә. Ничек кызыксынган идем?

Зариф. Нишләп сезнең кушаматыбыз "күке" дип сораган иден.

Кәшифә. Әйе.

Зариф. Әйтимме?

Кәшифә. Әйт.

Зариф *(җитди тавыш белән сөйли)*. Безнең нәсел урманда яшәгән бит инде—бабамның бабасыннан алып. Минем әти бәләкәй чакта (дүрт-биш яшьлек булгандыр), күке тавышы ишетелгән якка таба киткән. Күке кычкыра да кычкыра икән. Әти һич кенә дә таба алмый. Кайдадыр якында гына да шикелле, ә үзе һаман күренми. Шулай агач башларына карыйкарый йөри торгач адашкан бу. Бик озак эзләгәннәр әтине. Инде көн кичкә авышкач бабай Субайга төшеп халыктан ярдәм сораган. Бөтен авыл халкы белән урманны капшый торгач әтине тапканнар. Елап шешенеп, инде тәмам тавышсыз калып зур агач төбендә калтыранып утыра икән. Шактый ерак кергән булган урман эченә. Нишләп монда кереп адаштың дип сорагач, күкене эзләдем дип җавап биргән. Шуннан соң әти мәңгегә Күке Хәбибрахманы булып калган. Хәзер инде мина да күчте ул кушамат. Күке Зарифы булып йөрим. Һәм һич кенә дә гарьләнмим. *(Елмаеп Кәшифәгә карый.)* Тынычландыңмы?

Кәшифә. Тынычландым.

Ерактан *(кычкыралар)*. Зариф! Әйдә тизрәк, сонга калабыз!

Зариф. Хуш, Кәшифә!

Кәшифә. Исән-сау әйләнеп кайтуыңны көтәм!

Ерактан *(кычкыралар)*. Зариф!

Зариф. Үпкәләткән чакларым өчен гафу ит!

Кәшифә. Нинди үпкәләткән чаклар инде ул! *(Үзе елый, үзе елмаерга тырыша.)*

Ерактан *(кычкыралар)*. Зариф!

Зариф. Кәшифә!

Кәшифә. Зариф! *(Кочаклашалар.)*

Зариф. Хуш! *(Йөгерә.)*

Музыка. Караңгылык урнаша. Еракта, офык сызыгында прожектор утлары уйнаклый. Радиоалгычтан төрле дулкыннарны эзләгән тавышлар килә. Төрле телләрдә дикторлар сөйләве, бөтендөнья музыкасы

берсен-берсе алыштырып эфирда яңгырап тора.

Молотов—Председатель Совнаркома и народный комиссар иностранных дел СССР:

... В особом положении находятся наши отношения с Финляндией... Советско-финская граница "нависла" в 32 километрах над Ленинградом, и с этим нельзя мириться... Сообщение западной прессы, будто СССР требует себе город Випури (Выборг) и северную часть Ладожского озера—это чистый вымысел и ложь... (Речь Молотова в Верховном Совете 31 октября 1939 г.) *(Радиодулкыннар үзгәрә.)*

{Молотов—Халык Комиссарлары Шурасының Рәисе һәм СССРның чит илләр эше буенча халык комиссары:

...Финляндия белән безнең мөнәсәбәтләр гаять катлаулы һәм үзенчәлекле... Сәвит-фин чиге Ленинградтан нибары 32 километрда "эленеп тора", һәм дә моның белән һич кенә дә килешү мөмкин түгел... Көнбатыш прессасының СССР үзенә Випури (Выборг) шәһәрен һәм Ладога күленең төньяк өлешен таләп итә дию—ялган һәм уйдырма... (Молотовның 1939 елның 31 октябрендә Югары Шурада ясаган чыгышы.)}

Эркко—Министр иностранных дел Финляндии (фин телендә):

... Требование СССР касается якобы отдаления границы у Ленинграда на несколько километров. Но с точки зрения Финляндии—это русский империализм... Всему есть свои границы. Финляндия не может пойти на предложения Советского Союза.

{Эркко—Финляндиянең чит илләр буенча министры:

... Имештер, СССРның таләбе дәүләт чиген Ленинградтан берничә километрга ерагайту белән бәйле. Ләкин Финляндия күзлегеннән караганда бу—урыс империализмы... Һәрнәрсәнең үз чиге була. Финляндия берничек тә Советлар Союзы тәкъдимнәрен кабул итә алмый.}

Буденный:

... Держите, товарищи, порох сухим, возьмите свои клинки, готовьте коней к большим боевым походам... (Из статьи в "Правде" к 20-летию Первой Конной армии—19 ноября 1939 г.)

{Буденный:

... Иптәшләр, дарыны коры тотыгыз, кылычларыгызны алыгыз, атларыгызны зур һәм данлы яуларга әзерләгез... *("Правда" гәжитендәге Беренче Атлы армиянең 20 еллыгына багышланган мәкаләдән—1939 ел, 19 ноябрь.)}*

Сталин:

... Нам придется воевать с Финляндией... *(Высказывание На Военном совете.)*

{Сталин:

... Безгә Финляндия белән сугышырга туры киләчәк... *(Хәрби киңәштә әйткән сүзе.)}*

Каяндер—премьер-министр Финляндии *(фин телендә)*:

... Поскольку на переговорах трудно было найти общую платформу, они пока прервались. Об этом следует сожалеть, так как Финляндия искренне желает поддерживать хорошие отношения со всеми соседями. (Из речи 23 ноября 1939 г.)

{Каяндер—Финляндиянең премьер-министры:

... Уртак платформа таба алмау сәбәпле, сөйләшүләр әлегә өзелде. Әлбәттә, кызганыч, чөнки Финляндия барлык күршеләре белән дә ихластан яхшы мөнәсәбәтләрдә булырга тели *(1939 елнын 23 ноябрендә ясаган чыгышыннан).*}

Молотов:

... Советско-финские переговоры начались недавно по нашей инициативе. Что являлось предметом этих переговоров? Нетрудно понять, что в современной международной обстановке, когда в центре Европы развертывается война между крупнейшими государствами, чреватая большими неожиданностями и опасностями для всех европейских государств, СССР не только имеет право, но и обязан принимать серьезные меры для укрепления своей безопасности...

... Наши предложения финнам:

1. Отодвинуть на несколько десятков километров границу на север от Ленинграда (в обмен на вдвое большую территорию в Советской Карелии);

2. аренда территории у входа в Финский залив для размещения военно-морской базы;

3. обмен нескольких островов, а также части полуостровов Рыбачий и Средний в Баренцевом море на вдвое большую территорию;

4. в случае принятия своих основ-

ных предложений СССР готов отказаться от возражений против вооружения Финляндией Аландских островов.

(Молотов:

... Күптән түгел безнең инициатива буенча Сәвит-фин сөйләшүләре башланды. Бу сөйләшүләрнең эчтәлеге нидән гыйбарәт соң? Аңлашыладыр ки, хәзерге вакытта Европаның үзәгендә зур дәүләтләр арасында сугыш башланырга торганда, шул сәбәпле Европаның барлык илләренә көтелмәгән куркыныч вакыйгалар янаганда, СССРның үз куркынычсызлыгын ныгыту өчен житди чаралар кулланырга хакы бар, ә кайбер кискен адымнарны ясарга хәтта мәжбүр...

... Безнең финнәргә ясаган тәкъдимнәребез:

1. Ленинградтан төньякка таба чикне берничә дистә километрга күчерергә (Сәвит Карелиясендәге икеләтә зуррак территориягә алыштыру күздә тотыла);

2. хәрби-диңгез базасын урнаштыру өчен Фин култыгындагы территорияне арендалау;

3. берничә утрауны, шулай ук Балыкчылык һәм Урта ярымутрауларның кайбер өлешләрен икеләтә зуррак территориягә алыштыру;

4. төп тәкъдимнәребезне кабул иткән очракта СССР Финляндиянең Аланд утрауларын хәрбиләштерүенә каршы килмәячәк.)

Эркко—министр иностранных дел Финляндии (на финском языке):

... Финляндия не может пойти на предложение Советского Союза и будет защищать любыми средствами свою территорию, свою неприкосновенность и независимость...

(Эркко—Финляндиянең чит илләр буенча министры:

... Финляндия Советлар Союзы куйган шартларны үтәмәячәк һәм үзенең территориясен, үзенең иминлеген, үзенең бәйсезлеген ахыр чиккә кадәр саклаячак...)

Кэрк—Главнокомандующий Королевскими Вооруженными силами Великобритании *(инглиз телендә)*:

... "Линию Маннергейма" никакая армия не в состоянии разбить.

(Кэрк—Великобританиянең Хәрби көчләре башлыгы:

... "Маннергейм сызыгы"н бер армия дә жимерә алмаячак.)

Шомлы музыка.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1939 нчы ел. Сәвит-фин сугышы. Кыш. Фронт. Карелия муентыгы. "Маннергейм линия"се алдындагы урман. Бар дөньяны ап-ак кар баскан. Бер рота сәвит солдатлары килеп туктый.

Лебедев. Рота! Стой, раз-два! Напра-во! Товарищи солдаты! Финны яростно сопротивляются. Ожидается их контрнаступление на нашем участке. Оборону занимаем на опушке. Но необходима предельная осторожность—в лесу на деревьях, в подвешенных гамаках устроились так называемые "кукушки". Это финские снайперы. Многие из них готовы к смерти и они презирают и страх и смерть. Так что и даже в тылу мы имеем опасность. Ожидается подкрепление. Так как на нашей базе имеется важный груз с сопровождающими его людьми. Должен сказать, отступать мы не имеем права. Все. Больше нечего сказать. Думаю, непонятного ничего нет. Рота! Равняйсь! Смирно! Десять минут перекур. Вольно! Разойдись!

(Рота! Тукта, бер-ике! Уң-га! Иптәш солдатлар! Финнәр үзләрен аямыйча каршылык күрсәтәләр. Безнең тарафта аларның контрһөжүме көтелә. Оборонаны урман авызында тотачакбыз. Саклыкны, уяулыкны бер дә югалтырга ярамый—урманда, агач башларында урнаштырылган гамакларда фин снайперлары булуы ихтимал. "Күкеләр" дибез без аларны. Аларның күбесе жаннарын фида кылырга әзер—аларны үлем куркытмый. Димәк, безгә тылда да тынгылык юк. Менә-менә ярдәм килергә тиеш. Нәкъ безгә ярдәмгә киләчәкләр, чөнки безнең базада гаять әһәмиятле йөк бар һәм шул йөк белән килгән махсус кешеләр бар. Чигенергә безнең хакыбыз юк. Сүзем тәмам. Башка әйтер сүзем юк. Сораулар юктыр, барысы да аңлашыладыр дип уйлыйм. Рота! Тигезлән! Үрә кат! Тәмәке тартып алырга ун минут вакыт бирәм. Таралыгыз!)

Үзенең блиндажыннан капитан Зимин килеп чыга.

Зимин. Анатолий Евсеевич, помнишь мы с тобой приметили пять человек?

{Анатолий Евсеевич, биш кеше билгеләгән идек, хәтерлисезме?}

Лебедев. Помню.

{Хәтерлим.}

Зимин. Дай мне их.

{Бир син аларны мина.}

Лебедев. Товарищ капитан, у меня и так людей мало. Сейчас я их выделить вам никак не могу.

{Иптәш капитан. Минем болай да кешеләрем аз. Менә хәзер мин сезгә аларны һич кенә дә бирә алмыйм.}

Зимин. За эти секретные снаряды отвечаю я—представитель особого отдела НКВД капитан Зимин. Понял?!

{Бу серле снарядлар өчен мин—НКВД капитаны Зимин—җаваплы.}

Лебедев. В том то и дело, что теперь за сохранность этих снарядов более ответственен я—командир роты старший лейтенант Лебедев. У вас двенадцать человек...

{Юк шул, бу снарядларнын сакланышы өчен хәзер инде мин—рота командиры өлкән лейтенант Лебедев—җаваплы. Сезнен үзегезнен унике кешегез бар бит...}

Зимин. Они все считаются военными, но они физики и химики—сотрудники научно-исследовательских институтов. А пять солдат я у тебя прошу, чтобы они прочесали лес вокруг базы. Меня эти "кукушки" сильно тревожат. Заодно эти ребята могли бы разведать удобные места для хранения снарядов.

{Алар кәгаздә генә хәрбиләр булып саналалар, алар бит химиклар, физиклар—фәнни-тикшеренү институтыннан. База тирәсен әйләнеп, "капшап" чыгарга кирәк, шунын өчен биш кеше сорыйм мин синнән. "Күкеләр" шүрләтә мине. Бер унайдан снарядларны яшерер урыннар да караштырырлар иде.}

Лебедев. Финских снайперов именно возле базы нет, это точно. Чуть подальше "кукуют", это правда.

{Безнен база тирәсендә фин снайперлары юк, иманым камил. Ә менә чак кына читтәрәк "күке тавышлары" ишетелгәли.}

*(Уйланып тора.)* Ладно, ребят, все же, я вам дам.

{Ярар инде алайса, егетләрне бирәм мин сезгә.}

Зимин. Спасибо. Я минут через десять вернусь. Пусть ждут меня здесь. *(Китә.)*

{Рәхмәт. Мин ун минуттан әйләнеп киләм. Алар мине монда көтсеннәр.}

Лебедев. Рота! Становись! Равняйсь! Смирно! Рядовой Шаталов!

{Рота! Тезел! Тигезлән! Үрә кат! Рядовой Шаталов!}

Шаталов. Я!

{Мин!}

Лебедев. Рядовой Рассуханов!

Рассуханов. Я!

{Мин!}

Лебедев. Рядовой Севрюгин!

Севрюгин. Я!

{Мин!}

Лебедев. Рядовой Яхно!

Яхно. Я!

{Мин!}

Лебедев. Рядовой Зайнуллин!

Зариф. Я!

{Мин!}

Лебедев. Кого я назвал—выйти из строя на два шага!

{Мин атаган солдатлар—ике адым алга чыгыгыз!}

*(Биш солдат чыгалар.)* Вы остаетесь в распоряжении капитана Зимина. Командиром отделения назначаю Шаталова.

{Сез капитан Зимин янында каласыз. Нишләргә тиеш икәнегезне ул үзе анлатыр. Отделение командиры итеп Шаталовны билгелим.}

Шаталов. Есть!

Лебедев. Ждите Зимина. Он сейчас подойдет. Рота! Нале-во! Шаго-о-о-м марш!

{Зиминны көтегез. Ул хәзер килеп житәр. Рота! Сул-га! Шаго-о-о-м марш!}

*(Рота китә. Калган биш солдат ауган*

*агач ботакларына утырышалар.)*

Яхно *(гәжит кисәгенә махорка төрә).* Что, склады будем охранять?

(Нәрсә, складларны каравыллыйбызмы?)

Севрюгин. Хрен его знает. Ты мне оставишь покурить?

(Шайтан белсенме. Син мина тартырга калдырасынмы?)

Яхно. Оставлю. Ваня! Слышь, Шаталов, зачем нас оставили? *(Тәмәкесен тирән итеп суыра.)*

(Калдырырмын. Ваня! Ишетәсенме, Шаталов, безне нигә дип калдырдылар монда?)

Шаталов. Не знаю.

(Белмим.)

*(Куен кесәсеннән саклык белән генә ниндидер сигарет чыгара. Иснәп карый.)* Пахнет здорово!

(Исе шәп!)

Севрюгин. Трофейные?

(Трофейныймы?)

Шаталов *(сигаретын кабыза).* Да, настоящая финская сигарета.

(Әйе, чып-чын фин сигареты.)

Севрюгин. Еще есть?

(Синдә тагын бармы?)

Шаталов. Последняя.

(Соңгысы.)

Яхно. Вань, ты че не слышишь?

(Ваня, син ишетмисен мәллә?)

Шаталов. Чего тебе?

(Нәрсә кирәк сина?)

Яхно. Зачем нас выделили, для чего здесь оставили?

(Безне ник аердылар да, ни өчен монда калдырдылар?)

Шаталов. Ты что, глухой! Я же тебе сказал: не знаю.

(Син чукрак мәллә! Әйттем бит инде: белмим.)

Яхно. Раз тебя старшим назначили, думал, знаешь.

(Син өлкәнебез булгач беләсеңдер дип уйлаган идем.)

Севрюгин. А этот капитан... как его...

(Ә ул капитан... кем әле... онытгым...)

Шаталов. Зимин.

Севрюгин. Этот Зимин из НКВД?

(Ул НКВДданмы?)

*(Тынлык.)*

Шаталов, че молчишь-то?

(Ник дәшмисен, Шаталов?)

Яхно. Да, да, из Особого отдела. Есть такие отделы... И не говори громко.

(Әйе, әйе, Особый отделдан. Шундый отделлар бар... Кычкырып сөйләшмә.)

Шаталов. Разговорчики прекратить! Болтаете много.

(Тып-тын гына утырыгыз! Күп сөйләшәсез.)

Яхно. А че не поболтать-то?! Может быть, мы в последний раз вот так разговариваем.

(Сөйләшсәк ни! Балки без соңгы тапкыр сөйләшәбездер, бәлки бүтән насыйп булмас.)

*(Тәмәкесен Севрюгинга бирә. Севрюгин тирән итеп тарта башлый.)*

Рассуханов *(гел кавказ акценты белән сөйләшә).* Что ты хочешь сказать?

(Син ни әйтмәкче буласын?)

Яхно. А то, дорогой мой Асланбек Рассуханов, думается мне, что нас тоже "кукушками" сделают.

(Мин, калерле Асланбек Рассуханов туган, шуны әйтмәк булам: безне дә "күкеләр" итеп куярлар, ахрысы.)

Рассуханов. Как это?

(Ничек инде?)

Яхно. Посадят на макушки деревьев. И ежели вдруг роте придется отступать, то мы в тылу у финнов окажемся. И должны будем финнов поодиночке на мушку брать.

(Агач башларына менгезәчәкләр. Әгәренки ротабызга чигенергә туры килсә, без финнәрнең артында калачакбыз. Һәм финнәрне берәм-берәм мушкага алып утырырга тиеш булабыз.)

Севрюгин. Говорят, эти финские снайперы все из гражданского населения.

(Фин снайперлары хәрбиләр түгел,

гражданский халыктан ди, дөрес микән?}

Яхно. Я тоже слышал.

{Мин дә шулай дип ишеткән идем.}

Рассуханов *(уйга калып).* Мы же тоже из гражданского населения.

{Без дә армиягә кадәр гаскәриләр түгел идек.}

Севрюгин. Говорят, иногда целым батальонам голову поднять не дают.

{Хак булса, алар кайвакыт хәтта тулы бер батальонны жиргә сендерәләр, ди. Имештер, башны да калкыттырмыйлар.}

Яхно *(кинәт жанланып).* А правда, что за сбитие "кукушки" без разговоров дают орден Красного Знамени, а то и Героя?

{"Күке"не атып төшергән өчен берсүзсез Кызыл Байрак ордены белән бүләклиләр ди, хәтта Герой исеме дә бирүләре мөмкин дип ишеттем, хак сүз микән?}

Севрюгин *(бик хәбәрдар кеше кыяфәте белән).* Нет, за одного снайпера героя не дадут.

{Юк, бер снайпер өчен генә Герой исеме бирмәсләр.}

Шаталов *(каты һәм кырыс булырга тырышып).* Разговорчики!

{Сөйләшмәгез!}

Рассуханов. А ты, Шаталов, не знаешь, что делать будем?

{Ә син, Шаталов, безнең нишләргә тиеш икәнне беләсеңдер?}

Шаталов *(кырт кисеп).* Дождемся Зимина. Он все объяснит.

{Зимин килгәч бөтен йөкләмәләрне, бурычыбызны аңлатыр.}

*(Сигаретын сүндерә. Аның калган яртысын саклык белән кесәсенә тыга.)*

Севрюгин. Скорее всего, мы этих... ученых охранять будем.

{Минемчә, без теге галимнәрне сакларга тиеш булачакбыз.}

Яхно. Баллистиков, что ли?

{Теге баллистикларнымы?}

Севрюгин. Слушай, а что это они здесь хотят делать? Снаряды какие-то не такие...

{Карале, алар соң монда нишләргә жыеналар? Нииндидер гадәти булмаган снарядлар...}

Яхно. Наверно, новый тип снарядов хотят испытать.

{Яңа төрле снарядлар сынап карарга телиләрдер.}

Севрюгин. На финнах, что ли?

{Финнәргә атыпмы?}

Яхно. Нет, на нас.

{Юк, безгә атып.}

Шаталов *(ачуланып).* Разговорчики! Откуда про новый вид снарядов знаешь?

{Житте сезгә, лыгырдамагыз! Каян беләсең яңа снарядлар хакында?}

Яхно. Слышал.

{Ишеттем.}

Шаталов *(як-ягына карана).* Вот что я тебе скажу: держи язык за зубами, понял?!

{Син авызыңны чамалап ач, яме. Күп сөйләшмә, аңладыңмы?!}

Яхно. Понял.

{Аңладым.}

Шаталов. Зайнуллин!

Зариф. Я!

{Мин!}

Шаталов. Я обратил внимание, что ты один любишь по лесу гулять. Как свободное время появляется, ты где-то там бродишь, поешь...

{Мин шуңа игътибар иттем: син ялгызын гына урманда йөрергә яратасың. Буш вакыт чыгу белән берүзең каядыр читтә, жыр шыңшый-шыңшый, йөрисең...}

Рассуханов. Так он же в лесу родился, в лесу вырос.

{Ул бит урманда туып-үскән кеше.}

Шаталов. Я не с тобой разговариваю. Просто это опасно. Не только для Зайнуллина, но и для всех. Впредь никуда не отлучаться!

{Мин бит әле синең белән сөйләшмим. Аерылып читтә йөрү—куркыныч. Зәйнуллин өчен генә түгел, барыбыз өчен дә. Моннан соң читкә тайпылмаска!}

Зариф *(гел татар акценты белән сөйләшә).* Ладно.

{Ярар.}

Севрюгин. Не ладно, а "есть" надо отвечать.

{"Ярар" түгел, "есть" дип җавап бирергә кирәк.}

Яхно. Как тебя зовут?

{Исемең ничек синең?}

Зариф. Зариф.

Яхно. Меня Сергеем звать.

{Минеке—Сергей.}

Севрюгин. Зариф... *(Күзләрен чекрәйтеп.)* Странное имя.

{Зариф... Сәер исем.}

Зариф. А что странного в моем имени?!

{Нәрсәсе сәер минем атымның?}

Севрюгин. Впервые слышу.

{Монарчы ишеткәнем юк иде.}

Шаталов. Женат, что ли?

{Син өйләнгәнме?}

Зариф. Нет.

{Юк.}

Шаталов. А невестка-то осталась?

{Ә озатып калган кызың бармы соң?}

Зариф. Да.

{Бар.}

Шаталов. Ее как зовут?

{Аның исеме ничек?}

Зариф. Кашифа.

{Кәшифә.}

Севрюгин *(мыскыллы елмаю белән).* Ну и имена у вас. Язык можно сломать.

{Сезнең исемнәрне әйткәндә телне сындырырга мөмкин.}

Рассуханов *(ачулы тавыш белән).* Да, твой язык можно сломать, потому что он у тебя деревянный. Что ты к нему всегда пристаешь?

{Әйе, синең телең сынар да, чөнки син—агач телле. Нигә син аңа гел бәйләнәсен?}

Севрюгин. Ты че, поговорить, пошутить нельзя, что ли!

{Шаярып сөйләшергә дә ярамыймыни инде!}

Яхно *(тыныч кына).* А он татар не любит.

{Ә ул татарларны яратмый, куралмый.}

Севрюгин. Кто тебе сказал?

{Кем әйтте? Нидән чыгып әйтәсең әле моны?}

*(Ямьсез иттереп авызын кыйшайта.)* А вообще-то их есть за что не любить. Триста лет монголо-татарское иго было.

{Дөресен әйткәндә, аларны яратмаска житди сәбәп бар. Монгол-татар изүе өч йөз ел дәвам иткән.}

Яхно *(тавышын күтәрә).* Ты кончай. Это когда было-то?!

{Теленне тый. Ул бит инде әллә кайчан булган!}

Шаталов *(жикерә).* Разговорчики!

{Шаулашмагыз!}

Севрюгин *(зарланып).* Что разговорчики! Нас выделили и хотят какое-то серьезное задание дать. А людей-то подобрали не совсем совместимых!

{Шаулашырсың да! Безне аерып алдылар да ниндидер әһәмиятле эш кушмакчы булалар. Нишләп бер-беребезгә тәнгәл булмаган, үзара яраша алмаган кешеләрне сайлап алдылар!}

Рассуханов *(Севрюгинны өнәмәгәнен яшермичә).* Ты сам просто такой. Ты сам никого не любишь. Вот и ноешь сидишь. Чего тебе всегда не хватает?

{Син үзең шундый кеше. Син үзең беркемне дә яратмыйсың, барысын да куралмыйсың. Шуңа күрә сукранасың, шыңшыйсың. Нәрсә житми соң сиңа?}

Севрюгин. На серьезное задание надежных людей нужно посылать.

{Житди, әһәмиятле эшкә ышанычлы кешеләрне куярга кирәк.}

Зариф *(чак кына ишетелерлек итеп).* А из нас кто тебе не нравится?

{Безнең арадан кайсыбыз ошамый инде сиңа?}

Севрюгин *(кистереп әйтә).* Ты не нравишься!

{Син ошамыйсың!}

Зариф *(сабырлыгын жуймыйча тыныч кына сорый).* А что тебе во мне не нравится?

{Миндә синә нинди сыйфатларым ошамый?}

Севрюгин *(гасабиланып).* Людей сторонишься—вот что не нравится. С такими в одной группе патрулировать опасно.

{Кешеләрдән читләшәсең, аралашмыйсың—менә шул ошамый. Синең кебекләр белән бер патрульдә йөрү куркыныч.}

Зариф *(сабырлыгын саклап).* А еще кто-нибудь тебе здесь не нравится?

{Бу төркемдә тагын кемне өнәмисең?}

Севрюгин. Че пристал?!

{Ник бәйләнәсең?!}

Рассуханов. Он на меня подозрительно смотрит.

{Миннән дә шикләнә ул.}

Севрюгин *(тавышын күтәреп).* Да, угадал!

{Әйе, дөрес сизәсең!}

Рассуханов *(шулай ук тавышын бераз күтәреп).* За то что намаз читаю?

{Намаз укуым өченме?}

Севрюгин *(нәфрәтле тавыш белән).* Нет! За то, что еще недавно всем народом мятеж поднимали.

{Юк, намаз укуың өчен түгел! Күптән түгел бөтен халкыгыз белән фетнә күтәргәнегез өчен.}

Яхно *(Севрюгинның тик торганда кызып утыруын ошатмый).* А ты откуда знаешь?

{Ә син каян беләсең?}

Севрюгин. А у меня в Грозном родня живет.

{Грозный каласында минем туганнарым яши.}

*(Тәмәкесен ташлый. Төкерә.)*

Рассуханов *(кычкырмыйча, ләкин яман усал тавыш белән).* Я советую тебе не горячиться, а то ты у меня сейчас совсем остынешь.

{Мин сина кайнарланмаска киңәш итәм, юкса мин сине хәзер бөтенләй суытам.}

Севрюгин *(кычкырып диярлек).* А ты меня не пугай! Здесь больно-то кинжалом не помахаешь!

{Син мине куркытма! Монда алай бик хәнҗәр белән уңга-сулга селтәнә алмассың!}

Рассуханов *(үзен кулга ала).* Если бы сейчас не война, я бы тебе глотку перегрыз!

{Сугыш вакыты булмаса мин синең күптән инде бугазыңны чәйнәгән идем!}

Шаталов *(ни әйтергә белми).* Ну, что вы, ребята, в самом деле! Так не пойдет.

{Житәр инде, егетләр, сез нәрсә! Болай ярамый, болай булмый.}

Яхно *(Севрюгинга).* Послушай, ты... как тебя зовут, забыл?

{Карале, син... исемең ничек әле синең, оныттым?}

Севрюгин. Михаилом.

{Михаил.}

Яхно *(ачуланып).* Миша, ты, давай не кипятись. Не забывай, что ты на войне. Вот после войны приедешь к себе в Воронеж, и там матерись и кувыркайся сколько душе угодно. Ты себе врагов не наживай на пустом месте, понял.

{Миша, син алай нык кайнама, яме. Сугышта икәнеңне онытма. Менә сугыш тәмамлангач, Воронежыңа кайтырсың да, җаның күпме тели шул кадәре сүген, ызгыш, мәтәлчек ат—теләсә нишлә. Тик торганда үзеңә дошман җыеп йөрмә әле син монда.}

Севрюгин *(гаҗәпләнүле тавыш белән).* А че ты их защищаешь, сибиряк?!

{Син, Себер егете, нишләп әле аларны яклап утырасың?}

Шаталов *(җикерә).* Хватит! Вы уже мне надоели! Действительно, помоему не то отделение сформировали.

{Житте! Мин инде туйдым сездән! Чынлап та отделениене дөрес кешеләрдән төземәделәр, ахрысы.}

Яхно *(барысын да тынычландырасы килеп).* Да все нормально. Просто морозно, голодно, поэтому нервишки шалят.

{Әйбер-кара юк ла. Суык, тамак ач, шуна күрә нервылар бераз киеренкеләнде.}

Рассуханов *(тыныч кына)*. Зариф, не обращай на него внимания. И правда, у него нервы не в порядке.

{Зариф, син аңа игътибар итмә. Аның чыннан да нервылары рәтле түгел.}

Зариф *(барысы да чак кына ишетерлек итеп, ләкин инандырырлык куәткә ия тавыш белән әйтә)*. Он просто дурак!

{Җүләр ул!}

Севрюгин *(сикереп тора)*. Что ты сказал?!

{Нәрсә дидең?}

*(Тешләрен кысып Зарифка таба килә.)*

Зариф *(торып баса)*. Что слышал.

{Ишеткәнсеңдер бит нәрсә әйткәнемне.}

Севрюгин *(яман усал кыяфәт белән)*. Повтори.

{Кабатла.}

Зариф *(Севрюгинның кызуына бер дә аптырамыйча)*. Ты дурак!

{Син җүләр!}

Севрюгин. Да я тебя...

{Мин сине хәзер...}

*(Севрюгин йодрыгын төйнәп кизәнә. Зариф читкә тайпылып кала да, Севрюгинның аяк астына сугып җибәрә. Севрюгин әллә кая ук барып төшә. Беркавым тора алмый ята. Беркем дә Зарифтан мондый кыюлыкны һәм мондый җегәрне көтмәгән була. Шуңа күрә барысы да үз урынында катып кала.)*

Шаталов *(нишләргә белми, аптырагач кычкырып куя)*. Рядовой Зайнуллин!

{Рядовой Зәйнуллин!}

Севрюгин *(иягән капшый-капшый, көч-хәл белән яткан җиреннән тора да, кырыйда яткан кусәкне эләктереп алып Зарифка таба килә)*. Убью!

{Үтерәм!}

Яхно *(аны чалып ега һәм өстенә ята)*. Остановись! Нас и так, может быть, вот-вот убьют.

{Тукта! Аңына кил! Безне болай да менә-менә үтерүләре ихтимал.}

Зимин килә.

Шаталов. Строиться!

{Тезелергә!}

*(Барысы да кабаланып тезеләләр. Севрюгинга торып басырга ярдәм итәләр.)* Равняйсь! Смирно!

{Тигезлән! Үрә кат!}

Зимин. Вольно, вольно, товарищи бойцы! В честь чего драку устроили? Или перед боем с финнами между собой тренируетесь?

{Кирәкми, кирәкми, иркен торыгыз, иптәш кызыларміецлар! Нәрсә хөрмәтенә йодрык сугышы оештырдыгыз? Финнәр белән сугышыр алдыннан күнегүләр ясыйсызмы әллә?}

*(Сәгатенә карап.)* Шаталов! Сейчас вас накормят, потом явитесь ко мне поодному. *(Китә.)*

{Шаталов! Хәзер сезне ашатырлар, аннары берәм-берәм минем янга керерсез.}

Шаталов. Есть!

Яхно. Интересно, за драку накажут?

{Сугышканнары өчен егетләргә җәза бирерләр микән?}

Шаталов. Не знаю.

{Белмим.}

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Зимин үзенең землянкасында солдатларны берәм-берәм кабул итә.

Зимин *(кычкыра)*. Яхно!

Яхно керә.

Яхно. Товарищ капитан! Рядовой Яхно по вашему приказанию прибыл!

{Иптәш капитан! Рядовой Яхно сезнең боерык буенча килде.}

Зимин. Садись, Яхно! Покурим, давай.

{Утыр, Яхно! Әйдә, бер тартыйк.}

*(Папирос бирә.)*

Яхно *(Зимин каршысына утыра, папиросны ала)*. А можно я потом покурю. Я только что покурил.

{Мин соңрак тартсам ярыймы. Яна гына тарткан идем.}

Зимин. Конечно, можно.

{Әлбәттә ярый.}

*(Яхно папиросны бүрегенең колакчыны астына кыстыра.)* Ты у нас сибиряк?

{Син Себер егетеме?}

*(Елмая.)*

Яхно. Так точно. С Енисейска.

{Нәкъ шулай. Енисейскидан.}

Зимин. Красноярский край?

{Красноярск ягы?}

Яхно. Так точно.

{Нәкъ шулай.}

Зимин. Не знаешь, зачем выделили вас?

{Сезне ротадан ник монда аерып калдырдык, белмисенме?}

*(Серле караш белән Яхноны күзәтә.)*

Яхно. Никак нет, не знаю.

{Юк, белмим.}

Зимин. Финны перешли в наступление. Есть опасность остаться в окружении. У нас тут есть кое-что ценное. Вам предстоит патрулить вокруг наших складов. Заодно прочесывать. Разведчики финские, снайпера вокруг нас шуршат. А если финны серьезно пойдут в наступление, в случае окружения, придется все уничтожить самим.

{Финнәр һөҗүмгә күчте. Безгә чолганышта калу куркынычы яный. Монда безнең бик әһәмиятле складларыбыз бар. Базабыз тирәсендә патрульдә йөрерсез. Бер унайдан агачларны "капшау", куерак урыннарны тентү кирәк. Безнен тирәдә фин күзәтчеләре дә, снайперлары да күренгәли шикелле. Шуны да әйтә алам: әгәренки финнәр каты һөҗүмгә күчсәләр, базадагы бөтен нәрсәне үзебез шартлатып юк итәргә тиеш булабыз.}

Яхно. Что уничтожить?

{Нәрсәне юк итәргә?}

Зимин. То что находится на нашей базе. Чтобы врагу не досталось.

{Базадагы йөгебезне. Дошман кулына эләкмәсен өчен.}

Яхно. Понятно.

{Аңлашылды.}

Зимин *(тавышын әкренәйтеп)*. Я тебе все это откровенно сказал, потому что, как мне кажется, ты—среди всех самый надежный.

{Мин синең белән ачыктан-ачык сөйләшәм, чөнки сине биш кеше арасында иң ышанычлысы дип саныйм.}

Яхно *(гаҗәпләнеп)*. А с чего вы взяли, что самый надежный?

{Ә нишләп әле мине иң ышанычлысы дип уйлыйсыз?}

Зимин. Ты наполовину украинец?

{Син милләтең буенча—яртылаш украин.}

Яхно. Так точно.

{Нәкъ шулай.}

Зимин. Значит, кто-то из твоих предков из ссыльных или каторжан. Ты только не обижайся. А сибиряк из бывших ссыльных—это самый настоящий и крепкий сибиряк. И потом, ты хороший охотник, не так ли?

{Димәк, бабаңнарның берсе йә сөргенгә сөрелгән, йә каторжан булган. Син үпкәли күрмә. Бүгенге Себернең иң көчле кешеләре—сөргендәгеләрдән чыккан. Син бик яхшы аучы, шулай бит?}

Яхно *(аптырашта кала)*. Откуда вы все знаете?

{Сез каян барысын да беләсез?}

Зимин. Про что?

{Нәрсә турында?}

Яхно. Ну, про все.

{Бөтен нәрсә хакында.}

Зимин. Что охотник хороший—командир роты сказал. Остальное сам знаю. Я по долгу службы все про вас должен знать. И что ты настоящий парень—тоже знаю. Охотник он другим и не может быть.

{Яхшы мәргән икәнеңне рота командиры әйтте. Калганын үзем беләм. Минем вазифам шундый—сезнең турыда күп белергә тиеш.

Синең мәнә дигән нык егет икәнен дә мәгълүм. Аучы ул шундый була да.)

Яхно. Для охоты времени мало было. Я на лесосплаве работал. Сплавщик я.
(Ауга йөрергә вакыт аз тәтеде. Мин сал агызуда эшләдем. Сал куучы мин.)

Зимин. Поэтому ты такой мускулистый. В группе подобрались нормальные ребята?
(Шуна күрә беләкләрең таза синең. Группада әйбәт егетләр тупландымы?)

Яхно (*сагаеп*). Нормальные.
(Әйбәт.)

Зимин. Каково у них настроение? Пессимизма кто-нибудь высказывает?
(Аларның кәефләре ничек? Пессимизмга бирелүчеләр юкмы?)

Яхно. Никак нет, нормальные ребята!
(Юк, юк, андыйлар юк, әйбәт егетләр.)

Зимин. Ну, а на счет этой военной кампании что говорят? Ну, кто-нибудь высказывался, что мол, ненужная война и т. д. Не осуждают политику нашего правительства?
(Ә менә бу хәрби кампания турында ни диләр? Бу сугышның кирәге юк, тегеләйболай дигәнрәк фикерләр ычкындыручы юкмы? Хөкүмәтебезнең сәясәтен тәнкыйтьләмиләрме?)

Яхно. Никак нет!
(Юк!)

Зимин (*күзләрен кыса төшеп*). А что за ссора у вас возникла?
(Ә нинди низаг килеп чыкты сезнең анда?)

Яхно (*белмәмешкә салышып*). Никакой ссоры нет.
(Бернинди низаг та юк.)

Зимин (*елмая*). Ну, хорошо. Жалоб нет?
(Ярар алайса. Зарларың юкмы?)

Яхно. Никак нет!
(Юк.)

Зимин. Можешь идти.
(Ярый, чыксаң да була.)

Яхно (*сикереп тора*). Есть!

Зимин. Пусть зайдет Зайнуллин!
(Зәйнуллин керсен.)

Яхно. Есть! (*Чыгып китә.*)

Зариф керә.

Зариф. Товарищ капитан! Рядовой Зайнуллин по вашему...
(Иптәш капитан! Рядовой Зәйнуллин сезнең әмерегез буенча...)

Зимин (*якты елмаеп*). Кил, утыр.

Зариф (*Зиминның татарча сөйләшүенә гаҗәпләнә*). Вы...

Зимин (*акцент белән, вата-җимерә булса да, татарча сөйләшә*). Утыр, утыр. Тартасың киләме?

Зариф (*капитан каршына килеп утыра*). Никак нет... Юк. Мин тәмәке тартмыйм.

Зимин. Дөрес. Тартма. Мин беләм татарча... аз гына. Мин ЧОН составында басмачларга каршы сугыштым. Туркестанда. Мин чекист. Өйрәндем сөйләшергә. Сезнең телләр охшаган.

Зариф (*капитанның татарча белүенә сөенә*). Әйе. Төрки телләр бит.

Зимин (*ягымлы тавыш белән*). Хәлләр ничек?

Зариф. Әйбәт.

Зимин. Син яхшы мәргән диләр?

Зариф (*иңнәрен сикертеп*). Рас әйтәләр икән, димәк, яхшыдыр.

Зимин. Урман кешесеме син?

Зариф. Әйе.

Зимин. Командир роты сине отличный стрелок ди.

Зариф. Әйе, мин төз атам.

Зимин. Профессияң кем?

Зариф. Урман хуҗалыгындагы бригадада эшләдем мин. Урманны чистартып, үсентеләр утыртып, кыскасы урман караучы булып инде.

Зимин. Ник аерым группага алдырдык сезне, беләсеңме? (*Сынаулы караш белән Зарифны күзәтә.*)

Зариф. Бу тирәне сакларгадыр дип уйлыйм.

Зимин. Тәк, тәк... (*Кинәт сорап куя.*) Беркем дә кыерсытмыймы?

Зариф (*аптырап*). Юк!

Зимин (*елмая*). Син—аю. Сине җәберләргә куркыныч. (*Кыяфәте кинәт

*житдиләнә.)* Фронттагы обстановкадан канәгатьсезлек белдерүчеләр юкмы?

Зариф *(катгый итеп).* Юк!

Зимин *(тавышын әкренәйтә).* Ә мин Севрюгин канәгатьсезләнә дип ишеттем...

Зариф. Юк, ишеткәнем юк.

Зимин *(гаҗәпләнгән булып кылана).* А син аны паникерство өчен кыйнамадыңмыни?

Зариф *(бераз каушый).* Юк, юк. Ул миңа төрттереп, бәйләнеп сөйләште. Шуңа ачуым чыкты да... суктым. Виноват! Мин җавап бирергә әзер.

Зимин. Миңа синең кыю ихласлыгың ошый. *(Чак кына ишетелерлек тавыш белән.)* Син анда паникалы сүзләр сөйләүчеләр булса миңа әйт, яме. Гомумән, егетләрнең настроениеләрен күзәтебрәк йөр. Бу безнең җиңүебез өчен кирәк. Партиягә каршы... анда... Сталинга каршы берәр сүз әйтүче булмасмы. Син бит аңлыйсың, андый настроениеләр гаскәрне какшата.

Зариф *(ышанычлы һәм нык тавыш белән).* Безнең арада куркак кеше дә, тегенди-мондый әвеш-тәвеш кеше дә юк. Минемчә, без барыбыз да—сез үзегез сайлап алган кешеләр. Безнең арада паникерлар да, партиягә тел-теш тигезүчеләр дә юк.

Зимин *(ягымлы тонга күчә).* Әйе, әйе. Син мине дөрес аңла—сезгә ышанмаудан түгел бу сорауларым. Безнең объект бик әһәмиятле. Монда бик каты дисциплина кирәк. *(Кинәт Зарифның күзләренә карый.)* Минем кем икәнемне беләсеңдер бит?

Зариф. Беләм.

Зимин. Нинди отделдан икәнне?

Зариф. Так точно, беләм.

Зимин. Ничек уйлыйсың, финне җиңәбезме?

Зариф *(кыюланып).* Җиңәбез, иптәш капитан!

Зимин *(елмая).* Молодец! Бар.

Зариф. Есть! *(Кузгала.)*

Зимин. Анда әйт, Севрюгин керсен!

Зариф. Есть! *(Чыгып китә.)*

Севрюгин керә.

Севрюгин. Разрешите!
{Мөмкинме!}

Зимин. Заходи.
{Кер.}

Севрюгин. Товарищ капитан, рядовой Севрюгин по вашему приказанию прибыл.

{Иптәш капитан, рядовой Севрюгин сезнең фәрман буенча килде.}

Зимин. Садись, Севрюгин. Как дела?
{Утыр, Севрюгин. Хәлләр ничек?}

*(Севрюгинның бите жентекләп күзәтә.)*

Севрюгин. Да так... *(Урындыкка утыра.)*
{Әллә ничек шунда...}

Зимин. Как?
{Ничек?}

Севрюгин *(капитанның күз карашыннан шүрләп як-якка каранып куя).* Финны, говорят, наступают.
{Финнәр бик каты бастырып килә ди.}

Зимин *(сагаеп).* А кто это говорит?
{Кем әйтә моны?}

Севрюгин. Все говорят.
{Бөтенесе сөйли.}

Зимин *(кызып китә).* Не наступают они! Брехня это! Мы им скоро такой птичий базар устроим. Вся Скандинавия перьями покроется.

{Ялган! Финнәрнең каты һөҗүм өчен көчләре юк. Без аларга тиздән шундый кош базары оештырачакбыз—бөтен Скандинавия канат-мамык белән капланачак.}

*(Кинәт тынычлана.)* В роте какова обстановка, как думаешь?

{Ротаның рухи халәте ничегрәк, әйтә аласыңмы?}

Севрюгин *(артык житдиләнүдән борын тишекләре киңәя).* В самой роте то неплохо... И командир хороший... А вот... Вообщем, ну ладно...

{Ротаның үзендә начар түгел түгелен... Командир да әйбәт... Ә менә... Әй ярар сана...}

Зимин *(алга таба иелә төшеп).* Нет, нет, ты договаривай. В роте неплохо... А где плохо?

{Юк, юк, син әйтеп бетер, сүзеңне төгәлләп тәмамла. Ротада начар түгел... Ә кайда начар?}

Севрюгин *(гасабиланып).* Ладно,

скажу. А то точно, кроме меня никто не скажет. Вот группу выделили, вокруг этой базы патрулить. Пять человек. Из каких соображений таких людей подобрали, не понимаю?!

(Ярар, әйтәм инде. Алайса миннән башка беркем дә әйтмәс. Менә база тирәсен сакларга группа билгеләделәр. Биш кеше. Бу кешеләрне сайлаганда ни уйладылар икән, нинди исәптән чыгып билгеләделәр икән, һич анламыйм?!)

**Зимин.** Говори, говори...

(Дәвам ит, дәвам ит...)

**Севрюгин.** Я против воли командира роты, конечно, претензий иметь не должен, однако ж...

(Минем, әлбәттә, рота командиры фикеренә каршы претензиям булырга тиеш түгел, тик шулай да...)

**Зимин** *(ишетелер-ишетелмәс тавыш белән).* Так, так... Кто тебе не нравится в группе?

(Шуннан, шуннан... Төркемегездә кем ошамый сина?)

**Севрюгин.** Этот... Зайнуллин и...

(Теге... Зәйнуллин һәм...)

**Зимин.** И еще кто?

(Тагын кем?)

**Севрюгин.** Чеченец-то этот...

(Теге чечен...)

**Зимин.** Рассуханов?

**Севрюгин.** Так точно—Рассуханов.

(Нәкъ шулай—Рассуханов.)

**Зимин** *(күзләрен чекрәйтеп).* Интересно, что в них такого ты запреметил?

(Ни сәбәпле ошамыйлар икән алар сина?)

**Севрюгин** *(кырт кистереп).* Это ненадежные люди!

(Аларга ышанырга ярамый!)

**Зимин.** Почему? Потому что не русские?

(Ник? Урыс түгелләре өченме?)

**Севрюгин** *(нәфрәте йөзенә чыга).* Да нет... Черт с ними, что нерусские они... Этот Рассуханов намаз читает...

(Юк ла... Кадалып китсен урыс булмаулары... Мәсәлән, Рассуханов намаз укый...)

**Зимин.** Пусть молится, раз в Аллаха верит.

(Рас Аллага ышана икән, укысын.)

**Севрюгин.** Верующий человек, неизвестно, как может себя повести, когда врага встретит.

(Алай-болай дошман белән күзгә-күз очрашса, дини кеше үзен ничек тотар икән—билгесез.)

**Зимин.** Ты не лишен тонкости. А Зайнуллина за что невзлюбил?

(Син тирәнтен карый беләсен. Ә Зәйнуллинны ни өчен күралмыйсын?)

**Севрюгин** *(тәмам кыюланып китә).* Дикий он какой-то. Он же в лесу родился, в лесу вырос. Толком не общается. Во время перекуров уединяется, песню какую-то свою мурлычит. Мне кажется, группа должна быть компанейской, дружной и без странных людей.

(Кыргый бит ул. Урманда туган. Урманда үскән. Юньләп аралашмый. Мөмкинлек булган саен читкә тайпылып, үзе генә анлый торган жырлар жырлап йөри. Минем уйлавымча, группа бердәм, тату һәм сәер кешеләрсез булырга тиеш.)

**Зимин** *(серле итеп елмая).* А дрались сегодня с Зайнуллином по какой причине?

(Бүген Зәйнуллин белән сугышуынның сәбәбе нәрсәдә?)

*(Сынаулы караш белән карап тора.)*

**Севрюгин** *(ачу катыш аһ-зарлы тавыш белән).* Он ни за что ни про что меня ударил. Он дурной какой-то. Вот и ходи теперь с ним по лесу. Неизвестно, кто в тебя выстрелит—финский снайпер с ветки, или этот татарин сзади.

(Ул мина тик торганда китереп сукты. Ул жүләр бугай. Менә хәзер шуның белән урманда ничек йөрмәк кирәк. Хәзер инде белмәссен—сина агач ботагыннан фин снайперы атырмы, әллә арттан килеп шушы татар үтерерме.)

**Зимин** *(коры гына).* Ну, это ты лишку дал. Зайнуллин не из таких—он не будет стрелять из-за угла. Но в твоих соображениях есть кое-что правильное.

Молодец, что такой наблюдательный и переживаешь за судьбу группы. Кури.

{Алай артык шикчелләнмә инде. Зәйнуллин андый егет түгел, ул арттан атмаячак. Шулай да синең уйлануларыңда бераз хаклык та бар. Күзәтүчәнлегең һәм группаның язмышын кайгыртуың өчен рәхмәт. Тарт.}

(Папирос бирә.)

Севрюгин *(папиросын Зимин папиросыннан кабыза).* Будь моя воля, я бы их вообще в армию не брал.

{Ник армиягә алалардыр аларны, аңламыйм.}

Зимин *(күзләрен чекрәйтеп).* Кого?

{Кемнәрне?}

Севрюгин. Нерусских.

{Башка милләт кешеләрен, урыс түгелләрне.}

Зимин *(нотыклы тавыш белән).* Нет, Севрюгин, так нельзя. Если одни русские будут погибать на войне, то что же это получится. Ты с Воронежа, ты настоящий русский. Мне понятно твое настроение и все то, что ты сказал. Я этих людей подобрал, а не командир роты. Зайнуллин хорошо ориентируется в лесу, хороший охотник и отличный стрелок. Физически мощный.

{Юк, Севрюгин, алай мөмкин түгел. Сугышта гел урыслар гына үлсә нәрсә була инде ул. Син чын урыс, Воронеждан. Мин синең халәтеңне һәм ни әйтергә теләгәнеңне бик яхшы аңлыйм. Сезнең төркемне рота командиры түгел, мин үзем сайлап тупладым. Зәйнуллинның урманда ориентациясе шәп, оста мәргән, төз ата. Физик яктан да бик җегәрле.}

*(Севрюгинның иягенә карап елмаеп куя.)*

Севрюгин *(сабыйларча акланырга тотына).* Да если бы ребята не помешали, я бы его отлупил как следует.

{Егетләр аермаган булса, мин аны дөмбәсләп, изеп ташлый идем.}

Зимин. Ладно, ладно. Рассуханов—кавказец. Хорошо владеет кинжалом. Как кошка может незаметно подойти к противнику. И злости в нем много. Просто не надо с ним спорить. А воин он хороший. Ты—хороший лыжник. Очень нужный человек именно сейчас, в этих условиях. Ты, как я знаю, детей тренировал?

{Ярар, ярар. Рассуханов Кавказдан. Хәнҗәр белән оста сугыша. Мәче сыман шыпырт кына дошманның борын төбенә килеп чыга ала. Анарда явызлык та гаять көчле. Аның белән бәхәсләшмәскә генә кирәк. Шәп сугышчы ул. Син—менә дигән чаңгычы. Безнең хәзерге шартларда иң кирәк кешеләрнең берсе син. Белүемчә, яшь чаңгычылар тренеры булып эшләгәнсең?}

Севрюгин. Да, я детский тренер по лыжам.

{Әйе, мин чаңгы буенча балалар тренеры.}

Зимин. Яхно—крепкий сибиряк. Прекрасный охотник. Шаталов—одессит. Уже это о многом говорит. Физически выносливый. Мы специально выделили вас таких—сильных, выносливых.

{Яхно—Себердән. Оста аучы. Шаталов—Одессадан, димәк, бирешә торганнардан түгел. Бик чыдам егет. Без бит махсус менә шундый көчле, житез, чыдам егетләрне сайлап алдык.}

*(Тавышын әкренәйтеп.)* А что можешь про Яхно сказать?

{Ә Яхно турында син ниндирәк фикердә?}

Севрюгин. Он нормальный, но почему-то заступается всегда за этого татарина, и за того чеченца.

{Ул болай ярыйсы кебек, тик, никтер, һәрвакыт шул татар белән чеченны яклый.}

Зимин *(ягымлы тавыш белән).* Ну, и нормально. Все равно надо будет дружить. Думаю, все хорошо будет.

{Бик әйбәт. Сезгә барыбер тату булырга туры киләчәк.}

*(Сынаулы караш белән карап.)* А Шаталов чем не нравится?

{Ә Шаталов нәрсәсе белән ошамый сиңа?}

Севрюгин *(сискәнеп куя).* Да вы что! Он среди всех самый лучший. Вы не подумайте, не потому что он старшим назначен. Хороший мужик!

{Юк, юк, сез нәрсә! Арада ул иң яхшысы. Группаның җитәкчесе булганга әйтәм дип уйламагыз. Әйбәт мужик!}

Зимин *(тыныч кына).* Я тебе советую найти общий язык со всеми. Дело у нас общее. Охранять вы будете очень важный объект.

{Барысы белән дә уртак тел табарга киңәш

итәм. Без барыбыз да Кызыл армия солдатлары, безнең уртак вазифабыз, бер максатыбыз бар. Бик әһәмиятле, серле объектны саклаячаксыз.}

*(Пышылдап диярлек.)* Но тем не менее я тебя благодарю за некоторую наблюдательность. Иметь кое-какие сомнения—это тоже неплохо. Дружить необходимо со всеми, и со мной в том числе. Вижу—ты настоящий патриот. Ты будь наблюдательнее и запоминай, о чем говорят в группе, особенно пристальнее всмотрись в Рассуханова.

{Шулай да, кайбер нәрсәләрне игътибарсыз калдырмавың, күзәтүчәнлегең мактауга лаек. Шикләнү-икеләнү дә кайвакыт кирәк. Әмма барысы белән дә дус, тату булу мәслихәт, әлбәттә, минем белән дә. Күренеп тора, син—чын патриот. Тагы да игътибарлырак бул, төркемегездәге әңгәмәләрнең эчтәлеген исеңдә калдыр, бигрәк тә Рассухановны җентекләп күзәт.}

Севрюгин *(чак кына ишетелерлек итеп).* Хорошо.

{Ярар.}

Зимин. А так, об этой военной кампании Рассуханов не говорил ничего, не высказывал недовольств?

{Ә менә бу хәрби кампания хакында Рассухановның, канәгатьсезлек белдереп, кыек-мыек сүзләр ычкындырганы юкмы?}

Севрюгин. Высказывал. Ругал командование.

{Канәгатьсезлек белдергәне бар. Командованиене сүгә.}

Зимин *(алга таба иелеп).* Какое командование? Роты? Полка? Дивизии?

{Нинди командованиене? Ротаныкынмы? Полкныкынмы? Дивизиянекенме?}

Севрюгин. Вообще командиров. Мол, бездарные они все.

{Командирларны ачулана. Сәләтсезләр, булдыксызлар, ди.}

Зимин. Так, так... А Зайнуллин?

{Алай икән... Ә Зәйнуллин?}

Севрюгин. Тот вроде ничего такого не говорил... Он же молчит. Но ненадежный он.

{Анысы бигүк зарланмый бугай... Ул бит сөйләшми. Тик шулай да ышанычлы кеше түгел ул.}

Зимин *(тагын тыныч интонациягә күчә).* Ничего, ничего, помиритесь. Не деритесь больше. Еще впереди бои предстоят. Нормальная группа у вас.

{Ярар, ярар, татулашырсыз әле. Бүтән берберегезне кыйнамагыз. Алда әле канлы сугышлар күтә. Гомумән алганда группагыз начар түгел сезнең.}

*(Тавышын әкренәйтеп.)* Но ты все же подслушай о чем говорят, чем дышат... Понял?

{Төркемегездәге сөйләшүләрне дикъкать белән тыңла, кәефләрен күзәтеп тор... Аңладыңмы?}

Севрюгин. Так точно!

{Аңладым.}

Зимин. Можешь идти.

{Ярый, бар.}

Севрюгин *(урыныннан кузгала).* Есть!

Зимин. Позови Рассуханова!

{Рассухановны чакыр!}

Севрюгин. Есть! *(Чыгып китә.)*

Рассуханов керә.

Рассуханов. Товарищ капитан...

{Иптәш капитан...}

Зимин *(елмаеп каршы ала).* Проходи, садись, Аслан.

{Әйдә, уз, Аслан, кил, утыр.}

*(Кул биреп күрешә.)* К морозам привык?

{Салкыннарга күнектеңме инде?}

Рассуханов *(капитан каршысына килеп утыра).* Привыкаю. Валенок только вот нет.

{Күнегеп киләм. Киез итекләр генә бирмәделәр миңа.}

Зимин *(борчулы интонация белән).* Да, что-то там про валенки забыли. Понимаю, тебе труднее, чем другим. У вас в Грозном таких холодов не бывает...

{Әйе шул, киез итекләр турында, никтер, онытканнар. Аңлыйм, сиңа башкаларга караганда читенрәк. Сезнең Грозныйда мондый суыклар булмыйдыр...}

Рассуханов. Я с Гудермеса.

{Мин Гудерместан.}

**Зимин.** Ну, Гудермес с Грозным почти рядом.

{Гудермес Грозныйдан ерак түгел инде ул.}

*(Рассухановка игътибар белән карап.)* А еще какие жалобы есть?

{Тагын нинди зарларың бар?}

**Рассуханов.** У меня вообще жалоб нет. Насчет валенок я не жалуюсь, а просто говорю, что в валенках было бы теплее.

{Минем бөтенләй аһ-зарларым юк. Киез итекләр хакында да зарланып түгел, фәкать киез итекләр кисәк аякларыбыз туңмас иде, дип әйтүем генә.}

**Зимин** *(ягымлы тавыш белән)*. Да, конечно. Я очень рад, что в наших рядах находится представитель гордого и смелого кавказского народа. Конечно, там у вас еще сложностей много... Горные жители у вас с Советской властью не очень-то ладят... Ну, их же немного... Пострекатели, враги народа они везде и всюду есть. К сожалению, пока. Но есть у каждого народа вот такие орлы, как ты. Кем работал до армии?

{Әлбәттә шулай. Арабызда кыю һәм горур Кавказ халкының вәкиле булуга бик шатмын. Дөрес, сезнең әле анда катлаулы мәсьәләләр күп... Сезнең таудагы авыллар Сәвит власте белән бигүк килешеп бетмиләр, каршы торалар... Ләкин алар бит күп түгел... Котыртучы, коткы таратучы халык дошманнары бөтен җирдә һәм һәрбер милләттә бар инде алар. Кызганычка каршы, әлегә алар бар. Әмма дә ләкин һәр халыкның менә синең кебек асыл уллары да бар. Армиягә кадәр кем булып эшләдең?}

**Рассуханов.** Чабаном.

{Мин чабан.}

**Зимин** *(саклык белән генә сорый)*. Что на этой базе находится, знаешь?

{Бу базада нәрсә саклангынын беләсеңме?}

**Рассуханов** *(битараф тавыш белән)*. Не знаю. Мне никто не говорил.

{Белмим. Миңа беркем дә әйтмәде.}

**Зимин** *(кинәт сорап куя)*. Севрюгин достоин быть в вашей пятерке, как думаешь?

{Севрюгин сезнең төркемдә булырга лаеклымы?}

**Рассуханов** *(сорауларның берсенә дә аптырамый)*. Ну, если взяли, что вы у меня спрашиваете! Значит, достоен.

{Әгәр төркемгә алганнар икән, димәк, лаеклы. Ник аны миннән сорап торасыз!}

**Зимин.** В экстремальной ситуации не подведет?

{Экстремаль ситуациядә аңа таянып булырмы, ышанычлымы?}

**Рассуханов.** Не знаю. Мы недавно познакомились.

{Белмим. Без күптән түгел таныштык.}

**Зимин.** А как думаешь, почему он не смог Зайнуллину сдачи дать?

{Ничек уйлыйсың, нишләп ул Зәйнуллинга каршы торалмады? Нишләп җавап итеп иягенә берне бираламады?}

**Рассуханов** *(белмәмешкә салышып)*. Какой сдачи?

{Нәрсә биралмады?}

**Зимин.** Ну, когда они подрались.

{Сугышканда каршы тора алмады.}

**Рассуханов** *(аптыраган булып кылана)*. А что, они дрались, что ли? Я не видел. И никто не говорил мне, что они подрались.

{Алар сугышканнармыни? Күрмәдем. Аларның сугышканнарын миңа әйтүче дә булмады.}

**Зимин** *(кул селти)*. Ну, да, наверно, просто боролись, играли. Я хочу тебе сказать... Тебя здесь все очень уважают. Поэтому и ты будь со всеми пооткровеннее и дружелюбнее.

{Әй, ярар, бәлки болай гына, уйнап-шаярып көрәшүләре булгандыр. Мин сиңа шуны әйтергә телим... Сине монда бик нык ихтирам итәләр. Шуңа күрә син үзең дә башкалар белән дус бул һәм аларга ихлас белән кара.}

*(Елмая.)*

**Рассуханов.** Хорошо.

{Ярар.}

**Зимин.** Можешь идти.

{Бар.}

**Рассуханов.** Есть! *(Торып баса.)*

**Зимин.** Позови, пожалуйста, Шаталова!

(Шаталовны чакыр әле, яме!)

Рассуханов. Есть! *(Чыгып китә.)*

Шаталов керә.

Шаталов. Разрешите!
(Мөмкинме!)

Зимин. Да, да, пожалуйста.
(Әйе, әйе, рәхим ит!)

Шаталов. Товарищ капитан, рядовой Шаталов, старший выделенной группы по вашему приказанию прибыл.
(Иптәш капитан, рядовой Шаталов, билгеләнгән группаның башлыгы, сезнең фәрман буенча килде.)

Зимин. Садись, Ваня, поговорим. Куришь?
(Утыр, Ваня, гәпләшеп алыйк. Тәмәке тартасыңмы?)

Шаталов. Курю. Никак не могу бросить.
(Тартам. Һич кенә дә ташлый алмыйм.)
*(Капитан каршысына утыра.)*

Зимин *(папирос бирә)*. На войне особенно трудно бросить.
(Сугышта бигрәк тә авыр ташлавы.)

Шаталов *(папиросын кабыза)*. Да, вам лучше знать. Вы и до этого навоевались.
(Әйе, сез яхшырак беләсез. Сез бит моңарчы да сугышларда катнашкан кеше.)

Зимин *(авыр сулап куя)*. Было дело.
(Әйе, башына төшкәч, катнашасың инде ул.)
*(Кыяфәтенә борчылу төсе чыга.)* Ну что, Иван, ситуация тебе понятная? Доверие тебе оказано большое. К сожалению, подкрепления не видать. Короче, на произволе судьбы можем оказаться. Вам предстоит прочесать окрестность, поискать удобные места для этих снарядов. Здесь хранить их опасно. Ну а в случае окружения придется взорвать.
(Ну, нәрсә, Иван, ситуация сиңа аңлашыладыр дип уйлыйм. Сиңа гаять зур ышаныч күрсәтәбез. Кызганычка каршы, ярдәмгә өстәмә көч күренми дә көтелми дә. Сезгә базаның тирә-ягын тикшереп чыгу, бер уңайдан теге снарядларны яшерергә җайлы урыннар эзләү бурычы йөкләнә. Аларны хәзер монда яткыру куркыныч. Алай-болай чолганышта калсак, бөтенесен шартлатырга тиешбез.)

Шаталов. Что с этими учеными-то будете делать?
(Ә галимнәрне нишләтәбез?)

Зимин *(эченнән генә сүгенеп куя)*. Да какие это ученые! Просто специалисты по этим новым снарядам. Что с ними... Раздадим им по винтовке. Назад их отправлять бессмысленно. И потом приказано: быть здесь. И им тоже.
(Нинди галимнәр булсын алар! Шушы снарядлар буенча гап-гади белгечләр. Аларны нишләтәсең инде... Һәрберсенә винтовка тоттырырбыз. Аларны тылга озатып мәшәкатьләнеп йөрмәбез бит инде. Аннары, бөтенебезгә дә бер үк фәрман: монда булырга! Безгә дә, аларга да.)

Шаталов. Ясно.
(Аңлашылды.)

Зимин. Ребята как?
(Егетләр ничек?)

Шаталов. В каком смысле?
(Нинди мәгънәдә?)

Зимин. Устраивают тебя?
(Син егетләр белән канәгатьме?)

Шаталов *(капитанның күзләренә карамаска тырышып)*. Нормальные. Привыкнут друг к другу—все хорошо будет. До армии у меня в бригаде такие головорезы собрались. Я на заводе бригадиром слесарей работал. Со временем как одна семья работали.
(Әйбәт егетләр. Бер-беребезгә тәгаен ияләшкәч, тулы тәртип булачак. Армиягә кадәр мин заводта слесарьлар бригадиры булып эшләдем. Бригадамда коточкыч башкисәрләр җыйналган иде. Башта бик авыр иде, тора-бара тату, бердәм булып бер гаилә кебек эшләдек.)

Зимин. Но тут не Одесса, не завод и не слесарная бригада. Идет военная операция, как говорится, кампания... Хотя это настоящая война. Здесь, Ваня, люди друг к другу могут и привыкнуть, и, наоборот. Тем более, когда разные люди подобраны. Ты толковый парень, надеюсь, сможешь сколотить кулак.
(Әмма дә ләкин монда Одесса түгел, ә

слесарьлар бригадасы урынына солдатлар. Хәрби опреация бара, башкача әйткәндә, кампания... Ә дөресен әйткәндә, бу—чын сугыш. Монда, Ваня дус, кешеләр бер-берсенә бик якынаерга да мөмкин һәм киресенчә килеп чыгу да ихтимал. Рухи яктан бер-берсенә охшамаган кешеләр җыелган җирдә бигрәк тә. Син акыллы егет, төркемегездән бер каты йодрык оештыра алачагыңа минем иманым камил.}

Шаталов *(зарлы тавыш белән).* Товарищ капитан, а что, вместо меня офицера не могли найти, что ли?

{Иптәш капитан, минем урынга берәр офицер табылмадымыни?}

Зимин *(кырысланып).* Откуда?! Тыл далеко. Людей мало осталось. Откуда тут лишний офицер возьмется? Разве что с неба Рассуханов своими молитвами у Аллаха выпросит какого-нибудь старшего лейтенанта.

{Каян табарга соң аны?! Тыл ерагайды. Кешеләр аз, җитми. Каян монда артык офицер килеп чыксын? Шул Рассуханов үзенең догалары, намазлары белән Аллахтан берәр өлкән лейтенантны сорап алса гына инде}

Шаталов. Товарищ капитан, извините, но я не могу ему запретить читать молитвы.

{Иптәш капитан, гафу итегез, ләкин мин аңа намаз укыма дип әйтә алмыйм инде. Намаз укуны тыярга ярамый.}

Зимин. А и не надо. Пусть молится. Скажи откровенно: кто из этих четырех, на твой взгляд самый благонадежный?

{Юк, юк, рөхсәт бирергә кирәк. Укысын намазларын, догаларын. Ачыктан-ачык әйт әле: дүртесе арасында иң ышанычлысы, турылыклысы кем дип саныйсың?}

Шаталов *(уйга кала).* Ну, в роте я их уже знал хорошо...

{Ротада мин инде аларны яхшы белә идем...}

*(Пауза.)* Думаю, Яхно и Зайнуллин.

{Яхно һәм Зәйнуллин дип уйлыйм.}

Зимин. А остальные?

{Ә калганнары?}

Шаталов. Товарищ капитан! Я ответил просто как старший этой группы. Думаю, они все надежные, просто они разные. Не знаю почему, но от души я бы мог поговорить прежде всего с Яхно и Зайнуллиным.

{Иптәш капитан! Мин бу төркемнең башлыгы буларак кына җавап бирдем. Алар барысы да ышанычлы, гәрчә төрле холыклы булсалар да. Тик менә, белмим никтер, ихлас күңелдән мин иң әүвәле Яхно һәм Зәйнуллин белән сөйләшер идем шикелле...}

Зимин. Зайнуллин же нелюдимый и дикий!

{Зәйнуллин аралашмаучан, кыргый түгелме соң!}

*(Текәлеп карап җавап көтә.)*

Шаталов. Нет, он очень тонкой и доброй души человек. Просто к нему правильный подход необходимо иметь.

{Юк, ул нечкә күңелле, игелекле кеше. Аның белән сөйләшә белергә генә кирәк.}

Зимин *(җаваптан канәгать калып).* Кстати, командир роты Лебедев когда его рекомендовал, тоже очень хорошо отозвался. И Яхно тоже охарактеризовал только с положительной стороны.

{Сүз уңаенда, рота командиры Лебедев та тәкъдим иткәндә аңа бик яхшы бәя бирде.}

Шаталов. Ну, вот...

{Менә бит...}

Зимин *(кинәт сорый).* А за что Зайнуллин избил Севрюгина?

{Ә Севрюгинны Зәйнуллин ни өчен кыйнады?}

Шаталов *(елмаерга тырыша).* Да ерунда это, детские потасовки. Больше их не будет.

{Әй, кыйнау түгел, балаларча шаярып түбәләшү генә лә ул. Андый әүмәкләшүләр бүтән кабатланмас.}

*(Җитдиләнеп.)* Я постараюсь.

{Тырышырмын.}

Зимин *(кырыс тавыш белән).* Дисциплина прежде всего, Шаталов! Если вдруг не справишься—бегом ко мне!

{Ин мөһиме—дисциплина, Шаталов! Алай-болай сүзең үтмәсә, көчең җитмәсә, тартынма, шундук миңа йөгереп кил!}

Шаталов. Есть! Но, думаю, все будет в порядке.

{Есть! Аңа кадәре үк барып җитмәс, барысы да тәртиптә булыр дип уйлыйм.}

*(Папиросны сүндереп көл савытына сала.)*

Зимин *(тавышын әкренәйтеп)*. С Рассухановым как отношения?

{Рассуханов белән синең мөнәсәбәтләрең ничегрәк?}

Шаталов. Хорошие.

{Яхшы.}

Зимин. Не ругает Советскую власть?

{Сәвит властен сүкмиме?}

Шаталов. Никак нет. Ругается, что валенок нет.

{Юк, юк. Киез итек бирмәделәр дип кенә сукрана.}

Зимин *(елмая)*. Ну, что валенок нет, я сам тоже ругаюсь.

{Анысы киез итек бирмәгәннәренә мин үзем дә ачуланам.}

Шаталов. Да, худо без валенок.

{Әйе, киез итексез хәлләр начар монда.}

Зимин. Вас накормили?

{Сезне ашаттылармы?}

Шаталов. Так точно.

{Әйе.}

Зимин. Начинайте первый обход. Внимательно осмотрите все вокруг, все деревья. Вполне возможно, что финские снайперы находятся и здесь поблизости.

{Һәзер үк база тирәсен әйләнеп чыгыгыз. Урманның куерак урыннарын җентекләп тикшерегез, һәрбер агачны дикъкать белән күзәтегез. Фин мәргәннәренең бу тирәдә дә булулары ихтимал.}

Шаталов *(торып баса)*. Да, эти “кукушки” очень опасны.

{Әйе, ул “күкеләр” тынгы бирми, яман нәрсә булып чыкты “күке” дигәннәре.}

Зимин. Так вот, первый обход посвятите поимке “кукушек”.

{Менә нәрсә: беренче обходны “күке”ләрне эзләп табуга багышлагыз.}

Шаталов. Есть!

Зимин. У меня все. Вопросы имеются?

{Менә шул. Сорауларын бармы?}

Шаталов. Пока нет. Когда вернемся с обхода, думаю, появятся.

{Әлегә юк. Патрульдән кайтканда сорауларым булыр дип уйлыйм.}

Зимин. Хорошо. Как вернетесь, сразу ко мне!

{Ярый. Кайту белән үк минем янга кер!}

Шаталов. Есть. *(Кузгала.)* Разрешите идти!

{Китәргә рөхсәт итегез!}

Зимин. Идите. Спокойной вам “прогулки”!

{Барыгыз. Хәерле юл сезгә!}

Шаталов. Спасибо. *(Чыгып китә.)*

{Рәхмәт.}

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Карелия урманы. Бик салкын. Биш кешелек группа патрульдә йөри. Винтовкаларын кысып тотып, як-якка, агач башларына, куак араларына карый-карый әкрен генә баралар. Кайдадыр еракта бомбалар, снарядлар шартлавы ишетелә, пулемет тыкылдавы һәм винтовкадан аткан тавышлар яңгырап куя.

Яхно *(еракгагы тавышларга колак салып тыңлап тора)*. Совсем уже где-то рядом стреляют.

{Инде якында гына аталар.}

Севрюгин. Значит, финны наступают. Если бы наши наступали, то стрельба так близко не слышалась бы.

{Димәк, финнәр һөҗүмгә күчкән. Безнекеләр һөҗүм итсә ату тавышлары болай якын ишетелмәс иде.}

Шаталов *(гасабиланып)*. Разговорчики! И вообще, говорите шепотом.

{Лыгырдамагыз! Пышылдап кына сөйләшегез.}

Рассуханов *(кавказ акценты

*белән сөйләшә).* Да никого здесь нет. Сюда через линию нашей обороны они никак не могут проникнуть.

{Беркем дә юк монда. Оборона сызыгы аша монда кем үтеп керә алсын.}

Яхно. А ты, что, не слышал про их лыжные группы? Они где угодно и когда угодно могут появиться.

{Син аларның чаңгылы төркемнәре турында ишеткәнең юк мәллә? Алар теләсә кайсы тарафтан теләсә кайчан килеп чыга ала.}

Зариф *(гел татарча акцент белән сөйләшә).* Да тихо вы! Смотрите лучше по сторонам!

{Шыпырт кына барыгыз! Як-ягыгызга карагыз!}

Яхно. Страшно, Зариф?

{Куркасыңмы, Зариф?}

Зариф. А тебе?

{Ә сиңа куркыныч түгелме?}

Яхно. Есть чуть-чуть. Но на лучшее хочется надеяться. С нашей-то мощной армией разве их допустят до сюда?!

{Бераз бар. Ләкин ахыры хәерле булыр дип ышанасы килә. Шундый куәтле армиябез белән монда кадәр үк үткәрербез микәнни инде аларны?!}

Зариф. Я человек лесной. Но всегда лес для меня был самым спокойным местом, хоть и волков у нас много. Вот уж не думал, что буду остерегаться людей в лесу.

{Мин урман кешесе. Бездә бүреләр күп, тик шуңа кармастан минем өчен урман—иң тыныч мохит, иң имин дөнья иде. Менә болай урман уртасында ниндидер кешеләрдән куркып йөрермен дип уйламаган идем.}

Севрюгин. Ты на своих кулаками махать силен. А теперь что-то заговорил не по-храбрецки.

{Үзебезнекеләргә йодрыкларыңны селтәргә синең гаярьлегең бар. Ә хәзер менә, нишләптер, сөйләшүеңдә батырлык сизелми.}

Зариф. Не страшно мне, Севрюгин, нет. Просто задача у нас не совсем понятная, да и в положении мы в каком-то неопределенном.

{Юк, Севрюгин, миңа куркыныч түгел. Безгә йөкләнгән бурычны аңлап бетермим мин, аннары, без ниндидер аңлашылмый торганрак халәттә.}

Яхно. Это точно. Самое страшное—это неопределенность.

{Хак сүз әйттең. Билгесезлек—иң куркыныч нәрсә.}

Рассуханов. Хватит болтать! Зариф, ты сам просишь молчать, а сам громче всех заговорил.

{Җитте, сөйләшмәгез! Син, Зариф, үзең шыпырт булырга кушасың, ә үзең барыбыздан да катырак кычкырып сөйләшә башладың.}

Зариф. Молчу. Молчу. Все.

{Булды, булды. Сөйләшмим. Тын да чыгармыйм.}

Шаталов. Видите поваленное дерево? Там присядем, отдохнем. Сначала вокруг обойдем, на всякий случай.

{Әнә теге ауган агачны күрәсезме? Шунда утырып ял итәбез. Саклык йөзеннән башта тирә-якны тикшереп әйләнеп чыгыйк.}

*(Ауган агач кәүсәсе тирәсендәге куакларны, агачларны тикшереп килəләр.)*

Севрюгин. Миша, вытаскивай махорку.

{Миша, тәмәкеңне чыгар.}

Шаталов. Отставить! Курить нельзя!

{Отставить! Тартырга ярамый!}

Севрюгин. Это что, мы до базы так и не покурим?

{Без, нәрсә, базага кайтып җиткәнче бер тапкыр да тәмәке тартмаячакбызмы?}

Шаталов *(коры гына).* Потерпишь.

{Түзәрсең.}

Яхно *(як-ягына каранып).* Да, если бы не война, то места, конечно здесь красивые.

{Әлбәттә, бу якларда табигать искиткеч гүзәл, тик менә сугыш кына...}

Рассуханов *(уйчанланып).* Эти леса и так красивые, несмотря на войну.

{Сугыш булса да ямьле монда.}

Севрюгин. Небось, горы-то красивее?

{Тауларыгыз барыбер матуррактыр?}

**Рассуханов.** Все по-своему красиво.

{Табигать бөтен жирдә үзенчә гүзәл.}

**Шаталов** *(сагаеп)*. Слышите, волки завыли.

{Ишетәсезме, бүреләр улый.}

*(Бүреләр улаганы ишетелә.)*

**Севрюгин.** Здесь, наверно, много такого хищного зверья водится.

{Монда ерткыч жанварлар күптер.}

**Яхно.** Самый страшный хищник для нас сейчас—финская "кукушка".

{Безнең өчен хәзер иң яман ерткыч—фин "күке"се.}

**Шаталов.** Это точно. Волк хоть воет—услышать можно. А эта кукушка она даже и не кукует.

{Нәкъ шулай. Бүре ул ичмасам улый—ишетеп була. Ә бу күке хәтта кычкырмый да.}

**Рассуханов.** Немая кукушка, значит.

{Димәк, телсез күке.}

**Шаталов.** Нет уж, не немая она, коли может засадить пулю тебе промеж глаз.

{Юк инде, ике каш арасына атып тидерә алгач, телсез түгел инде ул.}

**Яхно** *(ачуы килеп)*. Кончайте страшные вещи рассказывать.

{Әллә нинди куркыныч нәрсәләр сөйләмәгез әле.}

**Севрюгин.** Винтовки у них, говорят, специальные, снайперские.

{Аларның винтовкалары да махсус снайперлар өчен ясалган ди.}

**Рассуханов.** Да, отчаянные люди эти "кукушки", если в тылу врага на деревьях сидят.

{Дошман тылында, агачта утырып калгач, димәк, үтә дә тәвәккәл нәрсәләр инде ул "күке"ләр.}

**Яхно.** Такие же люди должны быть. Приказали, вот и сидят там. Говорят, это смертники. То есть, они уже на верную погибель согласились и сидят стреляют, пока их не уничтожат.

{Гап-гади кешеләрдер инде. Утырырга фәрман биргәч утырмый кая барасың. Дөресен әйткәндә, алар бит үлемгә әзер, үзләрен атып төшергәнче утыралар да утыралар инде.}

**Севрюгин.** А у нас в армии есть кукушки?

{Безнең армиядә "күкеләр" бар микән?}

**Шаталов.** Снайперы-то есть. Но на ветках им незачем сидеть. Мы—мощная армия, мы их так разбомбим вместе с их кукушками и гнездами.

{Мәргәннәребез бар. Әмма безнекеләргә агач ботагында утыруның кирәге юк. Безнең бөек армиябез дошманны болай да тар-мар итеп, пыр туздырачак—бөтен күкеләре, оялары-ние белән.}

**Яхно** *(көлемсерәп)*. У кукушек вроде бы своих гнезд не бывает.

{Күкеләрнең үз оялары булмый бугай.}

**Зариф** *(авызын кыйшайтып)*. У финских, наверно, есть.

{Фин күкеләренеке, бәлки, бардыр.}

**Рассуханов.** Ты, Иван, говоришь—мощная армия... Валенки не могли дать.

{Армиябезне бөек дисең... Киез итекләр дә бирә алмадылар.}

**Севрюгин** *(чечен егетенә нәфрәт белән карап куя)*. Замучил своими валенками!

{Шул итекләрең белән тәмам саруны кайнаттың!}

**Яхно** *(авыр сулап)*. Костер бы разжечь.

{Учак якмыйбызмы?}

**Шаталов** *(боерыклы тавыш белән)*. Нельзя!

{Ярамый!}

*(Зариф көлеп куя.)*

**Рассуханов.** Че, Зариф, надо мной смеешься?

{Нәрсә, Зариф, миннән көләсеңме?}

**Зариф.** Нет, над собой. Севрюгин спрашивает: есть ли у нас в армии кукушки? А у меня кличка "кукушка". И у отца тоже. "Күке" по-татарски.

{Юк, үземнән көләм. Севрюгин безнең армиядә күкеләр бармы дип сорады. Минем бит кушаматым—"күке". Әтиемнеке дә.}

Шаталов *(кызыксынып)*. А за что такую кликуху-то дали?

{Ни өчен андый кушамат тактылар?}

Зариф. Отец, когда маленький был, услышал голос кукушки, пошел по лесу искать ее. И заблудился. Потом отца искали всей округой.

{Әтием бәләкәй чакта күке тавышын ишетеп, аны эзләп киткән һәм урман эчендә адашкан. Аннары әтиемне бөтен тирә-яктагы халык белән эзләгәннәр.}

Рассуханов. Нашли?

{Тапканнармы соң?}

Зариф. Нашли. Вот, с тех пор прозвали кукушкой.

{Тапканнар. Шуннан соң аны "күке" дип йөри башлаганнар.}

Яхно. Интересно.

{Кызык.}

Шаталов. А у тебя, Миша, прозвище было какое-нибудь?

{Миша, ә синен берәр кушаматын бармы?}

Яхно. Было, но не скажу. А то постоянно дразнить будете. А у тебя у самого?

{Бар, ләкин әйтмим. Алайса үртәп интектерәчәксез. Ә синен үзеннең бармы соң?}

Шаталов. "Боцман" моя кличка. Из-за того, что отец был боцманом. И потом, я то фуражку его на улицу вынесу, то бинокль старый. Иногда наряжусь его старьем и выхожу во двор. Вот и заслужил кличку.

{Минем кушаматым—"боцман". Әтием боцман булганга. Бала чакта анын фуражкасын киеп, иске биноколен күтәреп йөри идем. Кайвакыт киемнәрен киеп ишегалдына чыга идем. Бөтенесе көләләр иде. Шулай итеп, "боцман" кушаматын тактылар да куйдылар.}

Зариф. Аслан, а у вас есть клички.

{Аслан, ә сездә кушаматлар бармы?}

Рассуханов. Нет, у нас только у собак есть клички.

{Юк, бездә этләрнең генә кушаматлары бар.}

*(Тын калалар.)*

Шаталов. Ну, ты сказанул! Выходит, Зариф и я—сродни собакам.

{Син бигрәк инде! Зариф белән мине этләргә тинләвенме бу?}

Рассуханов. Нет, я это не хотел сказать.

{Юк, мин алай димәдем.}

Яхно. У Севрюгина, наверно, сильная кличка была.

{Севрюгинның кушаматы көчле булгандыр.}

Севрюгин *(канәгатьсезлек белән)*. А почему у меня сильная кличка должна быть?

{Нишләп әле минем көчле кушаматым булырга тиеш?}

Яхно *(елмаеп)*. Ну, у тебя и фамилия звучная.

{Синең бит фамилияң дә янгыравыклы.}

Севрюгин *(үпкәләгән сыман итеп)*. Не было у меня никогда клички.

{Минем беркайчан да кушаматым булганы юк.}

Яхно *(үчекләп)*. У вас там вблизи Воронежа ни озер, ни рек, ни морей. Откуда у тебя такая фамилия—Севрюгин?

{Воронеж тирәсендә күлләр дә, елгалар да, диңгезләр дә юк. Каян килгән сина Севрюгин дигән фамилия?}

Севрюгин *(пафос белән)*. Там у нас все есть!

{Бездә бөтен нәрсә бар.}

Яхно *(күзләрен чекрәйтеп)*. А клички имеют только хорошие люди. В народе говорится, что к нехорошему человеку и прозвище не пристает.

{Әйбәт кешеләрнең генә кушаматы була. Начар кешегә кушамат та йокмый дигән сүз бар.}

*(Көлә.)* Не обижайся, Сережа, че ты такой взвинченный и обидчивый!

{Үпкәләмә, Сережа, ник шул кадәре ярсулы соң син!}

Севрюгин *(читкәрәк борылып)*. Не обижаюсь я. "Боцман"—ладно. А "кукушка"—это что, хорошая кличка, что ли?! Между прочим, кукушка птенцов своих не высиживает, бросает в чу-

жих гнездах. И вообще у русских много поверья на счет кукушки. И по-моему ни в одном из них кукушка счастье не приносит.

{Үпкәләмим мин. "Боцман" дигән кушаматны анлыйм, ярыйсы гына янгырый. Ә "күке", нәрсә, әйбәт кушаматмы инде?! Беләсегез килсә, күке үзенең балаларын да үстерми, күкәйләрен башка кошлар оясында калдыра. Урыс халкында күке турында бик күп әйтемнәр, ышанулар бар һәм аларның берсендә дә күке бәхет китерми.}

Шаталов. Например, какие поверья?

{Мәсәлән, нинди ышанулар, әйтемнәр беләсең?}

Севрюгин. У нас говорят: если кукушка летает по деревне, то это к пожару.

{Бездә болай диләр: әгәр күке авыл буйлап очып йөри икән, янгын чыгасын көт тә тор.}

Яхно. А че это кукушка по деревне должна летать, она в лесу должна летать. И потом, почему это именно кукушка тебе счастье должна принести?

{Ә ни сәбәпле күке авылда очып йөрергә тиеш, ул бит урманда оча. Анннары, нишләп әле сина нәкъ менә күке бәхет китерергә тиеш?}

Шаталов. Погоди, погоди. Еще что говорит народ про кукушку?

{Туктале, туктале. Халык тагын нәрсә әйтә күке хакында?}

Севрюгин. Вообще, кукушка, кукующая после Петрова дня—не к добру: к пожару, к неурожаю, падежу скота. "Когда кукушка линяет, пусть хозяйка бережет яйца." Или вот еще: "Если весною кукушка в первый раз "окуккает" прямо в глаза—на весь год слезы."

{Питраудан соң күке кычкырса—яхшыга түгел: йә пожар чыга, йә игеннәр уңмый, йә терлек, кош-корт үлә. "Әгәренки язда күке йонын коя икән, тавык салган йомыркаларны сакларга кирәк. Тагын мондые бар: "Язын күке күзгә карап кычкырса, ел буена күз яшең кипмәс."}

Яхно. Ты просто все плохое о кукушках собираешь. Бабушка мне говорила: "Если весной ты услышишь первую кукушку справа, удача будет сопутствовать тебе, если слева—удача покинет тебя на весь остаток года." И еще: "Услышишь кукушку справа—загадай желание и оно исполнится."

{Әй, син үзең күкеләр турында гел начар ырымнар гына җыйгансың. Әбием әйтә торган иде: "Яз көне беренче күке тавышын уң яктан ишетсәң, елың уңышлы булыр, әгәренки сул яктан кычкырса—елың тынгысыз узар." Тагын болай әйткәне бар: "Күке тавышын уң яктан ишетсәң шундук теләгеңне әйт һәм ул кабул булыр."}

Шаталов. А ты, Зариф, че молчишь? У самого кликуха "кукушка", а сам не защищается.

{Зариф, ә син нишләп дәшмисең? Кушаматың "күке" булгач, әйдә, үз-үзеңне якла.}

Зариф. У нас говорят: "У рано прокукававшей кукушки после голова болит". Между прочим, все люди у кукушки спрашивают сколько им жить осталось.

{Бездә: "Алдан кычкырган күкенең башы авырта",—диләр. Дөньяда күпме яшәячәген бөтен кеше күкедән сорый, бу тикмәгә түгелдер.}

Шаталов *(йөзен караңгылатып).* Да, финская кукушка прокукует один раз, значит, самое многое одна минута осталась.

{Шулайдыр... Фин күкесе бер "күкелдәп" куйса, димәк, сиңа, иң күп дигәндә, бер минут яшисе калган.}

Рассуханов *(ачуланып).* Шутка не командирская у тебя.

{Командир шаяруы мондый булырга тиеш түгел.}

Зариф. А у вас, Аслан, что о кукушках говорят?

{Аслан, сездә күкеләр хакында ниләр сөйлиләр?}

Рассуханов *(гасабиланып).* Что, вам больше не о чем разговаривать, что ли?! Зачем вам эти кукушки!

{Бүтән сөйләр сүзегез юкмыни соң сезнең?! Нигә кирәк сезгә ул күкеләр!}

Севрюгин. Правильно. Что-то у нас все темы к финским снайперам тянутся.

{Әйтмә дә! Сүзне нидән генә башласак та, барыбер фин снайперлары хакында тәмамлана.}

Шаталов. Прошу прощения, я тоже вспомнил одно поверье про кукушку. "Ранняя кукушка (прежде листа на дереве) ворам неудача."

{Гафу итегез, мин дә күке турында бер ырымлы әйтемне исемә төшердем. "Агач яфрак ярганчы кычкырган күке каракларга хилафлык китерә".}

*(Барысы да көләләр.)*

Яхно. Одессит же. И поверье у тебя по-одесски.

{Одесситның әйтеме дә одессача инде аның.}

Шаталов *(татлы елмаеп)*. Ах, как я по Одессе соскучился. Вы тоже все скучаете.

{Их, Одессамны ничек сагынганымны белсәгез иде. Сез дә сагынасыздыр туган якларыгызны.}

*(Монсулана.)* Но мне вдвойне тягостнее, наверно. Вы все неженатые. Все это впереди у вас. А у меня жена и двухлетний сын там остался.

{Тик миңа күпкә авыррактыр. Сез әле берегез дә өйләнмгән, гаиләгез юк. Ә минем хатыным, ике яшьлек улым бар.}

*(Кинәт үтә җитдиләнә.)*

Зариф. Ничего, скоро разобьем финнов и разойдемся по домам. Думаю, это долго длиться не может.

{Борчылма, тиз арада финнәрне тар-мар китерәбез дә, өйгә кайтабыз. Бу матавык озакка сузылырга тиеш түгел.}

Рассуханов. Ну да. Надеялись за пару недель справиться. Замерзаем уже второй месяц.

{Ай-һай, белмим. Ике атна эчендә җиңәбез дип тотынган идек... Икенче ай инде туңып-өшеп ятабыз.}

Севрюгин. А ты хотел чтобы как на курорте было?

{Курорттагыча булыр дип уйлаган идең мәллә?}

Яхно *(җикереп)*. Ну что ты опять поперек начинаешь встревать! Слова, что ли, нельзя сказать!

{Нәрсә син тагын аркылыга сөйләшә башладың, ә! Һич бер сүз әйтергә ярамый!}

Шаталов. Не орите! Вас, наверно, за километр слышно.

{Акырышмагыз! Тавышыгыз әллә кайларга ишетеләдер, мөгаен.}

Яхно *(тавышын әкренәйтеп)*. Слышь, Иван, а что ты слышал про эту 44-юу дивизию?

{Карале, Иван, син теге 44-нче дивизия турында ишеттеңме?}

Шаталов. Про какую?

{Нинди дивизия соң ул?}

Яхно. Которая в окружение попала и почти полностью погибла.

Кто чудом смог выйти из окружения, тех сразу НКВД арестовал.

{Чолганышта калып тулысынча диярлек һәлак булган дивизия. Бик аз кеше исән калган ди. Чолганыштан чыкканнарны НКВД кулга алган.}

Шаталов *(кырыс тавыш белән)*. Нам нельзя много знать!

{Безгә артык күп белергә ярамый.}

Яхно. Говорят обвинили во всем командира дивизии... Виноградов, кажется фамилия... Его, по закону военного времени, перед строем расстреляли.

{Дивизия командирын... Фамилиясе Виноградов бугай... Гаскәр алдына алып чыгып атканнар.}

Севрюгин. Это кто тебе такие подробности докладывал?

{Син боларны каян беләсен?}

Яхно. Слышал. В роте говорили. Я же не ты! Слух имею и немного ума. А ты все ходишь и на каждого обижаешься, придираешься ко всем по пустякам. А что творится на фронте—тем ты не интересуешься.

{Ишеттем. Мин бит син түгел! Колагым да яхшы ишетә, акылым да бар. Ә синен күзең тонган: берни ишетмисен, анламыйсын. Бөтен кешегә бәйләнеп, үпкәләп йөрисең. Фронттагы хәлләр белән бер дә кызыксынмыйсың.}

Севрюгин. Иван тебе сказал: много нельзя знать... Это может тебе боком обернуться.

{Сина Иван әйтте бит инде: күп белергә ярамый. Бәлага тарыкмагаен.}

Яхно *(кызып)*. Что ты на всех все время сердишься? Вот за что ты на меня-то обижаешься?

{Ник син һәрвакыт тыпырчынасың? Мена мина нигә үпкәлисен?}

С е в р ю г и н *(тыныч кына).* Не сержусь я. И не обижаюсь на бестолковых людей.

{Тыпырчынмыйм мин. Үпкәләмим дә—бигрәк тә мингерәү кешеләргә.}

Ш а т а л о в. Вот я смотрю на вас и жутко становится. Вы—бойцы Красной Армии. Перед нами задача: бить белофиннов во имя безопасности Родины. Партия, Товарищ Сталин, весь советский народ оказал нам великую честь—обезопасить северные рубежи родной страны. А вы ведете себя как малолетние дети. И разговорчики у вас, действительно, бестолковые. Посерьезнее надо быть!

{Менә мин сезгә карап-карап торам да, күңелгә шик-шөбһә кереп урнаша. Сез—кызылармеецлар. Туган илебез безгә ак финнәрне тар-мар итәргә куша. Партиябез, иптәш Сталин, барлык сәвит халкы тарафыннан безгә абруйлы бурыч йөкләнде—Ватаныбызның төньяк чикләрен дошманнан азат итәргә! Ә сезнең кыланмышларыгыз бала-чаганыкыннан да болайрак. Сөйләшүегезнең бөтенләй мәгънәсе юк. Кайда нишләп йөрүегезне ниһаять аңлап бераз житдирәк, акыллырак булу мәслихәт!}

Р а с с у х а н о в. Если людям не дать поговорить и пошутить, в таком темном лесу с ума можно сойти.

{Сөйләшмәсәң, шаярышмасаң, бу карурманда тәмам акылдан язарга мөмкин.}

Ш а т а л о в *(ачуы килә башлый).* Рассуханов, так ты не согласен с тем, что я сказал?

{Рассуханов, димәк, син мин әйткәннәр белән килешмисең, шулаймы?}

Я х н о. Не горячись, командир, обещаем—будем посерьезнее.

{Ярсыма ла, командир, акыллырак, житдирәк булырга тырышырбыз.}

С е в р ю г и н *(Шаталовка ялагайланып).* Нет, пусть Рассуханов ответит: согласен он с тем, что сказал Иван?

{Юк, менә Рассуханов жавап бирсен әле: Иванның әйткән сүзенә ул каршымы, юкмы?}

Р а с с у х а н о в *(усал тавыш белән).* Когда меня таким тоном спрашивают, мне не хочется отвечать.

{Мондый тон, мондый тавыш белән бирелгән сорауга мин жавап бирмим.}

С е в р ю г и н *(кызып китә).* Ты злой, потому что не успел скрыться в горах, чтобы в армии не служить.

{Мин синең усаллыгыңның сәбәбен беләм. Армиядән котылыр өчен таугa менеп кача алмый калганыңа шундый әшәке син.}

Р а с с у х а н о в *(нәфрәтле тавыш белән, ләкин үзен кулга алып).* Зато я никому задницу не лизал и не буду, как ты.

{Аның каравы, мин синең шикелле беркемнең дә артын яламадым һәм яламаячакмын.}

С е в р ю г и н *(иптәшләренең һәрберсенә карап чыга).* Ничего себе! Ты что себе позволяешь?!

{Карале моны! Син ни әйткәнеңне чамалыйсыңмы?!}

Ш а т а л о в *(боерыклы тавыш белән).* Прекратите! Опять до драки дело дойдет!

{Житте! Тагын сугышырга тотынасыз бит инде!}

С е в р ю г и н *(тешләре арасыннан ысылдап).* Ты еще пожалеешь о том, что сказал.

{Син әле әйткән сүзләреңә үкенәчәксең.}

З а р и ф *(барысын да тынычландырырга тели).* Ваня, послушай, здесь все правильно понимают политику партии, и с тем, что ты сказал, все согласны. И Аслан тоже.

{Ваня, без һәммәбез дә партиябезнең сәясәтен дөрес аңлыйбыз, синең белән дә килешәбез. Аслан да сиңа һич кенә дә каршы түгел.}

Я х н о. Да, мы так скоро перегрыземся между собой. И волков не надо будет, и кукушки не потребуются.

{Без, чынлап та, тиздән бер-беребезнең бугазына ябышачакбыз. Бүреләрдә, күкеләрдә түгел, үзебездә дошман утыра икән.}

Ш а т а л о в. Кончайте ребята грызть друг друга. Да, неопределенность она, конечно, сильно давит. Но это не значит, что мы между собой бодаться должны. Придем на базу, успокоимся, отдохнем. А сейчас, давайте-ка, по баночке тушенки откроем!

{Егетләр бер-берегезне "ашамагыз", зинһар. Мин аңлыйм, билгесезлек авыр

нәрсә—тынгы бирми. Ләкин бер-беребез белән сөзешүдән хәлебез жинеләймәячәк. Тиздән базага әйләнеп кайтабыз, ял итәрбез, тынычланырбыз. Ә хәзер, әйдәгез, берәр банка тушенка ачыйк та тамак ялгап алыйк!}

Севрюгин. Давно пора.
{Күптән кирәк иде инде.}

Зариф. Вот это—дело.
{Әйдәгез.}
*(Барысының да кәефләре күтәрелә.)*

Рассуханов. Может быть, ругаемся из-за того, что голодные?
{Бәлки карыннарыбыз ач булганга ызгышабыздыр.}

Яхно. Может быть.
{Бик ихтимал.}
*(Тушенка банкаларын ачалар.)*

Зариф *(күтәренке рух белән)*. Да никто не ругается... Что уж...
{Ызгышумыни инде ул... Артык күпертмик инде...}

Шаталов. Рассуханов, опять только хлеб будешь есть?
{Рассуханов, син тагын ипи генә ашыйсыңмы?}

Рассуханов. Тушенка из свинины. Нельзя мне. Мне хлеба больше дайте.
{Тушенкада дуңгыз ите. Миңа харам ризык ашарга ярамый. Шуңа күрә миңа ипине күбрәк бирегез.}

Зариф. Я уж после войны... после демобилизации не буду тушенку есть... И намаз буду читать.
{Мин инде сугыш беткәч... демобилизациядән соң тушенка кебек нәрсәләрне ашаудан туктармын. Намаз да укыячакмын, Алла боерса.}

Шаталов *(ашый-ашый сөйләшәләр)*. У татар ведь вера тоже мусульманская?
{Татарлар да мөселманнармы?}

Зариф. Да.
{Әйе.}

Яхно. А мечети у вас есть?
{Мәчетләрегез бармы соң?}

Зариф. Почти не осталось. *(Тынлык.)* Все хорошо будет!
{Мәчетләр бик аз калды инде, кызганычка каршы.}
*(Тынлык.)* Все хорошо будет!
{Рәтләнер әле барысы да... мәчетләр дә, тормыш та...}

Шаталов *(кәефе күтәрелгәнне барысына да күрсәтеп)*. Если Зариф говорит, значит, нормально будет. Ты молодец, Зариф! Ты настоящий мужик. Главное, что в тебе ценю я: ты психуешь только когда это необходимо. А так твоей выдержке позавидовать можно.
{Зариф әйткәч, барысы да тәртипкә керер киләчәктә. Маладис син, Зариф! Синең иң яхшы сыйфатың шул: син бик кирәк чакта гына тузынасың. Ә болай синең тотнаклыгыңа, чыдамлыгыңа сокланмый мөмкин түгел.}

Рассуханов. Нас еще в настоящем бою никто не проверял.
{Безне әле чын сугышта сынап карамадылар.}

Шаталов. А тогда, возле речки два дня отстреливались. Что, разве не настоящий бой? Это хороший урок, и там уже видно было кто на что способен.
{Күптән түгел генә, елга буенда, ике көн оборона тоттык. Чын сугыш түгелмени ул? Безнең өчен зур сынау булды ул, анда инде кемнең кем икәнлеге ачык күренде.}

Рассуханов. Финны в окопе, и мы в окопе. Друг друга не видим. Стреляем куда-то в их сторону. Это не настоящий бой.
{Финнәр дә окопта, без дә окопта. Бер-беребезне күрмибез. Каядыр алар ягына атып ятабыз. Чын сугыш шундый була димени.}

Яхно. А настоящий бой что, по-твоему?
{Ә чын сугыш ул, синеңчә, ничек булырга тиеш?}

Рассуханов. Настоящий бой—это когда видишь глаза противника. И он вооружен, и ты вооружен. Решают мгновения—или ты, или он.
{Дошманыңның күзләрен күргәндә генә чын сугыш була ул. Ул да кораллы, синең дә коралың бар. Күз карашлары очраша. Шунда бер мизгел хәл итә—йә син исән каласың, йә ул.}

Шаталов. Ну, Аслан, здесь несколько другие условия, чем на Северном Кавказе.

{Аслан дустым, монда сина Төньяк Кавказ түгел, монда шартлар башка төрлерәк.}

Севрюгин. Фин он не допустит, чтобы ты ему в глаза заглядывал.

{Фин сина үзенең күз карашын күрсәтеп тормас.}

*(Көләләр.)* Это барану, когда его режешь, можно в глаза посмотреть.

{Сарык суйганда гына ул бичара хайванның күзен күреп була.}

*(Көләләр.)*

Зариф. Ты смотри, настроение поднялось.

{Карале, кәефләр күтәрелеп китте.}

*(Киерелеп куя.)*

Яхно *(банка төбен кашык белән кыра).* Это тушенка свое дело делает.

{Тушенка шулай итә ул.}

Севрюгин. Эх, покурить бы.

{Их, тәмәке көйрәтеп алырга иде.}

Шаталов. Потерпи. До базы совсем уже недалеко.

{Түз. Базага кайтып җитәбез бит инде.}

*(Торып баса.)* Короче, ребята, встать! Попрыгали!

{Егетләр, кузгалыгыз! Сикергәләп алыйк!}

*(Сикергәләп ала. Егетләр теләр-теләмәс кенә утырган урыннарыннан торалар.)* Идем до базы, встречаемся с Зиминым...

{Базага кайтып, Зиминны күрергә кирәк.}

Рассуханов. Потом?

{Аннары?}

Шаталов. Зимин скажет, когда следующий обход. Думаю, ночью еще раз придется пройтись.

{Киләсе обходка кайчан чыгасыбызны Зимин әйтер. Төнлә тагын бер тапкыр әйләнеп чыгарга кирәк булыр дип уйлыйм.}

*(Винтовкаларын иңнәренә асып кузгалалар.)*

Зариф. А кроме нас еще кто-нибудь будет патрулировать?

{Бездән башка тагын кем дә булса патрульгә чыгачакмы соң?}

Шаталов. Вряд ли. Людей нет.

{Юктыр. Кешеләр җитми.}

Яхно. Спать-то когда-нибудь будем, наверно?

{Кайчан да булса йокларбыздыр бит?}

Шаталов. Да, когда-нибудь, наверно, будем.

{Кайчан да булса бәлки йокы тәтер.}

Севрюгин. А мороз-то все крепчает. Сорок градусов есть поди?

{Тагы да катырак суытты түгелме. Кырык градус бардыр?}

Яхно. Тридцать пять где-то...

{Утыз биш тирәсе.}

Шаталов. Но на днях обещают сорок пять-пятьдесят градусов.

{Киләсе көннәрдә кырык биш-илле градус көтелә ди.}

Яхно. Ни хера себе!

{Бетәбез икән!}

Шаталов. Перезиму-у-уем!

{Чыдарбыз әле ничек тә.}

*(Урман эченә кереп югалалар. Каяндыр урман караңгылыгыннан Зарифның тавышы ишетелә.)*

Зариф. Шаталов! Товарищ командир!

{Шаталов! Иптәш командир!}

Шаталов. Что?

{Нәрсә?}

Зариф. Я ножик оставил. Разреши сбегать. Подарок невесты.

{Ашаган урында пәкемне онытып калдырганмын. Тиз генә барып килим әле. Кызның бүләге бит.}

Шаталов *(шулай ук урман эченнән).* Сбегай. Мы пока пойдем. Догонишь нас. Окоченели уже. Идти надо.

{Бар. Без кайта торабыз. Куып җитәрсең. Тәмам күшектек бит инде. Тизрәк кайтып җитәргә кирәк.}

Зариф. Я быстренько.

{Мин җәһәт кенә барып киләм.}

Зариф ял иткән урынга йөгереп килә. Пәкесен шактый вакыт эзли. Ниһаять таба

һәм чиксез сөенеп пәкене чалбар кесәсенә тыгып куя. Шуннан соң куен кесәсеннән кульъяулыкка төрелгән рәсемне ала. Чишеп карый.

Зариф *(рәсемгә карап).* Кәшифә. Чак кына югалтмадым син биргән пәкене. *(Елмая. Рәсемне кульъяулыкка төреп кесәсенә тыга. Як-ягына карана.)* Урман—урман инде ул! *(Кинәт кәефе күтәрелә, иркен итеп сулыш ала. Шуннан соң якындагы агач ботагына винтовкасын элеп куя да, ауган агачның җайлырак урынына утырып күнитеген сала һәм ыштырын җайлап янадан урарга тотына. Җырлый. Чын күңелдән, рәхәтләнеп татарча җырлый. Саклык турында да онытып иркенләп җырлый. Сугышта икәнлеген дә онытып җырлый.)*

Татар халык җыры
**"Иске кара урман".**

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк лә үтәргә;
Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым куш каен,
И-и, аерылмаек, дускаем.
Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк дөнья күтәргә.
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар усак,
И-и, аерылмабыз дус булсак.

Кара да гына елан, ай, туз башлы,
Йөридер лә камыш буенча;
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым куш каен,
И-и, аерылмаек, дускаем.
Ялгыз гына башым, юк юлдашым,
Йөримен лә язмыш буенча;
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар усак,
И-и, аерылмабыз дус булсак.

Зариф икенче күнитеген салгач аның артындагы агачлар арасыннан иелә-иелә фин солдаты килеп чыга. Аның киеме яртылаш кына хәрби. Фин солдаты икәнне аның бүрегеннән, кокардасыннан, каешыннан һәм коралыннан белеп була. Бәйләнгән свитер өстеннән җылы тун кигән. Ул шыпырт кына барып Зарифның винтовкасын ала һәм иненә аса, үзенең винтовкасын исә Зарифка төбәп әкрен генә аңа таба атлый. Зариф бу вакытта әле һаман җырлый һәм фин солдатын күрми дә ишетми дә. Фин солдаты бер урында басып катып кала һәм гаҗәпләнеп аның җырлавын тыңлый. Җыр тәмамланганчы фин солдаты Зарифның артында тыңлап басып тора. Әле күнитекләрен кигәч тә Зариф җырлап утыра.

Кара да гына урман, караңгы төн,
Нинди юллар белән үтәрбез?
Карурманны үткән чакта
Кисеп алдым куш каен,
И-и, аерылмаек, дускаем.
Дус-иш белән бергә эш иткәндә
Теләкләргә тизрәк җитәрбез.
Карурманны үткән чакта
Кисеп алдым пар усак,
И-и, аерылмабыз дус булсак.

Җырлап туктагач, Зариф артында кемнеңдер басып торуын сизеп ала. Әкрен генә башын винтовкасын элгән агачка таба бора. Винтовкасы юклыгын күргәч сикереп тора да, артында торучы фин солдатына алды белән борылып баса. Винтовкасын төбәп торучы фин хәрбиен күргәч Зариф тораташ булыпката. Ул нишләргә белми. Күз кырые белән тирә-яктагы ботакларга, таякларга карый—ничек тә булса дошманны бәреп егу җаен чамалый. Шул ук вакытта фин аны шундук атып үтерер дә төсле тоела. Бәлки әсир итеп алып китәр дип тә уйлый.

Уйлар өере курку хисе белән катыш үрелеп аны баскан урынына, гүя, бәйләп куя. Фин телендә сорау бирсә ничек аңлармын, дип уйлый ул. Урысча белмидер инде. Ә бәлки беләдер... Менә хәзер атып җибәрер дә, бөтен дөнья караңгылыкка төшеп китәчәк. Кәшифә аның һәлак булуын белерме-юкмы? Әти-әни ничек кичерер бу кайгыны? Бу уйлар яшен тизлегендә чигә аша сызгырып үтеп тордылар. Бу кадәре ваемсыз, саксыз булырга ярыймы инде! Ничек инде үземне коралсызландырырга ирек бирдем шушы чандыр гына фингә?! Югыйсә мин аны бер сугуда үтерә алам бит... Фин солдаты бер сүз дәшми карап тора. Зарифка сәер тоела—фин солдаты бернинди нәфрәтсез, хәтта елмаеп карап тора шикелле. Аңарда бернинди дошманлык юк сыман, киресенчә, дустын очраткан сыман елтырый күзләре. Әй, бу шулай тоела гына... Кызылармеецны әсир иткәнгә сөенә. Моның өчен командиры аны бүләкләр. Берәр медаль бирер, отпускыга кайтарыр. Фин солдаты винтовкасын төбәгән килеш Зарифка таба атлый. Зарифның җаны-тәне буенча калтырану тагын бер дулкын булып уза һәм бөтен вөҗүденнән тир бәреп чыга. Ләкин көтмәгәндә төшләрдә генә була торган хәл килеп чыга. Фин солдаты ап-ак тешләрен күрсәтеп шундый якты итеп елмая һәм... татарча эндәшә.

Ф и н *(елмая).* Шәп жырлыйсын! *(Үзе һаман Зариф алай-болай каршылык күрсәтмәсен дип винтовкасын төбәп тора.)*

З а р и ф *(ялгыш ишеттем микән әллә дип уйлап куйды).* Ә?

Ф и н *(чын күнелдән сокланып).* Матур жырлыйсын, туган!

З а р и ф *(каушаудан ни әйтергә белми).* Мин... пәкемне онытып калдырганмын.

Ф и н . Мин сине шул пәкенне кесәнә тыгып куйган моментта инде атып үтерергә әзерләнгән идем. Курокка басам гына дигәндә жырлый башладын.

З а р и ф *(финнен татарча сөйләшүе бераз хәл бирә).* Сездә жырлап торган кешене атмаска дигән приказ бар мәллә?

Ф и н . Дошманны атып үтерә алам, ләкин татар жырына ата алмыйм мин.

З а р и ф . Кем сон син?

Ф и н . Фин солдаты. Үзем теләп кулга корал алган кеше мин.

З а р и ф . Татарча сөйләшәсен... Әллә син дә төрекмән басмачыларына каршы сугыштынмы?

Ф и н *(көлемсерәп).* Син әсир төшкәч тә шаярасын... Ошыйсын син мина.

З а р и ф . Урыс кешесенен татарча сөйләшкәнен ишеткәнем бар, ә менә фин кешесенен татарча сөйләшүен беренче мәртәбә ишетүем. Хәер, гомумән финнәрне минем плакатларда гына күргәнем бар.

Ф и н . Мин сине очратуыма бик шат.

З а р и ф *(басынкы тавыш белән).* Сине әсир итсәм мин дә шат булыр идем.

Ф и н . Пәкен калганмы? *(Зур кызыксыну белән Зарифны күзәтә.)*

З а р и ф . Әйе. Пәкем калган. Ни... Карел урманында татарча сөйләшүче кеше килеп чыгар дип уйламаган идем. Синен кыяфәтен дә татарныкына охшаган.

Ф и н . Мин бит чып-чын татар!

З а р и ф . Алайса син мине атмассын инде.

Ф и н *(елмаеп).* "Кара урман"ны болай әйбәт жырлаучыны атмыйм инде мин.

З а р и ф *(ни уйларга белми).* Хәзер алып китәсенме мине?

Ф и н . Әлбәттә.

З а р и ф . Кая?

Ф и н . Үзебезнен якка. Син Татарстаннанмы?

З а р и ф . Әйе.

Ф и н *(көлә).* Кызык, кызык! Татар кешесен очраттым! Әле жырлап утыра!

З а р и ф . Син финнәр ягына чыккан кеше мәллә?

Ф и н . Алай мине үпкәләтүен ихтимал.

З а р и ф . Юк, юк, минем сине үпкәләтәсем килми. Сине үпкәләтү мина зыян гына китерәчәк. Татар кешесе... Карале, юри фин формасын киеп разведкага йөрисендер... Кайсы полкныкы син?

Ф и н . Мин сорау алырга тиеш синнән. Мин бит сине кулга алдым. Мин Финляндияне СССР агрессиясеннән саклаучы. Сездә ополченец диләр безнен кебекләрне. Мин Финляндиядә яшәүче татар.

З а р и ф . Ә-ә-ә. Минем ишеткәнем бар иде фин татарлары турында.

Ф и н . Мин фин татары түгел, Финляндиядә яшәүче татар.

З а р и ф . Ничәү сон сез анда?

Ф и н . Без анда бик күп.

З а р и ф . Анлашылды. Сез, татарлар Советлар Союзына каршы сугышасызмыни?

Ф и н . Финляндия безнен туган илебез. Аны саклау, анын бәйсезлеге өчен сугышу—безнен бурычыбыз.

З а р и ф . Берүзен монда нишләмәкче буласын? Бер-ике кешебезне үтерерсен дә, үзен харап булачаксын бит.

Ф и н . Ялгышасын. Без урман тутырук. Барыбер без жинәчәкбез!

З а р и ф . Син Финляндиядә туып-үстенмени?

Ф и н . Әйе.

З а р и ф . Без икебез дә татар кешеләре. Бер кинәш биримме?

Ф и н . Тынлыйм.

З а р и ф . Син мине хәзер атып үтерсән, безнекеләр ишетеп килеп житәчәкләр һәм сине тотачаклар. Син мине жибәр. Мин синен турыда беркемгә дә әйтмәм.

Ф и н . Юк, мин сине жибәрмим. Үзебезнен якка алып китәм.

З а р и ф . Сина минем өчен герой исемен бирмәсләр барыбер.

Ф и н . "Герой" нәрсә дигән сүз әле ул?

З а р и ф . Каһарман.

Ф и н . Юк, мина каһарман исеме кирәк түгел. Мин сине финнәр ягына алып чыгам. Финляндиядә син кешеләрчә яши башлаячаксын. Син ул СССРда кол халәтендә яшисен, синен

туйганчы ипи ашаганың да юк бит.

Зариф. Аңламадым.

Фин. Мин сине үзебезнең якка алып китәм. Финнәр татарларны бик ихтирам итәләр, ышан миңа.

Зариф *(ялварулы тавыш белән)*. Җибәр син мине.

Фин *(көлә)*. Юк, болай шәп җырлагач алып китәм мин сине үзебезнең якка.

Зариф. Ә мин теләмәсәм?

Фин. Теләмәсәң теләмисең инде. Мин бит сине әсир төшердем.

Зариф. Татар кешесе буларак җибәрә аласың бит инде...

Фин. Финляндиядә син үзеңне кешеләрчә хис итәчәксең.

Зариф. Кызык кеше син. Финляндиядә совет власте урнашкач мин ничек җавап тотармын?

Фин. Анда беркайчан да Совет власте урнашмаячак. Без сезне барыбер җиңәбез! *(Винтовкасын икенче иненә асып куя.)*

Зариф. Димәк, син "Күке"?

Фин. Кем?

Зариф. Син.

Фин. Нинди "күке"?

Зариф. Син снайпермы?

Фин. Әйе.

Зариф. Без сезне "күке" дип атыйбыз. Урысча "кукушка". Менә, ике "күке" очраштык. *(Елмаерга тырыша.)*

Фин *(усал кыяфәт белән)*. Әйе, ишеткәнем дә, укыганым да бар. Әйе, безне сәвитләр шулай атыйлар, агач башларыннан атканга күрә. Әмма арттырып сөйлиләр: имеш, фин снайперлары, ягъни "күке"ләр, гел агач башында утырып шарт-шорт атып торалар. Пропаганда өчен, мескенрәк итеп күрсәтер өчен күбрәк сөйлиләр шулай дип. Ярар, "күке" дип атасыннар. Әмма без агач башында гына утырмыйбыз, кайдан җайлы шуннан атабыз. Һәм безне беркем мәҗбүр итми.

Зариф. Рәхмәт, миңа атмаганың өчен.

Фин. Һәй, туган, әйтәм бит, татар җырына ата алмыйм мин. Шул татар җыры безне Җир шарының әллә кай тарафларында саклады да инде.

Зариф. Анысы дөрес.

Фин. Димәк, "күке" дип үртисез безнең снайперларны?

Зариф. Мин гомерем буе "күке" кушаматы белән йөрим әле.

Фин. Исемең ничек?

Зариф. Зәйнуллин Зариф Хәбибрахман улы. "Күке Зарифы" дип тә йөртәләр.

Фин *(көлә)*. Нәрсә, син дә агач башыннан кешеләр үтереп йөргән идеңме әллә?

Зариф. Юк. Әтиемнең кушаматы ул.

Фин. Мин Галиәкбәр улы Зыятдин булам. Бабам Якуб, сәүдәгәр буларак, дөнья гизгән. Финляндиядә куыш корган. Минем хәтта әтием дә инде Финляндиядә туган.

Зариф. Татар телендә яхшы сөйләшәсең. Барыгыз да шулаймы?

Фин. Әйе. Син Татарстанның кайсы төбәгеннән?

Зариф. Син Татарстанны белмисеңдер.

Фин. Һәрхәлдә үзебезнең нәсел чыккан якларны беләм—бабам сөйләве буенча, әлбәттә.

Зариф. Сез дә чыгышыгыз буенча Татарстаннанмыни?

Фин. Бабам ягыннан Татарстанныкы, әбием ягыннан Нижгарныкы. Бабай Нижгар кызына өйләнгән.

Зариф. Бабаң ягыннан чыгышың Татарстаннанмы чынлап та?!

Фин. Әйе, Субай авылыннан минем бабам.

Зариф *(шакката)*. Субайдан?! Мин дә бит шуннан. Субайның үзеннән түгел, бер чакрым арада гына урман хуҗалыгыннан. Бәрәкәт урман хуҗалыгыннан.

Фин *(таң кала)*. Чын әйтәсеңме?!

Зариф *(шатлык белән)*. Минем яратып йөргән кызым Субайдан. Анда Актүбә, Тоба, Каенлы, Иманле авыллары бар әле...

Фин *(илһамланып)*. Әйе, әйе, минем ул авыллар турында ишеткәнем бар. Димәк, без әле синең белән якташлар да. Бәлки туганнардыр да?

Зариф *(җанлана)*. Бәлки. *(Кул биреп күрешәләр.)*

Зыятдин *(ихлас күңелдән)*. Ай-яй матур җырлыйсың. Бу бит халык җыры— "Кара урман".

Зариф. Әйе. Халык җырларын да беләсең, ә!

Зыятдин. Әле сез белмәгәнне дә кайчак беләбез без. 1913 нче елда Мәскәүдә "Мандолина" исемле ноталы җыр китабы чыкккан иде. "Кара урман җыры"нда анда мондый юллар да бар. *(Җырлый.)*

Кара гына урман, ай, артыннан
Болыт кына килә, ай, күкрәп;
Карурманнан чыккан чакта,
Атым керми елгага,
Эх, берлек кирәк дөньяда.
Заманалар авыр, михнәтләр күп,
Күтәрә лә, ай, калын ла күкрәк;
Карурманнан чыккан чакта,
Атым керми елгага,
Эх, берлек кирәк дөньяда.

Зариф *(гаҗәпләнеп һәм сокланып)*. Карале, син үзең дә бик моңлы җырлыйсың.

Зыятдин. Чөнки без якташлар. *(Рәхәтләнеп көләләр.)*

Зариф. Өстәвенә икебез дә күкеләр. *(Җитдиләнеп).* Зыятдин, син миңа гомеремне бүләк иттең бит.

Зыятдин. Ташла! Татар җыры саклап калды сине! *(Зарифны иңеннән кагып.)* Киттекме безнең якка?

Зариф. Юк, Зыятдин! Әйдә, безнең якка! Барысын да аңлатырбыз. Синең тамырларың Татариядә икәнне исбатлап булыр.

Зыятдин. Ни сөйлисең син?!

Зариф. Ватанына кайтасың килмимени?

Зыятдин. Минем Ватаным икенче тарафта, Зариф. Дөресен әйтәм, минем сине җибәрәсем килми. Тик әсир буларак түгел. Якташым, кан кардәшем, җырдашым буларак якын син миңа. *(Зарифның винтовкасын бирә.)* Мә.

Зариф *(винтовкасын алып)*. Хәзер мин атырмын дип курыкмыйсыңмы? Яки әсир итәрмен дип?

Зыятдин. Юк, курыкмыйм. *(Ерактагы тавышларга колак салып тыңлап тора.)* Ишетәсеңме, фронт ягыннан гөрселдәүләр ишетелә. Сезнекеләр һич кенә дә "Маннергейм сызыгы"н үтә алмыйлар. Хәлегездән килмәячәк тә. Кан коела. Бер кирәксезгә, сезнең җуләр канәчкеч Сталиныгыз аркасында күпме кеше харап була.

Зариф *(кинәт ачуы кабара)*. Син алай сөйләшмә инде! Якташ дип тормам.

Зыятдин. Мин хаклы түгелмени?!

Зариф *(шундук үзен кулга ала һәм тынычлана)*. Күңелем, ничектер, тынычланып куйды әле. Шушы канкоешта кара урманда ике татар очрашсын әле. Бер-берсенә мылтык төзәсәләр дә, гаҗәеп күренеш бит бу! Мин һаман ышанып җиталмыйм әле. Зыятдин, хушлашыйк. Рәхмәт сиңа! Безнекеләрнең мине эзләп килеп җитүләре ихтимал. Сине аннары җырлап кына коткарып булмаячак. *(Китәргә әзерләнәләр.)*

Зыятдин *(инде киттем дигәндә генә)*. Ә син бу җырны беләсеңме?

Зариф. Кайсы?

Зыятдин. Менә моны... *(Татар халык җырын җырлый башлый.)*

Зариф. Нишләп белмәскә! *(Зариф та аңа кушылып җырлый.)*

Татар халык җыры.

Йөгердем, җиталмадем лә,
Сикердем читәннәрен;
Ни булгандыр телләремә -
Сау бул дип әйталмадем.

Урманнарда йөргән чакта
Адаштым юлларымны;
Күңелем нечкә—җыларммын дип,
Сузмадым кулларымны.

Кинәт төрле яктан, винтовкаларын төбәп, Шаталов, Яхно, Рассуханов, Севрюгин килеп чыгалар.

Шаталов *(бик кычкырмыйча гына)*. Бросай оружие!
(Ташла коралыңны!)
*(Зыятдин белән Зариф сискәнеп китәләр.)*

Яхно. Не понятно, что ли, оружие бросьте!
(Аңлашылмый мәллә, коралларыгызны ташлагыз!)

Зыятдин. Нәрсә диләр?

Зариф. Винтовкаларны ташларга кушалар. *(Зыятдин винтовкасын агачка сөяп куя да берничә адым артка чигенә.)*

Севрюгин. А ты, урод, не понял?! Фин понял, а ты нет?! Сука! Бросай винтовку!
(Ә син, үләксә, аңламадыңмы һаман?! Фингә барып җитте, ә сиңа юк! Сука! Ташла винтовканы!)

Шаталов. Тихо, не ори! Брось винтовку, Зайнуллин!
(Ул хәтле акырма! Зәйнуллин, читкә ташла винтовканы.)
*(Зариф винтовкасын ташлый.)*

Яхно. Руки вверх!

{Кулларыгызны күтәрегез!}

Севрюгин. Руки вверх сказано было!

{Кулларыгызны күтәрегез, диделәр сезгә!}

*(Зариф кулларын өскә күтәрә. Аңа карап Зыятдин да кулларын күтәрә.)*

Шаталов. Рассуханов, обыщи финна! Ты, Яхно,—Зайнуллина! Севрюгин, будь начеку, чтобы со стороны еще кто-нибудь не подошел!

{Рассуханов, финне тенте! Син, Яхно, Зәйнуллинны тентеп чык! Севрюгин тирәякны күзәтеп тор!}

*(Зыятдин белән Зарифны тентиләр. Зыятдинның пистолетын, үткен пычагын һәм зажигалкасын алып Шаталовка бирәләр.)* Документы и другие предметы заберите пока себе!

{Документларын, калган әйберләрен үзегезгә алып торыгыз!}

*(Яхно Зарифның кесәсендәге әйберләрне, Рассуханов Зыятдинныкын ала.)*

Яхно *(чыраен сытып)*. Аслан, на, засунь к себе в карман, не хочу я в свой карман вражьи вещи совать.

{Аслан, мә, кесәнә тык, үземнең кесәмдә дошман әйберләрен йөртәсем килми.}

*(Зарифның кесәләрендәге вак-төякне Рассухановка бирә.)*

Рассуханов. Давай.

{Бир.}

*(Ике татарның да әйберләрен алып үзенең кесәләренә урнаштыра.)*

Севрюгин *(тешләрен кыса-кыса)*. Песенки поете, да! Дерьмо! Кукушки ... мать вашу! Разрешение попрошу и сам застрелю обоих!

{Жырлар жырлап утырасызмы! Бук! Күкеләр... анагызны сатыйм! Рөхсәт алам да икегезне дә шәхсән үзем атып үтерәм, паскудалар!}

Шаталов. Тихо, не шуми. Отойди.

{Тынычлан, шаулама! Читкәрәк кит.}

*(Зарифка.)* Где обучался финскому?

{Фин телен кайда, кайчан өйрәндең?}

Зариф *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Я не знаю финского.

{Мин финчә сөйләшә белмим.}

Яхно. А на каком пели, разговаривали?

{Ә нинди телдә жырлап, сөйләшеп утырдыгыз?}

Зариф. На татарском.

{Татарча.}

*(Кинәт җанлана. Иптәшләренә аңлата алырмын дип өметләнә.)* Ребята! Я вам все объясню. Он меня видел, и не стал стрелять в меня, понимаете...

{Егетләр! Иптәшләр! Мин сезгә хәзер барысын да аңлатам. Ул мине күреп торган... Ләкин ул миңа атмады... аңлыйсызмы...}

Яхно *(таләпчән тавыш белән)*. А ты почему не выстрелил в него?

{Ә син үзең аңа ник атмадың?}

Зариф *(өзгәләнеп)*. Ну, он же не убил меня, зачем я его буду убивать.

{Ул бит мине мөмкинлеге була торып та үтермәде, шулай булгач ничек инде мин аны үтерергә тиеш.}

Севрюгин. Почему в плен не взял?

{Ник әсир итмәдең?}

Зариф. Это он сзади подкрался и взял меня в плен.

{Ул үзе арттан килеп мине әсир итте.}

Зыятдин *(Зарифка борылып)*. Син мине әсир иттем дип әйт, яме. Алайса харап итәләр сине. Мине әсир иттем дип әйт.

Яхно *(сүгенеп)*. Ну-ка, кончай там по-своему бубнить!

{Әй, үз телегездә мыгырдаудан туктагыз!}

Шаталов. Да! Будете переговариваться, по затылку будете получать. Все! Пошли. Яхно, сзади пойдешь. Рассуханов, Севрюгин—по бокам, я впереди. Арестованных срочно Зимину доставим. Не наше дело разбираться.

{Әйе! Үзегезчә сөйләшсәгез, муен тамырыгызга винтовка түтәсе төшәчәк. Булды! Киттек. Яхно, арттан барырсың. Рассуханов, Севрюгин—як-яктан, мин үзем алдан атлармын. Әсирләрне кичекмәстән Зиминга тапшырырга кирәк. Сорау алу, кем икәннәрен ачыклау—безнең эш түгел.}

*(Зыятдин белән Зарифны алып китәләр.)*

Севрюгин *(урман эченнән)*. Как

это не наше дело?! Этого Зайнуллина сам прикончу!

{Ничек инде безнен эш түгел?! Бу Зәйнуллинны шәхсән үзем дөмектерәчәкмен!}

Ш а т а л о в *(урман эченнән жикергәне ишетелә).* Замолчи!

{Шаулама!}

Авыр музыка. Сәхнә караңгылана.

# ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Түрдә Зиминның блиндажы. Блиндаж кырыенда Шаталов, Севрюгин, Яхно, Рассуханов тәмәке тартып утыралар.

Я х н о . Я думаю, он наш перебежчик.

{Безнең яктан чыгып качкан кешедер ул.}

Ш а т а л о в . Черт его знает.

{Шайтан белсенмени аны.}

Я х н о . И, наверно, Зариф его знал.

{Ә Зариф белән таныш булганнардыр.}

Р а с с у х а н о в *(борын астына мыгырдый).* Разберутся.

{Ачыкларлар.}

С е в р ю г и н *(кызып китә).* А я думаю—этот... слов не могу подобрать... ублюдок... Зайнуллин—как пить дать, финский шпион!

{Ә минем уйлавымча, теге... кем... ничек дип атарга да белмим кабахәт... адәм актыгы... үләксә... Зәйнуллин, иманым камил, фин шпионы!}

*(Тәмәке төпчеген ыргыта, төкерә.)*

Ш а т а л о в *(ачу белән).* Погоди брызгать слюной. Допросят, заставят все рассказать. Специальные органы для этого есть.

{Төкерегенне ул хәтле чәчрәтми тор әле. Сорау алганда барысын да үзләренә сөйләтерләр. Моның өчен махсус органнар, махсус кешеләр бар.}

С е в р ю г и н *(башын читкә борып).* Органы-то есть. А вот рядом вражина ходил. Из одного котелка, можно сказать, жрали.

{Органнар бар да... Ә менә бит янәшәдә генә дошман йөргән. Бер савыттан ашадык дисәң дә була.}

З и м и н *(блиндаж эченнән эндәшә).* Шаталов, зайди!

{Шаталов, кер!}

Шаталов блиндажга керә.

Ш а т а л о в . Товарищ...

{Иптәш...}

З и м и н *(шундук булә).* Кончай, времени нет. Садись. Что скажешь?

{Ташла, вакыт юк. Утыр. Нәрсә әйтерсен?}

Ш а т а л о в *(утыра).* Ну что... По дороге Зайнуллин рассказал, что к нему подкрался финский снайпер, который оказался по национальности татарином.

{Нәрсә әйтим инде... Базага кайтканда Зәйнуллин миңа сөйләде: имеш, аның янына арттан шыпырт кына фин снайперы килгән. Мәргән милләте буенча татар икән, имеш.}

З и м и н . А до этого, на передовой Зайнуллин как себя вел?

{Ә моңарчы, мәсәлән, рота белән алгы позициядә чакта, оборона вакытында Зәйнуллин үзен ничек тотты?}

Ш а т а л о в . Воин отважный... Тогда-то он показал себя как настоящий солдат... Ну, я не знаю... А тут с врагом сидеть и песни петь...

{Батыр сугышчы... Анда ул үзен чын солдат итеп күрсәтте... Ну, мин белмим... Бөтенләй көтмәгәндә, дошман белән бергә жырлап утырып...}

*(Уйга кала.)* Думаю, его расстреляют.

{Аны атарлар дип уйлыйм.}

З и м и н *(күзләрен кысып).* А тебе не жалко будет его?

{Атсалар жәлләмәссенме?}

Ш а т а л о в *(аптырап).* Кого?!

{Кемне?!}

Зимин. Зайнуллина.

{Зәйнуллинны.}

Шаталов *(кискен тавыш белән).* Нет! Потому что идет война, а на войне нет времени жалеть.

{Юк, кызганмам! Чөнки сугыш бара, ә сугышта андыйларны җәлләп торырга вакыт юк.}

Зимин. Иди. Пусть Рассуханов зайдет.

{Ярый. Бар. Рассуханов керсен.}

Шаталов. Есть. *(Чыгып китә.)*

Рассуханов керә.

Зимин. Заходи быстрей, садись, времени мало!

{Тизрәк кер, утыр, вакыт аз!}

*(Рассуханов килеп урындыкка утыра.)*

Зимин *(солдатка шактый вакыт карап тора).* Что можешь сказать о случившемся?

{Бүгенге вакыйга хакында ни уйлыйсың?}

Рассуханов *(тыныч кына тавыш белән).* Здесь ничего такого, думаю, нет. Встретились два татарина. Просто воюют они один за свою Родину, другой— за свою.

{Монда, минемчә, бернинди куркыныч нәрсә юк. Ике татар очрашканнар. Берсе үзенен Туган иле өчен сугыша, икенчесе үзенеке өчен.}

Зимин *(кыжрап).* Ну, если так, то они должны были стрелять друг в друга!

{Һәрберсе үз Туган иле өчен сугышкач, димәк, алар бит бер-берсенә атарга тиеш булганнар.}

*(Алга таба сузылып.)* Если бы ты чеченца на финской стороне увидел, то не стал бы убивать? А?

{Әгәр дә син фин ягында сугышучы чеченны күрсән, син аны үтермәс иденме? Ә?}

Рассуханов *(капитаннын күзенә карап).* Чеченцев нет на финской стороне.

{Фин ягында чеченнар юк.}

Зимин. Ну, а если бы были, стал бы с ним сидеть и распевать песни?!

{Шулай да, менә әгәренки булсалар, син алар белән җырлар җырлап утырыр идеңме?}

Рассуханов. Я сегодня боец Красной Армии и служу как положено. А что было бы, если бы... не надо так думать..

{Бүгенге көндә мин Кызыл Армия сугышчысы һәм тиешенчә хезмәт итәм. Чеченнар фин ягында булсалар... аларны очратсаң... тегеләйме-болаймы, нишләр идең... дип фараз итеп утыру дөрес түгел.}

Зимин *(беркавым тып-тын утырганнан сон).* Иди.

{Бар, чык.}

Рассуханов. Есть! *(Кузгала.)*

Зимин. Позови Яхно!

{Яхноны чакыр!}

Рассуханов. Есть! *(Чыгып китә.)*

Яхно керә һәм тиз генә барып Зимин каршына утыра.

Зимин *(папирос кабыза).* Плохи дела, Яхно.

{Эшләр яман, Яхно.}

Яхно *(корыч тавыш белән).* Расстрелять обоих и все!

{Икесен дә атып үтерергә һәм вәссәлам!}

Зимин *(папиросын суырып Яхнога игътибар белән карый).* Ты же всегда защищал Зайнуллина, когда между собой грызлись...

{Үзара тынышмаганда син бит Зәйнуллинны гел яклый торган идең...}

Яхно *(нәфрәтләнеп).* А кто знал, что он такой?!

{Аның кем икәнлеген, нинди икәнлеген белмәдем бит мин.}

Зимин. Какой?

{Кем икәнлеген?}

Яхно. Ну так... с финской кукушкой... по-братски.

{Ну... фин күкесе белән... туганнарча очрашкач кем була инде...}

Зимин *(күзләрен чекрәйтеп).* Но они одной национальности.

{Булса ни, алар бит бер милләт кешеләре.}

Яхно *(кыжрый).* Ну и что! Мне наплевать какой национальности! Враг есть враг!

{Бер миллэт дип! Төкерәм мин аларның нинди милләттән булуларына. Дошман—дошман инде ул!}

Зимин *(папиросын көл савытында сыта).* Правильно. Можешь идти.

{Дөрес әйттең. Ярый, бар.}

Яхно *(урыныннан кузгала).* Есть!

Зимин. Позови Севрюгина!

{Севрюгинны чакыр!}

Яхно. Есть! *(Чыгып китә.)*

Севрюгин керә.

Зимин. Садись.

{Утыр.}

Севрюгин *(утыра).* Ну что, я предупреждал вас! Я его сразу раскусил. И ножик он специально оставил.

{Нәрсә, аңладыгызмы?! Мин сезне кисәткән идем! Мин анардан башта ук шикләндем. Пәкесен дә юри калдырган ул.}

*(Тавышын әкренәйтеп.)* Завербованный он.

{Вербовкаланган ул.}

Зимин *(аңламаган булып кылана).* Кто?

{Кем?}

Севрюгин *(гажәпләнеп).* Как кто! Зайнуллин!

{Кем булсын инде! Зәйнуллин!}

Зимин. Давно?

{Күптәнме?}

Севрюгин. Откуда я знаю! Их еще не расстреляли?

{Каян белим мин! Аларны атмадылармы әле?}

Зимин *(тавышына искиткеч сабырлык салып).* А зачем спешить?! Сначала им язык развяжем, потом передадим куда следует... Каждый получит то, что заслуживает.

{Ашыгуның кирәге юк. Иң элек аларның телләрен чишәчәкбез, барысын да сөйләтәчәкбез, аннан соң инде тиешле инстанциягә тапшырырбыз... Тиешле җәзаны алырлар.}

Севрюгин *(кыжрый).* Да расстрелять их, и дело с концом!

{Алып чыгып атып үтерергә дә инде, шуның белән тәмам!}

Зимин *(землянка почмагының бер ноктасына текәлеп).* А какой толк их расстреливать?! Может быть, очень ценные сведения через них добудем. А?

{Аларны атып үтерүдән ни мәгънә?! Бәлки алар аша бик кыйммәтле мәгълүматлар алырбыз. Ә?}

*(Севрюгинга карап утыра.)*

Севрюгин *(капитанның күз карашыннан шүрли).* Не знаю.

{Белмим.}

Зимин. Иди!

{Бар.}

Севрюгин. Есть! *(Чыгып китә.)*

Якында гына снарядлар шартлый башлый. Пулеметтан, винтовкадан аткан тавышлар, кычкыру, ыгы-зыгы куба. Тирә-як карангылана. Солдатлар чабыша. Носилкалар белән яралыларны ташыйлар. Рота командиры Лебедев күренә.

Зимин *(кычкыра).* Товарищ Лебедев! Что там?

{Иптәш Лебедев! Белмисеңме, нәрсә бу?}

Лебедев *(Зиминга таба килә).* Наша артиллерия обстреливает. Но на ощупь. Правильно наводить нет возможности, сквозь лес ничего не видно.

{Үзебезнең артиллерия ата. Юнәлтүчеләр урман аша берни күрмиләр. Шуңа күрә, кая атканнарын да белмичә, болай чамалап кына аталар.}

Зимин. Подмога вроде идет.

{Ярдәм килә дип ишеттем.}

Лебедев. Давно уже обещают.

{Күптәннән вәгъдә итәләр инде.}

Зимин. А там что вообще происходит?

{Алгы сызыкта ничек соң хәлләр?}

Лебедев. Нам разрешили немного отступить. Ну, а финнов накрыли там.

{Безгә бераз чигенергә рөхсәт иттеләр дә, финнәрне авиация белән капладылар.}

Зимин. Понятно.
{Аңлашылды.}

Лебедев. Снаряды-то успели замаскировать?
{Снарядларны яшердегезме соң?}

Зимин. Да так, как могли. Но не очень надежно. Дай бог, чтобы наши первыми сюда успели. Финны подойдут, сразу найдут—у них чутье звериное.
{Житешә алганча. Урыннары бигүк ышанычлы түгел шул. Ходаем, тизрәк безнекеләр килсен инде монда. Финнәр бик сизгер, алар килеп житсәләр, шундук табачаклар снарядларыбызны.}

Лебедев. Ученые-то живы?
{Галимнәребез исән-саулармы соң?}

Зимин. Все живы-здоровы.
{Барысы да исән.}
*(Көлә.)* Но страху натерпелись. Я им оружие раздал. Некоторых никак стрелять не можем научить.
{Әлбәттә, котлары алынды. Мин аларга корал өләштем. Кайберләрен һич кенә дә атырга өйрәтә алмыйбыз.}

Лебедев. Еще бы дня два продержаться. Потерь очень много. Я прошу, товарищ Зимин, отдать моих пятерых ребят мне обратно. Они мне там очень нужны. Мы же опять туда поползем.
{Тагын ике көн каршы тора алсак иде. Югалтулар шундый күп. Иптәш Зимин, зинһар өчен, минем теге биш егетемне мина кире бир. Алар мина алгы сызыкта бик кирәк. Без бит янә шул позицияләргә үрмәләргә тиеш.}

Зимин *(уйланып тора)*. Хорошо, я тебе отдам ребят, но не пять человек, а только четверых.
{Ярар, егетләреңне бирермен, әмма бишесен дә түгел, дүртесен генә.}

Лебедев. Почему?
{Ник алай?}

Зимин. Скажи, положа руку на сердце—что ты про своего Зайнуллина можешь сказать, кроме того, что уже говорил?
{Син Зәйнуллин турында элегрәк сөйләгәннәренә өстәп тагын ниндирәк фикерләр әйтә аласың?}

Лебедев. Из второго отряда?
{Икенче отрядтагы Зәйнуллин турындамы?}

Зимин. Да.
{Әйе.}

Лебедев. Зариф?
Зимин. Зариф.
Лебедев *(инандырырлык тон белән)*. Отличный боец! Помню, на передовой он лучше всех воевал.
{Шәп солдат! Хәтерлим, алгы сызыкта ул үзен каһарманнарча тотты.}

Зимин *(теләр-теләмәс кенә әйтә)*. Он арестован.
{Ул кулга алынды.}

Лебедев. Не понял?! Кто?
{Аңламадым?! Кем кулга алынды?}

Зимин. Зайнуллин из твоей роты.
{Зәйнуллин. Синең ротадан.}

Лебедев *(кашларын җыерып)*. За что?
{Ни өчен?}

Зимин *(авыр сулап куя)*. С финской "кукушкой" тайком встречался.
{Яшертен генә фин "күке"се белән очрашканы өчен.}

Лебедев *(аптырап)*. Не может быть!
{Ышанмыйм!}

Зимин *(Лебедевка ачуланып карый)*. Не может быть, говоришь?! А не боишься так утверждать?
{Ышанмыйм дип әйтергә курыкмыйсыңмы?}

Лебедев *(Зиминга карап тора)*. Где он?
{Кайда ул?}

Зимин. Вон в той землянке.
{Әнә теге җир йортта.}

Лебедев. Я должен увидеть его.
{Мин аны күреп сөйләшергә телим.}

Зимин. Иди, охрана пустит тебя.
{Бар, сакчылар сине кертерләр.}

Лебедев *(басынкы тавыш белән)*.

А остальных отправь, пожалуйста, обратно в роту. *(Зариф янына китә.)*

{Калганнарын, зинһар, кире ротага жибәр.}

Зимин. Хорошо.

{Ярар.}

*(Кычкырып.)* Шаталов!

Шаталов. Я!

{Мин!}

Зимин. Забирай своих ребят и бегом в распоряжение заместителя командира роты!

{Дүртегез дә ротагызга кайтыгыз—әлегә командир урынбасары карамагына!}

Шаталов. Есть! *(Шаталов, Рассуханов, Севрюгин, Яхно иелә-иелә йөгерәләр. Якында гына бер-бер артлы снарядлар шартлый. Солдатлар йөгерешәләр. Яралыларны носилкаларга салып ташыйлар. Ыгы-зыгы. Акырыш-бакырыш. Төрле командалар янгырый. Сәхнә йә яктыра, йә кинәт карангылана. Зимин блиндажга кереп кача.)*

Авыр музыка. Снарядлар шартлавы бераздан тына. Лебедев күренә. Блиндаждан аның каршысына Зимин чыга.

Лебедев. Я поговорил с ним. Он мне все рассказал.

{Мин аның белән сөйләштем. Ул мина барысын да сөйләде.}

Зимин. Я знаю, что он тебе рассказал. И ты думаешь, ему можно верить?

{Аның сина ни сөйләгәнен мин беләм. Син ана ышанасыңмы?}

Лебедев. Я его хорошо знаю. Он бесстрашно вел себя под вражеским огнем.

{Мин аны бик яхшы беләм. Алгы сызыкта ул үзен аямыйча сугышты.}

Зимин *(жикереп)*. А что он любил отлучаться, притворяться нелюдимым, что он прогуливался один при каждом удобном случае—этого ты не замечал?!

{Ә мена башкалардан аерылып, аралашмаучан булып кыланып, жай чыккан саен читтә ялгызы гына йөрүенә бер дә игътибар итмәденме?!}

Лебедев *(усал тавыш белән)*. Попрошу не повышать на меня голос!

{Мина болай тавышыгызны күтәрмәгез!}

Зимин. А что на наш секретный объект уже который день ведется вражеский артиллерейский огонь—это-то ты замечаешь?

{Яшерен, серле объектыбызга инде ничәмә көн рәттән дошман туплары ата—ичмасам моны күрәсенме син?}

Лебедев. Хочешь сказать—это Зайнуллин наводку делает?

{Юнәлешне Зәйнуллин бирә дип әйтмәкче буласын мәллә?}

Зимин. Разберемся.

{Тикшерербез, төшенербез, ачыкларбыз.}

Лебедев. Ни за что этому не поверю. Я помню, как он пришел в роту, как начал службу, как вступил в первый бой! У меня к тебе предложение... просьба... Давай, это дело утрясем здесь, у себя. Пленного финского татарина оформим как пленного, а Зайнуллина отдай мне.

{Барыбер ышанмыйм. Мин аны ротага килгән беренче көненнән үк хәтерлим, хезмәт итә башлавы күз алдымда, беренче сугышка бергә барып кердек! Минем сина бер тәкъдимем... үтенечем бар... дөресрәге, Әйдә бу матавыкны үзебезнең арада гына тәмамлыйк. Эшләр зурга китмәсен инде. Фин татарын әсир буларак тапшырыйк, ә Зәйнуллинны мина бир—мин аны ротага алып кайтам.}

Зимин. Ты не боишься, что на тебя тень может пасть?

{Бу очракта синен үзенә дә шик төшүе ихтимал дип курыкмыйсынмы сон?}

Лебедев. На меня, товарищ капитан, может пасть вражеский снаряд—вот этого я, скажу откровенно, боюсь, а теней бояться не имею права, потому что я выполняю ответственную задачу.

{Иптәш капитан, минем өскә бүген үк дошман снаряды төшәргә мөмкин, бу мине, дөресен әйтәм, нык куркыта, ә кемнәрнендер шикләнүләреннән, төрле шәүләләрдән өркергә минем хакым юк, чөнки мина бик зур һәм мөһим бурыч йөкләнгән.}

Зимин *(авызын кыйшайтып)*. Ну, ну.

{Шулаймы...}

Лебедев *(сабырлыгын җуймаска тырышып).* Мы с вами должны доверять друг другу, Федор Семенович. Мы не первый день одну задачу с вами выполняем. И эти склады мы с вами отстоим, они не достанутся врагу. Закруглим это недоразумение прямо сейчас. Не надо никуда сообщать.

{Без сезнең белән бер-беребезгә ышанырга тиеш, Федор Семенович. Безнең бурычыбыз да, максатыбыз да бер үк. Базаны без бергәләп барыбер саклап калачакбыз, дошманга бирмәячәкбез. Килеп чыккан аңлашылмаучылыкны хәзер үк, шушында ук бетерик, юк итик. Зәйнуллин турында беркая да хәбәр итмәгез.}

Зимин. Анатолий Евсеевич, а что, если все гораздо глубже. Что, если он завербован еще до армии? А что, если вокруг нас паутину плетут вот такие сородичи и земляки?! А что, если твои Зарифы уже про наши реактивные снаряды сообщили маршалу Маннергейму, шведам, англичанам, всем, всем...

{Анатолий Евсеевич, әгәр дә тамырлар тирәнгә сузылган булып чыкса. Бәлкем, армиягә кадәр үк вербовкалангандыр ул? Бәлкем, безнең тирәдә менә шундый якташлар һәм кардәшләр ятьмә үреп маташалардыр?! Бәлкем, синең Зарифларың безнең реактив снарядларыбыз хакында маршал Маннергеймга, шведларга, инглизләргә һәм башкаларга инде күптән хәбәр иткәннәрдер!}

*(Тирә-якны бомбага тота башлыйлар. Ерактан кычкыралар.)*

Ерактагы тавыш. Товарищ старший лейтенант!

{Иптәш өлкән лейтенант!}

Лебедев *(үтенеп сорый).* Прошу вас, товарищ капитан, не губите парня! Я побежал.

{Иптәш капитан, үтенәм, егетне харап итмәгезче! Мине чакыралар! Йөгердем!}

*(Урман эченә кереп югала. Зимин блиндажга таба юнәлә.)*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә урталайга бүленгән. Бер яктагы кечкенә землянкага Зыятдинны ябып бикләп куйганнар. Икенче яктагы землянкага Зарифны бикләгәннәр. Сәхнә түрендәге калкулыкта Зимин үзенең блиндажында нәрсәдер язып утыра. Сикереп тора да, кызу-кызу атлап Зыятдин янына керә. Зыятдин җир идәндә утыра.

Зимин *(керә дә Зыятдинга карап тора, аннары тыныч кына эндәшә).* Встань.

{Тор.}

*(Зыятдин карап утыра. Зимин кул ишарәсе белән аңлата.)* Встань!

{Тор!}

*(Зыятдин торып баса.)* Теперь ты уж запомни русское "встань". Фамилию, имя, отчество назови.

{Син инде хәзер урысча "тор" дигәнне исеңдә калдыр. Фамилияңне, исемеңне, атаңның исемен әйт.}

Зыятдин *(фин телендә әйтә).* Мин русча аңламыйм.

Зимин *(Зыятдинны башыннан аягына кадәр җентекләп күзәтә).* Хочешь, чтобы я с тобой по-фински говорил?!

{Фин телендә сөйләшергә тиешмени мин синең белән?!}

*(Тынлык.)* Ты кто?

{Кем син?}

Зыятдин *(фин телендә әйтә).* Тәрҗемәчесез сөйләшә алмам мин сезнең белән.

Зимин *(Зыятдин тирәсендә әйләнеп йөри).* Ладненько. Общий язык мы с тобой все равно найдем.

{Ярар алайса. Барыбер безгә синең белән уртак тел табарга туры киләчәк.}

*(Кинәт татарчага күчә.)* Фамилияң, исемең ничек? *(Зыятдинның каршысында туктап күзләренә карый.)*

Зыятдин *(капитанның күзенә карарга курыкмый).* Минем документта барысы да язылган.

Зимин *(акцент белән, вата-җимерә татарча сөйләшә).* Кайсы дивизиядән, ничәнче полктан?

З ы я т д и н. Мин үз теләгем белән, үз ирегем белән сугышам.

З и м и н. Ополченец? *(Тынлык.)* Без алган территориядә яшисенме?

З ы я т д и н. Хельсинкидан мин.

З и м и н. Бу яктан качкан дезертир түгелме соң син?

З ы я т д и н *(көлемсерәп).* Мин сиңа бер начар сүз дә әйтмәдем, ә син мине мыскыл итәсең.

З и м и н. Кайчаннан бирле сугышасың?

З ы я т д и н. Беренче тапкыр Хельсинкины бомбага тотканнан соң ук җыенып чыгып киттем.

З и м и н. Син күзәтчеме, әллә "күке"ме?

З ы я т д и н. Мин туган илне яклаучы фин гражданы. "Күке" дип мине тагын мыскыл итәсең.

З и м и н *(ямьсез итеп елмая).* Сезнең Зариф үпкәләми бит "күке" дигәнгә. Аның да кушаматы "күке".

З ы я т д и н. Фин снайперларын "күкеләр" дип пропаганда йөзеннән сөйлисез бит сез. Имеш, агач башында утырырга фәрман бирәләр, үлгәнче шуннан атып утыралар. Ә асылда исә мин, мәсәлән, агач башыннан да, теләсә кайдан да ата алам.

З и м и н *(ясалма ягымлылык белән, ләкин яман усал итеп).* Инде күпме аттың?

З ы я т д и н. Әле бер кешегезне дә үтерергә җитешмәдем.

З и м и н. Нинди задание белән монда йөрисең?

З ы я т д и н. Аңламыйм?

З и м и н *(кычкырып).* Нишләп йөрисең монда?

З ы я т д и н *(башын югары тотып).* Агрессорга каршы сугышып.

З и м и н. Зарифтан башка тагын кемнәр белән элемтәдә?

З ы я т д и н. Мин беркем белән дә элемтәдә тормадым. Ә Зариф—ул сезнең каһарман. Ул зур батырлык күрсәтте. Мине әсир итте. Сезгә мөһим түгелмени—солдатыгыз фин снайперын әсир итте.

З и м и н. Ул сине пленга алды, да?

З ы я т д и н. Әйе.

З и м и н *(тагын килеп Зыятдинның күзләренә карый).* Ә миңа башкачарак сөйләделәр.

З ы я т д и н *(туп-туры карап).* Белмим, ничек сөйләгәннәрдер, ул мине әсир итте.

З и м и н *(землянка буйлап йөри).* Кем кемне әсир иткәндер, анысы вак мәсьәлә. Миңа Зариф кызыклы нәрсәләр әйтте инде. *(Пауза.)* Беләсең килсә, фин разведкасы белән элемтәдә торуын сөйләде ул миңа.

З ы я т д и н *(көлә).* Ышанмыйм. Ничек инде элемтәдә тора алсын ул Татарстанның бер урман хуҗалыгыннан килгән татар егете.

З и м и н *(кинәт Зыятдинның каршысына килеп баса).* Ә син каян беләсең аның Татарстаннан, урман хуҗалыгыннан икәнен?

З ы я т д и н. Үзе әйтте. Без бит аның белән сөйләштек.

З и м и н. "Кукушка" буларак күпме кешебезне үтердем дисең?

З ы я т д и н. Күке буларак та, кеше буларак та беркемне үтергәнем юк әлегә.

З и м и н. Нишләп?

З ы я т д и н. Ничек инде "нишләп"?!

З и м и н. Тып-тын гына килмәкче идеңмени безнең базага?

З ы я т д и н. Мин сезнең базагыз хакында белмәдем. Очраган совет солдатларын атып үтерергә дип йөрдем мин. Аучы мәргән кебек. Бу—СССР территориясе түгел. Бу—безнең ил. Бу—Финляндия!

З и м и н. Ә Зарифны ник атып үтермәдең?

З ы я т д и н. Татарча җырлаганын ишеттем.

З и м и н *(авызын кыйшайтып башын чайкый).* Ышанмыйм! Син аның җырлаганын ишеткәнсең, атмагансың... Ничек сине кулга алды соң ул?

З ы я т д и н. Шулай килеп чыкты. Мин аның татар икәнен аңлагач, янына килдем, соңыннан атып үтерермен дип. Шулчакны ул винтовкасын эләктереп алды да мине коралсызландырып кулга алды. Менә шулай әсир төштем.

З и м и н. Алдыйсың бит син.

З ы я т д и н. Ышанмасаң ышанмыйсың инде.

З и м и н. Гаҗәп—ничек син Финляндиядә яшәп татарча яхшы сөйлисең.

З ы я т д и н. Син дә бит урыс башың белән татарча хәйран әйбәт сөйләшәсең.

З и м и н *(горур тавыш белән).* Мин Ватанны дошманнардан саклый-саклый өйрәндем татарча сөйләшергә!

З ы я т д и н *(мыскыл итеп елмая).* Бөтен дөнья белән сугыша-сугыша йөз телдә өйрәнерсең әле син сөйләшергә.

З и м и н *(кинәт кыяфәте коточкыч*

*тәскә керә).* Син шаярасың... Но тиздән шаяру түгел, хәтта уйлый да алмый башлаячаксың. Әмма ләкин башта кем икәнеңне, нәрсәләр белүеңне тезеп-тезеп сөйләп бирерсең миңа. Мондагы агентурагызны ачып бирәчәксең! *(Чыгып китә. Зыятдин жир идәнгә утырып кала.)*

Зимин икенче землянкага—Зариф янына керә. Зариф жир идәндә кырын яткан һәм уйга баткан. Зимин кергәч әкрен генә торып баса.

З и м и н *(землянканың бер башыннан икенчесенә атлый).* Сөйлә.

З а р и ф. Нәрсә сөйлим?

З и м и н. Дөресен.

З а р и ф. Мин сезгә инде барысын да сөйләдем. Мин завербованный түгел. Чит ил шпионы түгел мин. Дезертир түгел, качарга җыенмадым. Бернинди фин разведкасы белән элемтәдә тормадым. Сатлыкҗан түгел мин... Тагын нәрсә сөйлим? Гаебем юк дип саныйм. Кабатлап әйтәм: ул снайпер миңа атмады—бу бит аның безне дошман итмәве. Аның үз илендә мылтык белән йөрергә хакы бар лабаса! Мине бит югыйсә атып үтерә ала иде, мин сизми дә калган булыр идем. Шуңа күрә, сез аны каты хөкем итәргә тиеш түгел. Ул беркемне дә үтермәгән. Җибәрегез аны.

З и м и н. Ул бит җибәргәч үтерергә может.

З а р и ф. Менә мине үтермәде бит! Ә мин—кызылармеец киеменнән. Атмады бит!

З и м и н. Менә шунысы сәер—нишләп атмады ул сине?

З а р и ф. Дөресен әйтәм: татарча җырлавымны ишеткәнгә атмаган.

З и м и н *(җикереп).* Ә русча җырлаган булсаң атар иде, шулаймы?

З а р и ф *(өзгәләнеп).* Иптәш капитан! Татарча җырласам да, мин—Кызыл Армия солдаты. Мине атып үтермәве аның язмышын җиңеләйтсен иде. Сез үзегез минем урында булсагыз, һәм дә снайпер сезне үтермәсә, сез аны дошман итәр идегезме?

З и м и н. Миңа каршы корал күтәреп йөргән кеше хет атсын, хет атмасын, ничек кенә карама—барыбер миңа дошман ул. Синең кличкаң "күке"... Ул да фин "күке"се... Моны ничек аңлатырга?

З а р и ф *(газаплы кыяфәт белән).* Нишләп ышанмыйсыз сез миңа!

З и м и н *(авызын кыйшайтып елмая).* А ул миңа бөтенләй башкача әйтте...

З а р и ф. Ничегрәк?

З и м и н. Безнең базадагы яңа төрле снарядлар хакында информация килде диде. Кем хәбәр итте дигәч, безнең агентура диде. *(Зарифка текәлеп карап тора.)*

З а р и ф. Сез ул агентура мин дип уйлыйсызмы?

З и м и н. Инде дошманны юк итәргә, яки пленга алырга тырышмавың гына да—куркаклыкка, хыянәткә тиң. Ә гомумән, асылда синең кем икәнлегеңне әле без ачыклаячакбыз.

З а р и ф. Әллә нәрсәләр ягарга маташмагыз инде миңа. Әйе, куркаклыкта, фин снайперын әсир итмәүдә мине, әлбәттә, гаепли аласыз. Мин бөтенләй гаепсез түгел инде, килешәм. Әмма ләкин Зыятдинның гаебе юк.

З и м и н. Ничек инде дошманның гаебе булмасын?! Дошман—дошман ул!

З а р и ф. Миңа гына түгел, биш кешенең берсенә дә атмаган бит ул—шуны аңлагыз сез!

З и м и н *(тешләрен шыгырдатып).* Син мине нәрсәне ничек аңларга өйрәтмә! Пәкесен онытып калдырган, видишь ли... Ялгызлык ярата... Нелюдимый... Нелюдимый татарча ничек?

З а р и ф. Аралашмаучан.

З и м и н. Аралашмаучан...

З а р и ф *(куркуын җиңеп сөйләшә).* Минем өчен дә сәер, могҗизалы вакыйга бу. Мин безгә каршы сугышучы татарны, якташымны очратырмын дип төшемдә дә күрмәс идем... Ничек кенә булмасын, мин ул кешегә рәхмәтле.

З и м и н. Ни өчен?

З а р и ф. Мине атып үтермәгәне өчен.

З и м и н *(үчекләп).* Ул да сиңа рәхмәт әйтә—предатель, сатлыкҗан булуың өчен.

З а р и ф *(кинәт кабарган нәфрәтен тыя алмый).* Син мине алып чыгып пистолетыңнан маңгаема ат, ләкин андый сүз әйтмә миңа!

З и м и н *(кыҗрап).* Син миңа койрыгыңны күтәрмә! Каян беләләр финнәр безнең складлар турында, аңлашылды. Әйтәм җирле шушы якка аталар да аталар, аталар да аталар. *(Землянка буйлап йөренә.)*

З а р и ф. Командованиенең тинтәклеге аркасында ул. Солдатларның гаебе

юк. Алдан снарядлар китереп өеп куеп, аның специалистларын монда кайчаннан бирле җәфалап... Ә ата торган пушкалары күренми дә күренми. Кем инде алгы линиягә секретный корал илтеп ташлый да бер ротага сакларга куша?!

Зимин *(көлемсерәп).* Бик акыллыланып киттең... *(Зарифның каршысына килеп баса.)* Бик хуп! Сине сөйләтергә әйбәт бу!

Зариф *(башын читкә бора).* Мин сөйлисен сөйләдем инде. Бүтән әйтер сүзем юк.

Зимин. Димәк, теге "күке? и... *(Зарифка бармагы белән төртә.)...* бу "күке" очраклы рәвештә очраштылар?! Кызык, кызык... Ә син нишләп ул фин снайперын пленга алдым дип әйтмисең?

Зариф *(Зиминга туп-туры карап).* Чөнки мин аны әсир итмәдем.

Зимин *(мыскыл итеп елмая).* Ә бит синең шулай дип әйтергә мөмкинлегең бар иде. Котылырга берданбер чара иде бу синең.

Зариф. Нишләп мин алай алдашыйм... Аннары, барыбер күргәннәр бит безнең бергә сөйләшеп утырганны.

Зимин. Ну, сөйләшеп утырганны күрү әле ул... Зыятдин бит әйтә: Зариф мине әсир итте ди. Зариф—ул сезнең героегыз диде.

Зариф *(шакката).* Ничек инде! *(Тышта тагын ыгы-зыгы куба, фин самолетлары оча башлый. Берничә җирдә бомба шартлый. Еракта исә каты сугыш бара, анда ату тавышлары бер дә тынмый. Зимин чыгып китә, Зариф камера вазифасын үтәүче землянка буйлап арыбире йөрергә тотына. Зимин үзенең блиндажына таба юнәлә. Кереп утыра да нәрсәләр яза башлый.)*

Лебедев керә.

Зимин. Ну и как?
(Хәлләр ничек анда?)

Лебедев. Потери большие. Лейтенанта из 44-й дивизии встретил.
(Хәлләр мөшкел. 44-нче дивизиядән бер лейтенантны очраттым.)

Зимин. Что говорит?
(Нәрсә ди?)

Лебедев. Рассказывал, что творилось там.
(Чолганыштагы мәхшәрне сөйләде.)

*(Урындыкка утыра.)*

Зимин. Как у него фамилия?
(Фамилиясе ничек?)

Лебедев. Не помню. Интересно, как у нас с запасами?
(Хәтерләмим. Запас күпме калды икән безнең?)

Зимин. Продовольствия у нас мало. Боеприпасы, ты знаешь, тоже на исходе. Но подкрепление вот-вот будет, надеюсь, успеют.
(Азык-төлек бик аз. Патроннар да, үзең беләсең, күп калмады. Өстәмә көч ярдәмгә менә-менә килеп җитәр дип өметләнәм.)

Лебедев. Но финны как раз на нашем участке собираются наступать.
(Финнәр нәкъ безгә таба һөҗүмгә күчәргә торалар.)

Зимин. Не успеют.
(Житешә алмаслар.)

Лебедев. А если успеют?
(Житешсәләр?)

Зимин. В первую очередь склады взрываем. А дальше видно будет.
(Ул очракта иң беренче нәүбәттә складларны шартлатабыз—снарядлар дошман кулына эләкмәсен. Аннары күз күрер.)

Лебедев. А может на другом участке пойдут...
(Башка якка кузгалырлар, бәлки...)

Зимин. Нет, они именно на нашем направлении пойдут.
(Юк инде, алар нәкъ безнең юнәлештә һөҗүмгә күчәчәкләр.)

Лебедев. Почему так уверен?
(Ник алай катгый иттереп әйтәсең?)

Зимин. Потому что эти финны про нашу базу знают.
(Чөнки финнәр безнең база хакында инде беләләр.)

Лебедев. Догадываться могут... Если даже про склады знают, они же не знают что за "товар" у нас здесь находится.
(Сизенүләре ихтимал... Әмма дә ләкин складлар турында белгән суратта да алар бит

монда нинди "товар" саклануын белмиләр.}

Зимин. Почему ты уверен, что не знают. Знают они про нашу базу, знают... И что у нас секретные снаряды хранятся—тоже знают.

{Кем әйтте сиңа белмиләр дип. Беләләр алар безнең база хакында, барысын да беләләр... Яшерен, серле снарядлар саклавыбызны да беләләр.}

Лебедев. Что пленный говорит?

{Әсир ниләр сөйли?}

Зимин. Все расскажет, никуда не денется.

{Сөйләр, барысын да ачып салыр, аның башка чарасы юк.}

Лебедев. Зайнуллин как?

{Зәйнуллин ничек?}

Зимин. Тоже расколется.

{Ул да урталай ярылачак, ул да бәйнә-бәйнә сөйләп бирер.}

Лебедев *(командирларга хас кискенлек белән)*. Невиновен он!

{Аның бер гаебе дә юк!}

Зимин *(шундый ук интонациядә җавап бирә)*. "Кукушка" он! По широко распространенному русскому народному поверью, дорогой ты мой, кукушка—это постоянный оборотень.

{"Күке" бит ул! Беләсең килсә, дускаем, борынгы урыс ырымы буенча, күке—убыр ул.}

Лебедев. Что-то не слышал.

{Бер дә ишеткәнем юк.}

Зимин. Ты коренной ленинградец, потому и далек от народа и его поверья тебе неведомы. Есть мнение, что кукушка и ястреб—одна и та же птица, принимающая по своему желанию, то вид кукушки, то вид ястреба.

{Син Ленинградта туып-үскән кеше, шул сәбәпле халык әйтемнәрен, им-томнарын, ырымнарын белмисең, анламыйсың. Күке һәм карчыга—бер үк кош дигән фикер-фараз бар. Менә шул кош теләсә кайсы вакытта күке дә була, карчыгага да әверелә ала.}

Лебедев. Не так уж я далек от своего народа, как ты думаешь. Я тоже знаю о кукушках кое-что.

{Мин син уйлаганча ук ерак түгел үземнең халкымнан. Минем дә күкеләр турында әйтер сүзем бар.}

*(Утырган урыныннан тора.)*

Зимин. Например?

{Мәсәлән?}

Лебедев. "Кукушка натощак окукукает—не к добру." Скоро бойцов кормить нечем будет. Как бы не пришлось, как в соседних дивизиях, дохлую конину жрать.

{"Ач карынга күке кычкырса—бәла буласын көт тә тор." Тиздән солдатларны ашатырлык ризык калмаячак. Күрше дивизияләрдәге кебек үлгән ат итен ашарга туры килмәгәе.}

Зимин *(боерулы тавыш белән)*. Перестань!

{Күп сөйләшмә!}

Лебедев *(кычкыра)*. Что, перестань! Там наши солдаты кипитят конские копыта и пьют этот гадкий сок. Там люди умирают больше от холода, чем от вражеских пуль!

{Кем күп сөйләшә?! Анда солдатлар, ат тоякларын кайнатып, шул әшәке шулпаны эчәләр. Салкыннан өшеп күпме кеше кырылды. Дошман пулялары да ул кадәре кешебезне үтермәгәндер.}

Зимин *(Лебедевка якын килеп битенә кычкыра)*. Замолчи!

{Житте!}

Лебедев *(тешләре арасыннан)*. Не кричи на меня! Не имеешь права!

{Кычкырма миңа! Миңа җикерергә синең хакың юк!}

Зимин *(үзен кулга алырга тырышып)*. Я не имею права?!

{Минем хакым юкмы?!}

Лебедев *(истерикада)*. Я еще знаю о кукушках! "При первой кукушке брякни деньгами, чтобы водились."

{Күке турында тагын әйтә алам әле мин! "Беренче күке тавышын ишеткәч кесәңдәге акчаңны чылтыратсаң—байыйсың."}

Зимин *(кинәт тынычлана)*. Успокойся, старший лейтенант!

{Гасабиланма, өлкән лейтенант!}

**Лебедев** *(еш-еш сулап).* Я спокоен, капитан. Отпусти Зайнуллина!

{Мин тыныч, капитан. Зәйнуллинны азат ит!}

**Зимин.** А финна?

{Ә финне?}

**Лебедев.** Он—военнопленный. Дальше видно будет.

{Анысы—әсир. Язмышын бездән башка да хәл итәрләр.}

**Зимин.** Зайнуллин—арестованный. Я должен держать его под стражей и сдать куда следует после некоторых формальностей. Я тебе советую быть осторожней, Анатолий Евсеевич. Ты сам себя можешь погубить, заступаясь черт знает за кого.

{Зәйнуллин—да, арестант. Мин аны сак астында тотам, кайбер формальлекләрдән соң тиешле урынга озатачакмын. Абай булырга киңәш итәм, Анатолий Евсеевич. Теләсә кемне яклап үз башыңны үзең харап итмәгәең.}

**Лебедев.** А если докажется, что он невиновен?!

{Ә гаепсезлеге исбатланса?!}

**Зимин.** Как невиновен! Он струсил, он не действовал так, как положено бойцу Красной Армии. Это равносильно предательству! Это уже точно! А о сотрудничестве с финнами предстоит еще тщательно разобраться. Не был ли он завербован еще у себя там в Татарии. Земляки... мать вашу!

{Нинди гаепсезлеге тагын! Ул, куркып, үзенең кызылармеец икәнлеген онытткан. Бу—сатлыкҗанлыкка тиң! Аның финнәр белән хезмәттәшлеге турында җентекләп казынырга туры киләчәк әле. Татариядә үк вербовкаланмады микән ул. Якташлар... аналарын сатыйм!}

**Лебедев.** А тот фин не наш перебежчик, не красноармеец бывший?

{Бу фин үзе дезертир кызылармеец түгел микән соң?}

**Зимин.** Не похож на перебежчика. Просто у него форма такая... Не армейская. Теплый свитер, шерстяные носки... У него кокарда и ремень только финские. Но тем не менее, он—финский воин.

{Бездән качкан кешегә охшамаган. Аның киеме генә шундый... хәрби түгел, иркәле. Җылы свитер, йон оекбаш... Аның кокардасы белән каешы гына финчә. Ә шулай да ул—фин сугышчысы.}

**Лебедев.** Среди пленных их много встречается в такой одежде.

{Әсирләр арасында андый киемлеләр бик күп очрый.}

**Зимин.** А они резервистам униформы не успели пошить. Да и экономят они—на ремни да на кокарды только тратятся. Теплый свитер, носки домашней вязки, тулуп—вот эта неуставная форма ихняя называется "каяндеркой".

{Чөнки алар резервистларга униформалар тегәргә житешә алмадылар. Экономия йөзеннән каеш белән кокардалар гына чыгаралар хәзер. Уставлары белән каралмаган шул иркәле киемнәре—үзләре өйдә бәйләгән свитер, оекбашлар, толыплар—"каяндерка" дип атала.}

**Лебедев.** В честь ихнего премьер-министра Каяндера, что ли?

{Премьер-министрлары Каяндер хөрмәтенә микәнни?}

**Зимин.** Да. Поэтому, если увидишь в лесу человека в простой одежде, это солдат финской армии.

{Әйе. Белеп тор, әгәр дә урманда гади генә киемле кеше очратсаң, ул—һичшиксез фин армиясе солдаты.}

**Лебедев** *(шактый вакыт тыштагы гөрселдәүләргә колак салып сөйләшми утыралар).* Да, не думал я, что финны так будут биться.

{Болай ук каты каршы торырлар дип уйламаган идем.}

**Зимин.** В местности хорошо ориентируются, сволочи.

{Жирле халык булгач, аларның монда ориентацияләре яхшы. Кабахәтләр!}

**Лебедев.** Целые дивизии наши в окружении погибают.

{Хәтта дивизияләребез чолганышта калып пыран-зыран килә бит.}

**Зимин.** Ну, это ты брось. Окружили несколько дивизий и все. На войне всякое бывает.

{Арттырма ла. Берничә дивизияне чолгап алдылар алуын. Сугышта була торган хал инде.}

Лебедев. Наших-то больше погибает.

{Барыбер безнекеләр күбрәк кырыла.}

Зимин. Ты боевой командир, ты уже показал себя геройски. А вот то, что сейчас сказал—это паникерство.

{Син булдыклы командир, үзеңне каһарман итеп күрсәтергә дә өлгердең. Тик менә хәзер шыншып утыруыңны паникерлык дип атарга мөмкин.}

Лебедев. Мне людей жалко.

{Мин кешеләрне кызганам.}

Зимин. Не тебе одному жалко людей.

{Сиңа гына җәлмени алар. Миңа да кызганыч.}

Лебедев. Мне кажется, надо выведать у этого снайпера информацию дислокации их войск на нашем участке, не тратя времени на другие подозрения и догадки.

{Миңа калса, бу фин мәргәненнән безнең тирәдәге фин гаскәрләренең дислокациясе хакында мәгълүматларны алу гына мәслихәт. Ә инде әллә нинди шикләнүләрнең, фараз кылып утыруларның кирәге юк.}

Зимин. Дорогой мой, об их дислокации мы знаем все. Меня интересует теперь их разведывательные связи. В этом деле ты мне не мешай, старший лейтенант!

{Дускаем, аларның дислокациясе турында бездә мәгълүматлар җитәрлек. Мине аларның күзәтү эшләре, разведка элементәләре кызыксындыра. Бу эштә инде син, өлкән лейтенант, комачаулама.}

Лебедев. А как себя чувствует научно-технический персонал?

{Фәнни-техник персоналыбызның хәлаәхвәлләре ничегрәк?}

Зимин. Нормально. Сегодня они будут перетаскивать снаряды в другое место. Людей не дашь?

{Болай ярыйсы. Бүген алар снарядларны икенче урынга күчерү белән мәшгуль булачаклар. Берничә кеше бирмәссең инде?}

Лебедев. Не могу.

{Юк, артык бер генә кешем дә юк, биралмыйм.}

Зимин. Погребов не хватает. Придется несколько землянок под погреба перестроить. Когда этих "кукушек" отправим куда следует—вот тебе еще две ямы освободятся.

{Казылган базлар гына җитмәс, ахрысы. Берничә җир йортка снарядлар тутырырга туры килер. Менә бу ике "күке"не озатканнан соң тагын ике чокыр бушый дигән сүз.}

Лебедев *(ялварулы тавыш белән).* Федор Семенович, я понимаю... У вас служба такая... Но мне кажется, что вы порой врагов ищете не там или совершенно в пустом месте.

{Федор Семенович, мин, әлбәттә, аңлыйм... Сезнең эшегез, вазифагыз шул... Ләкин кайвакыт, бер гаепсез кешеләрдән шикләнеп, бөтенләй юк җирдән, буш урыннан дошман эзлисездер шикелле тоела.}

Зимин *(коры гына).* Анатолий Евсеевич! Врагов мы будем искать везде и всюду! И будем находить! И будем уничтожать!

{Анатолий Евсеевич! Дошманнарны без һәрвакыт һәм һәркайдаэзләячәкбез. Һәм без аларны даими рәвештә табачакбыз! Һәм дә юк итәчәкбез!}

*(Лебедев бер сүз дә әйтми, чыгып китә.)*

Якын-тирәдә снарядлар шартлый. Яктылык һәм караңгылык бер-берсен алыштырып тора. Тынлык урнашкач Зимин янына Зыятдинны алып керәләр. Зыятдинның зажигалкасы белән әле кабызып әле сүндереп уйнап утыра.

Зимин *(зажигалканы күрсәтеп).* Синекеме?

Зыятдин. Минеке.

Зимин *(Зыятдинның паспортын актара).* Бабаң кайчан киткән Финляндиягә?

Зыятдин. XIX нчы гасырда.

Зимин. Соңгы тапкыр туганнарың кайчан безнең илдә булганнар?

Зыятдин. Унҗиденче елга каләр.

Зимин. Профессияң?

Зыятдин. Мин төрле калаларда тукыма кибетләре тотам.

Зимин *(паспортны куеп Зыятдинга карый).* Тиздән күрәбез инде келәмнәреңне. Ә син безнең төрмәләрне, лагерьларны күрәчәксең. Әлбәттә, анда тукымалар, паласлар, чигүле кашагалар юк. *(Елмая.)* Шунда кычкырачаксың инде ку-ку-ку дип.

**Зыятдин** *(үзен кыю һәм тыныч тота).* Минем телем бар. Әйтәсе сүземне сүз белән әйтермен.

**Зимин.** Син мина килеп эләкккәнен өчен язмышына рәхмәт укырга тиешсен.

**Зыятдин** *(көлемсерәп).* Рәхмәт укырга?!

**Зимин.** Син көлмә! Күптән түгел безнен күрше полктагы егетләр сезнен бер "күке"гезне тотканнар. Беркемгә әйтмичә, беркая тапшырмыйча, тотканнар да үзләре хөкем иткәннәр. *(Зыятдинга карап тора.)* Нигә сорамыйсын— нишләткәннәр дип?

**Зыятдин.** Нишләткәннәр?

**Зимин.** Ул снайперыгызнын хәтта исем-фамилиясен дә сорап тормаганнар, тотканнар да бәкегә салып батырганнар. *(Зыятдинга карап тора.)* Бигрәк коточкыч үлем, әйеме? Бәкедә батып үлү... Ай-яй... *(Кинәт сорап куя.)* Тагын ничәләп кешегез йөри бу тирәдә?

**Зыятдин** *(башын югары тотып).* Белмим. Урманда әллә кемнәр, әллә нәрсәләр йөрер... "Кара урманнын карыны кин", кем әйтмешли. Мин—үзем генә. Ниндидер полкныкы да түгел, бернинди фәрман буенча да түгел, вөжданым кушуы буенча сугышырга киттем.

**Зимин.** Белә-ә-әм мин нинди максат белән монда йөргуенне.

**Зыятдин.** Зарифнын язмышы ничек хәл ителәчәк?

**Зимин.** Анда синен ни эшен бар! Ул да "күке". Ана да келәмнәр, коверлар күрү насыйп булмас дип уйлыйм.

**Зыятдин.** Ул дошман снайперын әсир иткән кеше. Сез аны каһарман дип командованиегезгә хәбәр итәргә тиешсез.

**Зимин** *(үчекләп).* Тагын нәрсәләр эшләргә тиеш мин—бәлки өстәп әйтерсен?

**Зыятдин.** Дошман снайперын әсир иткән кешене бездә данлыйлар.

**Зимин.** Ә ул үзе баш тарта: мин аны кулга алмадым ди. Тора-бара әле тәгаен ихлас күнелдән сөйли башлаячак.

**Зыятдин.** Мин анладым: син тирәнрәк сәбәпләр эзлисен. Ниндидер шпиомания белән үзенне дә безне дә җәфалыйсын. Ә сәбәп гап-гади. Ул да татар, мин дә татар. Чыгышыбыз белән якташлар.

**Зимин** *(текәлеп карап тора).* Сез бераз бер-берегезгә кыяфәт белән дә охшагансыз.

**Зыятдин.** Әйе шул. Бер үк җырлар җырлыйбыз, бер үк телдә сөйләшәбез...

**Зимин.** Но сез бит фронтнын төрле якларында сугышасыз. Сина анда үзегездә рәхмәт әйтерләр иде мәллә, менә шушындый ситуация килеп чыкса?

**Зыятдин** *(тыныч кына).* Бездә кешене анлый беләләр.

**Зимин** *(шулай ук тыныч кына).* Ә безда анлата беләләр. *(Кычкыра.)* Уведите!

(Алып китегез!)

*(Конвой Зыятдинны янә кечкенә землянкага алып китеп бикләп куя.)*

Зимин янына Зарифны алып киләләр. Зариф кергәндә Зимин анын пәкесе белән уйнап утыра.

**Зимин** *(пәкене кулында әйләндергәләп).* Шушы ножикны онытып калдырган иденме?

**Зариф.** Әйе.

**Зимин.** Ничек але татарча?

**Зариф.** Пәке.

**Зимин.** Пәке. Шуны алырга дип бардын инде алайса?

**Зариф.** Әйе.

**Зимин** *(пәкене шалтыратып өсталгә ташлый).* Нишләп үзен генә бардын пәкенне эзләргә? *(Зарифка игътибар белән карый.)* Урманда куркыныч. Нигә берәрсен үзен белән иптәшкә алмадын?

**Зариф.** Без ул урыннан ерак китмәгән идек. Аннары, без ул тирәне инде әллә ничә кат тикшердек.

**Зимин** *(кинәт сорап куя).* Ничә тапкыр очраштыгыз фин разведчигы белән?

**Зариф.** Шул беренче тапкыр очрашуыбыз инде ул.

**Зимин** *(сорауларны тиз-тиз бирә).* Анарчы ничек элемтәдә тордыгыз?

**Зариф.** Нинди элемтәдә? Ни сөйлисез сез?!

**Зимин.** База турында финнәр каян беләләр сон?

**Зариф.** Кем әйтте беләләр дип?

**Зимин.** Нишләп гел безне бомбага тоталар да, гел безгә пушкалардан аталар?!

**Зариф.** Алар бөтен җиргә аталар, монда гына түгел.

**Зимин** *(гасаби киеренкелеккә чыдый алмый, кыза башлый).* Ник дөресен сөйләмисен? Барыбер заставят ведь, паскуда, барысын да сөйләргә!

**Зариф** *(тавышын күтәреп).* Мин дөресен сөйләдем. Мин инде туйдым. Тагын бер кат кабатлыйм. Мин сатлык-

жан түгел! Мин фин шпионы түгел! Мин завербованный түгел! Мин диверсант түгел! Минем бердәнбер гаебем: милләттәшем мине үтермәгәч, мин дә аңа кул күтәрмәдем.

Зимин *(шундук тынычлана башлый).* Димәк, синең аны пленга алырга или үтерергә жаең, мөмкинлегең булган?

Зариф. Соңыннан, танышкач, янәшә утырып сөйләшкәндә мөмкинлегем булгандыр, бәлки. Чөнки ул минем винтовкамны миңа кире бирде. *(Өзгәләнеп.)* Ну, ничек мин аңа атыйм инде, үзегез уйлап карагыз!

Зимин *(читкә карап).* Син башыңны жүләргә саласың, мине дә жүләргә санийсың, ахрысы. Дошман белән кочаклашып жырлап утыручыны, әлбәттә, менә хәзер үк, шушында ук атып үтерергә кирәк. Тик минем күңелем сизә—жепләр ераккарак һәм тирәнгәрәк сузылган монда...

Зариф *(әкрен генә).* Ул миңа атмады.

Зимин *(жикереп).* Башка кеше булса атар иде!

Зариф. Белмим. Ләкин бит башка кеше булмаган анда, мин булдым. Мин—кызылармеец. Ә ул мине үтермәде. *(Кычкырып жибәрә.)* Мине гаепләгез: куркаклыкта, хыянәттә, теләсә нәрсәдә, ә ул кешене әллә нинди жепләр суза-суза гаепләмәгез!

Зимин *(авызын кыйшайтып, күзләрен чекрәйтеп).* Сиңа атмады дип аның башыннан сыпырыйм мәллә?!

Зариф *(жан ачысы белән).* Сугыш булса да, кешеләр бит инде без!

Зимин. Кешеләр?! Ул кеше түгел! Ул—күке!

Зариф *(газапланып).* Ярар, күке булсын. Ләкин ул Телсез Күке! Ул атмады. Димәк ул—Телсез Күке.

Зимин *(өстәлдәге кәгазь өемен актара).* Икегез буенча да тирәнтен тикшерүләр алып барылачак. Архивларны күтәрәчәкләр. Татариянең Субай тирәсен капшаячаклар. Кемнең ата-бабасы кем булган. Кем ничек кайда кемнәр белән аралашкан. Кемнәр кемгә хат язган. Кем белән кем кайда һәм кайчан очрашкан. Бөтенесен актарачаклар. Аңладыңмы?

Зариф. Аңладым.

Зимин *(Зарифны башыннан аягына кадәр күзәтә).* Син инде бик арыгансың.

Зариф *(авыр сулап).* Әйе, арыдым мин.

Зимин *(күзләрендә чиксез нәфрәт чагыла).* Ә бит әле бу—башы гына, Күке Зариф! *(Кычкыра.)* Уведите! *(Зарифны янә теге землянкага илтеп ябалар.)*

Музыка. Гөрселдәүләр тагын кабатлана. Еракта солдатлар йөгереп үтә. Яралыларны күтәргән санитарлар күренә. Төрле командалар ишетелә. Зимин блиндажында нәрсәдер яза да яза. Музыка көчәя.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кечкенә генә землянка. Зыятдин белән Зарифны икесен бергә ябып бикләп куйганнар. Бүрәнәләрне урталай ярып ясалган өстәлдә керосин лампасы яна. Зариф белән Зыятдин, стенага сөяләп, янәшә утыралар.

Зыятдин. Ничек икебезне бергә ябарга булдылар икән?

Зариф *(тавышындагы калтырауны жиңә алмый).* Димәк, тиздән безне алып чыгып атачаклар.

Зыятдин. Ә сине нәрсә өчен?

Зариф. Фингә хезмәт иткән дип уйлыйлар.

Зыятдин. Бездән сорау алган кеше акылга зәгыйфь, ахрысы.

Зариф. Син: "Зариф мине әсир итте,"—дип мине коткарырга уйлаган идең мәллә?

Зыятдин. Әйе. Минем алай дип әйтүем ярдәм итмәде инде алайса?

Зариф *(беркавым тып-тын утыралар).* Бер караганда безне жәзасыз калдырырга тиеш түгелләр инде. Ни дисәң дә сугыш бара бит.

Зыятдин. Белүемчә, сезнең илдә бер генә жәза бар.

Зариф *(авыр сулап куя).* Безнең илдә бер генә жәза түгел...

Зыятдин. Сагынасыңмы туган якларыңны?

Зариф *(күзләрен йомып елмая).* Сагынмаган кая ул.

Зыятдин. Субай хәзер дә матур авылмы?

**Зариф**. Искиткеч! Кәшифә шул авылныкы бит.

**Зыятдин**. Зәй елгасы ерак түгел аннан, шулаймы?

**Зариф** *(башын Зыятдин ягына бора)*. Әйе. Син каян беләсен?

**Зыятдин** *(елмаеп сөйли)*. Әтием сөйли иде. Бабам бигрәк озак-озак итеп сөйли иде. Әти кечкенә вакытта киткәннәр бит инде алар, шуна күрә бабам сөйләгәннәрe кызыграк иде. Әти күп нәрсәне хәтерләми. Бабай сөйли-сөйли дә, жылый. Аннары жырлап ала. Тагын сөйли.

**Зариф**. Алай икән...

**Зыятдин**. Ташлы Таудан бөтен тирә-як күренеп торамы?

**Зариф** *(татлы елмаеп)*. Әйе.

**Зыятдин**. Бәрәкәт урманы күкеләренен кычкырганы Субайга ишетелеп торамы?

**Зариф** *(көлә)*. Әйе, ишетелә. Күке, күке...

**Зыятдин** *(көлә)*. Синен кушаматын "Күке"ме?

**Зариф**. Әти бәләкәй чакта адашкан. Ник болай урман эченә керден дип сорагач, күке тавышы артыннан бардым, күкене эзләдем дигән. Шуна "күке" дигәннәр безне. Зимин сине кеше түгел ул, күке ди. Мин әйтәм, атмагач Телсез күке була бит инде ул.

**Зыятдин**. Ничек кенә мыскыл итмиләр мине монда! Күке генә түгел, хәзер инде Телсез Күке икән мин. *(Көләләр.)*

**Зариф** *(йөзенә кинәт сагыш йөгерә)*. Атарга иден, Зыятдин, атарга иден! Хәзер мин дә жәфаланмас идем, син дә үзегезнен урманнарыгызда саф һава сулап йөрер иден.

**Зыятдин** *(Зарифка карап елмая)*. Жырламаска иден.

**Зариф**. Жырламыйча да булмый шул. *(Кинәт жанлана.)* Ай-яй, малай минем Кәшифәм жырлый иде ул! Минем Кәшифәм кебек монлы жырлаучы кызлар татарда бүтән юктыр. *(Куен кесәсеннән кульяулыкка төрелгән фоторәсемне ала. Сокланып карыйлар.)*

**Зыятдин**. Бигрәк чибәр. *(Кәшифәнен жырлаганы ишетелә.)*

Татар халык жыры
**"Кошларга".**

Һаваларда очкан кошкайларнын
Кунганнарын күрдем киртәгә;
Мәхәббәтем көчле, янган утлар төсле,
Сүнмәс, бәгърем, иртә дә, кичтә дә.

Һаваларда очкан кошкайларнын
Күнелле икән шаулап үтүе;
Авыр икән, дуслар, сөйгән ярны озату,
Тагы да авыр сагынып көтүе.

Һаваларда очкан кошкайларым,
Әйтегезче сагынып көтүем,
Аны уйлый-уйлый, күзем йокы алмый,
Йокысыз төннәрем үтүен.

**Зариф**. Кайда гына юк икән татар. Бер караганда куанычлы күренеш, ә икенче караганда...

**Зыятдин**. Бер-беребезгә каршы сугышып йөрибез димәкче буласынмы?

**Зариф**. Алай гына түгел... Сугыш бит ул кайчан да булса бетә барыбер.

**Зыятдин**. Һәрнәрсәнен азагы, чиге бар.

**Зариф**. Газапнын дамы?

**Зыятдин**. Газапнын да чиге булырга тиештер. *(Пауза.)* Мин бит анладым синен күнелендә ниләр кайнаганны. Татарга газапсыз яшәү ярамыйдыр инде ул.

**Зариф**. Яратмыйлар татарны, яратмыйлар, Зыятдин туган!

**Зыятдин**. Кайда, сездәме?

**Зариф**. Ә кайда татарны яраталар?

**Зыятдин**. Беренчедән, татарны яратмыйлар дип әйтмәс идем. Икенчедән, кайдадыр яратмыйлар икән, ә нишләп әле татарны яратырга тиешләр? Яратырлык итсен татар үзен. Бүгенге татар халкы турында дөньяда белмиләр дә беләселәре дә килми.

**Зариф**. Таралып, сибелеп беткән халык үзен яраттыра аламы сон?

**Зыятдин**. СССРда татарны яратмаслар инде ул. Кайчандыр котларын алып торган халыкны ничек яратсыннар. Тирәнрәк уйлап баксан, кайсы халык кайсысын ярата сон? Әле тегендә сугыш кабына, әле монда... Әле теге халык корал белән тегесенә күтәрелә, әле монысы кылыч кайрый.

**Зариф**. Шулай инде...

**Зыятдин**. Ә сездә кайсы халыкны ныграк яраталар сон? Бөтен төрмәләрегез, лагерьларыгыз тулды—милләтенә карап тутырмыйлар бит.

**Зариф**. Барыбер төрле тарафларга сибелеп бетмәсәк көчлерәк булыр идек шикелле.

**Зыятдин**. Бүген Сталин көчле,

Гитлер көчле. Төрле сәбәпләр аркасында таралды безнең халык дөнья буйлап. Исән калыр өчен китүчесе дә булгандыр, яхшырак тормыш эзләүчесе дә булгандыр, үзен кеше дип хис итәр өчен китүчесе дә булгандыр. Халык язмышы—халык язмышы инде ул. Аны без синең белән җырда гына җырлый алабыз. Ул сезнең илдә татар михнәтне күп күрде инде ул. Әле алда күрәселәр күпмедер!

Зариф. Барыбыз да авыр тормыштан котылу нияте белән чит илләргә китеп, җиңелрәк тормыш эзләп дөнья буйлап йөрсәк без бөтенләй беткән булыр идек, бәлки?

Зыятдин. Әйтүе кыен. Бәлки халык газабында мәгънә бардыр. Бәлки яктылык эзләп, гүзәллектән мөкиббән китеп йөрсә бөтен халык—үзенең асылына кире кайта алмыйдыр. Синең әтиең күке артыннан йөреп адашкан... Син бу турыда сөйләгәч Скандинавия халыкларының бер риваяте искә төште. Имеш, бер үсмер егет һавада очкан бер шундый гүзәл кошны күреп таң кала. Кош моны сизгәндәй якындагы агач ботагына килеп куна. Егет бу кошның гүзәллегеннән, аның сайравыннан һушсыз кала. Егетне котырткандай, кош урман эченәрәк очып керә. Егет башын өскә күтәреп, коштан күзләрен алмыйча бара да бара. Кош беркавым туктап сайрый да, тагын куе урманның эченәрәк очып китә. Егет исә бар дөньясын онытып шул кош артынан бара да бара. Ул вакытны да, узган араны да инкарь итә. Инде бик озак баргач кош югарырак очып китә һәм күздән югала. Ә үсмер егет адаша һәм кире кайтыр юлны тапмый. Гүзәл кош артыннан барып, ул кире кайта алмый. Шуның белән тәмам. Моның мәгънәсе бит болай: чит гүзәллекә омтылып үзеңне югалтуың ихтимал, адашып үзеңнең асылына кайта алмавың ихтимал.

Зариф *(өстә ишетелгән гөрселдәүләрне тыңлап утыралар).* Сезнең Субайда туганнарыгыз калдымы соң әле?

Зыятдин. Анда Әүһәди Һадиулласы дигән агайны беләсеңме? Бик карттыр инде ул хәзер...

Зариф *(җанланып).* Беләм, беләм! Аның улы Саматны да, Самат абыйның кызы Гөлчирәне дә бик яхшы беләм.

Зыятдин. Менә шул Һадиулла бабайлар безнең ерак туганнарыбыз була инде. Башка туган-тумачабызны кулаклар дип барысын да сөргәннәр. *(Йөзе кинәт караңгылана.)* Шулай дип ишеттек.

Зариф. Менә ничек икән...

Зыятдин. Нижгар якларында булганың юктыр?

Зариф. Юк.

Зыятдин. Анда әнием ягыннан туганнарыбыз шактый.

Зариф. Алай икән. *(Землянкада авыр тынлык урнаша.)*

Зыятдин *(Зарифның каефен күтәрергә ниятләп).* Кәрәкә чишмәсенең суы тәмлеме?

Зариф *(елмаеп).* Искиткеч.

Зыятдин. Җиләк хәзер дә күпме?

Зариф. Каен җиләге күп була бездә. Шомырт, чикләвек мул була. Хәер, елына карап.

Зыятдин. Сазлы Күл төнбоеклар чәчәк аткач сап-сары буламы?

Зариф. Әйе.

Зыятдин. Ә урман эчендәге Көмеш Күлнең суы һаман да шифалымы?

Зариф. Безнең якта су гомумән шифалы. *(Шаккатып.)* Карале, боларның барысын да бабаң сөйләдеме?

Зыятдин Әйе. Әти дә бер кайткач шаккаткан булган.

Зариф. Һаман да шул бабаң сөйләгәнчә бит!

Зыятдин. Большевиклар власте урнашкач бүтән кайта алмаган инде алар.

Зариф *(кинәт канатлана).* Зыятдин туган! Синең Ватаның Зәй буйлары, Чулман буйлары! Синең туган ягың Субай җирләре! Әйдә безнең якка чыгарга сора!

Зыятдин *(аптырап карап тора).* Аңламадым?

Зариф *(ялварып).* Зиминга әйт: сезнең якка чыгам, чөнки минем тамырларым Татариядә дип әйт.

Зыятдин. Акылдан яза башладың мәллә?!

Зариф *(Зыятдинны җилтерәтә).* Синең тамырлар шунда—Татарстан җирендә бит! *(Кинәт хәлсезләнә.)* Без шулай гына котыла алырбыз мөгаен.

Зыятдин. Мин синнән мондый тәкъдимне көтмәгән идем.

Зариф *(ыңгырашып).* Харап булабыз бит. Син дә харап булачаксың бит.

Зыятдин. Юк, Зариф, минем ике ватаным бар. Берсе Казан иле, берсе Финляндия. Мина СССР Ватан булалмый. Минем андый үтенеч белән пычранасым килми.

Зариф *(ачуы килә).* Туктале, ни-

чек килеп чыга соң бу! Син татарча җырлап-моңаеп утырган буласың, ә үзең корал күтәреп шул җыр-моң туган илгә каршы сугышасың!

Зыятдин *(тавышын күтәреп)*. Мин ул җыр-моң туган илгә каршы сугышмыйм! Мин үземнең Финляндиямне яклыйм!

Зариф *(ярсып)*. "Үзеңнең Финляндиянне"?! Кешедә ике Ватан була аламы соң?

Зыятдин *(кычкырып)*. Финляндиягә сугыш игълан иткән ил ул синең дә минем дә ватаным булалмый! Бүтән кычкырма миңа! *(Күзләрен йома.)*

Зариф *(хәлсез тавыш белән)*. Сездәге татарлар барысы да Кызыл Армиягә каршы сугышамы?

Зыятдин *(шулай ук көчсезләнгән тавыш белән)*. Мин белгәннәре барысы да. Һәм моның белән чиксез горурланалар. *(Тынлык урнаша.)*

Зариф. Без татарлар бер-беребезгә каршы сугышабыз булып чыгамыни?! Синең бабаң җылый-җылый сөйләгән җир синең өчен изге түгелме?

Зыятдин. Син бер нәрсәне аңлап бетермисең, Зариф туган... Минем бабам туган изге җиргә каршы сугышмыйбыз без. Шул бабаларыбызның җирен таптаган, мыскыл иткән аждаһага каршы сугышабыз. *(Кайдадыр өстә гөрселдәүләр көчәя. Шул тавышларга колак салып бер кавым сөйләшмичә утыралар.)*

Зариф *(кулын Зыятдинның иңенә куя)*. Мин кызып киттем, ахрысы. Зинһар, ачуланма. Мин сиңа мең рәхмәтле— исән калуым өчен.

Зыятдин *(үчекләп)*. Исән калуым өчен... Ә алда сине хурлау һәм төрле мыскыллаулар көтсә, мине каргамассыңмы?

Зариф. Юк, Зыятдин, юк!

Зыятдин. Ә син миңа ачуланма, яме.

Зариф. Ярар.

Зыятдин. Син кем булып эшләдең?

Зариф. Урман үстерүчеләр без нәселебез белән. Ә син?

Зыятдин. Без нәселебез белән сәүдәгәрләр.

Зариф. Хельсинки матур шәһәрме?

Зыятдин. Шундый гүзәл кала! Тик менә бомбага тоталар аны соңгы вакытта.

Зариф. Гаиләң бармы?

Зыятдин. Бар. Хатыным, алты яшьлек улым.

Зариф. Хатының татармы?

Зыятдин. Әлбәттә.

Зариф. Исеме ничек?

Зыятдин. Гөлтан.

Зариф. Матур исем. Ә улыңның аты?

Зыятдин. Раиф.

Зариф. Хатының татарча сөйләшәме соң?

Зыятдин. Миннән дә әйбәтрәк сөйләшә.

Зариф. Улың?

Зыятдин. Улым да татарча сиптерә генә.

Зариф. Гаҗәп! *(Хыялланып.)* Мин шуны уйлап куйдым әле... Алай-болай, могҗиза булып, исән калсак... Суд булыр бит инде. Хөкем иткәндә гаепләребез коточкыч дип тапмасалар исән калырбыз, иншалла. Менә, исән калсак... Барыбер Финляндияне Кызыл Армия алачак, СССР составында булачак бит инде бу тирә... Бер-беребезне эзләп табарбыз... Субайга кайтырсыз. Кунакка йөрешербез.

Зыятдин. Күңелеңнең күтәрелүе бик әйбәт. Тик шуны әйтәсем килә. Шулай да син тилереп барасың бугай. Беркайчан да Финляндияне буйсындыра алмаячаклар. СССРныкы булмаячак безнең ил! Без барыбер җиңәбез! "Маннергейм сызыгы"н үтә алмый сезнең танклар. Безгә барыбер башка илләр дә ярдәм итәчәк. Ул ит чабучы Сталинга Финляндияне Европа бирмәячәк.

Зариф *(тагын кабынмакчы булып)*. Син туган, авызыңны чамалап ач әле! Ату син бигрәк... теге... чаманы бел әле син... Синең каршыңда башкачарак уйлаучы кеше утыра... *(Шулай да үзен кулга алып тынычлана.)*

Зыятдин. Сез барыгыз да корбаннар. Сезне кызганырга гына кирәк. Кеше сөякләре өстендә, кан сеңгән җирдә гөлбакча үстерү мөмкин түгел. Ул сезнең СССР үзенең нәфрәте белән тончыгачак, үзенең канында үзе батачак.

Зариф *(көчкә тыелып)*. Юк, Зыятдин, син мине үтермәгәч тә, миңа әллә нәрсәләр әйтергә хакың бар дип уйлыйсың, ахрысы.

Зыятдин *(елмаеп Зарифны иңеннән коча)*. Ачуың киләме миңа?

Зариф *(башын читкә борып)*. Нишләп килмәсен!

Зыятдин *(илһамланып)*. Зариф, җырла әле туган!

Зариф *(киреләнеп)*. Юк, дошман-

га жыр жырлап утырырга мин...

Зыятдин. Алайса үзем жырлыйм. *(Жырлый. Зариф та түзми, кушылып жырлый башлый.)*

Татар халык жыры
**"Әсирләр моңы".**

Утырдым көймә түренә,
Карадым су төбенә;
Су төбендә асыл таш,
Әсир булды газиз баш.

Безнен илләр кайда диеп,
Кыр казыннан сорадым;
Кыр казлары кыйгылдагач,
Утырдым да еладым.

Өй башында күгәрчен
Укый әлхәм сүрәсен;
Без дә болай булмас идек,
Ходай язган, күрәсен.

*(Беркавым тып-тын утыралар.)*

Зариф. Син миңа үпкәләмә инде, Зыятдин!

Зыятдин. Син дә үпкәләмә!

Зариф. Карале, шулай да дөресен әйт әле—монда махсус максат белән килмәгән иденме соң син?

Зыятдин. Кайда ул—"монда"?

Зариф. Безнең база янына?

Зыятдин. Монда дошман базасы барлыкны сизеп кенә килдем мин. Миңа монда килеп сезнең базаны күзәтеп йөрергә беркем дә кушмады.

Зариф. Ә монда нәрсәләр барлыгын белмисенмени?

Зыятдин. Нәрсә булсын инде. Хәрбиләрнең нәрсәсе булырга тиеш - шулдыр инде.

Зариф. Димәк, бу база турында мәгълүматлар синдә юк?

Зыятдин. Юк. Ә нәрсәләр бар соң монда?

Зариф. Нәрсә булсын инде! Бетле солдатлардан һәм сасы землянкалардан башка ни булсын! Тагын бер сорау бирсәм ачуланырсың инде...

Зыятдин. Сора.

Зариф. Ничә кешебезне атып үтерден?

Зыятдин *(сорауны ошатмый, шулай да коры гына жавап бирә).* Әле берне дә үтерергә өлгермәдем. Жай чыкмады.

Зариф. Без бишәү йөргәндә син безне күзәтеп тордыңмы?

Зыятдин. Әйе. Тик агач башыннан түгел, куаклар арасыннан. Сез базагызга кайтып китәргә жыенганда гына мин агач башына мендем. Сез ашап утырганда мин инде берегезгә төбәгән идем винтовкамны. Инде атып жибәрәм дигәндә ул, никтер, кырыйга янтайды—миңа жайсыз булды. Атмадым, чөнки тигезә алмас идем. Аннары сез бер-бер артлы кузгалгач иң арттагыгызга төбәгән идем. Якында гына бер кош пырхылдап очып китте дә, игътибарымны жәлеп итте. Шул арада барыгызны да агачлар каплады.

Зариф *(уйга калып).* Иң артта Шаталов бара иде. Ходай саклаган Шаталовны. Ә без ашап утырганда... башта син кайсыбызга төбәгән идең икән? Кырыйга янтаючысы кем иде икән? Тасвирлап бир әле.

Зыятдин. Сиңа нигә инде ул?!

Зариф. Белмим, никтер, бу сорау кинәт тынгылык бирми башлады.

Зыятдин. Нинди рәк солдатка төбәгәнемне тасвирлап биримме?

Зариф. Әйе.

Зыятдин. Дөресен әйтимме?

Зариф. Дөресен әйт.

Зыятдин *(Зарифка туп-туры карап).* Сиңа төбәгән идем.

Зариф *(мондый жавапны көтмәгән булган).* Нишләп менә нәкъ миңа? *(Калтыранып ала.)*

Зыятдин *(тыныч кына).* Арада иң зур гәүдәлесе син булгангадыр, мөгаен. Аннары, син снайпер өчен бик жайлы утыра идең—буенны төп-төз тотып.

Зариф *(чыраен сытып).* Димәк, син мине үтерә алгансың?!

Зыятдин. Мин сине пәкеңне эзләп килгәч тә үтерә ала идем.

Зариф. Димәк, без барыбер дошманнар синең белән?

Зыятдин. Үзең өчен үзең хәл ит анысын. Дошман итсәң дошман итәсең инде.

Зариф *(милләттәшенә бик озак карап тора).* Зыятдин! Ничекләр дошман итим соң мин сине! Бу турыда сөйләшеп утырыр вакытмыни! Бу мизгелдә исән, икенчесендә—юк. Казынып утыруда ни мәгънә!

Зыятдин. Бездә менә бу жырны бик яраталар. *(Жырлый. Аңа Зариф та кушыла.)*

Татар халык җыры
**"Галиябану".**

Кара кашым, йолдызым,
Энҗе тешем, гөл йөзем;
Ак чыраен, кыйгач кашын,
Галиябану, сылуым иркәм,
Күреп туймыйдыр күзем.

Йөгерә-йөгерә җыя алмадым,
Җир җиләге пешкәндә;
Һушсыз булып егылып ятам,
Галиябану, сылуым иркәм,
Син исемә төшкәндә.

Энҗе яка, чын ука
Җиргә төшсә уала;
Сине күрсәм күз алдымда,
Галиябану, сылуым иркәм,
Күңелләрем юана.

Җырның уртасында базаны фин самолетлары бомбага тота башлый. Землянка җимерелә һәм аның өстендә ачыклык хасил була. Башта Зариф белән Зыятдин почмакка посып башларын куллары белән каплап утыралар. Төтен белән тузан өере бераз таралгач алар землянканың түшәме җимерелеп ачылган икәнне абайлыйлар. Өсләренә коелган балчыкны каккалап, алар өскә чыгалар. Тирә-якта беркем дә юк. Дөньяны караңгылык баскан. Гөрселдәгән тавышлар ишетелеп тора. Тирә-юньдә бөтен нәрсә җимерелгән, агачлар ауган. Төтен сулышны буа. Гөрселдәүләр ерактарак ишетелә башлый.

Зариф *(як-ягына каранып)*. Финнәр һөҗүм итә. Әллә безнекеләр качканнар инде?

Зыятдин *(кабаланып сөйли)*. Зариф! Ходай безгә шанс бирә. Йөгерик безнең якка. Бу якта харап булабыз икебез дә. Без синең белән монда беркемгә бернәрсә исбатлый алмаячакбыз. Син моны үзең дә беләсең.

Зариф *(ары-бире сугыла)*. Тукта, корал эзлик башта.

Зыятдин *(йөгереп барып Зарифны түшеннән эләктереп җилтерәтә)*. Вакыт әрәм итмик, киттек тизрәк!

Зариф. Киттек! *(Финнәр позициясе ягына кача-поса йөгерәләр.)*

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә әйләнә. Урман. Музыка. Бара торгач Зыятдин белән Зариф урман авызына килеп чыгалар. Туктап хәл алалар. Якында гына финнәрнең оборона сызыгы сузылган. Инде финнәрнең аягүрә басып йөргәннәре дә күренә. Фин телендә сөйләшкәннәре ишетелә. Төрле командалар яңгырый.

Зыятдин *(шатланып)*. Әнә, безнекеләр!

Зариф *(бер дә куанмыйча)*. Әйе, сезнекеләр.

Зыятдин *(фин телендә кычкыра)*. Егетләр! Безгә атмагыз! Без үзебезнекеләр!

Финнәр ягыннан *(фин телендә)*. Әйдәгез, күренегез! Без аңларбыз кем икәнегезне. Әкрен генә килегез монда таба!

Зариф *(катгый карарга килеп)*. Ярый, туган, шушында хушлашыйк.

Зыятдин. Аңламадым!

Зариф. Син бар.

Зыятдин *(котсыз калып)*. Ә син?

Зариф. Мин кире кайтам.

Зыятдин. Кая?

Зариф. Үзебезнекеләр янына.

Зыятдин *(ачуланып җикерә)*. Үзебезнекеләр! Алар сине бетерәчәкләр анда!

Зариф *(җан сызлавын көчкә җиңеп ыңгыраша)*. Мин кире кайтам. Дошман ягына чыкмыйм мин.

Зыятдин *(ялынып, ялварып)*. Котылдык бит инде!

Зариф. Нәрсәдән?

Зыятдин *(Зарифны җиңеннән йомарлап тота)*. Мин сине беркая җибәрмим. Киттек безнекеләр ягына!

Зариф *(үзенең көчле кулын кискен хәрәкәт белән ычкындыра)* Мин дошман ягына чыгарга сатлыкҗан түгел! *(Зыятдин чайкалып чак кына егылмый кала.)*

Зыятдин. Дошман?! Хәзер сиңа кем дошман соң? Минме? Әллә теге канэчкеч НКВД капитанымы? Син, ниһаять, үзеңне кеше дип хис итәчәксең. Син бит белмисең Финляндиядәге кешеләрне. Әйдә, киттек дим мин сиңа!

Зариф *(нык тавыш белән)*. Минем туган илемдә атам-анам, Кәшифәм бар. НКВД капитаны каныңны эчә дип мин алар өчен сатлыкҗан дип аталасым килми.

Зыятдин *(елардай булып)*. Тфү! Син бит туп-туры үзеннең үлеменә таба кайтачаксың кире китсәң. Атып үтермәсәләр дә башың төрмәдә чериячәк бит синен!

Зариф *(тыныч кына)*. Мин төрмәдә утырырга әзер. Үләргә дә әзер. Мин сатлыкжан түгел.

Зыятдин *(нәфрәтләнеп китеп бара, аннары кире килә)*. Соңгы тапкыр әйтәм: әйдә фин ягына!

Зариф. Юк!

Зыятдин. Һай, тиле кеше булып чыктың син, Зариф!

Зариф. Рәхмәт сиңа! Мин мәңге бурычлы сиңа, Зыятдин!

Зыятдин. Нәрсә өчен рәхмәт?!

Зариф. Мине урманда атып үтермәгәнең өчен.

Зыятдин. Нинди рәхмәт?! Хәзер кире кайтсаң, минем өчен синең башыңны бетерәчәкләр. Кире кайтсаң теге капитаннар атып үтерәчәк!

Зариф. Барыбер рәхмәт, туган!

Зыятдин *(нишләргә белми)*. Һай, тиле кеше булып чыктың син, туган!

Зариф *(ихлас күңелдән)*. Рәхмәт сиңа!

Зыятдин *(үгетләүнең мәгънәсе юклыгын аңлап баскан урынында катып тора)*. Үзенә рәхмәт!

Зариф. Мин сиңа бернинди яхшылык эшләмәдем.

Зыятдин. Жырың өчен рәхмәт! Чын кеше булуың өчен рәхмәт! Дөньяда күп түгел мондый кешеләр. *(Кочаклашалар.)* Хуш, туган!

Зариф. Хуш!

Зыятдин. Бәлки инде бүтән күрешмәбез.

Зариф *(елмаерга тырышып)*. Очрашсак та бер-беребезгә мылтык төбәп очрашмасак иде. Туктале... Минем сиңа бер үтенечем бар. *(Куеныннан кульяулыкка төрелгән Кәшифәнең рәсемен ала, аны ачып карап тора.)* Минем язмыш инде хәл ителгән. Мә, ал әле Кәшифәмнең рәсемен һәм кульяулыгын. Кульяулыкны да ул биргән иде. Мине барыбер атарлар инде. Сакла рәсемне дә, кульяулыкны да.

Зыятдин *(тагын өзгәләнеп ялынырга тотына)*. Әйдә киттек фин ягына! Үзе атачаклар ди, үзе кире кайтмакчы була, тинтәк!

Зариф *(кырт кисеп)*. Булды! Күп сөйләшмик! Хуш!

Зыятдин. Тиле! Инде котылдык дигәч... *(Рәсемне алып кульяулыкка төрә һәм үзенең куен кесәсенә тыга.)*

Зариф. Бар. *(Тагын бер тапкыр ирләрчә каты итеп кочаклашалар да икесе ике якка юнәләләр.)*

Музыка.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Базада эш кайный. Снарядларны ашыга-ашыга каядыр күчерәләр. Ящиклар ташучы солдатлар ыгы-зыгы килә. Тезелешеп солдатлар узып китә. Төрле командалар һәм ашыктыру боерыклары яңгырап тора. Яралылар күренә. Ыгы-зыгы. Күтәреп бүрәнәләр ташыйлар. Кыскасы, ярдәмгә тулаем бер полк килеп җиткән һәм базаны ныгыту эшләре кайный.

Уртада, бернигә ригаясез булып, Зариф каткан кар өемендә утыра. Аның кыяфәтеннән битарафлык аңкый. Аның барлыгын әллә сизеп, әллә сизмичә, яныннан солдатлар үтеп китә. Аңа караучы да юк. Зарифны исә бу һич кенә дә гаҗәпләндерми. Берникадәр вакыт узгач, ул хезмәт иткән рота калдыклары кайта. Яралылар бик күп. Йончыганнар, арыганнар, көч-хәл белән атлыйлар.

Зариф рота командиры Лебедевны күреп ала. Лебедев та аны абайлый, ләкин күрмәмешкә салыша. Зариф торып командиры янына бара.

Зариф *(карлыккан тавыш белән)*. Товарищ командир! Товарищ старший лейтенант! Я—не предатель. Я вам всю правду рассказал.

{Иптәш командир! Иптәш өлкән лейтенант! Мин—сатлыкжан түгел! Мин сезгә дөресен сөйләдем.}

Лебедев *(Зарифка карап куя да башын читкә бора)*. Я-то тебе верю.

{Мин сиңа ышанам да бит...}

Зариф. И какой из меня шпион, сами подумайте.

{Үзегез уйлап карагыз, нинди шпион ди инде мин.}

Лебедев *(Зарифка карап тора)*. Я

верю тебе. Это все, что я могу.

{Мин сиңа ышанам. Бары тик шуны гына әйтә алам.}

Зариф. Спасибо.

{Рәхмәт.}

Лебедев. А где "кукушка"? Улетела?

{Ә "күке" кайда? Очып китте мәллә?}

Зариф. Сбежал, наверно. Я без сознания был.

{Мөгаен, качкандыр. Мин бик озак аңымны югалтып яттым.}

Лебедев *(авыр сулап куя)*. Эх, Зариф, Зариф!

{Их, Зариф, Зариф!}

Зариф. Меня скоро, наверно, расстреляют. Я, ползком залез в разваленный блиндаж капитана Зимина. Там паспорт этого финского снайпера лежал.

{Мине тиздән атып үтерерләр инде. Мин капитан Зиминның блиндажына үрмәләп кереп чыктым. Анда теге фин снайперының паспортын таптым.}

*(Куеныннан Зыятдинның паспортын алып Лебедевка суза.)* Возьмите.

{Мәгез.}

Лебедев *(паспортка карап тора)*. Зачем он мне.

{Нигә ул миңа.}

*(Бераз уйлангач.)* Хотя, дай-ка, пригодится.

{Хәер, кирәк булуы да ихтимал.}

*(Зыятдинның паспортын алып шинель кесәсенә тыга.)*

Зариф. Простите меня.

{Кичерегез мине. Ярлыкагыз.}

*(Лебедев бер сүз дәшми китеп бара.)*

Бу вакытта Рассухановны носилкада күтәреп баралар. Зариф аның янына йөгереп килә. Санитарлар туктап ял итәләр.

Зариф *(әкрен генә эндәшә)*. Аслан!

Рассуханов *(башын Зариф ягына бора)* Да.

{Әйе.}

*(Карап ята)*. Зариф?..

Зариф. Я.

{Мин.}

*(Аслан янына тезләнә)*. Куда тебя ранило, Аслан?

{Аслан, кайсы төшең яраланды?}

Рассуханов *(газаплы чырай белән)*. В ногу. Страшная боль.

{Аягым. Үтереп авырта.}

Зариф *(елмаерга тырышып)*. Ничего, потерпи. Санчасть рядом. Туда тоже подмога прибыла.

{Түз инде, түз. Санчасть монда, янәшә генә. Анда да ярдәм килде инде.}

Рассуханов. Не знаешь, какая ужасная боль!

{Белсәң иде ничек авыртканын!}

*(Ыңгыраша.)*

Зариф. Пройдет, пройдет. На, там в госпитале похвастаешься перед медсестрами...

{Төзәлер, төзәлер. Мә, госпитальда шәфкать туташлары алдында мактанырсың...}

*(Кесәсеннән пәке һәм зажигалка чыгара, аларны Асланга бирә.)* На, возьми.

{Мә, ал.}

Рассуханов *(пәке белән зажигалканы ала)*. Ножик же тебе невестка подарила.

{Пәкене бит сиңа кызың бүләк иткән.}

Зариф. Да, она подарила.

{Әйе, аның бүләге ул.}

Рассуханов. Так оставь у себя ее подарок.

{Кызыңның бүләген үзеңдә калдыр инде.}

Зариф. Так меня же судить будут скоро.

{Мине хөкем итәчәкләр барыбер.}

Рассуханов *(зажигалканы әйләндергәләп карый)*. Зажигалка финская?

{Уткабызгыч финнекеме?}

Зариф. Да. Этого... финского снайпера?

{Әйе. Теге фин мәргәненеке.}

Рассуханов. А кто тебе эти вещи вернул?

{Боларны сиңа кем кире кайтарды соң?}

Зариф. Я залез в разбомбленный

блиндаж Зимина... Там все это валялось.
{Зиминның җимерелгән блиндажына кергән идем... Шунда таптым.}

Рассуханов. А этот фин и вправду татарин?
{Ә ул фин чынлап та татармы?}

Зариф. Да. Его дед из соседнего села.
{Әйе. Аның бабасы безнең күрше авылдан.}

Рассуханов. Спасибо за ножик и зажигалку.
{Пәке белән уткабызгыч өчен рәхмәт.}
*(Зариф пәке белән зажигалканы аның шинель кесәсенә тыгарга ярдәм итә.)*

Зариф. Дай Аллах, чтобы быстрее твая рана зажила.
{Алла кушып, яраларың тизрәк төзәлсен.}

Рассуханов. Спасибо. Думаю, после госпиталя увидимся. Нашу роту же не расформируют?
{Рәхмәт. Госпитальдән соң очрашырбыз әле. Безнең ротаны таратмаслар, шәт?}

Зариф *(кинәт карангыланып)*. Мы с тобой уже не увидимся, Аслан.
{Без инде синең белән, Аслан, бүтән беркайчан да очрашмабыз, күрешмәбез.}

Рассуханов. Почему?
{Ник алай?}

Зариф. Меня, наверно, расстреляют.
{Мине атарлар дип уйлыйм.}
*(Рассуханов күзләрен йома. Ыңгыраша.)* Аслан! Я свой! Я и не шпион, и не предатель! Никакой я не враг! Я свой!
{Аслан! Мин шпион түгел! Мин дошман түгел! Ишетәсеңме! Бернинди дә дошман түгел мин!}

Рассуханов. Я знаю, Зариф.
{Беләм, Зариф. Нинди шпион инде син?!}
*(Ыңгыраша.)* Больно мне.
{Хәлем бик начар минем.}
*(Санитарлар аны күтәреп алып китәләр.)*

Алар сөйләшкән арада Шаталов белән Севрюгин кайталар. Агач кәүсәсенә утырып тәмәке көйрәтәләр. Зариф әкрен генә алар яныннан уза. Тегеләр Зарифка карамаска тырышалар.

Зариф *(алар яныннан узганда туктый)*. Ребята, я не предатель! Я свой!
{Егетләр, мин сатлыкҗан түгел!}
*(Тегеләр читкә карап тәмәке тарталар.)* А где Яхно?
{Яхно кайда?}

Шаталов. Погиб Яхно. Из пулемета насквозь прошили.
{Яхно һәлак булды. Пулеметтан... Бөтен гәүдәсе чәрдәкләнгән...}
*(Зариф читкәрәк китә дә карга утыра.)*

Базада эш кайный. Ыгы-зыгы дәвам итә. Зариф уйга чумып утыра. Бераздан Зимин ике солдат ияртеп килә. Солдатлар кораллы. Зиминның кыяфәте яман усал.

Зимин *(кобурасыннан пистолетын чыгара)*. Встать! Руки за спину!
{Тор! Кулларыңны артка куй!}
*(Зариф торып баса, кулларын артка куя. Конвоирлар аны алып китәләр. Алар артыннан Зимин үзе дә бара.)*

Музыка.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Авыр музыка. Сәхнәдә тоткыннар күренә. Болар—Сталин лагереның тоткыннары. Эфирда Зарифның тавышы яңгырый.

Зариф:
—1940 нчы елның март аенда совет-фин сугышы тәмамланды. 12 нче мартта СССР белән Финляндия арасында килешү төзелде. Бу хурлыклы сугышта кем җиңгәнне әйтүе кыен. Әлбәттә, бездә Финляндия җинелде диделәр. Алар территорияләрен югалттылар. Сталинга акча түләделәр. Ләкин минем бөтен уй-кайгыларым кешеләр турында. Кешеләр, кешеләр... Күпме яшь гомерләр өзелде Карел урманнарында. Күпмесе өшеп үлде, күпмесе ачтан җан бирде. Фин пулеметлары күпме кешенең җанын

кыйды. Финляндия үзе дә корбанны күп бирде. Ләкин СССРның югалтулары коточкыч иде.

Карелия урманнарының агачлары кышкы салкында шыкраеп каталар да сәер һәм шомлы авазлар чыгаралар. Игътибар белән тыңласаң, бу күп төрле тавышлар сихри, тантаналы һәм шул ук вакытта күңелгә авыр булып баса торган бер көйгә әверелә. Бу шомлы, моңлы һәм бәгырьне кыса торган көй шунда мәңгегә ятып калганнарга багышланган соңгы җыр булып яңгырый шикелле.

Мине көнбатыш шпионы дип тә көнчыгыш шпионы дип тә исбатлый алмадылар. Фин снайперы белән җырлап утырганым өчен ун ел бирделәр. Шул Карелиядән ерак түгел лагерьларның берсендә мин ун ел гомеремне калдырырга тиеш идем. *(Бу вакытта сәхнәдә тоткыннар эшли. Аларның кыяфәтләре дә, йөрүләре дә өрәкләрнеке сыман.)*

Мин үземә бирелгән җәзага түзәргә әзер тордым. Күз алдымда һәрвакыт атам-анам, Кәшифәм булдылар. Алар алдында мин җавапны ничек тотармын?! Алар турында уйлаганда җанның сызлавына чыдарлык түгел иде. Ләкин түзәргә, түзәргә, исән калырга, яшәргә, гаепсез икәнемне ничек тә булса исбатларга дип үземә гел тукып тордым.

Тик шулай да шушы зольмәт эчендә бер шатлыгым бар иде: Зыятдин—мине исән калдырган миһербанлы җан—үз ягына чыгып котылды бит. Минем аркада ул да харап була дип башта бик кайгырган идем. Ул инде Хельсинкида гаиләсе белән чөркелдәшеп яшидер, үзенең паласларын сатып рәхәтләнеп ятадыр дигән уй мине куандырып торды.

Срогымның бер елдан артыгын утырдым инде... Тагын тугыз ел чамасы калды... Беркемгә хат язмадым, язсам да барып җитәр иде микән?! Атам-анам ут йотып яталардыр... Ә Кәшифә... Кәшифә мине ун ел буе көтмәс дип уйладым мин. Җан газабымны сөйләргә сүзләр җитмәс, җиткән сурәттә дә аны тәфсилләп бәян итәргә йөрәк чыдамас.

Музыка.

Кинәт күк күкри, яшен яшьни. 1941 нче елның 22 нче июне.

Сугыш игълан ы. "Вставай, страна огромная,"—дигән җыр яңгырап куя.

Тагын ерактан гөрселдәүләр ишетелә башлый.

Эфирда татар халык җыры яңгырый.

**"Герман җире яшел үлән."**

Әнкәй мине тапкан-баккан,
Ак биләүгә биләгән лә;
Гомере булсын дип теләгән,
Бәхете булсын димәгән.

Биек тауның башларыннан
Герман таяк ташлаган ла;
Без бәхетсез бала үскәч,
Герман сугыш башлаган.

Утырабыз да китәбез
Кап-кара повозкага ла;
Безнең газиз башлар үскән
Германга закускага.

Без утырган машинаның
Артта кала тәтене лә;
Без дә болай йөрмәс идек,
Йөртә патша хөкеме.

Миндем туры ат биленә,
Чыктым Герман җиренә лә;
Герман җире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.

Зариф:

—Лагерьда утыручыларга штрафбатлар составында сугышта катнашырга рөхсәт бирелде. Мин шундук ризалаштым. Һәм фронтка фашистларга каршы сугышка алып китүләрен зарыгып көттем. Менә ул көн килеп тә җитте. *(Зариф җилкәсенә капчыгын аскан. Таш ташучы тоткыннар янынннан акрын гына уза.)* Ләкин барлык тоткыннарга да рөхсәт булмады сугышка китәргә. Фронтка барырга теләмичә лагерьда калучы тоткыннар да күп булды. Ә кайберәүләрне теләсәләр дә сугышка алмадылар—кылган җинаятенә карап, Совет иленә ни дәрәҗәдә куркыныч булуына карап... *(Зариф тоткыннар яныннан узып барганда кинәт тораташ булып ката.)*

Зариф. Зыятдин! *(Зыятдин башта күрмәмешкә салыша.)* Зыятдин! Синме?

Зыятдин. Мин. *(күз кырые белән генә як-якка карап.)* Ә бу—синме? *(Зыятдин коры сөяккә генә калган. Көчкә басып тора. Кулындагы таш кисәген төшереп җибәрә.)*

Зариф *(нишләргә белми—келәргәме, еларгамы).* Мин! Күрмисеңмени! Ник җавап бирмисең, эндәшкәч?!

Зыятдин *(чак кына ишетелерлек итеп).* Ник кычкырасың. Минем аркада

тагын михнәт күрәсен киләмени?

Зариф *(күзләре яшьләнә).* Син нишләп монда?

Зыятдин *(төссезләнгән күзләре белән Зарифка карап тора).* Әсир төштем.

Зариф *(өзгәләнеп сорый).* Кайчан тагын пленга эләктең соң син?

Зыятдин *(иреннәрен кочкә кыймылдатып сөйли).* Теге вакытта үзебезнең окопларга гына барып җиттем,—сезнекеләр һөҗүмгә күчте. Чолганышта калдык. Әсир иттеләр.

Зариф *(газаплы тавыш белән).* Хәрби әсирләрне дә шушылай интектерәләрмени?! Син бит шыр сөяк кенә.

Зыятдин *(авызын кыйшайтып).* Мин бит гади әсир түгел...

Зариф. Ничек?

Зыятдин. Инде сезнекеләргә бер эләгеп качкан "күке" һәм "диверсант" бит мин.

Зариф. Теге вакытта эләккәненне белделәрмени?

Зыятдин. Белделәр. Синең хакта озак төпченделәр. Кыйный-кыйный. Минем гади снайпер икәнемә ышанмыйлар һаман. Эрерәк балык дип уйлыйлар.

Зариф *(чарасызлыктан нишләргә белми).* Их, Зыятдин, Зыятдин. Мин бит берничек тә ярдәм италмыйм сиңа?

Зыятдин *(Зарифка карап авырлык белән генә елмая).* Үзең дә бик беткәнсең. Кайларда булдың? Син дә утыргансың, ахрысы?

Зариф. Миңа ун ел биргәннәр иде.

Зыятдин. Шул, минем белән җырлап утырганың өченме?

Зариф. Әйе. Бер елдан артыгын утырдым. Сугышка барырга теләүчеләрне фронтка җибәрәләр. Лагерьда череп ятканчы мин фашистларга каршы сугышырга телим. Әйдә, немеска каршы сугышка. Анда хәйләсен табарсың. Сугышка барырга телим, Гитлерга каршы сугышасым килә диген. Теләгән кешене фронтка җибәрәләр. Хәер, барысын да түгел. Зыятдин, ишетәсенме мине. Сорап кара, сине җибәрүләре ихтимал сугышка. *(Йөзендә кинәт өмет нуры балкый.)*

Зыятдин. Мине, беренчедән, фронтка җибәрмәячәкләр. Юк нәрсәләр ягып, сорау алып башыма җитәрләр инде, ахрысы. Икенчедән, синең илең миңа дошман, мин сезнең якта сугыша алмыйм.

Зариф *(ачынып).* Син һаман үз киреңне сукалыйсың.

Зыятдин *(көлемсерәп).* Синең кебек кире инде. Татарда кирелек бар бит инде ул.

Зариф *(ялварып).* Котылу чарасын уйларга кирәк, Зыятдин! Фронтка җибәрүләрен сора... Аннары хет кайсы якка чык. *(Тешләрен кысып үтенә.)* Хәйләләп кара инде, Зыятдин!

Зыятдин *(башын чайкап тыныч кына җавап бирә).* Юк, Зариф! Юри генә булса да йолдызлы пилотканы беркайчан кимим мин!

Зариф. Бәхәсебезнең кирәк түгеллеге, мәгънәсезлеге, урынсызлыгы аңлашыла. Ярый...

Зыятдин. Сугышта саграк бул инде. Исән-сау әйләнеп кайт. Ләкин лагерьга әйләнеп кайтма. Атаң-анаң, Кәшифәң янына әйләнеп кайт.

Зариф *(күз яшьләрен тыя алмый).* Тагын бер кат рәхмәт сиңа! Мин инде сине котылып өеңдә ятасындыр дип уйлаган идем. Мин ышанам, җибәрерләр сине. Әсирләрне үз илләренә бирергә тиешләр. Түз инде, чыда. Бирешмә.

Зыятдин. Син дә сугыштан исәнсау кайтып җит.

Зариф. Минем аркада интегәсең шикелле.

Зыятдин. Ә миңа син минем аркада җәфа чигәсең шикелле. Штрафбатта булачаксыңмы?

Зариф. Әйе. Рәхмәт, Зыятдин, исән калуым өчен.

Зыятдин. Сине татар җыры коткарды. Татар җырын ишетмәгән булсам, аткан булыр идем. Татар җырына, татар теленә рәхмәт укы!

Конвой *(акыра).* Эй, ну-ка отойди от заключенного.

Зыятдин. Бар, Зариф. Минем белән сөйләшкәнең өчен тагын берәр матавык килеп чыкмагае.

Зариф *(читкәрәк китеп).* Сиңа күпме бирделәр соң?

Зыятдин. Белмим. Хуш!

Зариф. Хуш! *(Зариф китә. Зыятдин таш кисәген күтәреп калкулыкка таба атлый.)*

Авыр һәм көчле музыка.

## ЖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кәшифә өйдә нәрсәдер бәйләп утыра. Жырлый.

Татар халык жыры
**"Кошларга".**

Һаваларда очкан кошкайларның
Кунганнарын күрдем киртәгә;
Мәхәббәтем көчле, янган утлар төсле,
Сүнмәс, бәгърем, иртә дә, кичтә дә.

Һаваларда очкан кошкайларның
Күнелле икән шаулап үтүе;
Авыр икән, дуслар, сөйгән ярны озату,
Тагы да авыр сагынып көтүе.

Һаваларда очкан кошкайларым,
Әйтегезче сагынып көтүем,
Аны уйлый-уйлый, күзем йокы алмый,
Йокысыз төннәрем үтүен.

Жыр фонында Зариф сөйли.

Зариф:
—Штрафной батальоннар турында күп ишеткәнегез бардыр. Ләкин сөйләгәнне тыңлап кына ул мәхшәрне тулысынча күз алдына китерү мөмкин түгел. Сугышның иң канлы, иң коточкыч төбәкләренә ташладылар безне. Кайвакыт бер фашист дотын алганда бер ротадан өч-дүрт кеше генә исән кала иде. Бөтенләй кеше йөрмәслек сазлыклардан штрафбатны үткәрәләр һәм батальонның дүрттән бер өлеше генә исән калып атакага күтәрелә иде. Мин алты немец таныгын яндырдым. Дүрт немесне кулга алып частька алып кайттым. Анын берсе полковник чинында иде. Офицер иттеләр. Капитанга кадәр күтәрелдем. Батальон белән командалык иттем. Минем батальон бер тулы СС полкын юк итте. Белоруссиядә булды бу. Шунда мин каты яраландым. Полный кавалер орденов славы идем инде батальонны кабул иткәндә үк. Берлинга кадәр үк барып житеп булмады. Шулай итеп, капитан званиесендә, мин, полный кавалер орденов славы, туган ягыма кайтып киттем.

Кәшифә белән өйләнештек. Бәрәкәт урманында бәрәкәтле тормыш корырбыз дип хыялланып яши башладык.

Фронтта да, өйгә кайткач та мина көн саен диярлек Зыятдиннын язмышы тынгылык бирмәде. Кабат-кабат уйлыйм да, гел минем аркада харап булгандыр шикелле тоела.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Зариф белән Кәшифә үз өйләрендә. Кәшифә йокле. Өстал тирәсендә кайнаша. Зариф тастымал белән битен, муенын сөрткаләп өстал янына килә. Йөргәндә бераз аксый.

Кәшифә. Ашыйсың киләме?

Зариф. Кичкә бәрәңге пешерерсен.

Кәшифә *(иренең күнелен ничек булса да күтәрергә тели)*. Ашаганнан соң аякларына теге суны сыларбыз.

Зариф *(кашларын жыерып)*. Сина кем әйтте соң ярдәме тия дип?

Кәшифә. Бөтен әбиләр шулай ди. Мин нәкъ алар әйткәнчә жыйдым үләннәрне дә, пешектерүен дә нәкъ аларча эшләдем.

Зариф. Снаряд кыйпылчыклары кергән жирләр бәлки төзәлер дә...

Кәшифә. Хәзер менә сызламыйдыр бит?

Зариф. Юк. Төнлә кинәт сызлап куя. Аннары, һава торышы бозылгач.

Кәшифә *(елмаеп иренә карап тора)*. Бетерәбез ул сызлауларны, бетерәбез.

Зариф. Тән жәрәхәтләре бәлки төзәлер дә, менә жан газабын нинди үләннәр белән дәвалап була икән? *(Уйга чума.)*

Кәшифә *(авыр сулап)*. Син сугышта күргәннәрең белән бимазаланасың һаман... Тиз генә онытылмас инде ул. Менә балабыз тугач, уйларың башка юнәлеш алыр, караңгы хәтирәләрең дә бәлки югалыр.

Зариф. Мин сина фин татары Зыятдин турында сөйләгән идем бит...

Кәшифә. Әйе.

Зариф. Мине аның язмышы нык

борчый. Исән микән? Лагерьда үлде микән... Нишләттеләр икән?

Кәшифә. Син анысын белешә алмыйсың инде.

Зариф *(газапланып)*. Мин бит үзләренекеләр ягына чыгып киткәч, инде котылды дигән идем... Үземне барыбер атарлар дип синең рәсемең белән кульъяулыгыңны да аңа биреп җибәргән идем. Менә—мин исән, ә ул...

Кәшифә *(өметле тавыш белән)*. Ул да исәндер. Күпме кеше төрмәләрдән кире әйләнеп кайтты. Фин татарын гына нишләп үтерерләр икән.

Зариф. Ә күпме кеше кайтмады! Күпмесе юкка чыкты.

Кәшифә *(иренең каршысына килеп утыра)*. Зариф, тынычлан инде, зинһар. Син генә бернишләтә алмыйсың бит инде хәзер.

Зариф. Аңа бит гади әсир итеп карамадылар. Монда бит минем дә гаебем бар булып чыга...

Кәшифә *(өзгәләнеп)*. Нинди гаебең булсын инде аның алдында. Син гел шулай үзеңнән үзең гаеп эзләп, үзеңне үзең ашыйсың.

Зариф *(кинәт җанланып)*. Ничек уйлыйсың, шул лагерьга хат язып белешсәм?..

Кәшифә *(пошаманга кала)*. Җүләрләнден мәллә?! Үзеңне дә шунын янына утыртып куячаклар. Тагын да ныграк шикләнә башлаячаклар.

Зариф. Акыллы хатын син. Аңлыйсың. Ләкин миңа бик авыр ул кешенең лагерьда калуын искә төшерү.

Кәшифә. Анысы шулайдыр да.

Зариф *(ныклы тавыш белән)*. Хат язып белешсәм була инде. Мин бит кавалер орденов славы. Офицер. Батальон командиры. Мин бит Туган ил өчен, Сталин өчен кан койган кеше. Гаебем булган сурәттә дә, кан белән юдым бит мин гаебемне. Мин үземә атмаган, исән калдырган кешенең язмышы белән кызыксына алмыйммыни?!

Кәшифә *(еламсырап)*. Сиңа бит шул кеше аркасында инде ун ел биргәннәр иде. Штрафбатларда да шуның аркасында череден.

Зариф. Кәшифә, алай димә. Аның аркасында димә. Ул миңа гомеремне бүләк итте 1940 нчы елның гыйнварында.

Кәшифә. Алладан курыккандыр. Шуңа атмагандыр.

Зариф. Әйе, бәлки шулайдыр. *(Бераз кызып.)* Ә менә үзебезнекеләр Алладан куркып тормадылар. Судсыз-нисез аттылар. Лагерьларда исә хайван урынына гына күрделәр.

Кәшифә. Ул сине татар булганың өчен үтермәгән. Татар икәненне белә торып та аткан булса нәрсә була инде ул...

Зариф. Ничек аңлатырга икән сиңа... Һәрбер татар шулай икенче бер татарны коткарырга әзерме соң?

Кәшифә. Татарча җырлап утыручы кешегә үзең атар идеңме?

Зариф *(ачусыз гына)*. Кәшифә, бәгърем, акыллы дигәч, син бигрәк, артыгын ук сөйли башладың.

Кәшифә. Ярар, ярар, артыгын сөйләмим. *(Чак кына ишетелерлек итеп.)* Мин сине озак көттем, Зариф. Инде сине тагын югалтудан куркам.

Зариф. Әгәр дә ул хәзер дә лагерьда икән, мин аны коткарырга тырышырга тиеш.

Кәшифә *(өзгәләнеп)*. Тагын шпионлыкта гаепләячәкләр бит үзеңне. *(Пышылдап.)* Минем йөкле икәнемне онытма. Без инде хәзер өчәү, Зариф.

Зариф *(күңеленә шундук шатлык керә)*. Авырлы хатынга җырларга ярый микән?

Кәшифә *(көлә)*. Нишләп ярамасын.

Зариф *(ягымлы тавыш белән)*. Җырла әле, зинһар, Кәшифә, җырла, җанкисәгем!

Кәшифә. Хәзер. *(Зариф каршысына утырып әкрен генә җырлый.)*

**"Саннар."**

Күбрәк сана, кәккүк, күбрәк сана,
Санга сугып санар саннарны,
Гомер дисбесенең төймәләрен -
Икәү бергә узар елларны.

Күп санама, кәккүк, күп санама
Башка төшәр хәсрәт саннарын;
Өметләрем инде бер өзелсә
Сине бүтән тыңлый алмамын.

Саный кәккүк үзе белгән көйгә
Айлы төнне, алсу таңнарны;
Ә йөрәкләр үз көенә тибә
Санламыйча сансыз саннарны.

Зариф *(хатынын кочаклап алдына утырта)*. Рәхмәт! Әй, Кәшифә, ярый син бар әле.

Кәшифә *(сикереп тора)*. Аякла-

рын болай да авыртып тора. Ә син алдына утыртасың һаман.

Зариф *(кулын селти)*. Аннан гына авыртырлык булса аяк буламыни ул.

Кәшифә *(иренен кәефе күтәрелгәнгә чиксез шатланып)*. Ул Зыятдин инде күптән Хельсинкиенда яшәп ятадыр.

Зариф *(кинәт житдиләнә)*. Мин аны табарга тиеш.

Кәшифә *(котсыз калып)*. Үз акылыңдамы соң син?! Тагын үзенә бәйләнә башлаячаклар!

Зариф *(усал тавыш белән)*. Хәзер мина бәйләнсәләр дә, бәйләнмәсәләр дә инде мин үземнең кем икәнемне исбатладым. Минем кем икәнемне бергә сугышкан иптәшләрем белә, батальоным белә, югары командование белә, хәтта Мәскәүдә дә беләләр!

Музыка. Сәхнә караңгылана. Сәхнә яктыра. Зариф атылып килеп керә. Бераз аксый.

Зариф *(бусагадан ук кычкыра)*. Кәшифә! Сугыш беткән!

Кәшифә *(аралыктан килеп чыга)*. Уф, котымны алдың!

Зариф *(шатлыктан ярылырдай булып кычкыра)*. Сугыш бетте!

Кәшифә. И, Ходаем. Чын микән?!

Зариф. Радиодан үзем ишеттем. Жиңдек, жиңдек, жиңдек! *(Кочаклашалар.)*

Кәшифә *(нишләргә белми)*. Матуррак күлмәк киим микән әллә?! *(Арыбире сугыла.)*

Зариф. Ки. Ни кисәң дә гүзәл син. Сылу кешегә солы капчыгы да килешә, ди. *(Көләләр.)*

Кәшифә нишләргә белми. Кабалана-кабалана йөри. Икенче бүлмәгә чыгып китә. Зариф үзенең хәрби киемен кия. Орден-медальләре ялтырый. Көзге каршына килә. Кәшифә икенче бүлмәдән матур күлмәк киеп йөгереп чыга.

Кәшифә *(иренә мәхәббәтле күз карашы белән карап)*. О-о-о! Менә бу егет ичмаса!

Зариф *(тел шартлатып)*. Шулай булырмын мин. *(Кәшифәгә сокланып карап тора.)* Синме бу?! Мондый чибәр кыз минем хатыным була ала микәнни?!

Кәшифә *(оялган булып)*. Әй, кыланма әле! *(Ире каршына килеп баса. Кыланып честь биргән була.)* Иптәш капитан Күке Зариф! Әйдә, Субайга барып кайтабыз!

Зариф *(хатынын кочып ала һәм житди тавыш белән әйтә)*. Бәгърем, мин ерак сәфәргә чыгарга булдым.

Кәшифә *(иренен кочагыннан шуып чыга)*. Нинди сәфәргә, ник һаман кыланасың инде! *(Пауза.)* Әйдә, берәр жиргә барып кайтыйк әле. Карале, көн ничек матур бүген?!

Зариф *(катгый карарга килеп)*. Кәшифә, жаным! Мин теге лагерьга барып кайтырга тиешмен.

Кәшифә *(сискәнеп)*. Нинди лагерьга?

Зариф. Зыятдин утырган лагерьга.

Кәшифә *(ачыргаланып)*. Үз акылыңдамы син?!

Зариф *(хатынын юатырга тырышып ягымлы тавыш белән)*. Мин тиз арада әйләнеп кайтачакмын. Минем бурычым ул анда бару, аның язмышы белән кызыксыну. Югыйсә мин мәңге жан тынычлыгына ирешмәячәкмен.

Кәшифә *(елый)*. Күнелем сизә, бәлага тарыгачаксың. Нинди тынгысыз кеше булдың соң син?!

Зариф. Елама, Кәшифә!

Кәшифә *(ыңгырашып)*. Харап буласың бит.

Зариф *(көр тавыш белән)*. Мин—офицер! Зыятдинның язмышы белән кызыксынмасам, мин офицер гына түгел, кеше дә булалмыйм! *(Кәшифә елый.)*

Музыка.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Сәхнәдә караңгылык. Сәхнә яктырганда подполковник званиесендәге бер кеше тәрәзәдән тышка карап тора. Зариф шулай ук үзенең хәрби киеменнән килеп керә.

Зариф. Разрешите. *(Подполковник борылмый.)* Вы—начальник лагеря?

Подполковник *(теләр-теләмәс кенә борылып баса)*. Да.

Зариф. Здравия... желаю... *(Зариф шакката—аның каршында Зимин басып тора.)* Вы...

Зимин *(коры гына)*. Я—начальник лагеря. А вы кто будете?

Зариф. Я капитан Зайнуллин.

Полный кавалер орденов славы.

Зимин *(бер дә гаҗәпсенмичә).* Вижу, вижу.

Зариф. Вы должны меня помнить.

Зимин *(авыз кырые белән генә елмая).* Как же не помнить-то. *(Шундук татарчага күчә.)* Хәтерлим мин сине. Тик син ул вакытта герой түгел идең, ә киресенчә... Утыр. *(Өстәле янына барып утыра.)*

Зариф *(аның каршына килеп утыра).* Сез лагерь начальнигы икән?..

Зимин. Партия кая куша—шунда барабыз инде хезмәткә. *(Зарифны жентекләп күзәтә.)* Кайда тәмамладың сугышны?

Зариф. Белоруссиядә. Берлинга ук барып җитеп булмады. Каты яраландым.

Зимин. Берлинга барып җитмәсәң дә, көченнән килгәнне эшләгәнсең—герой булып кайткансың. Молодец, молодец. Штрафниклардан сирәк кешене болай зурлап данлыйлар. Офицер булгансың. Монда килгәч, мин синең хакта кызыксындым. Фронтта диделәр.

Зариф *(үз күзләренә һаман ышанып җитми).* Мин сине монда очратырмын дип уйламаган идем.

Зимин. Мин дә сине кабат бу лагерьда күрермен дип уйламаган идем. *(Серле һәм шомлы итеп елмая.)* Сагындырдымы мәллә?

Зариф *(кыяфәтенә салкынлык йөгерә).* Синең юморны кабул италмыйм мин.

Зимин *(папирос кабызып тарта).* Әйе, мондый сугышлардан соң нинди юмор хисе калсын кешедә.

Зариф *(саклык белән генә сорап куя).* Фин снайперын хәтерлисеңме?

Зимин *(кашларын җыерып).* Нинди снайперны?

Зариф. Финляндия татары...

Зимин *(бераз уйланып утырганнан соң).* Ә-ә-ә, нишләп хәтерләмәскә. Күке! *(Көлемсерәп.)* Карале, синең дә кушаматың "күке" иде түгелме? *(Зарифның түшендәге орденнарга карап.)* Мондый геройга хәзер инде алай дәшмәсләр.

Зариф *(гасабиланып).* Мин төкерәм ничек дәшүләренә! Ул кешене мин фронтка китәр алдыннан шушы лагерьда күрдем.

Зимин. Ничек монда булсын ул?! Кырыгынчы елны үзләренең ягына качкан "күке" син кырык беренчедә сугышка киткәндә ничек монда булырга мөмкин?!

Зариф *(кызып).* Мин бит аны күреп сөйләштем. Алар таш ташуда иде.

Зимин *(папиросын сүндереп көл савытына ташлый).* Белмим, белмим. Ничек монда килеп эләккәндер ул. Хәер, монда күпмедер хәрби әсирләр булган. Ну, аларны илләренә озатканнар. Тә-ә-әк, син аны монда кырык беренче елны күргәнсең... *(Уйга кала.)*

Зариф. Кырык беренче елны. Үз күзләрем белән күрдем.

Зимин. Мин бит кырык икенче елның көзендә генә килдем монда эшкә. Папкаларны күтәрербез. Эзләве авыр булыр, чөнки монда күпме кеше утырган бит, малай, һәм дә ки хәзер күпме утыра—коточкыч. Кайберәүләр арасында хәтта теркәлмәгәннәре дә бар.

Зариф. Зыятдинны теркәми калмаганнардыр.

Зимин. Кемне дисең?

Зариф. Зыятдинны.

Зимин. Ә-ә-ә, бу теге "күке"нең исеме, шулай бит?

Зариф. "Телсез Күке". Атмады ул.

Зимин *(уйланып).* Әйе, сиңа атмаган ул.

Зариф *(таләпчән тавыш белән).* Мин Зыятдинның язмышы белән кызыксынып килдем!

Зимин *(Зарифка ачуы килгәнне күрсәтмәскә тырышып).* Аларны партиялап-партиялап туган илләренә озаттылар. *(Елмаеп.)* Ул да инде үзенең Финляндиясендә безне сүгеп, кыҗрап ятадыр.

Зариф. Ул бик ябык, хәлсез иде. Үлмәде микән?

Зимин *(сабыр гына).* Белешермен, белешермен. *(Кинәт күзләрендә явызлык очкынлап ала.)* Аның язмышы белән кызыксынырга курыкмыйсыңмыни?

Зариф *(Зиминга текәлеп карый).* Анламадым?

Зимин. Син хәзер фашистны җиңеп кайткан боевой офицер, полный кавалер орденов славы.

Зариф. Әйе, шулай...

Зимин. Гаилән бармы?

Зариф. Бар.

Зимин. Гаилән белән тыныч кына, унга-сулга карамыйча, тегендә-монда тыгылмыйча яшәп ят. Нишләп үзеңә мажаралар эзләп йөрисең?

Зариф. Мин Зыятдинның язмышын мәгълүм кылмыйча тыныч яшәп ята алмыйм.

Зимин. Син үзгәрмәгәнсең икән.

**Зариф**. Әйе, мин шул ук! Кешеләр барысы да син теләгәнчә бертөрле булмаячак беркайчан да!

**Зимин** *(кисәтүле тавыш белән)*. Син тагын баткаклыкка таба кереп барасың түгелме?

**Зариф** *(каты ачу белән)*. Нинди баткаклыкка?! Мин анлыйм нәрсә әйтергә теләгәненне!

**Зимин** *(күзләрен кыса төшеп)*. Аңласаң бик яхшы.

**Зариф** *(тавышына ялвару төсе кертеп)*. Мин үтенәм, әйт мина, исәнме ул? Исән булса, ул кайда хәзер?

**Зимин** *(салкын тавыш белән)*. Мин белешермен. Тик син үзеннең язмышынны катлауландырырга маташасың, ахрысы.

**Зариф** *(ачыргаланып)*. Тагын ничек катлауландыру мөмкин соң безнең язмышларны, иптәш подполковник! Мин катлаулы язмышларны үзем белән янәшә сугышкан штрафниклардан ишетеп чак кына акылдан язмадым! Төрмәләрдән чыгып утка кергән егетләрнең яртысыннан күбесе бер гаепсез кешеләр иде!

**Зимин**. Ә син каян беләсең, гаеплеме-юкмы?! Үзләре сөйләгәннән генәме?

**Зариф** *(кызып-кызып сөйли)*. Анда кем ялган, кем дөресен сөйли—шундук күренә. Үлем белән күн саен күзгә-күз карашучы унсигез яшьлек егет, беләсенме, ни өчен төрмәгә утырган булган? Аның атасын донос буенча атканнар. Имеш, Сталинны ачуланып нәрсәдер әйткән. Ә шул егетнең үзен, шикаять язучының битенә төкергәне өчен, биш елга утырталар. Сугыш башлангач бу егет фронтка җибәрүләрен үтенеп сорый. Минем батальонда сугышты. Авианалеттан соң мин бу егетне носилкада күрдем. Чәрдәкләнеп беткән һәм канга баткан иде. Актык сулышын алганда мин аның янында тордым. Күз яшьләремне тыя алмадым—шунда, солдатларым янында елап җибәрдем. "Берәр үтенечен, теләгең юкмы миңа?"—дип сорадым мин аңардан. Беләсенме, ничек дип җавап бирде?

**Зимин**. Ничек дип?

**Зариф**. "Иптәш капитан, минем атам да, үзем дә халык дошманы түгел,"—дип ыңгырашты.

**Зимин** *(үгет-нәсихәтле тавыш белән)*. Минем сина бер киңәшем бар: артык ихласланма. Күңелендәген ачып, әйтергә кирәкмәгәнне әйтеп ташлый торган гадәттән арынырга иде сина.

**Зариф**. Әйе, син минем гадәтләрне беләсен... Юкса кырыгынчы елны ун елга хөкем итмәсләр иде...

**Зимин** *(кинәт кырысланып)*. Мин хөкем итмәдем сине. Трибунал хөкем итте.

**Зариф**. Материалны әзерләүче син булдың бит.

**Зимин**. Әйе, мин. Ә нәрсә. Син мине шунын өчен битәрләргә дип килдеңме?

**Зариф**. Юк.

**Зимин** *(җикереп)*. Рәхмәт әйт, партиягә, иптәш Сталинга—ун ел урынына сина ышанып кулына корал тоттырганы өчен һәм үзеннең Ватан алдындагы гаебеңне кан белән юарга мөмкинлек биргәннәре өчен!

**Зариф** *(теш арасыннан ысыллап)*. Син усалланма! Кемгә нинди рәхмәт әйтү—минем шәхси эшем!

**Зимин**. Ә син шулай да үз урыныңны бел.

**Зариф**. Мин аны бик яхшы беләм.

**Зимин** *(һаман тынычлана алмый)*. Синең кебек геройлар бик күп кайтты фронттан! Барысы да синең кебек амбицияләр белән йөри башласа тәртип булмаячак.

**Зариф** *(мыскыллап)*. Тәртип урнаштыру өчен сез бар бит.

**Зимин**. Чәнчүләп сөйләшмә! Әйе, без бар. Һәм пока без бар, тәртип булачак. Беребезнең дә язмышы җинел түгел. Беребез дә үз ихтыяры белән яшәми. Без һәммәбез хезмәтчеләр, безнең һәрберебезнең үз урыны, үз вазифасы, үз миссиясе бар. *(Тагын папирос кабызып тарта.)*

**Зариф** *(тыныч булырга тырыша)*. Шулай. Мин үтенеч белән килдем. Зинһар, ярдәм ит Зыятдин турында белешергә.

**Зимин**. Ник кирәк ул сина?

**Зариф**. Мин бурычлы ул кеше алдында.

**Зимин**. Нинди бурычың калды?

**Зариф**. Ул мина атмады. Мин хәзер исән булмас идем, әгәр ул аткан булса?!

**Зимин**. Шуннан?

**Зариф**. Соң, әйтәм бит: үземне аның алдында бурычлы итеп тоям.

**Зимин** *(авызын кыйшайтып елмая)*. Син тагын ачыктан-ачык сөйлисен. Бик яхшы. Сөйлә. Фин әсирен эзләп йөрүче кеше турында ни уйларга тиеш

мин? Ә?! Контрразведка нәрсә уйларга тиеш? *(Зарифка таба сузылып пышылдый.)* Мин сина киңәш итәм: бар, кайтып кит, йөрмә монда.

Зариф *(кырт кисеп).* Юк! Син беләсең ул кеше турында!

Зимин. "Күке" турындамы?

Зариф. "Телсез Күке".

Зимин. Әйе, беләм. *(Тавышын күтәрә.)* Беләм! *(Чак кына ишетелерлек итеп.)* Белгән сурәттә дә мин бит сер итеп сакларга тиеш теге яки бу әсир турындагы мәгълүматларны.

Зариф *(тавышын әкренәйтеп).* Исәнме ул?

Зимин. Исән.

Зариф. Кайда ул?

Зимин *(папиросын тирән итеп суыра).* 1944 нче елны Финляндиягә унсигез әсирне кайтарып җибәрделәр. Шулар арасында ул да бар иде. Нишлисең бит, дүрт ел утырды инде утыруын лагерьда... Әгәр дә ул безнең серле снарядлар яшерелгән база тирәсенә килеп чыкмаган булса, аны утыртмыйлар иде. Аны бит шул тикшерү өчен дүрт ел тоттылар.

Зариф *(Зиминга озак карап тора).* Минем турында да бик озак иснәнеп йөргәннәр туган ягымда. Хәтта лесхозга эшкә килгән булып, безнең нәсел турында төпченеп ятканнар. Сезнең чекистлар эше бит инде бу.

Зимин. Кем әйтте?

Зариф. Якташларым лесхозга читтән килеп яшәүчеләр турында сөйләделәр. Кайдан һәм кемнәр икәнен үзем сизендем, аңладым.

Зимин *(елмаеп).* Сизгер үзең тагы...

Зариф. Хәтта фронтта да минем сөйләшүләрне гел особистка җиткереп торалар иде.

Зимин *(үтә дә эшлекле кыяфәт белән).* Сугыш вакытында башкача булалмый инде ул. *(Папиросын сүндереп урыныннан кузгала.)* Аның каравы, син исән! Шаталовны хәтерлисеңме?

Зариф. Әйе.

Зимин. Одессаны фашистлардан саклаганда һәлак була. Севрюгин Воронеждан иде бит. Ул немец оккупациясендә кала. Германиягә куалар. Шуннан хәбәре юк. Пропал без вести.

Зариф. Ә Рассуханов?

Зимин *(әйтергәме-юкмы дип уйлап тора).* Чеченнарның эшләре катлаулырак килеп чыкты шул...

Зариф *(борчулы тавыш белән).* Ул да высылкага эләкте микәнни?

Зимин. 44 нче елда аларның барысын да сөрделәр... Күпмесендер Казахстанга, күпмесендер ераграк.

Зариф *(уйга чума).* Ай-яй.

Зимин *(килеп Зарифның иңенә кулын куя).* Ихлас күңелдән әйтәм: синең исән-сау булуыңа мин шат. Күрүемә дә шат.

Зариф *(утырган урыныннан тора).* Димәк, Зыятдинны кырык дүртенче елны кайтарып җибәрделәр.

Зимин. Әйе.

Зариф. Ярый... *(Кәефе күтәрелә.)* Нинди яхшы хәбәр!

Зимин. Күңелең булдымы? *(Елмаеп.)* Ярый, дустым, исән-сау бул. Бөтен дөнья өчен уйланып, кайгырып утыру дөрес түгел.

Зариф. Димәк, Зыятдинны Финляндиягә озаттылар?

Зимин *(көлә).* Әйе, тынычлан. Бар, кайт. Йөрмә үзеңне үзең бимазалап.

Зариф. Ярый, киттем. *(Ишеккә таба юнәлә.)*

Зимин. Сау бул!

Зариф. Киттем. *(Чыгып китә.)*

Шомлы музыка. Сәхнә карангылана. Зимин телефоннан шалтырата.

Зимин. Приведите! *(Бүлмә буйлап ары-бире йөри.)*

Зыятдинны алып керәләр. Ул бөтенләй хәлсез, ябык һәм бөтен кыяфәтеннән битарафлык аңкый.

Зимин. Утырыгыз! *(Зыятдин килеп утыра. Күзләре төссез—Зиминга карый, ләкин аны күрми шикелле, әйтерсең лә аның аша каядыр бушлыкка карый.)* Сез кем?

Зыятдин *(каядыр төпсез бушлыкка караган сыман).* Галиәкбәр улы Зыятдин.

Зимин *(җанбиздергеч тоныкк тавыш белән бер-бер артлы сорау бирә).* Тагын?

Зыятдин. Әсир.

Зимин. Тагын?

Зыятдин. Мин—Финляндия татары.

Зимин. Тагын?

Зыятдин. Мин совет-фин сугышында әсир төштем.

Зимин. Анысын әйттең. Тагын?

Зыятдин. Шуның белән тәмам.

Зимин *(барып урынына утыра).* Юк, тәмам түгел. Әйт дөресен, 1940 нчы елда теге безнең база турында кем әйтте сиңа?

Зыятдин. Беркем дә әйтмәде.

Зимин. Ә каян белдең?

Зыятдин. Белмәдем.

Зимин. Нәрсә иде ул базада?

Зыятдин. Белмим. *(Тәмам хәлсезләнә. Зиминга карап тора. Һәрбер сүзен бик авырлык белән генә әйтә.)* Сез акылга зәгыйфь түгелдер бит? Ул базада нәрсә барлыгын миннән сорыйсыз. Каян белим мин. Сезнең база бит ул.

Зимин *(тешләрен шыгырдатып).* Тәмам туйдым мин синнән.

Зыятдин *(әкрен генә).* Атып үтерегез мине.

Зимин *(ямьсез итеп елмая).* Юк, суд сине атарга хөкем итмәде. Мин синнән барыбер барысын да сөйләтәчәкмен.

Зыятдин *(ишетелер-ишетелмәс кенә).* Нәрсә сөйләтмәкче буласың?

Зимин. Зариф белән беренче тапкыр кайчан таныштыгыз?

Зыятдин. Мин сезгә инде мең тапкыр әйттем. 1940 нчы елның гыйнварында. Урманда. Сезнең базагыздан ерак түгел.

Зимин *(урыныннан торып Зыятдин янына килә).* Аның белән элемтәгә кайсы разведоешма аркылы кердегез?

Зыятдин. Нинди разведка?! Ул да, мин дә бернинди разведка кешеләре түгел.

Зимин *(кабинеты буйлап йөри).* Безнең агентлар Зариф торган якларны нык айкадылар. "Күке" кушаматын аңа тагулары бик сәер—ул сөйләгәнчә үк килеп чыкмый.

Зыятдин. Кушаматның ни катнашы бар монда.

Зимин. Ул сине күке диде. Ләкин "Телсез Күке" диде. Бу нәрсәне аңлата? *(Зыятдин янына килеп текәлеп карап тора.)*

Зыятдин. Атмаганым өчен әйткәндер.

Зимин *(үчекләп).* "...Дер"!.. *(Күзләрен чекрәйтеп.)* Ничек уйлыйсың, хәзер кайда ул?

Зыятдин *(күзләрен йома).* Кем?

Зимин. Зариф.

Зыятдин *(көч-хәл белән сөйләшә).* Ул сугышка киткән иде.

Зимин. Мәгълүм ки, сугыш бетте... *(Барып графиннан су эчә.)*

Зыятдин. Исән булса кайткандыр инде.

Зимин *(авызын кыйшайтып елмая).* Исән ул.

Зыятдин *(бераз хәл кергәндәй була).* Исәнме?

Зимин. Исән. Тик менә нишләп синең язмыш белән кызыксынмый икән ул?

Зыятдин *(иреннәрен көчкә кыймылдатып).* Ул бит нинди илдә яшәгәнен белә. Артыннан гел күзәтеп торуларын да сизенә... Аннары, нишләп әле ул минем язмыш турында кайгыртып йөрергә тиеш?! Фронт узган кеше... Ял итсен өендә.

Зимин *(мыскыллы елмаеп).* Срогың беткәч иреккә чыгармын дип уйлыйсың инде син... Мина дөресен сөйләмичә беркая да чыкмыйсың!

Зыятдин *(битараф тавыш белән).* Сөйлисен сөйләдем инде мин. *(Зарифнең исән икәнлеген ишеткәч үзендә әле күпмедер көч барлыгын тоя.)*

Зимин. Ярый. Син миңа шунысын гына әйт: АБВЕРның катнашы юкмы монда?

Зыятдин *(чыраен сытып).* Нинди АБВЕР инде тагын?! Нишләп сез буш урында казынасыз.

Зимин *(яман усал тавыш белән).* Ник атмадың Зарифка?

Зыятдин. Татар җырын ишеттем.

Зимин. Шуның өчен генә атмый калдыңмы?

Зыятдин. Нишләп син татарча җырлавын ишеткәнгә атмадым дигәч ышанмыйсың.

Зимин *(кыҗрап).* Чөнки шуның өчен генә дошманны үтерми калу мөмкин түгел!

Зыятдин. Нишләп ул миңа дошман булсын!

Зимин *(кабинеты буйлап ары-бире йөри).* Тәк. Без тагын круг буйлап киттек. *(Килеп Зыятдинның күзенә карый.)* Нишләп ул сиңа дошман түгел?

Зыятдин *(Зиминга туп-туры карап).* Татарча җырлаганга.

Зимин. Мин берзәнбер сәбәп шулдыр дип ышанмыйм һәм ышанмаячакмын. Хәзер менә атып үтерер идеңме Зарифны?

Зыятдин. Юк.

Зимин. Мине атып үтерер идеңме?

Зыятдин. Әйе.

Зимин. Әлбәттә инде...

Зыятдин *(ыңгырашып).* Минем хәлем бик начар.

Зимин. Әсир төшкән дошманның хәле яхшы булмый инде аның. Әйт әле миңа: ни өчен бер таныш түгел кеше кинәт якын була башларга мөмкин? Минем аңлыйсым килә! Әйт дөресен, сугышка кадәр таныш идегезме?

Зыятдин. Юк.

Зимин. Безнекеләр арасында әллә тагын берәр сезнең кеше бар идеме? Шуның аша таныштыгызмы?

Зыятдин *(чак кына ишетелерлек итеп).* Юк.

Зимин *(сорауларны якын килеп бирә башлый).* Ул сиңа базада нәрсә барлыгын әйткән бит.

Зыятдин. Юк, әйтмәде.

Зимин. Ә ул миңа әйтте: Зыятдинга сөйләдем диде.

Зыятдин. Ул алай алдашмас.

Зимин. Ә нишләп син аңа шулкадәре нык ышанасың? Һәрвакыт: ул андый түгел дисең, ул алдашмас дисең...

Зыятдин. Чөнки ул—чын ир-егет! Иманлы кешене имансызландыру мөмкин түгел. Иман ул йә бар, йә юк. Ул—иманлы инсан.

Зимин. Алай икән.

Зыятдин *(ишетелер-ишетелмәс тавыш белән).* Бер соравым бар.

Зимин. Тыңлыйм.

Зыятдин. Әгәр дә мин аны атып үтергән булсам һәм сез мине кулга алган булсагыз, минем хәлем җиңелрәк булыр идеме?

Зимин. Әлбәттә. Син хәрби әсир генә булып саналыр идең.

Зыятдин. Ә аны үтереп сезгә эләкми калган булсам?

Зимин *(көлә).* Иң бәхетле кеше булыр идең.

Зыятдин. Ялгышасың. Менә бу вариантларны тирәнтен уйлап карагач, миңа үземнең хаклы икәнем аңлашыла.

Зимин *(җирәнеп карый).* Лагерьда черү—хаклык билгесеме?

Зыятдин *(шулай ук җирәнеп карый).* Минем лагерьда черүем—сезнең кабахәтлек билгесе!

Зимин *(өстәле янына барып утыра).* Сиңа хәзер ике дөнья—бер морҗа дип әймәкче буласың мәллә бу дорфалыгың белән? Ышанмыйм. Әле синдә азатлык хыялы яши. Син әле Финляндиягә кайтып хатыныңны, улыңны кочакларрмын дигән өмет белән җан асрыйсың. *(Зыятдин сулкылдап еларга тотына. Озак елый. Зимин тыныч кына карап утыра. Кинәт сикереп тора да, Зыятдинга урындык китереп бирә.)* Утыр. *(Зыятдин утыра. Сулкылдаудан бөтен гәүдәсе дер селкенә. Зимин графиннан стаканга су салып Зыятдинга бирә.)* Эч. *(Зыятдин тончыга-тончыга суны эчеп бетерә. Зимин стаканны алып китә. Зыятдин елаудан туктагач Зимин үз урынына барып утыра).* Ә Зарифның исән булуына син шатмы?

Зыятдин. Шат.

Зимин. Ярар, мин сиңа бер серне ачам. *(Зыятдин нинди сер икән дип көтеп карап утыра.)* Зариф бик зур хата җибәрде.

Зыятдин *(сагаеп).* Нинди хата?

Зимин. Ул монда килде.

Зыятдин *(аптырап).* Ник?

Зимин *(көлемсери).* Синең язмыш белән кызыксынып. Орденнарын чылтыратып, погоннарын ялтыратып...

Зыятдин. Нишләп йөри инде ул?!

Зимин. Менә шул-шул! *(Күзләрен чекрәйтеп сынаулы караш белән карап тора.)* Нык кызыксынды ул синең язмыш белән.

Зыятдин *(башын читкә борып).* Җүләр икән!

Зимин *(бармагы белән Зыятдин ягына төртә-төртә).* Вот-вот! Җүләр! *(Тавышын әкренәйтеп.)* Ә ник җүләр дисең аны? Әйе, әйе, синең тел очыңда гына тора... *(Нәфрәт катыш сөенечле елмаю белән.)* 1940 нчы елның гыйнварында Карел урманнарында безнең базадан ерак түгел дошман разведчигы белән очрашуы турындагы делоны күтәрергә туры киләчәк.

Зыятдин *(котсыз кала).* Сез үз акылыгыздамы, юкмы? Юк нәрсәгә вакыт әрәм итәсез.

Зимин *(кискен хәрәкәтләр белән өстәл тартмаларын ачып-ачып карый).* Юк, юк, тикшерүләрне яңадан башлыйбыз.

Зыятдин *(күзләрен йома).* Зариф кайда соң хәзер?

Зимин *(битараф тавыш белән).* Кайтып киткәндер.

Зыятдин *(хәлсез тавыш белән).* Минем турыда нәрсә диден соң син?

Зимин. 1944 нче елны унсигез әсирне Финляндиягә кайтарып җибәрдек дидем. Шулар арасында Зыятдин да бар иде дидем.

Зыятдин *(көч-хәл белән ялвара).* Аптыратмагыз Зарифны. Бер гаепсез кеше бит ул.

Зимин. Әле яшиселәр бар, алда го-

мер шактый—ачыкларбыз кемнең күпме дәрәҗәдә гаепле икәнлеген. *(Зыятдин аның югалтып идәнгә егыла. Зимин өстәлендәге звонокка баса. Конвоирлар керә.)* Аның җуйды. Алып китегез! *(Зыятдинны кул-аякларыннан күтәреп алып чыгып китәләр.)*

Зимин графиннан су салып эчә. Үзенә урын табалмый йөренә. Көтмәгәндә Зариф атылып керә.

Зариф *(көчкә сулыш алып).* Ышанмыйм мин сина! Кайда ул?

Зимин *(кыжрап Зарифка таба килә).* Мин синнән туя башладым!

Зариф *(кычкырып).* Ул әле һаман шушы лагерьда.

Зимин *(кычкыра).* Кем?

Зариф. Зыятдин!

Зимин *(мыскыл итеп елмая).* Бәлки. Монда кем генә юк. *(Зарифка якын килеп карап тора.)*

Зариф *(Зиминга җирәнеп карый).* Мин Мәскәүгә барам!

Зимин *(көлә).* Бар! Анда көтәләр сине! *(Йөзе кинәт караңгылана, күзләре коточкычлана.)* 1940 нчы елгы эшнең кузгатылуын телисең инде син.

Зариф *(кычкырып).* Кузгалсын! Әллә нәрсәләр кузгалсын! Мин соңгы тапкыр таләп итәм, күрсәт мина ул кешене!

Зимин *(Зарифның гасабилануын инкарь итеп елмая).* Ә синең таләпләр куярга хакың юк.

Зариф *(тешләрен кысып).* Табыйк ул кешене!

Зимин *(мыскыллы елмаеп).* Лагерь бик зур. Аны эзләтергә кешеләрем юк, үзем эзләп йөри алмыйм. *(Кабинеты буйлап атлый.)*

Зариф. Аңламадым?

Зимин *(төкерекләрен чәчеп акыра).* Мин ул күкене эзләп йөрергә синең атаң Хәбибрахман түгел бит!

Зариф *(ярсып).* Син—кабахәт! Син тылда үз кешеләребезнең канын эчүче җанвар! Сез фронтта да каныбызны күп эчтегез! Ниместән дә күбрәк харап иттегез сез безнең иң асыл кешеләребезне!

Зимин *(бөтен эчке зәһәрлеген, вәхшилеген чагылдырып әйтә).* Ну, хана тебе, герой! *(Кыжрап килә дә, тешләрен шыгырдатып кабатлый.)* Хана тебе! Хана! Понял?! Хана!

Зариф *(барлык булган нәфрәтен чыгарып).* Бук!!! *(Зиминнын битенә төкерә.)*

Зимин *(беркавым һушсызланып торганнан соң кобурасыннан пистолетын чыгара.)* Атам, сука!

Зариф. Минем дә пистолетым бар! Минеке именной! Командующий үзе бүләк иткән пистолет. *(Пистолетын чыгара.)*

Зиминнын ярдәмчеләре атылып килеп керә. Алар Зарифның өстенә ташланып аның кулларын артка каералар һәм пистолетын тартып алалар.

Зимин *(килеп Зарифка карап тора).* Совет власте дошманнарын, халык дошманнарын мин гомерем буе таптадым һәм таптаячакмын! *(Зарифның погоннарын йолкып ташлый. Шуннан соң барып өстәле янына утыра. Телефоннан шалтырата.)* Задержан агент западной разведки. У меня в кабинете. Хорошо. *(Зарифны җибәрәләр. Ул хәлсезләнеп көчкә аягында басып тора.)*

Зариф. Менә ничек... *(Үзенең түшендәге орденнарын йолкып идәнгә ташлый.)* Мин шушындый хәшәрәтләр өчен, лагерь көсе ләре өчен сугышып йөргәнмен икән! *(Зарифны алып китәләр.)*

Музыка.

Зариф сөйли.

Зариф:

—Көнбатыш разведкасының агенты дип исбатлый алмасалар да мина биш ел бирделәр. Миннән барыбер шикләнделәр. Магаданга этап белән китеп бардым.

Бер тапкыр лагерьларны тикшерергә дип Мәскәүдән югары дәрәҗәдәге инспекция килде. Инспекция составында безнең армиянең политотдел начальнигы да бар иде. Фронтта ул мине яхшы белә һәм ихтирам итә иде. Мине күреп шаккатты. За что герой сидит дип бик борчылды. Мәскәүгә кайткач, минем өчен ходатайство язган. Мине, рәхмәт яусын аңа, ике елга алданрак, ягъни өч ел утыргач чыгардылар. Мин ут йотып яшәп ятучы Кәшифәм янына кайтып киттем. Мин кайтканда улыма ике яшь ярым иде инде.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бәрәкәт урманы. Зариф йорты. Зариф, Назимә, Хәбиб өстәл янында утыралар. Чәйләре суынып беткән.

Зариф. Кәшифә мин кайткач бер утырып елады да: "Бүтән беркая җибәрмим үзенне!"—дип кычкырды. Бу аның бердәнбер кычкыруы булды гомер буена.

Назимә. Син үзең әбиемә бер дә тавыш күтәрмәгәнсең.

Зариф. Каян беләсең?

Назимә. Әти әйтте.

Зариф. Минем өчен бөтенләй бер могҗиза—улым булды. Яшәргә дәрт һәм дәрманны Кәшифә, ата-анам бирсә, вәхши дөнья өстеннән очып яшәргә исә минем улым Мансур ярдәм итте.

Хәбиб. Назимәнең әтисе була инде ул?

Назимә. Әйе, минем әтием.

Зариф. Улым белән бөтенләй башкача ачылып китте дөньялары. Кызганыч, якын кешеләрем иртә вафат булдылар. Әти житмеш ике яшендә, әнкәй житмеш дүрттә. Кәшифә, жаным, алтмышын да тутырмыйча дөнья куйды. Йөрәк белән интекте. *(Тынлык.)* Мин гаепле! Мин, мин! Минем өчен саргайды ул, бичара. Назимәгә өч яшь иде әбисе үлгәндә.

Хәбиб. Көн саен каберенә барасыз икән.

Зариф. Көн саен барам.

Назимә. Бабай, мин Санкт-Петербургка... Ленинградка барып кайттым.

Зариф *(гаҗәпләнеп)*. Кай арада житештен?

Назимә. Житештем инде. Хәтта андагы татарларның сабантуен да күреп кайттым. Ә менә синең фин сугышындагы рота командирыңны күрә алмадым. Оныгы Ирина белән генә бер очраштык. Лебедев Анатолий Евсеевич бик карт икән инде. Сырхауханәдә ята. Инде сөйләшми дә икән. Миңа аның янына Ирина барып йөрмәскә кушты.

Зариф *(уйга калып)*. Бездән шактый өлкәнрәк иде шул ул...

Назимә. Мин Иринага әйттем: Зәйнуллин Зариф турында әйт, дидем. Синен Анатолий Евсеевич алдында гаебенне сизүенне дә, гафу үтенүенне дә әйттем.

Зариф. Рәхмәт, кызым.

Назимә *(әле бабасына, әле Хәбибкә карап куя)*. Дөнья барыбер могҗизаларсыз булмый инде ул. Хәбибнең кем икәнен белмисең бит әле син, бабай? *(Елмая.)*

Зариф *(хәтерендә казынып Хәбибкә шактый вакыт карап тора)*. Йөзе бик таныш.

Хәбиб *(елмая)*. Йөзем танышмы?

Зариф. Таныш. Тик Субай егете түгел, ахрысы.

Хәбиб. Субайныкы дисәң дә була, Зариф бабай. Мин—Финляндиядә яшим. Ерак бабаларым Субайдан?

Зариф. Алай икән... *(Сагаеп кала. Егетне игътибар белән күзәтә.)*

Назимә *(түземлеген җуя)*. Бабай, игътибар белән кара әле.

Зариф *(бите агара, куллары дерелди, тавышы калтырый)*. Син... әллә...

Хәбиб *(торып баса)*. Әйе, мин Зыятдин бабайның оныгы. *(Зариф абынасөртенә тора да Хәбибне кочаклап елый башлый. Музыка. Егетне кочаклаган килеш озак елый. Музыка көчле яңгырый. Аннары музыканың тавышы әкреняя.)*

Зариф *(күз яшьләрен җиңе белән сыпыра)*. Исәнме ул?

Хәбиб. Юк. Узган елны вафат булды. Сине гел искә алды. Бигрәк тә гомеренең соңгы көннәрендә. Синең язмышыңны бик беләсе килде.

Назимә. Утыр әле, бабай, утыр. Син дә, Хәбиб, утыр. Басып тормагыз. *(Утырышалар.)*

Зариф. Кайчан, ничек котылган соң ул?

Хәбиб. 1948 нче елны азат итеп Финляндиягә кайтарып җибәргәннәр аны.

Зариф *(үзен чиксез бәхетле итеп тоя)*. Алай икән... Исән калган! Кайтып китә алган! Молодец, молодец! Миңа бит гомер буе аның язмышы тынгы бирмәде. Димәк, барыбер котылган!

Хәбиб. Аның "үзгәртеп кору" башлангач Зарифка хат язарга мөмкиндер инде хәзер дип әйткәне булды. Ләкин тегe вакытта НКВДдан курку шулкадәр нык сеңеп калган ки, юк, йә тагын сиңа бәйләнә башларлар дип элемтәгә керергә җөрьәт итмәде. Һәм безгә дә рөхсәт бирмәде. *(Портфеленнән кульяулыкка*

*төрелгән фоторәсемне чыгара.)* Үләр алдыннан ул миңа монда барырга кушты. Субайда бабаларыбыз нигезендә дога кылырсың диде. Бәрәкәт урманында Зариф исән булса, аны күреп миннән сәламемне тапшыр диде. Рәхмәт әйт Зарифка диде.. Миндә ниндидер гаеп булса кичерүен үтен, диде.

Зариф *(фоторәсемгә карап тора).* Кәшифәнең яшь чагы. Кулъяулыкны да Кәшифә бүләк иткән иде. Зыятдин боларны ничек саклап кала алды икән лагерьда? *(Кулъяулыкны күкрәгенә кыса.)*

Хәбиб. Лагерьдагы лазаретта яткан-да бер шәфкать туташына биргән ул аны. "Сакла. Үлеп китсәм Татарстанның Субай авылына җибәр, ә инде исән калып моннан чыгарга насыйп булса кире миңа бирерсең",—дигән. Шәфкать туташы алып саклаган. Иреккә чыкканда бабай аңа мең рәхмәтләр укып алып киткән фоторәсем белән кулъяулыкны.

Зариф *(кабаланып чалбар кесәсеннән пәке чыгара).* Менә бу пәкене дә Кәшифә бүләк иткән иде. Гел кесәмдә йөри. Шушы пәкене онытып калдырып кире барган идем мин теге аланга. Шунда Зыятдин килеп чыкты.

Хәбиб. Пәке белән зажигалканы теге чечен егетенә бирдем диде бит.

Зариф. Әйе. Зажигалка Зыятдинныкы иде. Алтмышынчы еллар башында Казахстаннан посылка килеп төште. Мин аптырадым: кемнән бу, нәрсә аның эчендә? Посылканы ачтым. Берничә төрле кәнфит, берничә төрле чикләвек, менә шушы пәке һәм бабаңның паспорты белән зажигалкасы. Шунда хат та бар иде. Ачып укыдым—Рассуханов Асланнан икән бу. Шаккаттым. Яраланганнан соң аның аягын кисканнәр икән. Чеченнарны кырык дүртенче елда вагоннарга төяп Көнчыгышка таба сөрделәр бит—сатылган халык дип. Шул бер аяклы килеш ул да эләккән переселениегә. *(Күзләрен йомып башын чайкый.)* Айяй! Хаты тетрәндергеч! Ничек курыкмаган миңа посылка җибәрергә, өстәвенә хат та язарга! Мин—көнбатыш разведкасына ярдәм итүче дигән шик астында утырып чыккан кеше, ә ул сөрелгән чечен кешесе. Белсәләр, икебезгә дә эләгә бит инде... Җавап хаты язып торма дигән, чөнки үзең беләсең, күзәтеп кенә торалар дигән... Шулай итеп, Кәшифә бүләк иткән пәке белән бабаңның паспорты һәм зажигалкасы миңа кайтып төште.

Хәбиб. Бабамның паспортын рота командирына бирдем диден шикелле...

Зариф. Хәзер аңлатып бирәм. 1940 нчы елны мине кулга алгач, Лебедевны да допроска йөртә башлыйлар. Рота командиры булганга гына түгел. Мине бик каты яклаган иде ул. Үзен дә хөкемгә тартасылары билгеле булгач, Лебедев госпитальгә барып Зыятдинның паспортын Рассухановка бирә. Пәке белән зажигалканы мин Рассухановка биргәнне күрде бугай ул, шуңа күрә паспортны да аңа тапшырырга карар кылгандыр.

Назимә. Лебедевны да утырталар мәллә?

Зариф. Әйе. Ленинградта следственный изоляторда бер елдан артык яткан ул. Сугыш башлангач та төрмәдә булган әле. Аннары инде блокада... Ленинградны сакларга чыгарганнар. Миңа Лебедев турында инде немецка каршы сугышканда фронтта берәү сөйләде. Фин компаниясендә безнең рота пулеметчысы иде—ул да Ленинград егете, Лебедев белән бер мәктәптә укыган булганнар.

Хәбиб. Хәзер бабамның паспорты, зажигалкасы, димәк, синдә?

Зариф *(уфтанып).* Караклар алып чыгып киткән бит. Мин бит шул Зыятдинның паспортын урлаганнарына бик нык кайгырдым. Зажигалка зажигалка гына инде ул... Хәер, анысы да кызганыч. Ә менә паспорты миндә булганда, ничектер, әле ниндидер өмет бар иде—белмим нинди өметтер ул.

Хәбиб *(якты елмаеп).* Зариф бабай, бик кайгырма ул нәрсәләр өчен. Минем бабам гел сине искә алып, сагынып, синең өчен кайгырып яшәде. *(Зариф тагын елап ала.)*

Зиновьев килеп керә.

Зиновьев *(гадәттәгечә елмаеп һәм "куелган" тавыш белән).* Добрый день!

(Хәерле көн!)

Назимә *(чит кешенең кем икәнлеген аңларга тырышып игътибар белән карый).* Здравствуйте!

(Исәнмесез!)

Зариф *(бернинди эмоциясез).* Опять приехал?

(Тагын килдеңме?)

Зиновьев. Да, должен побеспокоить вас... И обрадовать.

{Әйе, тагын борчырга тиешмен инде сезне... Һәм шул ук вакытта куандырырга да.}

*(Елмая.)*

Назимә. Бабай, бу кеше синең янына килдеме?

Зариф. Әйе.

Хәбиб. Алайса без Назимә белән урманда йөреп керик әле.

Зариф. Барыгыз, бар, балалар.

Назимә. И-и-и, Хәбиб, мин сиңа хәзер шундый матур урыннарны күрсәтәм. *(Чыгып китәләр.)*

Зиновьев *(ясалма ягымлылык белән).* Исянмесез!

Зариф *(Зиновьевның килүенә шат түгеллеген күрсәтеп).* Исәнме. Нәрсә кирәк?

Зиновьев *(тантаналы тавыш белән).* Мы нашли грабителей.

{Без каракларны тоттык.}

Зариф. Каких?

{Нинди каракларны?}

Зиновьев *(гаҗәпләнеп).* Как каких! Тех, кто дом ваш ограбил. Представляете, это оказались бомжи.

{Ничек инде—нинди! Йортыгызны басучыларны тоттык. Бомжлар булып чыкты.}

Зариф. Бомжи?

{Бомжлар?}

Зиновьев *(көлә).* Да. Ну, это люди без места жительства, без работы и так далее... Если хотите, мы их привлечем к уголовной ответственности.

{Әйе. Теге, торыр урыннары булмаган, эшсез-нисез кангырап йөрүче кешеләр инде алар. Денем өчен түгел, кенем өчен дип яшәүчеләр. Теләсәгез без аларны хөкемгә тартабыз.}

Зариф. Ни к чему это.

{Юк, юк, кирәкми.}

*(Ике кеше Зарифның телевизорын күтәреп керәләр.)*

Зиновьев. Зариф абы, покажите, куда ставить?

{Зариф абый, күрсәтегез, кая куярга?}

Зариф *(түрдәге тумбочкага ишарәләп).* Вот его место.

{Менә аның урыны.}

*(Грузчиклар телевизорны тумбочкага куеп чыгып китәләр.)*

Зиновьев *(зур канәгатьлек белән).* Думаю, и остальные вещи ваши скомпенсируются.

{Башка әйберләрегез дә компенсацияләнер дип уйлыйм.}

Зариф. Если это бомжи, то не надо их наказывать. И не требуйте с них моих вещей, я прошу вас. Оставьте их в покое.

{Ул бомжларны җәзага тарта күрмәгез. Зинһар өчен, минем әйберләремне дә алардан таләп итмәгез, түләтмәгез. Бүтән борчымагыз аларны.}

*(Зиновьевка карап тора һәм паузадан соң өстәп куя.)* И меня оставьте в покое.

{Моннан соң инде мине дә борчымагыз.}

Зиновьев *(кәефе кырыла).* Хорошо. Как себя чувствуете?

{Ярар. Хәлләрегез ничек?}

Зариф *(кырысланып).* Когда ты приходишь, не важно!

{Син килгәч минем хәлем начарлана!}

Зиновьев *(үпкәле тавыш белән).* Я только с благими намерениями приезжаю к вам.

{Мин сезгә гел игелекле ниятләр белән киләм.}

*(Папкасыннан бер документ һәм зажигалка чыгара.)* И это тоже ваше...

{Болары да бит сезнеке.}

Зариф *(документны һәм зажигалканы ала).* Вот за них спасибо. За паспорт и зажигалку Зыятдина большое спасибо.

{Менә бу әйберләр өчен рәхмәт. Зыятдинның паспорты белән уткабызгычы өчен зур рәхмәт.}

Зиновьев. Наконец-то, я смог хоть чем-то вас обрадовать.

{Ниһаять, сезне аз гына булса да сөендерә алдым.}

Зариф *(Зиновьевка текәлеп карап тора).* Думаешь, ты меня смог обмануть?!

{Син мине алдый алдың дип уйлыйсыңмы?!}

Зиновьев *(каушый).* Ты что, старик?!

{Син нәрсә, бабай?!}

Зариф. Ты не Зиновьев! Может

быть, ты фамилию не дедовскую носишь... Но все равно ты не тот, за кого выдаешь. Ты еще молод, и по молодости тебе опыта не хватает.

{Син Зиновьев түгел! Бәлки син бабаң фамилиясе белән йөрмисеңдер... Танышканда ук мине алдый башладың. Син башка кеше булып кыланасың. Ләкин син әле яшь, тәҗрибәң аз.}

**Зиновьев** *(гасабиланып).* Какого опыта?

{Нинди тәҗрибә?}

**Зариф** *(авызын кыйшайтып).* Опыта работы с людьми.

{Кешеләр белән аралашу тәҗрибәсе.}

**Зиновьев** *(югалыбрак кала).* Я к вам отношусь с большой симпатией. Я знаком со всей вашей биографией. Да. Я хочу с вами быть искренним. Моя фамилия—не Зиновьев. Моя фамилия—Зимин.

{Мин сезне бик хөрмәт итәм, сез күңелемә якын кеше. Әйе, мин сезнең тәрҗемәи хәлегез белән таныштым. Хәзер инде ихластан сөйләшәсем килә. Чыннан да минем фамилиям Зиновьев түгел. Минем фамилиям—Зимин.}

**Зариф** *(бөтенләй якын килеп Зиминның оныгын күзәтә).* Похож, очень похож.

{Охшагансың, охшагансың.}

**Зимин** *(тавышы калтырый).* Дед о вас часто спрашивает... Мы в Челнах живем... Я его перевез к себе...

{Бабай сезнең турыда гел сораштыра... Без Чаллыда яшибез... Мин аны Чаллыга, үзебезгә алып киллем.}

**Зариф.** А почему столицу на Челны поменяли?

{Ни сәбәпле башкаланы Чаллыга алыштырдыгыз?}

**Зимин.** Отец КамАЗ строил... Меня тоже в Челны направили.

{Әтием КамАЗ төзелешендә эшләде... Мине дә Чаллыга җибәрделәр.}

**Зариф** *(горур тавыш белән).* У меня сын тоже на КамАЗе работает, начальником цеха. А ты кем работаешь—я догадываюсь.

{Минем дә улым КамАЗда цех начальнигы булып эшли. Синең нинди эштә икәнеңне чамалыйм.}

**Зимин** *(үзен кулга ала һәм тынычлана).* Я откровенно вам скажу: это меня дед попросил пообщаться с вами.

{Дөресен әйткәндә, сезнең белән аралашырга мина бабам кушты.}

**Зариф.** А что, других методов не смогли придумать?!

{Нәрсә, башка ысул табалмадыгызмы?!}

**Зимин.** Дед часто вспоминает о вас...

{Бабай сезне гел искә ала...}

**Зариф.** Ну, что он никак не угомонится!

{Нишләп һаман тынычланалмый соң инде ул!}

**Зимин.** Нет, нет, вы не то подумали, Зариф абы. Он просто... по-человечески интересуется—как ты живешь, как у тебя здоровье...

{Юк, юк, Зариф абый, сез дөрес аңламадыгыз. Ул чын күңелдән, кешеләрчә, сезнең яшәү рәвеше белән кызыксына, сәламәтлегегез өчен борчыла...}

**Зариф** *(кырыс тавыш белән).* Почеловечески?! Спасибо вам за все. И тебе спасибо. Я прошу—меня больше не тревожьте.

{Кешеләрчә дисеңме?! Барысы өчен дә рәхмәт сезгә! Сиңа да рәхмәт. Моннан ары мине бүтән борчымагыз.}

**Зимин.** Зариф абы, наоборот, я хочу вам помочь, чем могу. Если понадобиться какая помощь, звоните мне. Вот моя визитка.

{Зариф абый, мин, киресенчә, сезгә булдыра алган каләре игапә күрсәтергә телим. Алай-болай берәр ярдәм кирәк булса, шуңдук мина шалтыратыгыз. Менә минем визиткам.}

**Зариф.** Не надо.

{Кирәкми.}

*(Боерып.)* Уходи!

{Бар, кит!}

**Зимин.** До свидания!

{Сау булыгыз!}

*(Чыгып китә.)*

Зиминның оныгы чыгып китү белән Назимә белән Хәбиб йөгереп кераләр.

Назимә. Бабай, кем иде ул?

Зариф *(битараф тавыш белән)*. Милициядән.

Назимә *(телевизорны күреп сөенә)*. Телевизорны алып килгәннәр.

Зариф. Каракларны тотканнар. Менә, Зыятдинның паспорты, зажигалкасы...

Хәбиб *(бабасының паспортын саклык белән генә алып ачып карый)*. Менә бит ә... *(Зажигалканы алып карый.)*

Назимә *(борчулы тавыш белән)*. Бабай, ятып тормыйсыңмы?

Зариф. Ник?

Назимә. Арыганга охшагансың.

Зариф. Нинди яту инде бүген, кызым! Ә инде арыганга охшаганмын икән... *(Кызына карап тора.)* Кызым, мин, ахрысы, яшәп арыганмындыр.

Назимә *(битәрләп)*. Әй, бабай, кайчак әллә ниләр әйтеп куясың!

Зариф *(кинәт йөзе яктырып китә)* И-и-и, кызым, шушы кадәр Кәшифә әбиенә охшасаң да охшарсың икән! *(Кызын аркасыннан сөя.)*

Хәбиб *(Назимәгә карап)*. Әйе шул. Теге фоторәсемдә әллә Назимә, әллә Кәшифә әби—аңламассың.

Зариф *(күтәренке рух белән)*. Хәбиб, улым, бездә кунасыңдыр бит?

Хәбиб. Ни...

Зариф. Бездә, бездә. Ни дә түгел, берни дә түгел... Миндә Финляндия түгел, кәнишне. Шулай да бәрәңге кыздырып хуш ис чыгарсак хәйран күңелле булачак. *(Көләләр.)*

Хәбиб. Ярар. Алайса иртәгә Субайга бергәләп барырбыз. Мине зыяратка алып барырсыз. Ерак бабамнарның каберләре дә шунда. Кәшифә әбинең дә каберен күреп китәрмен.

Музыка.

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бәрәкәт урманы. Зарифның йорты, каралты-курасы күренеп тора. Назимә белән Хәбиб наратлык янында йөриләр. Зариф жыр шыншый-шыншый кайбер ычкынган рәшәткәләрне каккалап йөри. Читтәрәк машина килеп туктый. Карт Зимин килә. Ул инде бик картайган—таякка таянып акрын гына атлый. Өс киеме бик пөхтә һәм затлы. Зариф чакырылмаган кунакка карап тора. Алар бер-берсен шундук таныйлар.

Зимин. Исәнме.

Зариф. Исән. *(Яшьләр йөргән якка карап койма буенда яткан бүрәнәгә янәшә утыралар.)*

Зимин. Ничек яшисең?

Зариф. Син минем ничек яшәгәнемне һәм ничек яшәвемне үземә караганда да әйбәтрәк белә торган кеше түгелме?! *(Бер-берсенә, ничектер, карамаска тырышалар кебек.)*

Зимин. Менә, язмыш тагын очраштырды. Дөнья бер дә киң түгел ул, Зариф, килешәсеңме?

Зариф. Синең өчен тар инде ул. Сезнең өчен... Минем өемне басу кәмитләрен ник оештырдың соң син? Оныгыңның стажировкасын миндә уздырырга булдыңмыни?

Зимин. Мин сине очратуыма бик шат... *(Ерактан Назимәнең "Кошларга" дигән җырны җырлаганы ишетелә.)*

Зариф. Зыятдинның паспорты белән зажигалка ник кирәк булды соң?

Зимин. Минем тагын бер кат карыйсым килде.

Зариф. Юк. Мин беләм. Оныгына мирас итеп калдырмакчы буласың син ул эшне. Оныгыңа ул әйберләрне фотога төшерергә кушкансыңдыр әле.

Зимин. Ул аны үзе дә белә.

Зариф. Димәк, бабасының эшен дәвам итә—тулы мәгънәсендә?

Зимин *(канәгатьсезләнеп)*. Ташла әле, Зариф, безнең синең белән сөйләшер сүз беткәнмени?! Без бит синең белән күп авырлыклар кичергән кешеләр.

Зариф. Без төрлечә кичердек ул авырлыкларны.

Зимин. Өянәкләрең еш буламы?

Зариф. Төрлечә. *(Зимин ягына караш ташлап ала.)* Хәтта өянәкләрем турында да беләсең...

Зимин *(көлемсерәп)*. "Телсез Күке" дигән кушаматыңны да беләм. Хәтерлисеңме, теге фин татарын "күке" булса да ул бит "телсез күке"—чөнки атмады дигән идең.

Зариф *(кәефенең күтәренкелегән җуймыйча)*. Кичә мина бик шатлыклы хәбәр алып килделәр, шуңа күрә минем хәлем яхшы бүген.

Зимин. Нинди хәбәр?
Зариф. Сез анысын да беләсез инде.
Зимин *(жыр ишетелгән якка карап).* Кем жырлый?
Зариф. Минем оныгым Назимә. Нәкъ Кәшифә әбисе кебек искиткеч матур жырлый.
Зимин. Нинди жыр бу?
Зариф. Татар халык жыры. *(Зиминга карап тора.)* Сез безгә бүтән кагылмагыз инде. Актык көннәремне тыныч кына яшим инде, зинһар.
Зимин *(аптыраган кыяфәт белән).* Сина кагылучы юк! Әле бик кагылырлык вакытларда да борчымаска булдык сине.
Зариф. Аңламадым?..
Зимин. Сөргенгә сөрелгән чечен Рассухановтан посылка алгач сина беркем бер сүз әйтмәде.
Зариф *(төсен үзгәртеп).* Рассухановка аның өчен бер-бер нәрсә булмагандыр бит?
Зимин. Юк. Алтмышынчы еллар уртасында ул гаиләсе белән туган жиренә кайтты.
Зариф *(читкә карап).* Аяксыз кешене сөргенгә сөрмәсәләр...
Зимин *(авыр сулап).* Бернишләп булмый...
Зариф *(уфтанып).* Анда хәзер дә мәхшәр бит әле.
Зимин. Кайда?
Зариф. Чечняда.
Зимин. Шулай шул. Рассуханов соңгы елларда уртанчы улында Грозный шәһәрендә яшәде. Зурысы Мәскәүдә зур бизнесмен иде. Кече улы да Мәскәү белән Грозный арасында ниндидер эшләр майтарып йөрде.
Зариф. Ә Аслан үзе ничек икән хәзер?
Зимин *(игълан укыгандагы интонация белән әйтә).* Рассуханов Аслан—безнең сослуживец, совит-фин сугышы инвалиды—1995 нче елны федераль авиация Грозныйны бомбага тотканда һәлак була. Нәкъ йортлары өстенә төшә бомба. Өч улы да хәзер тауларда качып Россиягә каршы сугышалар. Алга таба нәрсәләр булып бетәр анда, белмим.
Зариф *(чиксез нәфрәт белән).* Мин беләм!
Зимин. Ничек?
Зариф. Гадәттәгечә!
Зимин. Ничек, гадәттәгечә?
Зариф. Менә шул! Гадәттәгечә! Ник килден син монда?!
Зимин *(аптырашта калып).* Сине күрергә дип.
Зариф. Аңлыйм: бөтен нәрсәне белеп торасыз. Сина һаман Зыятдинның мина атмавы тынгылык бирми. Күпме еллар узды. Үзенә үзең куйган сорауга жавап табалмыйча иза чигәсең. Син һаман мина ышанмыйсың? Үзем белән гүргә ниндидер бер зур серне алып китәм дип кайгырасың!
Зимин *(көлемсерәп).* Башлы кеше син, Зариф. *(Кесәсеннән Зарифның орденнарын алып бирә.)* Мә, Зариф, бу синең орденнарың. Дан орденнарың түшеннән үзең йолкыган идең. *(Зариф орденнарын ала. Ике учына салып орденнарына озак карап утыра.)* Ә офицерлыкта восстановление булачак сина—мөрәҗәгать итүең генә кирәк.
Зариф. Анысы кирәкми инде.
Зимин. Ветеран войны булып исәпләнсәң, льготалар була. Киреләнмә!
Зариф *(Зиминга таба борылып).* Мина иң зур льгота, беләсеңме, нәрсә булыр иде? Зыятдин турында, минем турында, безнең балаларыбыз, оныкларыбыз турында мәгълүматлар жыеп йөрмәсәгез иде.
Зимин. Син нәрсә инде. Син бигрәк. Артык шикчелләнгәнсең син!
Зариф. Синнән дә шикчелерәк кеше дөньяда юктыр.
Зимин. Һәркемнең үз эше, үз вазифасы, үз бурычы бу яшәештә.
Зариф. Мин исән чакта, нәселебез исән чакта, гомумән татар исән чакта син тынгылык тапмаячаксың. Мин аңладым: сина сәбәп кенә кирәк.
Зимин. Алай түгел, Зариф. Күпертмә. Жавап табалмый калган сораулар бар, әлбәттә...
Зариф. Әйт дөресен, син бит һаман ышанмыйсың Зыятдинның татар жырын ишеткәнгә атмаганына.
Зимин. Хәзер ышанам инде.
Зариф *(кызып-кызып).* Юк, син хәзер дә шикләнәсең. Синең мин-минлеген тынгылык бирми—бәлки Зыятдин чынлап та зуррак "күке" булгандыр, бәлки Зариф дөрестән дә көнбатыш шпионы булгандыр... Мине бер уй сискәндерде әле. *(Тавышын әкренәйтеп.)* Әгәренки син шизофреник икән?! Синең шикчеллегең аркасында күпме кеше харап була ала?
Зимин *(үпкәли).* Син мине мыскыл итәргә ашыкма.

Зариф *(Хәбиб белән Назимә йөргән якка карап елмая).* Ашыгасы юк инде хәзер. Кичә миңа яхшы хәбәр китерделәр! Зыятдинның исән калып кырык сигезенче елда Финляндиягә кайтып китүен мәгълүм кылдым!

Назимә белән Хәбиб киләләр. Исәнләшәләр. Зимин Хәбибкә бик озак карап тора. Хәбиб Зарифның кулындагы орденнарны күргәч бу кешенең кем икәненә төшенгән кебек була.

Назимә. Исәнмесез!

Хәбиб. Исәнмесез!

Зимин. Исәнмесез! *(Шаккатып Хәбибкә карап утыра.)* Бу кадәре охшаса охшар икән!

Хәбиб *(салкын тавыш белән).* Беләсеңме, кешеләр нишләп бер-берсен хәтерләтәләр? Ник кайберәүләр бер-берсенә нык охшаганнар?

Зимин. Ник?

Хәбиб. Хәтер исән булсын өчен, күп нәрсәләр онытылмасын, югалмасын өчен.

Назимә *(нәрсәдәндер шикләнеп һәм беraз шурләп Хәбибне көтелмәгән кунак яныннан алып китәргә була).* Әйдә, комачауламыйк бабайларга.

Хәбиб. Киттек! *(Китәләр.)*

Зимин. Син хәзер инде бернәрсәдән дә куркырга тиеш түгел.

Зариф. Курку юк, ләкин оныклар өчен борчылам. Зыятдинның онығы өчен дә, үземнеке өчен дә. *(Зимингa карап тора.)* Борчылу һәм шомлану бар. Чөнки синең дә оныкларың бар!

Зимин. Ташла!

Зариф. Менә шундый хәлләр... *(Ерактан Хәбибнең жырлаганы ишетелә.)*

Урманнарда йөргән чакта
Алаштым юлларымны;
Күңелем нечкә—жылармын дип,
Сузмадым кулларымны.

Йөгердем житәлмәдем лә,
Сикердем читәннәрен;
Ни булгандыр телләремә -
Сау бул дип әйтәлмәдем.

Зимин *(жыр ишетелгән якка карап).* Кем жырлый моны?

Зариф. Зыятдинның онығы Хәбиб. Нәкъ бабасы Зыятдин кебек шәп жырлый.

Зимин. Ә монысы нинди жыр?

Зариф. Татар халык жыры.

Зимин. Әйт әле, Зариф, ни сәбәпле сез теге вакытта Зыятдин белән бер-берегезне шулай нык якладыгыз?

Зариф. Әйтәм бит, син актык сулышыңа кадәр шикләнәчәксең дип.

Зимин. "Күке" дигән сүзнең тагын мин белмәгән мәгънәсе бар идеме сезнең арада?

Зариф. Син үзеңнең мантыйкларында буталып беткәнгә күрә онытуыңа дәвам итәргә кушкансың инде бу эшне. *(Ерактан Хәбиб жырлый. Ул "Иске кара урман" дигән жырны башкара.)* Син акылсыз кеше түгел, ләкин беркайчан менә бу жырларның моңын, мәгънәсен, асылын аңламаячаксың. "Күке" сүзе нечектер, ә менә бу жырның син беркайчан белмәячәк һәм аңламаячак тирән мәгънәсе бар.

Зимин. Әлбәттә, һәрнәрсәне белеп, аңлап бетерү мөмкин түгел.

Зариф. Син әллә кайларга үтеп керергә тырышып казындың, ә ярылып яткан хакыйкатьне аңлый алмадың.

Зимин *(өзгәләнеп).* Нишләп соң сез икегез дә "Күке" идегез? Икегез дә аннары "Телсез Күке" булдыгыз?!

Зариф *(утырган урыныннан кузгала, як-ягына, аннары күккә карап куя).* Өянәкләрем кузгалып тотлыга башлаганда, вакыты-вакыты белән телсез калып торгач мин курыктым. *(Хәбибнең жырлавы ишетелә. Шул фонда сөйли.)* Ләкин бөтенләй үк котсыз калдым дип әйталмыйм. Бер күке телсез калганнан урман яшәүдән туктамас, дидем мин үземә. Ләкин барыбыз да телсез калсак?.. Мин инде үзем әйтәсемне әйттем, жырлыйсымны жырладым. Ә миннән соң барысы да телсез булса?! "Телсез" сүзенең син аңламый торган мәгънәсеннән курыктым мин. Ә менә Зыятдинның исән калып, балаларын, оныкларын үстергәнне белгәч, онығының телле икәнен күргәч вә ишеткәч минем өметемнең ялкыны югары күтәрелде. *(Кычкырыбрак.)* Сугышта винтовканы телсез иткән тел әле яшәячәк ул! Винтовканы телсез калдырган жырны ничек үтереп булсын икән?! *(Жыр көчәя.)*

Зимин. Син бөтенләй башка нәрсә турында сөйлисең.

Зариф. Бәлки шулайдыр. Бу дөньяда һәркем үзенекен сөйли. Аллага шөкер! Телсез түгел мин. Зыятдин да телсез түгел иде. Оныкларыбыз да телсез түгел! Аллага шөкер!

Зимин. Ә мине тынычландырырдай берәр сүз әйтмәссеңме икән?

Зариф. Мин туйдым синнән! Кайтып кит! Бар, үз юлыңда бул! *(Иркен сулап куя.)* Бүген безнең мунча кирәсебез бар. Аннары Кәшифәнең каберенә барып кайтырга кирәк. Бар! Борчымагыз безне!

Зимин. Син мине шулай чиксез куралмыйсыңмыни?!

Зариф. Ялгышасың. Нәфрәт түгел бу. Киресенчә, бүген минем күңелемдә андый кара хискә урын юк. Мин элегрәк әле бераз шөбһәләнеп йөргән идем: яшьләр, балалар нәфрәтле булмасалармы безгә карата дип. Улымны, оныкларымны тыңлагач, мин аларда безгә карата үпкә, нәфрәт тоймыйм. Яшь буыннар безне бернәрсәдә гаепләмиләр. Алар безне яраталар. Аннары, шунысы бар: нинди генә коточкыч сынаулар аша үтсәк тә, алар без үткәннәр, без кичергәннәр белән яшәмәячәкләр. Безнең заман безнең белән узып китте. Башкача мөмкин түгел. Безнең җәрәхәтләр безнең белән китә. Безнең җан газаплары—безнеке, фәкать безнеке генә. Газапларның да чиге, азагы бар. Үтә, үтә! Үтеп китә болар барысы да. Безнең баштан узганнарны, ни гаҗәп: югалтасы килми шикелле! Әмма ләкин шулай кирәк, шулай тиеш! Әлбәттә, синең җан газабының каядыр китеп гаип булуы кызганыч, бик кызганыч! Ләкин башкача ярамый! Башкача мөмкин түгел! Барысы да үтә! Кызганыч, ләкин шулай кирәк! *(Ерактан Назимәнең "Саннар" җырын җырлавы ишетелә. Ана Хәбиб кушылып җырлый.)*

Зимин. Әгәр дә... мин синнән гафу үтенсәм?.. Кичерүеңне сорасам?..

Зариф. Беренчедән, синең гафу үтенергә җыенуыңа мин ышанмыйм. Икенчедән, мин сине гафу итә алам, тик аңлый алмыйм.

Зимин. Бәлки аңларга теләмисеңдер?

Зариф. Әйе, әйе, менә болай дөресрәк булыр мөгаен: гафу итәргә телим, ә менә аңларга хәтта теләмим дә.

Зимин *(китәргә җыена)*. Тагын нәрсә телисең яки нәрсә теләмисең миңа?

Зариф *(тавышы көрәя, куәте арта)*. Мин сиңа саулык-сәламәтлек телим! Озын гомер телим! Озак яшә! Ике йөз ел, ике йөз илле ел яшә тагын! Чөнки аңламый калган нәрсәләрне аңларга вакыт сиңа күп кирәк. Сорауларыңа җавапларны табарга сиңа озын гомер кирәк! Ниһаять, аңлагач, бәлки тәүбә итәргә дә бераз вакыт кирәк булыр әле. Хуш! *(Җыр көчәя. Зимин акрын гына, таягына таянып, көтеп торучы машина ягына таба китеп бара. Зариф орденнарын пинжәк кесәсенә тыга да, яшьләр йөргән яктан яңгыраган җырга кушылып җырлый-җырлый, рәшәткәләрне калаклый.)*

Музыка.

*Тәмам*



# Рөстәм Мингалим

## БЕЗНЕ ВАТЫП АГА ВАКЫТ

### Теге якка узам әле

Әллә чынлап, әллә юри картаелды бит әле...
И, гүзәл зат! Мин узасы юл янынннан кит әле?!
Дәшми узып, йә сөйләшеп, сине үпкәләтермен.
Начарланып куйды әле бу арада хәтерем.
Начарланып куйды әле йөрүем, күрүем дә.
Әмма дуслар элеккедән ачыграк та күренә.
Тузган гомерем дивары ишелә иңнәремә.
—Әй, ишелде,
Нык ишелде, бетерде мине!—дисәм,
Ярый әле дусларыма бирәсе кулым исән.
Теге якка узам әле, ишеге ерак калмады,
Ни үкенеч, мәңгелеккә әзерлегем чамалы.
Үкенү дә һәм елау да файдасыз инде, беләм.
Шуңа бүген мин—үземнән
Һәм... миндәйләрдән көләм.

### Гомер артык тиз уза

Гомер юллары һәммәсе
Бер-беренә охшаштыр:
Уйлап сүгенер урыны да,
Сагыныр җире дә булыр.

—"Бу яшәү—яшәү түгел",—дип,
Сүгенүче ишәйде.
Алай ук сызып ташламам
Мин үземнең яшәүне.

Рөстәм МИНГАЛИМ (1937) — *шагыйрь, драматург; өлкәннәр һәм балалар өчен күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Тычкан куган мәче кебек
Бәхет аулап карадым.
Бәхет тычканнан да елгыр,—
Акыл кергәч, аңладым.

Әкрен керә шул акыл.
Гомер артык тиз уза.
Хәзер бәхет тә ауламыйм,
Теш-тырнагым нык тузган.

—"Яшьлек—тиле",—диләр инде,
Ярый, "тиле" тиз дә узсын,
Үпкәм юк анысына.
Бәйләнчек картлыгым гына,
Акылына абына-абына,
Озаграк узар сыман...

## Кәбисә ел мәрхәмәтсез, диләр

Бу җәй миңа әллә ни зур
Шатлык китермәде:
Эреле-ваклы
Ун, егерме шигырь—
Бөтен китергәне.
Зур кайгы да китермәде,
Рәхмәт бу җәемә,
Эреле-ваклы борчуларын
Җиңдем җае белән.
Инде җәем китеп бара,
Китә кышлавына.
Мин исәнлек теләп калам
Урман-кырларыма,
Хайван-кошларыма.
Озатып җәйне,
Кул болгап,
Мин балконда калам.
Һәм җәй миңа
Кабат кайтыр,
Әгәр кушса Аллам.
Колач җәеп каршылармын,
Йә каршылый алмам...
Бу җәй миңа әллә ни зур
Шатлык китермәде.
Шөкер әле
Киләчәккә өметемне
Бетермәде.
Гаиләм дә бөтен,
Казаным да бөтен әле.
—"Кәбисә ел мәрхәмәтсез!"—диләр.
Мәрхәмәтсез түгеллеген
Исбат итим әле:
Шушы елның аркасына сыенып кына
Мәрхәмәтле еллар ягына үтим әле...

## Сөйләргә дә хурланам

“Дөнья ямьсез!”—дип әйтмә син.
Әйтмә минем ишегә:
Дөнья матур—
Матурлыкны
Таный белгән кешегә!
Үз бала охшар атага,
Йә охшар анасына...
Кайчак уйлыйм да,
Бу дөнья—
Миңа үз түгел сыман.
Мондый зур охшашсызлыкны
Сөйләргә дә хурланам:
Яшәгән, олгайган саен
Ямьсезләнә барам ич мин,
Ә дөнья—матурлана...
Шундый матурлыкны бозып
Күпме яшәргә мөмкин?
...Вакыты җиткәч, китәрмен:
Китә тора бит кешеләр,
Китәрмен,—
Мин кемнән ким?

## Безне ватып ага вакыт

Ага сулар, суга ярга,
Ватылып кала ярлар.
Ватылып калган яр сыман
Яшәгән чакларым бар.
Сулар ага, чигенә яр
Чигенә алган кадәр.
Безне ватып ага вакыт.
Чигенсәк —
...Артта кабер.

## Юк, бу эшләп ару түгел

Алмыйм бүген кулга кәгазь,
Каләм дә алмыйм әле.
Алдады мине шигърият,
Һаман да алдый әле...
Эшләсен Равил, Ренатлар,*
Мин эшләп ардым бугай.
Юк, бу эшләп ару түгел,
Мин яшәп ардым бугай...
Тик зарлану миңа оят,
Хәтта оят ару да
Каршымда Ходай бүләге —
Мәңгелек ял барында...

## Шат яшәүнең сере бардыр

Шат яшәүнең сере бардыр,
Озак шуны белми йөрдем.
Хәзер бераз чамалыйм:
Тәрәзгә килгән һәр көнне

*Равил Фәйзуллин, Ренат Харис турында сүз бара.

—Минем өчен туган көн! — дип,
Мин елмаеп каршылыйм.

Әйтерсең лә һәр көн миңа
Сөенечле яңалык,
Ә дөресе — һәр көн миңа
Бик кирәкле ямаулык...
Һәр бүгенем — йөрәгемә
Кичә алган
Яраларны ямарлык.

## Синең базар

(Милләтен сатучыга)

Авыр туфрак телим сиңа, атың корсын,
ата-анаң рухы шуны сизеп торсын:
син яхшырак киенер өчен — халкың саттың,
кәеф-сафа сөрер өчен — халкың саттың.
Халкың саттың — түш киереп йөрер өчен.
Дәү дәрәҗә алу өчен — халкың саттың,
гел базарда калу өчен — халкың саттың.
Үтеп бара гомерең шулай сата-ала,
милләт кала — хәтереңдә исемең кала:
исемең кара, йөзең кара, кара бәгырь!
Исле җисемең каршысында —
кара кабер.
Авыр туфрак телим сиңа, атың корсын —
әби-бабаң рухы шуны сизеп торсын!

## Томаннарга таба илттеләр

Сары бодай кыры җилдә кайный,
әйләнәсе — тимер сак иде...
Үҗәтләнеп безнең үсеп йөргән,
гел ашыйсы килгән чак иде.
Бирмәделәр ипи туган якта,
читтә бәхет вәгъдә иттеләр.
Төяп-төяп безне поездларга,
томаннарга таба илттеләр.
Безне суга сипте пароходлар,
машиналар җиргә таратты.
Кемдер сугып тешне
койды безнең,
кемдер каршылады яратып...
Әвереләдек моңлы килмешәккә,
чын йөрәктән җырлар чыгардык.
Җырыбызга тыгылып үләр чакта,
туган якны уйлап чыдадык.
Табалмадык читтә бәхет димим,
бөтенләй үк буш кул кайтмадык.
Туган якка кайткач, күпләребез
әнкәйләрне генә тапмадык.
Инде безнең күңел
шул вакыттан
мәңгелеккә хәтле өшегән...
Киләчәкнең тимер түрәләре —
ни күрсәтер тагын кешегә?!

*Әдәбиятлар дуслыгы—халыклар дуслыгы*

## Олег Шестинский

# ТАТАР ИЗҮЕ ТАТЛЫ

ХИКӘЯ

Кырык икенче елның кышы. Ленинградны блокада кыскан, буганнан-буа барган көннәр иде.

Бер малай, кулдан ясалган киң чанага бау белән беркетелгән калай чиләкләрен даңгырдатып, бозланып каткан трамвай юллары аша Нева елгасына таба атлый.

Елгага кадәр булган юл малай өчен һәр йөз метрны үткән саен авырлаша бара. Юк, чанага бернәрсә дә өстәлми анысы, ә малайга шулай тоела, борчый—кемдер, әллә җенме—чиләкләрне һаман авырайта, чананы өстерәү кыенлашканнан-кыенлаша. Малай моның арудан, талчыгудан икәнен дә аңлый. Әмма барырга-атларга кирәк. Өйдә бер йотым су юк. Ул әле тагын шуны да төшенә: эш чанада түгел, ачлыкта, бер сынык ярым чи икмәк кисәге белән бер сәдәф сахарин тамагыңны туйдырыр дип алдану гына инде бу.

Малай салкын һаваны тутырып сулады, бушый төшкән бавын тартыбрак тотты да, авыр итекләрен шыгырдата-шыгырдата, каткан кар өстеннән атлады. Үтеп-сүтеп йөрүчеләрнең нинди кием кигәнлекләрен дә абайлап булмый, алар ни-нәрсә тапсалар, кат-кат шуны кигәннәр, җанлы чатыр кебек әкрен генә өстерәләләр, ачлыктан кытыршыланып беткән тәннәрен өтеп алырдай салкыннан ничек тә сакларга тырышалар иде.

Бәке тирәсендә шәһәр халкы мәш килә. Нева елгасына таудан төшәр өчен махсус бер күнегү, осталык кирәк. Юкса чиләкләрең чананың бозланып шомарган такталары өстеннән янтаеп китәчәкләр дә карга төшеп капланачаклар.

Малай остарып җиткән инде, ул иелеп, бер кулы белән чиләкләрен тота, икенчесе белән бавын җыя төшеп, чананы әкренәйтә. Бәке янына килеп җиткәч, ул ашыкмый гына бәке тирәсенә түгелеп каткан бозга тезләнде дә чүмеч белән су тутыра башлады. Аны ашыктырмадылар, ул бу зәмһәрир җилле салкында чират көтеп торуның нинди газап икәнен үзе дә белә, шуңа күрә бәкедән суны чүмече белән чиләкләргә ашыга-ашыга тутыра иде. Чиләкләре мөлдерәмә тулгач, малай чанасын бәке яныннан кузгатып җибәрде дә тау өстенә сөйрәп менә башлады. Гаиләсе сусыз калса, тиздән үлеп бетәчәкләр бит. Аның башына чыкмаслык булып кереп утырган уе шул иде.

Шунысы сәер—берәр потлы зур чиләкләре белән өйгә таба атлавы җиңелрәк тоелды, таш йорт, әйтерсең лә, аны магнит кебек үзенә тарта иде. Ерактан ук капкаларын күрүгә, ул җанланып китте, әнисенең куанып каршы алачагын белеп, адымнарын тизләтә төште.

---

*Олег ШЕСТИНСКИЙ (1929)—рус шагыйре, тәрҗемәче; «Вижу берег столетия!», «Поле», «Блокадные новеллы» һ.б. китаплар авторы. Мәскәүдә яши.*

Капка төбенә житәрәк каршысына балалар чанасына шома калай чиләк утырткан кызчык килеп чыкты. Аның өстендә каешланып беткән кыска итәкле пәлтә, якаларын күтәреп, шарф белән буып бәйләгән, кулларында—зур-зур бияләйләр, аякларында—фетр итекчекләр. Малай аны шундук танып алды.

—Фатыйма! Син кая болай теркелдисең әле?—Югыйсә, кызның да Невага барганы күренеп тора иде. Малай аның җавабын көтмәде дә, тигезләнгәч, ни өчендер борчулы кыяфәткә керде.

Фатыйма сугышка кадәр күршедәге күп гаиләле йортларның берсендә яши иде. Алар монда күптәннән торалар инде. Тыныч кына кызый ул, хәтта ач блокада вакытында да озын толымнары пөхтәләп үрелгән булыр, күзләре—миндаль чикләвеге сыман коңгырт-кара.

Татарлар һөнәргә оста, өй ремонтлау эшендә дә катнашалар. Фатыйманың әтисе төрле тиредән тун тегә иде, туннары да туннары! Аларны, еллар үткәч, "дубленка туннар" дип йөртә башлаячаклар, мода яратучы чибәрләр киячәк. Тирә-юньдә Фатыйманың әтисен иң оста кеше дип санайлар. Блокада барысын да тигезләде. Әтисе фронтка киткәч, әнисе белән кызы бик ярлы яшиләр. Хәер, ул вакытта кем генә бай яшәде икән?

Без—рус үсмерләре, татар балалары белән бик дус-тату булдык. Дөресрәге, безнең арада берниндн аерма да сизелми иде. Бәлки, татар яшьтәшләр өйләрендә үз гореф-гадәтләрен тотканнардыр да, ә урамда һәм мәктәптә алар исемнәре һәм кара тутлы йөзләре белән генә аерылып тора иделәр.

Без—унөч-ундүрт яшьлекләр, өйдәге тәртипләргә буйсынып үскәнлектән, нинди дә булса зурларча гыйшык-мәхәббәт, яки башка фәлән-фәсмәтәннәр турында уйлый да белми идек, бары тик шуклык-шаянлык артына яшеренгән, тыеп торылган дулкынлануларыбыз гына кызларга тартып тора иде.

Володя исемле малай да "үз өлешенә тигән көмештән" мәхрүм калмады. Ул ябык, какча гына, юк, ачлыктан түгел, ачлык аның ябыклыгын тагын да сиздереп кенә тора, ул тумыштан, табигый шулай какча иде. Әгәр дә аның үз-үзенә ышанган, даими бәйсез төс-кыяфәте булмаса, без кыюлар арасында ул бераз мескенрәк тә күренер иде. Ул үзен бик хөрмәт итә. Телдән әйтмәсә дә, мәктәп малайлары аның хикмәтен белә. Ул үзен Изге Синод обер-прокуроры Обольянинов токымы дип саный. Ә обер-прокурор император Павел I нең яраткан кешесе була, бу хакта имеш-мимешләр генә түгел, тарих үзе шаһит икән. Үзенең шул аксөяк бабасының бабасы Володяга гаять көчле тәэсир итә иде. Башка чорда, башка вәзгыятьтә яшәсә дә, Володя үзен дә шундый илтифатлы-тәртипле итеп сизә, императорга соңгы көннәренә кадәр турылыклы булган бабасының бабасына охшарга тырыша иде.

Фатыйма белән Володя арасында ниндидер сизелер-сизелмәслек якынлык бар иде шикелле. Моны, бу эчке бер хисне, һавада тирбәлүче генә хисне, беркем дә сизмәс иде, мөгаен.

—Мин сине озата барам,—дип баш какты Володя.

—Ни сөйлисең?!—Фатыйма каушабрак калды.—Син анда булгансың ич инде…

—Булса ни!—дип кистереп әйтте Володя.—Чиләкләрне генә кертеп чыгам да… кот…

Ул, хәлдән тайган, ачлыктан эчен укшытырлык халәттә булса да, көчсез кызчыкка ярдәм итәргә ашыкты. Бигрәк тә кызчыкның куркынган-каушаган карашлары кызгандырды, аңа бит Невага суга барганда әллә нинди бәлаләр очрарга мөмкин.

Әнисе аны җиңеннән тотып калырга теләде, ләкин малай ычкынып, урамга чыгып шылды. Каян көч, житезлек алгандыр!

Алар чана бавына икәүләп тотынып, янәшә атлап бара башладылар. Ул кызның вак адымнарына яраклашырга тырыша, ә кызчык аның кебек зур-зур атлап барырга маташа, шуңа күрә икесенең дә адымнары бутала иде.

—Әйдә, бер аяктан атлыйк,—диде Володя.—Сөйләшеп тә барыйк, юл кыскарак тоелыр…

—Әйдә,—дип ризалашты Фатыйма, чөнки сүзсез генә бару аңа да уңайсыз иде.

—Әтигә сержант дәрәҗәсе биргәннәр,—дип мактанып алды кызчык. Янә сүзсез калдылар. Фатыйма кинәт кенә ярып салды:

—Татарлар русларны җиңгән, диләр. Шул дөресме?

Володя күз кырые белән генә аңа карап куйды:

—Ул бит борынгы заманда булган хәл. Руслар да татарларны җиңгәләгән. Ул заманнарда руслар белән руслар, татарлар белән татарлар да үзара сугышкалап торган.—Шуннан ул өстәп куйды:—Хәзер руслар белән татарларның немецләрне җиңүе кирәк…

—Җиңәрбез дә!—дип яктырып китте кызчык.—Минем әти сержант әнә!

Володя, житди генә өстәп куйды:

—Граф Кутаисов император Павелга турылыклы татар булган, минем бабамның бабасы белән дус яшәгән.

Фатыйма беркатлыланып сорады:

—Без синең белән дус булган кебекме?

—Без дусларммыни?—Володяның йөрәге ешрак тибә башлады.—Ә мин болай гына дип уйлаган идем…

—Болай гына, димәк, дуслар да,—дип Фатыйма кинәт көлеп җибәрде. Аның көлүе үз бәлаләренә баткан урамда кискенрәк яңгырады. Ә Володя өчен бу көлү ниндидер бер могҗиза, кышкы зәһәр салкын белән бәйләнмәгән ниндидер бер сергә ишарә төсле ишетелде.

Чаналарын өстерәп кайтып җиткәч, Фатыйма Володяга күтәрелеп карады:

—Син зәңгәрләнеп катккансың…—дип куркынып әйтте.—Хәзер егылырсың…—Ул кулын малайның күкрәгенә куйды, әйтерсең, егылудан саклап калырга теләде.

—Егылмам,—диде Володя горур гына.—Ял итәрмен. Ә синең белән Невага бергәләп барырга сөйләшеп куярбыз, бер-беребезгә ярдәм итешергә,—дип өстәде. "Ярдәм итешүне" ул үзе генә башкарачагы көн кебек ачык иде.

Алар ишек төбеннән үк чаналарын өстерәп бергә йөри башладылар, Невага чаклы юлны да бергәләп үтү җиңелрәк иде. Аларны суга йөрүче хатыннар да абайлап алды, риясыз гына макташтыра да башладылар, ә берсе:

—Әниегезгә булышасызмы? Ә ул абыйлы-сеңелле сезне дә аякка бастырыр…—дип куйды.

Балалар аның ягымлы сүзләренә җавап бирмәделәр, бары тик кар ерып Невага барып җиткәч кенә, Володя:

—Ә түтәйнең күзе үткен… Безне туганлаштырды…—диде.

Бервакыт ул Фатыйманың капка төбендә үзен көтеп торганын күрмәде. Салкыннан куырыла-куырыла ярты сәгатьләп көтте дә, өйләренә керергә булды. Ишекне кызның әнисе ачты.

—Без суга бергә йөри идек…—диде Володя.

—Беләм, беләм,—дип еш-еш сөйли башлады Фатыйманың әнисе.—Рәхмәт инде сиңа… Ә Фатыйманың тамагына салкын тигән… Ангина… Буржуйка мичендә кар эретербез инде…

—Корымлы карнымы?

—Сөзеп алырбыз… Сусыз нишләрбез соң?..

—Сез миңа аның чиләкләрен бирегез…

—Син ни сөйлисең! Сине үтерергәме әллә? Өч чиләк белән көрткә кереп капланырсың…

—Капланмам!—диде Володя кырыс кына.

Фатыйманың әнисе, аның сүзләренә буйсынып, куркынып кына чиләкләрен сузды.

—Үзеңне сакла,—дип әйтеп калды.

Өстәмә чиләкләрне дә тартып баруы кыен иде. Чана бата, табаннары карга күмелә. Әмма Володя бер хәйлә тапты, кичтән берәр сынык ипине яшереп куя да, юлга чыгар алдыннан гына шуны ашый, аннары ул әнисенең йон кофтасын киеп йөри башлады, аягына әтисенә дип бәйләгән солдат оекбашларын киде. Хәзер ул ял итәргә дә ешрак туктый, берәр минут ял итеп алса, көч кереп киткәндәй була иде.

Фатыйма бер атналап авырып ятты, Володя һаман да үҗәтлек белән чанасына өченче чиләкне беркетеп йөрде.

Ничектер көннәрдән бер көнне Васька Жмень дигән елгыр үсмер, базарда тегесен монысын сатып-алып йөргәндә, Володяны сызгырып туктатты:

—Татар изүенә элактеңме?—диде.

Башка вакыт булса, Володя аңа селтәнеп уң кулы белән шундый итеп ямар иде! Әмма хәзер сугышып йөреп, бу юләргә көчен әрәм итеп тормады:

—Әйе, изүгә! Дуслык изүенә! Син, җир корты, аны аңлый алмассың!—дип кенә суктырды.

Васька аптырап телен шартлатып куйды:

—Әйттең дә инде! Мескен философ!—диде.

Ә Фатыйманың әнисе Володяны, соңгы мәртәбә су алып кайтып биргәч, чәй эчәргә чакырды:

—Фатыйма аякка басты…—диде.—Сине чәйгә чакыра… Мин бәрәңге кәлҗемәсе пешердем. Бака кебек шоп-шомалар. Хәзер авызга керергә генә торалар…

Фатыйма Володяны үзе сыйлады, зур кружкага чәй ясап бирде. Урынынннан торып, Володяның борын төбенә Панкратовның тарих дәреслеген төртте:

—Укы, Володя! Минин белән Пожарский, татар атлылары ярдәм итмәсә,

баскынчыларны Мәскәүдән куып чыгара алмаган булыр иделәр. Безнең туганлык турында шундый фикерләрне уку күңелле!

Володя Фатыйманың алсуланып киткән йөзенә карап алды:

—Без татарлар белән бергәләп фрицларны куып чыгарачакбыз да чыгарачакбыз!—диде.

Алар бер үк сыйныфта укыйлар, йортлары да уртак бер ишегалдында булганлыктан, дәресләрдән соң гел бергә кайтып йөри башладылар. Мәктәптән өйләренә кадәр юл озын түгел, алар вак-төяк турында гына сөйләшеп алалар, ләкин соңыннан шул вак-төяк сүзләрдән дә аерым бер мәгънә табарга тырышалар иде.

Алар блокаданың көндәлек фаҗигасе уртасында үстеләр. Фаҗигагә күнегеп тә беттеләр шикелле. Ак кар астыннан бераз буран күмеп киткән, көкрәеп каткан аяк-куллары тырпаеп торучы мәетләр шәһәр урамнарында ята; янган биналарның нигезләре һаман төтенләп утыра; боз тавы булып каткан нәҗесләр кышкы кояшта алмаздай ялтырап тора; шәһәрне бер туктаусыз утка тоталар—болар барысы да аларның яшәү рәвеше иде. Ленинградлыларны кырып бетерергә, юк итәргә шайтаннар үҗәтлеге белән тырышучы дошманга каршы нәфрәт хисе тәннең һәр күзәнәгенә кереп тулган иде.

Соңыннан, инде Володя үсеп җиткәч, шул һәлакәт, хәрабәләр, нәфрәт эчендә яралган-бөреләнгән беренче хисләрен бер җепкә тезеп үрергә тырышты. Ул шундый уйга килде: нәфрәт бар нәрсәне дә йотып бетерә алмый, аның аша һәрвакыт яктылык, аклык-пакьлек нурлары, яхшылык бәреп чыга икән… Нәфрәт һаваны яндырып бетерә, ә кешеләр, сулар һава булмаса, яши алмыйлар.

Йөз башлы үлем гыйфрите үзләренә таба котылгысыз шуышкан-якынайган саен алар бер-берләренә ныграк сыенып яшәделәр, шунда үзләренең котылу чарасын күрделәр, шунда яклау таптылар.

…Ул май көнендә шәһәрнең алар яшәгән ягына туплардан ату ишелеп төшкәндәй күп булды, алар сызгыру-күкрәү тавышлары астында капка артына йөгереп керделәр. Бар дөньяны зир-зәбәр китергән ату тавышы тиздән тынды. Җимерелеп төшкән диварларның хәрабәләре әле төтенләп тора, сандружина кызлары ыңгырашып ятучы яралыларны носилкаларга салып каядыр алып китәләр иде. Фатыйма белән Володя дары төтененнән буыла-буыла торып йөгерделәр. Аннары кинәт кенә бер бакчаның коймасы янында тораташ катып калдылар: тездән өстәнрәк снаряд кисеп ыргыткан хатын-кыз аягын һава дулкыны коймага элеп куйган иде. Фатыйма агарынган иреннәрен көч-хәл белән ачып пышылдады:

—Минеке шикелле…

—Нәрсә синеке шикелле?..—дип катып калды Володя.

—Аягындагы оегы минеке шикелле…

Володяның тамагына укшыткыч төер килеп утырды, тораташ каткан Фатыйманы пәлтәсенең якасыннан йолкып, кычкырып җибәрде:

—Йөгерик…

Алар, әле генә күргән коточкыч күренештән акылларын җуеп, кая барганнарын да белмәстән, торып йөгерделәр.

Кич белән Фатыйма әнисенә дәште:

—Мин синең сугышка кадәр киеп йөргән ефәк оегыңны киим әле…

—Иртәрәк булыр, көләш булып үсеп җиткәч киярсең…

—Алайса, балачагымда кигән шакмаклысын…—Фатыйма, үксеп елый-елый, бүген күргән-кичергәннәрен сөйләп бирергә азапланды.

Кызының илереп елавын басарга тырышкан әнисе бер генә сүз әйтә алды:

—Тынычлан…—Аннары, башыннан сыйпап, өстәде:—Кайсын телисең, шунысын ал…

Язгы һаваданмы, күңелләре ачылып, мәктәптән урау юллар аша кайтканда, Володя, бераз тотлыга-тотлыга, тиз-тиз сөйли башлады:

—Зур булып үскәч, эшләп акча ала башлауга, сиңа иң-иң матур оек бүләк итәрмен…—дип, башын түбән иде.

—Без ул чакта да очрашырбыз микәнни?—дип, хәйләкәр сорау бирде Фатыйма.

—Әлбәттә,—диде тыныч кына итеп Володя.

Моңа кадәр кичерелмәгән хис аларны тагын да якынайткан иде.

Блокада беткәндә, аларга инде унбишәр яшь тулган иде, тартынмыйча очрашып йөри башладылар. Шәһәрне азат иткән бәхетле көндә алар Нева буенда йөрделәр, Петропавел крепосте бастионыннан аткан аллы-гөлле салават күпере төсле салютка сокланып карап тордылар. Шәһәрнең исән-сау калган халкы Тучков күперennән Киров проспектына чаклы шатлыклы ташкын булып агыла иде, алар шул халыкны ерып-ерып йөрделәр. Фатыйма кыюсыз гына итеп Володяга борылды:

—Кара әле, безнең районда бары тик Татар мәчете белән Изге Владимир чиркәвенә генә бер ярчык та тимәгән икән. Ә нинди матурлык бит!—диде.

—Аларга шул матур булганнары өчен дә снарядлар тимәгән инде!—дип җавап бирде Володя.

***

Аларның аяусыз кырыс та, дулкынландыргыч та кабатланмас тормыш тарихлары алга таба ничегрәк булды соң?

Володя Обольянинов Фрунзе исемендәге Югары диңгез училищесына укырга керде, укып чыккач, Фатыймага өйләнде. Мин аның лейтенант чагын хәтерлим әле. Диңгез мундиры аңа шундый килешеп тора иде! Билендәге кортигы матур ялтырый! Аны су асты флотына билгеләделәр, утыз җиде яшендә ул инде беренче ранг капитаны дәрәҗәсен алган иде. Ә тиздән ул командалык иткән су асты көймәсе Атлантика суларында һәлакәткә очраган, бер кеше дә котыла алмаган икән.

Мин күптән инде аның эзен югалттым, әмма бервакыт аңа багышланган шигырь яздым. Шигырь мондый юллар белән тәмамлана иде:

Обольянинов дустым яшьлектә,
Төннәрен рифмалар сырлап,
Татар кызы альбомына
Шигырь яза иде матурлап.
Хыялында шигыренең
Блокаданы өзәчәген

яза иде... Үлемне дә
Мәхәббәте җиңәчәген.
Соңрак, капитан да булгач,
Иптәшләре сорый иде:
—Ничек исән-сау калдың?—дип...
—Мин үлемне җиңдем инде...

Бу шигырьдәге капитанның җавабы, ул Атлантикада һәлак булгач, минем өчен серле-сихри бер мәгънәгә ия булды шикелле. "Мин үлемне җиңдем инде..." Ничек җиңгән? Блокададан исән-сау чыгуын ничек дәлилли? Һәм мин аның "үлемне җиңдем инде..." дигән сүзләрен чолганышта калган Ленинградтагы Фатыйманың "татлы татар изүе"нә, шул кызга булган могҗизалы хисенә бәйләп карый башладым. Буй җиткереп килгән сөйкемле кызның аңа нинди тормышчан көч биргәнен, тормышчан хисләренең мәңге яшәячәген тойган кебек булдым.

Тагын җанны газаплаучы бер уй бар иде: әгәр Володя Атлантиканың рәхимсез дулкыннарында чагында янәшәсендә Фатыймасы да барлыгын тойса, ул, бәлки, исән дә калган булыр иде. "Татлы татар изүе..." Аңа, бәлки, нәкъ менә шул җитмәгәндер...

P. S.

Дистәләрчә еллар үткәч, мин блокаданы бергә кичергән сыйныфташымнан хат алдым. Ул: "...1998 елның февралендә без Фатыйма белән очраштык. Бик кызыклы очрашу булды. Володя Обольянинов аңа багышлап шигырьләр язган икән, бу минем өчен ачыш булды. Фатыйманың шул шигырьләрне туплаган альбомы да саклана икән..."

Мин кабынып киттем! Володяның мәктәптә укыганда ук шигырьләр язып йөргәнен белә идем. Сыйныфташыма шундук җавап хаты язып салдым, һәм Фатыймадан ул шигырьләрне миңа күрсәтүен үтендем.

Иптәшем дә җавапны көттермәде. Әмма дә җавап өметсез булып чыкты: "Кызганыч, Фатыйма беркемгә дә Володяның хатларын һәм шигырьләрен күрсәтми... Миңа да моңланып кына: "Алар минем белән бергә батарга тиешләр... Минем кайгым диңгезенең төбенә..."—диде.

Шулай булмыйча соң! Мин дә аның күңелен аңладым: Фатыйма Володясының күңел серләрен, уй-хисләрен беркемгә дә ачарга теләми. Сөйгәненең рухы бары аныкы гына иде. Үз сәгате җиткәч, Фатыйма аның рухы белән бергә бу дөньядан китәргә җыена иде...

*Марс Шабаев тәрҗемәсе.*
*2004.*

⁂

*Яңа исемнәр*

## ТУГАН ТЕЛГӘ—
## УРАУ ЮЛДАН... ТӘРҖЕМӘДӘ

***Бу санда укучыларыбызга шигырьләре тәкъдим ителә торган авторыбыз Камил Тангалычев—Мордва иле егете, Такташыбыз якташы. Ельников районы Акчеево (Күгеш) авылында туып-үскән Камил Тангалычев Мордва дәүләт педагогика университетын тәмамлаган. Аннары—иҗат, шигырь дөньясы...***

***Менә аның төрле нәшриятларда дөнья күргән китаплары: "Рябиновые бубенцы", "Мой поводырь", "Ближняя деревня", "Дорога в Казань" (соңгысының исеме бик мәгънәле, безнеңчә!) һ. б. исемле шигырь, "Лунная мастерская", "Грядущая земля" дип аталган эссе җыентыклары. Әсәрләре шулай ук "Дон", "Север", безнең "Идел" кебек журналларда, "Мәдәни Җомга" газетасында; чит илләрдә, әйтик, АКШта, мәртәбәле әдәби басмаларда дөнья күрде. Һәм менә, безнең журналда...***

***Шуны да искәртик: язмышы рус телле шагыйрь итсә дә, Камил туган халкына, аның рухына, якташы Такташ моңнарына тугры калган хәлдә яши. Туган теле, тирән фаҗига белән өртелгән татар язмышы, татар авыллары, Сыркыдылар турында күп шигырьләрендә уйлана ул, үзен укып та җанын аңламаячак әнкәсен сагынып, ачынып, шигъри хатлар яза, җиңел генә милләтен, телен алмаштырган күп тәти егетләрдән аермалы буларак, "тел биләгән сихри биләү"гә кабаттан юллар да эзли... Тел югалту авырлыгын тою әрнүләрен сөйли аның шигырьләре...***

***Үзе дә Казаннан читтә, күрше Чуаш илендә туып-үскән, бәхетенә, татар мәктәбендә, аннан университетның татар филологиясе бүлегендә укып, милли тамырлардан аерылмыйча, бүген татарның танылган шагыйре булган Ркаил Зәйдулла Камилнең нәкъ менә шундый шигырьләрен сайлап, яратып тәрҗемә иткән.***

**Рәдиф ГАТАШ**



## Камил Тангалычев

## ТЕЛ БИЛӘГӘН СИХРИ БИЛӘҮДӘ

### Тәңре

**Күк—сәфәрдә иде япа-ялгыз:**
**Миңа гына очрады ул Күк.**
**Аңа сәҗдә кылган бабамнарны**
**Эзли чыккан ахры кичтән үк.**

Онытылу дигән караңгылык!
Һәркем кала монда югалып.
Күк-Тәңре дә коткаруны эзли—
Коткаралыр аны тик халык.

Онытылган Күкнең каршысында
Тып-тын калдым. Мин соң ни әйтим?—
Җир йөзендә ябык фикеремне
Иксез-чиксез күккә юнәлтмим.

Тавыш-тынсыз төнлә елады күк.
Ул адашкан иде, ахрысы.
Караңгыда аңа юл табыйм, дип,
Йөрәгем ут булып кабынсын.

Ул шәрекъкә китте—халкым күге.
Сөендерде бер хис бәгъремне:
Безнең белән кавышасы юлда
Адаштырмас иблис Тәңрене.

## Туган тел

Безгә һаман җилләр каршы булды,
Ачы булды, карлы, яңгырлы...
Һәм арынды халык "артык йөктән"—
Туган телен... ташлап калдырды.

Тел шуышты, өстерәлде алга,
Телсез калган халкын эзләде.
Ят кавемнәр аңа ташлар атты,
Тел
Калкынырга теләп тезләнде...

Күкләр ишетмәде бу халыкны.
Иблис адаштырган далада
Эзләп тапты да тел, сулыш өрде—
Кабат кайтты халык Аллага.

Ак биләүгә биләп үз халкын тел,
Уян инде, диеп инәлде.
Кырлар буйлап, гүя күк йөзеннән,
Татар авылына юнәлде.

Телгә йөзен ачты Тәңре шулчак,
Теләкләрен тоеп, иң тәүдә
Бәби булып биләнәсе килде
Тел биләгән сихри биләүдә.

Җитте алар өнсез бер авылга.
Гадәти бер авыл—юлдагы...
Мескен халык—
Шул борынгы сабый—
Җир-анага сыенып елады.

## Шагыйрь ватаны

Ут алган татар авылын...
Коткарам, дип, әлбәттә,
Тәңре боерган шагыйрьгә,
Илт аны, дип, җәннәткә.

Уттан алган да авылны,
Шагыйрь аны куенда
Алып киткән. Юлларына
Сәмави нур коелган.

Галәм диварларын хәзер
Ялмаган ялкын теле.
Ахирәткә киткән шагыйрь,
Дөнья калган өтелеп...

Утка чорналган Галәмнән
Аерып Җирнең ямен,
Үзе белән алган шагыйрь,
Белгән ул яшәү тәмен.

Кисәүләр бераз суынгач
Галәми салкын җилдә,
Төннең көлен күрәр өчен
Бирегә Тәңре килгән...

Кулын пешергән ул шулчак,
Актарып тарих көлен!
Сөю тулы йөрәк икән
Яндырган шагыйрь илен.

Ут алган татар авылын...
Коткарам, дип, әлбәттә,
Тәңре боерган шагыйрьгә,
Илт аны, дип, җәннәткә.

## Сыркыды авылында

*Якташым Һади Такташ истәлегенә*

Сыркыды шунда ук...
Әмма
Күченгән икән күптән...
...Юлбашчы рәсемен Шәхми
Өенә алып киткән.

Ташландык өй түбәсеннән
Кояш узды,
Хәерсез...
Ватылган арба көпчәге
Тәгәрәде, әйтерсең.

Мокамайлар курасында
Югалды ул аларып:
Иртән кояшны урлауда
Гаепләрләр малайны.

Мокамай
Эзли шагыйрьне,
Тартып ватык арбаны.
Аерылды да тәгәрмәчләр,
Дөнья буйлап таралды.

Атларны да
Алып киткән,
Ат карагы—бу вакыт.
Эзли хәзер үз шагыйрен
Бөтен дөнья буйлатып.

Ай балкый күктә.
Ярымай...
Исә йолдызлар җиле.
Тиздән печән чабарга дип
Хәйрулла абзый килер.

Тезен чүгә алмаганга
Шагыйрьнең нигезенә,
Мәңге елар бер карт каен,
Яшь кояр үзе генә...

## Мишәрләр

Сыкрап елый җилдә тирә-ягым.
Җир-анадан килгән ишарә:
Әрвахлары эзсез югалган да,
Үксез калган
Безнең мишәрләр.

Әрвахларны эзли киткән Тәңре.
Кардәшләрем! Халык!
Әгәр сез
Очратсагыз аны, яктырыгыз,—
Югалмасын Тәңре хәбәрсез.

Авылыңда иркенлекне сакла,
Тик дивар кор җиде ятларга.
Кайтачак бит Тәңре.
Туры килер
Кылган гамәлеңне акларга.

Табармы тик әрвахларны Тәңре?
Тапмас, тапмас, беләм тапмасын.
Килер вакыт—бөтен үксезләргә
Алмаштырыр нәсел бабасын...

* * *

Тәрәз төбе...
Әни гәҗит тоткан.
Анда минем шигырь. Һәм рәсем—
Улы карап тора.
Ә шигырьне
Укый алмый әни, күрәсең.

Укый алмый әни.
Шигырьләрем
Язылмаган ана телендә.
Һәрбер сүзем монда өнсез кош күк,
Һәрбер сүзем—сулган гөл генә...

Ул улының ни язганын белми.
Тәкъдир миңа ниләр язганын
Чамалыйдыр: Җан авазын минем
Аңа җиткерәлмәү газабын.

Дәшми-тынмый дисбе тарта әни,
Күз алдыннан үтә гомере.
Мин төшенмәм инде бу доганы,
Ул укымас минем шигырьне.

## Манара

*Риваятьләр буенча, Сөембикә, урысларга тоткын буласы килмичә, манарадан ташланган, имеш.*

Манарасы күккә ашмый икән,
Бу җир шулай үзе югары.
Манарадан өскә атлаганда,
Күкне җуйган синең кулларың...

Сулган ай да сине сагынадыр.
Анык булган зирәк хатынга:
Биеклекләр иблис өчен түгел,
Биеклекләр—Алла катында.

Казан буйлап җилләр елап йөри,
Сагынадыр шәһит киткәнне;
Тәңре өчен җирдә һәркем тигез,
Тик мәңгелек—якын иткәне.

Кырлар иркенлегеn сеңдергән җан
Тарта һаман синең Казанга.
Манараңны иңгә салган бу җир
Әйтерсең лә күкләр казана.

*Русчадан Ркаил Зәйдулла тәрҗемәләре.*

Айрат Суфиянов—1958 елда Башкортстанның Балтач районы Усман авылында туып үскән; урта мәктәп тәмамлагач, Уфада энергетика техникумында укый, армиядә була; аннан соң Коми АССРда хезмәт юлын башлый. 1985 елдан бирле ул Чаллыда яши; КамАЗның двигательләр заводында сынаучы-контролер булып эшли.

Шигырьләре көндәлек матбугатта, шул исәптән "Мәйдан" кебек басмаларда зур бәйләмнәр булып дөнья күрде. Журналыбызда беренче тапкыр басыла.



# Айрат Суфиянов

## Өмет калыр

Берсен-берсе таңнар кабатламый,
Кабатланмый көннәр шулай ук.
Кичә генә шат елмайган күзләр
Бүген инде карый моңаеп.

Бәхетнең дә, гамьле кайгының да
Үлемсезлек үпми—урынын...
Иртәгә үк кимчелеге калкыр
Бүген камил дигән җырымның.

Тормыш, тормыш мәңге хәрәкәттә,
Өлгереп тә булмый артыннан.
Мин бары бер сабый гына бугай—
Аның таганында атынган.

Галәм бożра, Галәм божрасының
Башлангычы да юк, азагы.
Тиеп узган җил шикелле генә
Керфекләргә тормыш газабы.

Күкләр рөхсәт иткән хәтле генә
Ача тормыш серләр пәрдәсен.
Бөекләр дә үлчи алганы юк
Яшәешнең төпсез мәгънәсен.

...Мавыктыргыч бер әкият сөйләп,
Бөекләр дә җирдән китәләр.
Кабатланмас тормыш мәйданында
Киртә артларында киртәләр.
Берсен-берсе көннәр кабатламый,
Кабатланып тумый иртәләр.

...Вакыт—иләк... Вакыт иләгеннән
Очып төшәчәкмен көл булып.
Төшенәм, дип, тормыш мәгънәсенә—
Торып калыр кебек өмет кенә,
Ак күбәләк көткән гөл булып.

***

Үз-үземне һаман ача алмыйм...
Яши алмыйм җирдә ачынмыйча—
Ачылмас шул тормыш серләре дә,
Азаккача үзем ачылмыйча.

***

Күңелдә таң туып килгән мәл...
Кызышып яңаклар аллана.
Уянган юкәләр ягыннан
Җил исә, ireннәр баллана.

Сандугач моңына таянып
Таң кызы чишмәдән су ала.
Гөлләрнең хуш исле төшләрен
Сеңдергән толымы чайкала.

Елмаеп карый да: "Нур йөзгән
Суым эч, сусасаң, әгәр",—ди.
Керфеге очыннан, чык булып,
Илаһи керсезлек тәгәри.

Кабатлый ягымлы таң кызы:
—Адашма караңгы юлларда.
Дөньяга син тудың ләбаса
Матурлык турында җырларга.

Тоймыйм да вакытның үткәнен,
Тукталды микән соң ул әллә?..
Таң кызы тотырган чиләктә
Кояшлы матурлык тирбәлә.

...Сөенеп карадым дөньяга,
Сабыйлык сафлыгын сагынып.
Таң кызы күзеннән күңелгә,
Мөгаен, нур калган ягылып.

Күңелдә таң туып килгән мәл:
Былбылын, юк! бирмәм тилгәнгә.
Ышанып яшәрмен, "дөньяны
Матурлык коткарыр" дигәнгә...

Күңелдә таң туып килгән мәл!..

***

Мизгел булсын, вакыт узды:
Ишеттеңме шуны кешем?..
Исәнләштең... Сөенечең
Бер сапламга якынайтты
Бәхилләшү көенечен...

Алдагысын кем соң белгән:
Ходай күпме гомер биргән?..
Йөрәгемдә янганда шәм,
Мин, кешеләр, сезнең белән
Исәнләшеп бәхилләшәм.

***

Шигърияттне тиңсез чәчәк күреп,
Сайрый-сайрый,
Килеп кунган идем кашына:
Йомылды да, йотты, шул мизгелдән
Мин бер әсир аның таҗында.

Ачылса да, инде чыкмамдыр ла,
Шул халәттә килә яшисем:
Хыялларның тойсам хуш исен, мин
Чынбарлыкның тоям яшь исен...

Шул халәттә килә яшисем...

## Тормыш бөек каршылыгы белән

Сагыштан да олы шатлык табам,
Болыт аша әзлим кояшны.
Төшенкелек авыр таш булса да,
Он итәргә телим шул ташны...

Тормыш бөек каршылыгы белән,
Ул һәрвакыт бәхет яудырмас.
Әйтә алмыйм, дип: бүген иркәләсә,
Иртәгәсен коры калдырмас...

Тормыш бөек каршылыгы белән:
Каршылыктан акыл, ямь табам.
Кайгыда да, бәхеттә дә сулыш,
Ачы, татлы гамь вә тәм табам.

Тормыш бөек каршылыгы белән
Каршылыкка кеше мохтаҗ ул.
Каршылык бит—аңга очкын өргән,
Җанга үсеш биргән остаз ул...

...Тормыш, барлык каршылыгың белән,
Хөрмәтләргә туган улыңмын:
Болыт аша саркып чыкса гына
Кадере зур кояш нурының...

# Ədəbi tənqit
# Әдәби тәнкыйть

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

## КАЙДА БЕЗНЕҢ РЫЦАРЬЛАР?!

Могтәбәр журналыбыз оештырган бик кирәкле, хәтта зарури әдәби дискуссиягә катнашып, тәүге сүземне яңа әдәбият яңа формадан да, яңа стильдән дә түгел, ә яңа геройдан юл ала, дигән гыйльми карашны искәртүдән башлар идем. Ә Совет системасы һәм аның базис, өскорма күренешләре беткәннән соң, базар шартларына яраклашкан сүз сәнгатенең эчтәлек һәм форма ягыннан да, стиль һәм жанрлар мөнәсәбәтендә дә бик күп үзгәреш-яңалыклары бар. Яңа әдәбиятның мөһим бер юнәлешен тәшкил иткән эссеистик проза әнә шундыйлардан. Без аның аеруча кызыклы үрнәкләре итеп Ә. Еникиның "Соңгы китап", "Кояш баер алдыннан", М. Мәһдиевның "Ачы тәҗрибә авазы", Т. Миңнуллинның "Утырып уйлар уйладым", М. Галиевның "Догалы еллар", Р. Мөхәммәдиевның "Утлы таба өстендә", А. Гыйлажевның "Йөгез, бер дога", А. Хәлимнең "Телем минем—дустым минем", "Гомеремнең ун көне" әсәрләрен саныйбыз. Болар чынлап та, эссе жанрындагы үрнәкләр. Башкортстанның Халык шагыйре Мостай Кәрим, мәсәлән, *"Советская Россия" (04.01.89)* газитендә: "Появилось эссе "Язык мой—друг мой" писателя из Уфы Айдара Халима",—дигән иде. Ләкин бездә саналган әсәрләрне әлегә төрлечә атыйлар һәм аларга булган мөнәсәбәт тә төрлечә.

Р. Сверигин без искә алган "Утлы таба өстендә", "Догалы еллар"ны *("Казан утлары". № 5, 1997)* публицистик проза дип исемләде һәм әдәбият өчен "публицистика, автобиографияләр, мемуарлар белән артык мавыгу" зыянлы дигән карашын белдерде. Ә икенче бер абруйлы тәнкыйтьчебез Р. Мостафин исә яңа сәяси чорда аякка баскан "публицистика тармагын" кайнар хуплады: "Бер Айдар Хәлимнең ялкынлы публицистикасы гына да ни тора! Шулай ук Фәүзия Бәйрәмова, Әмир Мәхмүдов, Әхмәт Рәшитов, Рафаэль Хәкимовларның чыгышлары суверенитет өчен көрәш барганда үз ролен уйнады, халыкның аңын агартуда зур әһәмияткә ия булды" *("Казан утлары". № 5, 2004)*. Әлбәттә, текстта искәртелгән барлык авторлар да эссе язучы түгел. Ләкин Р. Мостафинның "публицистика тармагы" эченә А. Хәлимнең эссе жанрындагы мәшһүр китапларын кертүе инкяр ителмәс.

Эссе үрнәкләрендә, жанр табигате кушканча, теге яки бу тема, мәсьәлә, күренеш хакында әдәби-эстетик, фәлсәфи, гыйльми-публицистик фикерләүләр үткәрелә, шул ук вакытта автор эмоциональлегенә—тойгы-хисләренә, күңел бушатуларына да урын бирелә. Гамьле кайнар проза төре бу. Нәкъ шул сыйфатларга ия булганга, тоталитар режим системасы мондый әсәрләрдән курыкты. Һәм искә алынган авторларның аерым китаплары да рәсми дәүләт нәшриятларында түгел, ә аулак яисә чит җөмһүриятләрнең басмаханәләрендә дөньяга чыкты. Бу әлегәчә әдәбиятыбызда ят-чит булып торган жанрга мөрәҗәгать итүнең сәбәпләре дә ачык: "Йөрәгендә намусы булган кичәге тыныч шагыйрьләр һәм язучылар көрәшчеләргә, публицистларга әйләнде. Без үзебезне яңадан танып-белергә, үзебезгә читтән карап бәя бирергә, үткәнебезгә һәм

бүгенгебезгә дөрес анализ ясарга тиешбез, тәүбә дә кирәк",—ди "Гомеремнең ун көне" авторы.

Герой проблемасын хәл итүдә иҗат фантазиясе ярдәмендә тудырылган әсәрләр кебек үк роль уйный алмаса да, мәгълүм эссеистик проза катламы, безнең карашка, яңа әдәбиятның идея-эстетик нигезләрен корыда ифрат зур әһәмияткә ия. Укучылар һәм, шулай ук, язучы кеше зирәк каләм осталарының күзәтү, фикер йөртүге аша катлаулы чынбарлыгыбызның яңа нечкәлекләрен ача, фәһем ала, бәя бирә. Боларда без иллюзионистның оста оештырылган фокусы кебек, көтмәгәндә тере замандашларыбыз белән очрашабыз. Ә аларның байтагы киләчәктә повесть, роман, поэмалар язучылар өчен алдан өйрәнелергә лаеклы шәхесләр булып торырга мөмкин бит. Безне Ә. Еникиның укучы белән кеше гомере хакында соңгы кабат ихластан сөйләшүләре дә, М. Мәһдиевнең яшьлегендә һәм ир уртасында тойган төрле-төрле кичерешләре белән бүлешүе дә, Т. Миңнуллинның милли тормышка карата ифрат кызыклы бәяләре, хөкем чыгаруы да, М. Галиевның зур төркем татар зыялыларын үзенчә бер осталык белән сурәтләп, тасвирлап бирүе дә, Р. Мөхәммәдиевның Ельцин сәясәтендә катнашып "маңгай канатулары", әрнеш алулары да, А. Гыйлаҗевның Сталин тоткыны буларак, сәяси лагерь-төрмә тормышы белән әтрафлы таныштыруы да теләсә кайсы укучыны, хәтта бәгырьсезләрне дә, ваемсыз-битараф калдыра алмый. Ә инде Русия күләмендә "экстремист" булып танылган А. Хәлим китаплары үзләре— чын-чынлап милли энциклопедия! Менә шулай һәркайсы безне чолгаган дөньяның бер кыйсьмен ачсалар да, аларны берләштергән зур уртаклык та бар. Бу—элекке, тоталитар системаның кешене кысрыклау, басу, хәтта кол итүенә каршы нәфрәт, золымны фаш итү пафосы. Моның югары чагылышы, әлбәттә, А. Хәлим әсәрләрендә. Уйлап кына карагыз, үз халкының милли мәнфәгатьләре хакына, аерым алганда, туган телне, мәктәпләрне исән-имин сакларга теләп югары хакимиятнең ишеге төбендә кеше чатыр кора һәм … ачлык игълан итә! 1990 елгы октябрьнең яңгырлы ун көнендә тулы бер җөмһүрият, юк, Русия язучы корган кайнар сәяси акция шаукымы белән яши. Кемдер нәфрәтләнә, кемдер шатлана, ә кемнәрдер җил-давыл булып Ак йорт мәйданыннан чатыры-ние белән "ата милләтче"не себереп ату турында планнар кора… Мин әле дә еш кына Айдар чатыр корган Совет мәйданына килеп чыгам, шул көннәрдәге мәхшәрне хәтерлим, әмма бу эшнең гади бер кеше тарафыннан эшләнүенә хәзер инде ышанасы да килми. Өйгә кайткач, татар тотмыйча ышанмас дигән төсле, шкафтан әлеге көннәрнең җисми шаһиты булган "Гомеремнең ун көне" китабын алам. Ул исә кулны өтеп, пешереп алгандай була…

Милләте хакына үз-үзен аямыйча хәтәр гамәл кора һәм кайнар тойгылы әсәрләр яза алган әдибе булган әдәбият зәгыйфь була алмый инде ул! Айдар Хәлимгә Бөтендөнья рыцарьлары Конференциясенең Ак Хач ордены кавалеры исеме бирелү милли иҗатның киләчәгенә тагын да өмет белән карарга хокук тудыра. Уенмыни, золымга каршы чыгып, тел-лөгать, рух, матурлык сагына баскан кыю рыцарьларыбыз бар!

2

Әлегә без яңа әдәбиятның бер катламы булган эссеистик прозаны аерым, әдәби процесска бәйләнешсез күренеш итебрәк карадык. Әмма мәгълүм әсәрләр, язучы эшгамәлләренең "заман героен иҗат итүгә йогынтысы бармы?" соравын куйгач, көтелмәгән парадокс туды. Тормыш белән бәйләнеше көчле булган әдәбиятта, һичшиксез, Айдар Хәлим феномены киң һәм тирән яңгыраш табарга тиеш кебек. Шуның өстенә аның тибы ялгыз түгел, милли хәрәкәт геройлары һәм активистлары Фәүзия Бәйрәмова, Рәшит Әхмәтҗанов, Газинур Морат бар иде.

Хәер, нигә язучылар гына? Бу мәсьәләне киңрәк кую мөмкин бит. Үзгәртеп кору елларының болгавыр мохитендә үсеп чыккан әллә ничаклы милли хәрәкәт лидерлары, узаманнары, милләт хадимнәре бар иде безнең. Фәндәс Сафиуллин, Марат Мөлеков, Әмир Мәхмүдов, Зәки Зәйнуллин, Зиннур Әһлиуллин, Рәшит Ягъфәров, Индус Таһиров һәм тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр. Шуның өстенә Татарстан суверенлыгы өчен Русия күләмендә шаулаган данлы тарихыбыз да бар бит безнең.

Әлеге фактлар яктылыгында без "заман герое" бәхәсен ачып җибәргән Р. Шәрәфиевнең "Әдәби геройга әверелерлек шәхесләребез мәйданга килгән иде", тик аларны заман герое итеп күрсәтү омтылышы "өлгермәгән килеш пыскып сүнде" (*"Казан утлары". № 1, 2004*) дигән фикерен бик урынлы итеп табабыз. Без дә яңа әдәбиятның геройлар галереясында, теге яки бу сюжетлар канвасында милли азатлык хәрәкәте рыцарьларын, һич булмаса, шәүләләрен күрергә теләү бик урынлы һәм табигый теләк дибез. Әмма замана әдәбияты моның һаман әле кысыр өмет икәнен раслап килә.

Ник? Дискуссиядә нәкъ шул сәбәпләрне җитди ачыкларга кирәк безгә.

Милли кузгалыш каһарманнарын туксанынчы еллардагы азатлык хәрәкәтендә кайнап, шул вәзгыятьнең бөтен нечкәлекләрен үз миендә һәм йөрәгендә тойган Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Рәшит Әхмәтҗанов кебек язучыларыбыз, шагыйрьләребез иҗат итә ала иде. Ләкин ни гаҗәп, аларның күпсанлы һәм төрле жанрдагы әсәрләр тезмәсендә мин бу омтылышны күрмим. Аерым табышлары булса да, үткәндәге әдәби персонажларны хәтерләткән геройлар тасвирлау, заман язучылары тапкан гомум коллизияләрдән файдалану... Дөрес, А. Хәлимнең "Өч аяклы ат" повестена карасаң, андагы Кәбир образы аша заман героен күрсәтү омтылышын сизәсең. Бүре талаган атны ерак чакрымнар аша авылына алып кайтып, ул әнисе Саниянең намусын саклый, үзендәге үҗәтлек, булдыклылык, зирәклек, табигать белән берләшү, кешеләр белән мөгамәлә урнаштыру кебек матур сыйфатларын ача. Сүз юк, матур әсәр! Ләкин элек-электән шулай килгән, узаманнар ераккарак карый, төптәнрәк күрә, нечкәрәк кичерә. Халык томанлы күзаллаган өмет-идеалны да мондыйлар ачык, аңлаешлы идеяләргә, сүзләргә, ниятләргә төрәләр. Яңа сүз, образ-сурәт аркылы өметләргә ачкыч кәтә иде безнең заман әдәбияты Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова кебек милли узаман язучыларыбыздан. Ә соравымны урынсыз һәм тактсыз итеп тапсагыз, гафу итә күрегез: мәшһүр Андерсен әкиятендәге сыман халык каршына чыккан король ялангач һәм буш булмагандыр бит? Шулай булса, бу—безнең әдәбиятыбызның гына түгел, бәлки бөтен татар милли хәрәкәтенең олы фаҗигасе.

Әлбәттә, заман героен табу, бигрәк тә көрәшче, каһарманнарны әдәби мәйданга чыгару тик инкыйлабчы-язучы эше генә түгел. Әдәбиятта яңа сын, яңа матурлык табу һәрчакта күмәк көч һәм иҗади дуслык, хезмәттәшлек белән башкарылган. Берәү тапканны икенче үстерә, берәү башлаганны калганнары дәвам итә. Болгар әдибе Кол Галиның кем булуы—дәүләт эшлеклесеме, руханимы яисә бары шагыйрьме—безгә ачык түгел. Ләкин ул үз заманында Болгарга кергән ислам динен хак иман итеп танытырга теләүчеләрнең берсе. Һәм нәкъ әлеге ният белән аның бөек язмышлы Йосыф китабы язылган. Моннан соң төрки телле әдипләр әлеге китап тәэсирендә әллә ничаклы әсәрләр—кыйссалар, дастаннар, поэмалар иҗат итәләр һәм шулай "Коръән" кануннарын кешеләргә җиткерү өчен көрәш дәрте үсә, көчәя бара.

XIX йөзнең соңгы чирегендә формалашкан мәгърифәтчелек әдәбиятында да шундый ук хәл. Зирәк язучыбыз Муса Акъегет "Хисаметдин менла" (1886) романында мәгърифәтчелек хәрәкәтенең төрле омтылыш-ниятләрен, хәтта әхлаки-этик кодексын ачып салды. Шул милли-сәяси мәзһәбкә Риза Фәхретдин, Фатих Кәрими, Ш. Мөхәммәдев, З. Һади, Акмулла кебек талантлы каләм осталары килеп кушыла һәм нәтиҗәдә әдәбият халыкны аң-белем, югары әхлак, һөнәр үзләштерү өчен көрәшкә чакыручы кодрәтле көчкә әйләнә.

Ә безнең хәзерге әдәбиятта милләт язмышы, киләчәге турында ихлас кайгыртып уртак идеягә тупланучы язучылар төркеме, юнәлешләр бармы? Тормыш дәрте, көрәш пафосы көчлеме бүгенге әдипләрдә?

Әмма шөкер, әлеге мәсьәләдә әлеге дә баягы өлгер Айдар Хәлим уйланган икән. "Милли хәрәкәткә тәрәзәдән генә авыз ерып, "язучының эше бары язу ул", "җырчының эше бары сәхнәдән җырлау ул", дип үзеңне юатып кына милләт алдындагы изге бурычыңны аклап буламы икән?" Һәм икенче бер уңай белән бу автор үз уйларын аныклый төшә: татар язучыларының "милләт хакына борчылуларын, теләк, фикер белән көрәшчеләр сафына басуын телим. Әмма мин беләм, әлеге татар зыялыларының туксан проценты җитмеш ел буе куркытылудан соң тик "үзем" тирәсендә генә әйләнә".

1996 елгы татар прозасына күзәтү-анализ ясагач, Р. Сверигин да төшенкелек белән искәртеп куйган: "Аянычлы хәлләрне күреп, бүген берәү дә чаң сукмый. Киресенчә, әдәбият дөньясында ниндидер үз-үзеңнән канәгатьлек, бар булганына шөкер кылып яшәү, сөенү, бәйрәм итү рәхәтлеге хөкем сөрә" *("Казан утлары". № 5, 1997)*.

Язучы һәм тәнкыйтьчене тыңлагач, дискуссиягә катнашып, сүз әйткән Рафаэль Мостафин фикере искә төшә: "Тоталитаризм чорында язучы бердәнбер туры сүз, кыю фикер әйтүче булса, демократия чоры килү белән ул гади бер авторга әйләнә" *("Казан утлары". № 5, 2004)*.

Элек "Русиядә шагыйрь бары тик шагыйрь булып кына кала алмый" диләр иде, юраган чынлап та юш килә микәнни?

Хәер, заманыбыз әдәбиятында актив геройлар, көчле һәм тормышчан идеяләр зәгыйфь булуга тик язучылар гына гаеплеме соң? Әдипне әдип иткән, зур иткән, бөек иткән ике әйбер бар: олы тарих вакыйгасы һәм ачык, гуманлы идеология. Безгә хәзер инде вакыйгалар кирәкми, халык алардан күптән гарык, ә менә әйбәт идеологиягә без чынлап торып сусаганбыз.

Бу да мәсьәлә: кемнәрдер заманга хас иҗтимагый идеяләр системасына зарыга, ә кемнәрдер аның әһәмиятен бөтенләй танымый да. "Коммунистик идеология урынына яңа рәсми идеология, ягъни әзер догмалар кирәкми. Дөньяны дөрес аңлар өчен гомумкешелек идеологиясенә, халкыбызның мең еллык рухи мирасына таянырга кирәк", ди, мәсәлән, Рафаэль Мостафин ("Казан утлары". № 5, 2004).

Теге яки бу этнос, халык, милләтнең үз рухи, мәдәни һәм икътисади тормышын ниндидер универсаль гомумкешелек идеологиясенә нигезләнеп коруы—иллюзия. Татар өлешенә генә аны такмыйк! Халыкның мең еллык рухи мирасыннан әтмәлләгән идеологияне дә мин, карчыкларның корама юрганы кебек, заманга яраклы булыр дип уйламыйм. Безгә, һичшиксез, үз чорыбызга, үз рух-менталитетыбыз һәм милли омтылышларыбызны чагылдырган идеология кирәк! Моны кору, иң элек, хөкүмәт, Дәүләт системасы эше. Русия һәм Татарстан хакимиятләре үз гражданнары белән чын мәгънәсендә демократик һәм мәдәниятле нигездә идарә итәргә омтылсалар, халыкка күптән җиткерелгән, ачык идеология яшәргә тиеш иде инде. Чынлап та кая барабыз, кем булабыз, нинди әхлакый кыйммәтләрне олылыйбыз соң без? Бүгенге ил Дәрдмәнд шигырендәге җилләр-давыллар ихтыярында төрле якка ташланган, юлсыз-кыйблэсыз калган кораб хәлендә түгелме?

Әдәбиятта өлге булырлык заман героен күрү күп төрле таләпләрне гамәлгә ашыруга бәйле икән ул. Монда да "алма пеш, авызыма төш!" дип көтеп ятып кына берни чыкмый икән шул...

Кадими хакыйкать яктылыгында халкыбызга мәдәни-рухи күтәрелеш өчен бүген асыл, олпатлы ирләр, булдыклы егет һәм кызларның кирәклеген аеруча ачык тоябыз. Милләткә рыцарьлар кирәк! Чынлап та, кайда безнең рыцарьлар?

3

Ә борынгыдан килгән, безне тик вакытлы юлдаш кына иткән әдәбият көтми. Каләмнәрнең рухи өлгерү-өлгермәү яисә язучыга илһам килү, таланты ачылу-ачылмауда да аның эше юк. Поездагы кебек, кем өлгер, аның ымсындыргыч сәхифәләренә шул кереп утыра һәм үзенең әхлакый, этик, эстетик кануннарын урнаштыра башлый.

Болгавыр еллар башлангач, әдәбиятыбызның төссезләнә, зәгыйфьләнә баруын күпләр күзәтсә дә, моны ачык итеп башлап Р. Сверигин әйтте шикелле: "Тормыш шыксызлыгын, аның ямьсез якларын иркенләп, тәфсилләп сурәтләүче әсәрләргә әдәби басмаларда урын көннән-көн күбрәк бирелә". Тәнкыйтьче "Кенәри читлек кошы" *(Р. Мөхәммәдиев)*, "Балта кем кулында" *(А. Гыйләҗев)*, "Ирекле тоткыннар" *(Р. Айзатуллин)*, "Җимерелгән хыяллар" *(Ә. Галиев)* кебек романнарны "негатив проза" дип атады. Кемнәрдер бу терминны "кара проза" төшенчәсе белән алмаштыра. Бер үк вакытта "кара роман" төшенчәсе дә әйләнешкә кереп бара бугай. Мәсәлән, Р. Раков А. Хәлимнең "Татар вакыты" әсәрен нәкъ шулай дип атый *("Казан утлары". № 9, 2004)*. Тик әйләнешкә керү омтылышы һәм хаҗәте туган икән, әлеге атаманың

кулланылыш даирәсен ачыкларга кирәк. Безнеңчә, негатив яисә кара проза үрнәге дип А. Гыйләҗевның "Балта кем кулында" романын атау тирән хата. Р. Сверигинча эш итсәк, без әлеге әсәр белән янәшә И. Салаховның "Тайгак кичү", Г. Тавлинның "Афәт", Р. Кәраминың "Каргышлы этаплар", Р. Мөхәммәдиевнең "Сират күпере" кебек сталинизмны фаш итүгә өлеш керткән сәяси юнәлештәге әдәбият үрнәкләрен дә санарга тиеш булачакбыз. Ә мондыйларга "каргышлы проза" термины туры килеп тора түгелме? Айдар Хәлимчә әйтсәк, "шәхестән кол ясаган системага, иҗтимагый корылышка каргыш".

Кара проза үрнәге, аңлашыла инде, кеше тормышындагы рухи таркалу һәм көрчек—эгоистлык, икейөзлелек, алдашу, җинаять дөньясына чумуны сурәтләү ул. Мондый әсәрнең финалы да ачык—фаҗига. Кара проза, кыскача әйтсәң, тормыштагы әзлаксызлык, идеалсызлык чагылышы ул. Һәм билгеле инде, акыллы тәнкыйть мондый әсәрләргә юлны бикләү чарасын да күрер сыман. "Караңгы проза татар әдәбиятына, аның традицияләренә бигүк ярашлы күренеш түгел һәм аны артык үрчетү кирәкмәс иде", ди, мәсәлән, Р. Сверигин *("Казан утлары". № 5. 1977)*. Әмма гамәлдә эш ансат кына хәл кылынып димә. Чөнки бездә кара проза әсәрен тануда һәм аның геройларын бәяләүдә бернинди уртаклык юк. Әйтик, мәгълүм дискуссиядә байтак авторлар Т. Галиуллинның "Тәүбә" трилогиясенә кагылдылар. Дөресен әйткәндә, бәхәсләр күчәре әлегә кара проза һәм андагы персонажлар тирәсендә әйләнә дә. Р. Шәрәфиев, мәсәлән, "Тәүбә", "Элмәк", "Төнге юллар" исемнәре белән аталган трилогияне укып, алардагы үзәк герой Сәет Сакманов белән танышкач, икеләнмичә, аны "уңай герой түгел", дип атый һәм сорау куя: "Чыннан да безме соң бу? Бигрәкләр дә пычранганбыз, гөнаһка батканбыз, миһербансызланганбыз, йөзебезне дә югалта барабыз ич" *("Казан утлары". № 1, 2004)*.

Шулай ук, Р. Мостафин да Т. Галиуллин романын "бозыклык реализмы" дип бәяли һәм катгый төстә: "Мондый әсәрләрнең персонажлары никадәр тормышчан булмасын, заман герое дип атап булмый" *("Казан утлары". № 5, 2004)*.

Р. Зариповның "Кызганычка каршы татар әдәбиятында үтә дә тискәре Свидригайлов *(Ф. М. Достоевский персонажы)* сыман агайлар уңай геройлар буларак тәкъдим ителә башлады" *("Казан утлары". № 9, 2004)* сүзләрендә Т. Галиуллинныкы кебек әсәрләрне күздә тоту һәм аңа үтә тискәре мөнәсәбәт тотуы аңлашыла.

Мәгълүм романга карата Р. Сверигин мөнәсәбәте бик кызык. Алданрак язылган бер мәкаләсендә *("Казан утлары". № 5. 1997)* ул "Тәүбә"нең, күңеле тарткан әсәр буларак, тиз бетүенә канәгатьсезләнсә, хәзер инде аңа бөтенләй башкача мөнәсәбәт тота: "Бу икейөзлелек, алдашу, эгоистлык күренешләреннән туеп бетәм, китапны бер якка ыргытып, тизрәк яктырак, сафрак дөньяга чыгып китәсе килә"... *("Казан утлары". № 11, 2004)*. Әмма шуңа карамастан, миһербанлы өлкән әдәбиятчыбыз романга уңай мөнәсәбәтен дә җуймый: "Тәлгат Галиуллинның әсәре әнә шул бозыклыкны, череклекне күзләребезгә төртеп күрсәтеп кисәтүе белән дә әһәмиятле", дип укучыга Сакмановны явызлыкны фаш итүче герой итеп тәкъдир итә.

Ә инде А. Әхмәдуллин әдәбият герое Сәет Сакмановка карата соклану белән карый, ул шик-шөбһәләрдән дә азат: "Сакманов—кыю, яшәешебездә торган саен урын ала һәм ныгый барган гаделсезлеккә үзенчә каршы чыга, заман үзе барлыкка китергән ысулларга таянып көрәшә, саф мәхәббәтне зурлый белә" *("Казан утлары". № 7, 2004)*. Шулай итеп, кыйбласызлык заманында безне яшәргә, исән-имин калырга һәм баю юлларын табарга өйрәткән Т. Галиуллинның эшкуар һәм башкисәр герое хөрмәтле галимебез каршында "безнең көннәр герое" булып күтәрелә.

Нәрсә соң бу? Инде кыйблаларны гына түгел, бөтенләй зәвык югалту, бәяләрне дә буташтырумы, акның карага, ә караның акка күчүеме? Югыйсә, дискуссиядәгеләр әдәби күренешне бәяләүдә дальтониклар хәленә калмаслар иде бит... Менә шуннан соң куарга тырышып кара инде син Т. Галиуллин героен әдәбият мәйданыннан. Юк, Сакманов китәргә килмәгән. Тип буларак ул әле анда тагын үсәчәк, ишәячәк. Шуңа күрә аны аңларга һәм аның турында җитди сөйләшергә кирәк безгә.

Рәхмәт төшкере, А. Әхмәдуллин Сакмановка карата үз бәясен генә бирмәгән, ә аны аңлар өчен ачкыч та калдырган икән. Бәхәсләшүчеләр, ди ул: "бүгенге

җәмгыятьнең нинди икәнен үзләре дә ахыргача аңлап һәм белеп бетермиләр". Әйе, нәкъ шулай! Инкыйлаб кичергән заманнан чыгып бәяләргә кирәк бу геройны. Беренчедән, Сакманов—"яңа татар", ягъни бүгенге элитаның акыл асты чагылышы, икенчедән, ул ук безгә милли сәнгать, әдәбият дөньясында элекке пролетар зәвыкның бөтенләй бетеп, сыйнфый эстетиканың гамәлгә керүен, хәтта буржуаз эстетиканың инде өстенлек алуын да раслый.

Әйе, уяныгыз әфәнделәр! "Яңа руслар", "яңа татарлар" ясаган хәтәр инкыйлаб җилләре икътисадны, рухны гына түгел, әдәбият дөньясын да үзенчә тетрәтә, әверелешләр ясый, принципларны үзгәртә... Шул алмашынулар шаукымында Сакманов әдәбият дөньясына килеп төп герой булырга ымсына икән, һич аптырарлык хәл юк. Хәтерләгез, "Тәүбә" романының төп герое—"Игелек" ширкәте башлыгы. Начармы ул, яхшымы, аның визит карточкасында "предприниматель" дип искәртелгән. Ә предприниматель, ягъни безнеңчә эшкуар, малтабар, Русия президенты Б. Н. Ельцин игълан иткәнчә, җәмгыятьнең төп әйдәүче көче, җитәкче сыйныфы булды.

Ә руль кем кулында, шул идарә итә: машина белән, хуҗалык белән, сәнгать-мәдәният белән, ил белән... Кыскасы, кызлар җәймәсе кебек ак, чиста мораль-әхлак канвасында ничек кенә килешсез күренмәсен, Сакманов сәнгать өчен дә ят зат түгел. Юк, алай гына түгел, Сакманов тибы хәтта безнең өчен элекке таныш икән—аның әдәбиятыбызга кабат килүе бу.

Мин татар мәгърифәтчелек әдәбиятының мәшһүр әсәре "Хисаметдин менла" турында әйткән идем инде. М. Акъегет милләтпәрвәр затлар төркеме арасында бакырчылык мастерское хуҗасы Гайса Зурколаковны бик яратып сурәтли. Эшкуар буларак, ул вакытның кадерен белә, аны сәрмая—акчага тиңли, мал табуны идеал итә һәм тапканыннан халыкка да өлеш чыгара, ярлы-ябаганы укытып һөнәрле ясый. Милләт рыцаре да ул: "Уйланыгыз, кардәшләр!" дип халыкны зур мәдәниятле халыклар үрнәгендә мәгърифәткә, үсешкә чакыра, шуңа гамәли өлеш кертә.

Үткәндә әлеге эшкуар тибы теләп һәм зур өметләр белән каршыланган. Ник Сакманов та шундый сөйкемле әдәби герой була алмады соң?

Урыс әйтмешли, чынлап та бер елгага ике кат кереп булмый икән... Ә төгәлрәк әйткәндә, Сакманов та безгә Гайса кебек теләп алган зат рәвешендә килгән булыр иде, әмма аны затсыз Ельцин хакимияте бозды. Халык бу исерекбашның "Суверенитетны никадәр йота аласыз, шулкадәр йотыгыз!" дигәнен хәтерли. Әмма бу аның премьер Е. Гайдар аркылы: "Акча, мал туплагыз, ничек, монысы әһәмиятле түгел" дип эшкуарлар күңеленә салган шайтан вәсвәсәсе белән чагыштырганда гөнаһсыз бер гөнаһ булып кына кала. Иблислык дәүләт күләмендәге сәясәткә әйләнде һәм А. Чубайс тарафыннан оештырылган ваучер аферасы, С. Кириенко эшләгән дефолт акты финанс махинацияләре, коррупция, алдашу, урлашу галәмәтләре үрчетүдә яңа русларга дәүләт биргән дәрес буларак хезмәт итте. Димәк, гаделсезлек канун белән ныгытылган дәүләттә әхлак, вөҗдан саклыйм дип җан атасы юк... Шулай итеп, Сакмановны әхлаксызлыкта гаеплиләр икән, бу Ельцин намусында!

Хәер, әхлаксызлык Ельцин намусында гына микән? Бу бит җимерелгән СССРның, таркала барган Русиянең рухи өлкәсендәге олы чагылышы булды. Очлы күз рухи таркалуның Максановка гына түгел, ә үзгәртеп кору әдәбиятының байтак геройларына, әрсез кырмавык, йогышлы микроб сыман, ияргәнен күрер.

М. Хәсәновның "Язгы аҗаган" романындагы Иргали исемле олпат ирне искә төшерик. Элек татар әдәбиятында тәрәзә төпләрендә образ тотып коммунарларны атарга йөргән, атлар агулаган, террор оештырып сәнәкчеләр дигән исем алган, ә хәзер инде баш-аяк үзгәртелгән бу кулак тибына кайсы тәнкыйтьче генә сокланмады: эшчән, тырыш, булдыклы, игелекле, ярдәмчел, намус белә... Ә соң аның хатыны була торып, качып-посып балдызы Миңсылу белән уйнашчылык итүенә ничек карарга? Берәү дә дәшмәде. Күрәмсең, бу фигыль геройдагы ирлекне көчәйткән бер гөнаһсыз сыйфат рәвешендә генә күзаллана. Шул хакта, татар әдәбиятындагы башка ямьсез яклар хакында 1987 елгы "Ватаным Татарстан" гәзитендә "Үзгәрергә кирәк, үзгәрергә" мәкаләсе белән чыгыш ясарга җөрьәт иткән идем. Мәдәни-әдәби сәясәттә һава ясаучылар бөтереп

алдылар: янәсе, Хафизов дигән адәм актыгы "дингез бинокле алып, Уфа тауларыннан күзәтеп, татар язучыларына акыл өйрәтә, әрли, аларны мыскыл итә".

Минем мондагы "дуслар" "Татарстан яшьләре"нең әле бер санын, әле икенче санын тотып әй кинәнделәр, халыкка мине Казаннан куылган адәм итеп тә исбатлап йөрделәр.

"Яңа татар", "Яңа руслар"дагы рәхәт тормыш, женси азгынлыкка тартылуның кыргый матурлыгын Р. Мөхәммәдиев "Кенәри—читлек кошы" романындагы Арслан, Лев Борисович, Капкаев кебек геройларында күрсәтте. Тик укучы ачык төшенә генә алмады, әллә соклана, әллә нәфрәтләнә автор акча корольләре оештырган иблис гамәлләренә.

Гулаг тоткыны булган А. Гыйләҗевны "Яңа татарлар" белән әшнәлектә кем гаепләр? Ләкин аның "Балта кем кулында" романында да шулар оештырган мәҗлесләр романтикасы, женси азгынлык, урлашу үзәктә. Дөрес, автор мөнәсәбәтләрендә томан, буталыш юк. Ләкин барыбер бу язучы да янәшәдә кемнәрдер өчен оҗмах яшәвенә укучыны ышандыра бара бит.

Т. Миңнуллинның "Сөяркә" драмасында Хәбир мөлкәткә генә түгел, хатынга һәм бик чибәр сөяркәгә дә ия. Ир-ат өчен четерекле хәл инде бу. Әнә бит Мирхәйдәр Фәйзинең "Тәкъдирнең шаяруы" драмасындагы Гыйсмәт ике ут арасында калып үз-үзен һәлак итә. Тик М. Фәйзи, аның герое иллә дә беркатлы романтиклар булганнар икән! Безнең заман драматургы исә мут Хәбирне хәзрәткә алып барып сөяркәсе Мәдинә белән никахлаштыра да, вәссәлам, сарык та исән һәм бүре дә тук... Т. Миңнуллин дәлилли белә инде ул, теләсә, киллерны да аклап драма язар. Әнә бит каләмдәше Зөлфәт Хәким дә "Гөнаһ" романында акка кара белән "Кешенең кешене үтерергә хакы бар", дип раслап тора...

Безнең әдәби геройларның әхлакый дөньясында вакханалия барлыгын дискуссиягә катнашкан Р. Раков та күрсәткән. Мәсәлән, ул язучы Әсгать Сәлахның "Каеннар юлы" повестенда "Сафуан, Сандра, Микулай, Минзәки, Гөлмәрфуга кебек ир хатынын, хатын ирен бутап бетергән образларга" карый да бик урынлы сорау бирә: "Кем инде үзенең хатынын сөяркә итеп тоткан кешегә, шуны белә торып, йорт төзергә бүрәнә бирсен дә, изгелек кылып йөрсен ди?! Халыкта кеше ышанмаслык хәлне чын булса да сөйләмә, дигән әйтем дә бар бит әле?" *("Казан утлары". № 9, 2004).*

Менә шулай исерек сәясәт һәм әхлакый кыйбланы саташтырган дистәләрчә әсәрләр аша, кыек сызыклар мантыйгы аша татар әдәбияты Т. Галиуллин герое Сәет Сакмановка һәм аның ишләренә килеп чыкты, шуларны оялмыйча заман геройлары дип атадык. Кыскасы, нәрсә теләдек, шуңа ирештек инде без.

Әмма әдәбиятның төп нигезе, тоткасы булган герой проблемасындагы фикерләүне шунда гына туктатырга ярамый. Киләчәккә төбәлергә кирәк. Бу турыда миннән башка да төрлечә уйланучылар күп булыр. Исәбемчә, без үзебезнең милли тормышыбызны, халкыбызны яхшылап белмибез. Бүгенгесе турында диванга кырын ятып Русия еврейлары сәясәте белән әтмәлләгән "кара ящик"тан чыгып фикер йөртсәк, үткәнебезгә Совет чорында чамасыз идеаллаштырылган Тукайның бер күзе аркылы гына карыйбыз. Бәлки шуңа күрәдер, байлар, эшкуарлар, милләт хадимнәренә карата үтә бертөрле, мыскыллы караш яшәп килә, берләшү омтылышы да юк. Заманында Исмәгыйль Гаспринский, Риза Фәхретдин, Фатих Кәрими, Рәшит Ибраһимов, Муса Бигиев, Садрый Максуди кебек зыялылар һәм милләт хадимнәренең атаклы Әхмәт бай, Гани бай, Кәримовлар, Рәмиевләр һәм башка акча корольләре белән милли мәнфәгатьләр хакына тыгыз хезмәттәшлеге корылган булган. Атаклы җәдит мәктәпләре төзү, шәкертләр тәрбиясе, йөзләрчә газета һәм журналлар чыгару, китап нәшриятләре оештыру һәм тагын әллә никадәр игелекле эшләр безнең байларыбыз иганәсенә корылган бит! Халыкны талаган патша хөкүмәте үз казнасыннан татар мәдәнияте, татар мәгарифе өчен сукыр тиен дә тотмаган ласа... Хәзерге эшкуарларыбыз, малтуарларыбыз да үз корсакларын туйдыру, фахишәлек кылу нияте белән генә яшәми. Ходайга шөкер, бер татар бизнесменының да киллер яллап көндәшен үтергәнен ишетмәдем мин. Заман байларында да милләтпәрвәрлек тойгысы бар. Тик тагын да үстерергә, көчәйтергә генә кирәк аны. Әмма моны милли

зыялыларыбыздан башка кем эшләсен соң? Димәк, мәдәниятебезне үстерүгә юнәлгән кыю милли идеяләр, зур проектлар тудыру да зыялылар өстендә.

Һәм мин бу өлкәдә киләчәгебезгә өметле карыйм. Чөнки "яшь татар"лар арасында да милләт җанлы, игелекле һәм шәфкатьле затлар барлыгын беләм. "Хәйрия" ярдәм җәмгыятен төзегәнен ишеткәч, М. Гафури кичәсен оештыру өчен дип Заһир Хәкимовтан акча сораган идем. Эшкуар ике дә уйламады, бирде. Күпме? Әйтмим, әмма Башкорт педагогия университетының актлар залын тelәгәнчә музыкаль һәм художестволы бизәргә дә, номерларны яхшы башкаручы студентларны бүләкләргә дә җитте ул. Заһир Хәкимовның Уфада татар яшьләренең "Азатлык" оешмасын төзеп, мәдәни чаралар үткәрү өчен матди ярдәмен кызганмавын да искәртик.

Башкортстан татарлары мохтариятен төзергә дип җиң сызганып тотынган һәм шул максат өчен кызганмыйча тапканын бүлгән эшкуар Рәмил Бигновка да халык өметләр баглый...

Кыскасы, безнең чынбарлыгыбыз тик Сакмановтан һәм аның тар дөньясыннан тормый. Заһир Хәкимов, Рәмил Бигнов сыман шәфкатьле һәм милләтпәрвәр байларыбыз да әдәбиятыбызның бүгенге якты геройлары булырга бик хаклылар. Бармы бездә тагын шундый милләт рыцарьлары?

4

Әдәбият кебек рух өлкәсендә иң яманы—өметсезлек, гаҗизлек. Кеше болай да үз тормышында бик еш чарасыз кала, ә инде ташка басылып таратылган өметсез сүзнең халыкка тәэсир итү көче, психологиясе әйтеп бетергесез зур, мәкерле. Пессимизм дигән төшенкелекне бигрәк тә лирика чәчә. Яңа әдәбиятның лирик үрнәкләрендә дә, бетә барган совет дәверендәге сыман, инкыйраз мотивы тантана итә. Тарих төпкелләренә, ераккарак китеп, шагыйрьләр хәтта аның даирәсен көчәйтә дә төштеләр булса кирәк. Үткәндәге гөнаһлар, милли ызгыш-гауга куптаруда, сатылуда гаепләп ата-бабаны битәрләү, каргау, нәгърә орулар яисә ташлаган нигез төпләренә кайтып үкереп елау һәм борынгы каберләрдә күңел ташып исерек сыктаулар, яисә шәһәрдә торып авылга кайта алмаудан, берне сөеп икенчегә өйләнүдән олы фаҗига ясаулар һәм башка менә шундый вак тойгылар укучы каршында лирик геройның кадерен күпме үстерә икән?

Поэзия, бигрәк тә бүгенге лирика торышына багышлап зур мәкалә язган Зиннур Мансуровтан әлеге соравыма җавап алырмын дип, "Казан утлары"ның өр-яңа санын кулыма алдым. Язманың дискуссия материалы итеп тәкъдим ителүе дә өметне арттырды. Әмма дөресен әйтим, ул элекке партком секретаренең теге яки бу рәсми бәйрәм уңае белән уңышларны барлаучы докладыннан да кайтышрак тоелды.

Күп каләм әһелләрендә өлкән тәнкыйтьчебез искәрткән бәйрәм шаукымы, хушкүңеллек кенә җитмәгән иде, әлеге дискуссияне дә үзара макташу, банкеттагы сыман чыгышларга, мәдхиягә әйләндерергә теләүме инде бу?

Дискуссия материаллары арасында миңа әдәбиятыбызның укылу-укылмавы, аның киләчәгенә кагылышлы төшенке уйлар да һич ошамады. Мәсәлән, Р. Сверигин әлеге темага кагылып, яшьләр, аларның кызыксыну даирәсен барлый һәм әйтә: "Дөресен әйткәндә, матур әдәбият китаплары укып утырырга аларның вакытлары да, теләкләре дә юк" *("Казан утлары". № 11, 2004)*. Моны ниндидер маргинал, манкорт татар яисә берәр технарь, финансист, сәясәтче милләттәш авызыннан ишетсәк, гаҗәпләнмәс идек. Әмма бу куркыныч, өметсез фикерне гомере буена югары уку йортында эшләп, студентлар тәрбияләгән һәм язмышын милли әдәбият белән бәйләгән, аның кешегә, тормышка искиткеч зур, шифалы йогынты ясау көчен тойган могтәбәр галим әйтә бит. Рифат ага, әдәбиятчы буларак, кайда сездә рыцарьлык? Әдәбиятның сафлыгы, матурлыгы һәм өметле киләчәге өчен Сездә электән килгән көрәш рухы бүген кайда? Әлеге төшенке сүзләрегез белән Сез бит татар әдәбиятының киләчәгенә балта чабасыз... Юк, мин югары уку йортында эшләүче кеше һәм әдәбият мөгаллиме буларак, башка, өметле карашны хуп күрәм. Әдәбиятны, шулай ук милли язучыларыбызны яратып укучы меңнәрчә мәктәп шәкертләре бар. Татарстан югары уку йортларында гына түгел, Уфа, Эстәрлетамак, Бөре институтларының милли

бүлекләрендә тәрбияләнүче йөзләрчә татар талипләре дә әдәбиятыбыз әсәрләренә гаҗәп игътибарлы. Укып кына калмыйлар, бәхәсләшәләр, хөкем чыгаралар, шул әсәрләрне язучы каләм әһелләрен илаһилаштырып, очрашырга, күрергә хыялланалар алар. Тик бәла, безнең якларга "тере язучы"лар килеп кенә чыкмыйлар, ә аларны чакырып китерергә безнең көч-куәт җитми.

Әдәбият һәм сәнгатьнең халыкларны якынайтуда һәм бер-берсен ныграк аңлауда әйтеп бетергесез зур роль уйнавын истә тотканда, нәкъ менә бүген, Татарстан һәм Башкортстанның рәсми даирәләрендә сәяси психологик салкынлык, аралашу кыенлыклары яшәгән дәвердә, игезәк халык язучыларыннан югары активлык һәм бердәм максатларда хезмәттәшлек сорала бит. Халык шагыйрьләре, "ата бүреләр" ник эндәшмиләр? Рыцарьлык Салават Юлаев, Акмулла, Тукай, Җәлилләрне генә бизәми, бүгенге шагыйрьләрнең лирик геройларына да кирәкле сыйфат бит ул.

Шулай итеп, бүлмәдә ятып "укыр җаннар беткән!" дип өметсез шигъри чаң сугарга ашыкмыйк, әфәнделәр! Аннары, онытмыйк, базар заманында яшибез бит. Элекке "оештыручы һәм туплаучы КПСС" дигән абзый юк, язганнарыңны үзеңә таныта һәм тарата белергә кирәк, ә сыйфатның көн тәртибендә торган мәсьәлә икәне әйтмәсәң дә ачык. Ә халык идеяле һәм эстетик тойгылы безнең, әдәбиятыбызны укый. Төссез, йөгәнсез, оятсыз һәм рекламалар белән дыңгычлап тутырылган "кара ящик"тан тәмам туеп, ул хәзер үз телебездә әйбәт язылган роман, повестьларны, шигырьне якын күрә.

Аннары милли әдәбиятның тәэсир көченә кинрәк тә карарга кирәк минемчә. Замандашыбыз Фәүзия Бәйрәмованы милләт мәнфәгатьләре өчен җан атучы изге зат итеп беләбез. Изге булса да, ул бит күктән төшмәгән. Айдар Хәлим әйтте бугай: "Фәүзия Бәйрәмова кебек шәхеснең бары тик Сөембикәсе, Мөхәммәдьяры, Батыршасы булган милләттә генә булуы мөмкин". Дөрес һәм мәгънәле әйтелгән. Заманында Фәүзия Кадыйрова дигән кыз Казан дәүләт университетының милли тел-әдәбият бүлегендә тәрбияләнде, үз акылына әдипләребез, галимнәребез рухын сеңдерде, шуларның идеал-омтылышларын йөрәгенә салды.

Һәр елны милли бүлектә тәрбияләп, вуз дипломы тоттырып эшкә озатканда мин әдәбиятыбызның әнә шундый могҗизалы көче турында уйлыйм. Менә димен, йөзгә якын ардаклы, гыйлемле яшь милләттәш үзендәге Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Тукай, Такташ, Туфан, Еникиләр рухын балаларга житкерер, аларның йөрәкләренә дә милләт гамен кертер, шуны изге итеп сеңдерер, Алла боерса, димен… Һәм шул гади генә уй минем эшемә, тормышыма мәгънә бирә, ямь өсти. Юк, шәхси тормышыбызда вәсвәсәле мизгелләр еш булса да, безгә халкыбыз яшәешенә, рухи-мәдәни киләчәгенә карата һич кенә дә өметсез уйларга төшәргә ярамый. Алай итсәк, без үзебез утырган ботакка үзебез балта чабабыз… Бу хис өчен безне ата-бабаларыбыз кичермәс…

Безгә югары рух рыцарьлары кирәк. Бармы, күпме бездә андый рыцарьлар?

Ә әдәбиятта заман герое мәсьәләсенә килгәндә, барлык авторлар кебек мин дә югары теләктә калам. Борынгыдан килеп, безне тик вакытлы юлдаш кына иткән әдәбият сәхифәләренә без үз заманыбызның югары тойгыларын, керсез омтылышларын язып өлгерергә тиешбез. Моны тик олпат, югары әхлаклы, кабатланмас язмышлы геройлар иҗат иткәндә генә эшләп була.

**Сәгыйдулла ХАФИЗОВ**

**Редакциядән:**

*Журналыбызның даими авторы, Татарстан Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге премиясе лауреаты, филология фәннәре докторы Сәгыйдулла Хафизовка шушы елның апрель аенда 60 яшь тулды. Аны олы юбилее белән кайнар котлыйбыз, тормышында һәм иҗатында уңышлар, нык сәламәтлек телибез.*

# ШИГЪРИ ҖАНЛЫ ГАЛИМ

Журналыбызның бу санында без мәгълүм татар галиме-фольклорчы Илбарис Надировның Истанбулда эш алып баручы Әхмәтвәли Мәңгәр исемендәге төрек-татар мәдәни вакыфына багышланган мәкаләсен урнаштырабыз. Шунысы игътибарга лаек: ул вакыф оештырылуга быелгы яз айларында 10 ел тулды, ә түбәндәге мәкалә авторы Илбарис Нурислам улы Надиров апрель аенда 80 яшьлек бусаганы атлап керде. Шул рәвешле, язмыш дигәнең, бу түгәрәк даталарны бер-берсенә бәйләгән булып чыкты. Илбарис ага Надиров, искә алган вакыф корылган көннән башлап бүгенгә кадәр аның эшчәнлегендә якыннан катнашып, фәнни киңәшче сыйфатында хәл кадәри хезмәт куйган могтәбәр галимнәребезнең берсе.

Мин аның фольклорчы буларак, төгәлрәк әйткәндә, халкыбызның җырларын җыючы, өйрәнүче белгеч буларак кылган эш-гамәлләре хакында "Шигъри җанлы галим" дигән бер мәкаләдә сөйләп тә узган идем. Ул юбилярның 75 еллыгына багышлап Тел, әдәбият һәм сәнгать институты чыгарган бер җыентыкта 2000 елда дөнья күргән иде.

Бүгенге язмамда исә, мин мөхтәрәм галимебезнең ерактагы татар диаспорасы белән бәйле эшчәнлегенә беркадәр киңрәк тукталып үтәргә телим.

Билгеле булганча, безнең "татар" дип йөртелгән туган кавемебез дөньяның төрле төбәкләренә таралып яши. Әйтик, бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитетында тупланган мәгълүматларга караганда, Австралия, Кытай, Канада, Польша, Румыния, АКШ, Алмания, Төркия, Финляндия, Швециядә һәм башка тагын бернична илдә 70 меңгә якын татар яши икән. Алар әлеге илләрнең кайберләрендә милли-мәдәни җәмгыятьләр оештырып, соңгы елларда Казан белән урнашкан рухи бәйланышларны сакларга тырышып гомер итәләр. Шул уңайдан Австралия, АКШ, Алмания, Төркия һәм Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең эшчәнлеген аерып күрсәтергә кирәктер. Чөнки нәкъ менә шул илләрдә милли-мәдәни җәмгыятьләр оешканрак төстә эш алып баралар дип ишетеп беләбез.

Илбарис ага Надиров иң әүвәл Төркия һәм Финляндиядәге татарлар белән күбрәк аралашып, алар турында күбрәк язган авторлардан. Күпләр хәтерли булыр: узган ел ахырында Казанда "Татарстан-Төркия: мәдәни бәйланышлар. 1992—2003" дигән күләмле бер җыентык дөнья күргән иде. 600 битле, фоторәсемнәр белән баетылган һәм латин имлясында басылган бу җыентык Илбарис Надиров тарафыннан төзелгән. Җыентыкның җаваплы мөхәррире дә—ул. Мәгълүм булганча, китап Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфының матди ярдәме белән нәшер ителгән. Хәбәрләргә караганда, аның тиражының бер өлеше Төркиягә җибәрелгән, шактые Татарстан Милли китапханәсе, Бөтендөнья Татар конгрессына бирелгән һәм белгечләргә таратылган. Шунсын да әйтергә кирәк, бу басмага әйбәт бәя биргән бернична рецензия басылды да инде, ә Бөтендөнья Татар конгрессы аны тәкъдир итү утырышы үткәрде.

Әлеге китап белән танышканда мине куандырган бер хәлне укучыларга хәбәр итәсем килә. Әйтик, җыентыкка соңгы елларда "Казан утлары" журналында басылган дистәгә якын мәкалә сайлап алынган. Шулар рәтендә Төркия һәм анда яшәүче татарлар турында Тәүфикъ Әйди, Рабит Батулла, Әбрар Кәримуллин, Әлфинә Сибгатуллина тарафыннан язылган бай мәгълүматлы мәкаләләрне аерып күрсәтү гадел булыр. Боларга өстәп Илбарис аганың безнең журналда басылган "Төркиядәге ике милләттәшем" дигән кызыклы хатирәсен дә телгә алу кирәктер.

Гомумән, әлеге җыентыкны Татарстан белән Төркия арасындагы тарихи, мәдәни

бәйләнешләрнең үткәнен, бүгенгесен шактый киң итеп яктыртучы һәм үзара бәйланышларга багышланган кыйммәтле бер чыганак дип санарга тулы нигез бар.

Илбарис Надировның Финляндиягә барган саен андагы милләттәшләр тормышыннан игътибарга лаек яңалыклар алып кайтуын беләбез. Соңгы утыз ел дәвамында Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең тарихы һәм бүгенге көнкүреше, Габдулла Тукай исемендәге мәдәни җәмгыять һәм аның җитәкчесе профессор Гомәр Таһир хакында Казан матбугатында егермегә якын мәкалә һәм хәбәр-язма бастырды ул. Аларның күбесе "Казан утлары" журналында дөнья күрде. Ул мәкаләләрнең кайберләре рус һәм инглиз телләрендә дә басылып чыкты. Шул нәүбәттән мин Илбарис аганы Татарстан белән Финляндия арасында рухи-мәдәни күпер салуга зур өлеш керткән хөрмәтле зыялыларыбызның берсе дип санар идем.

Татар диаспорасы тарихы турында әлегә монографик төстәге махсус тикшеренүләр булмаса да, алар һичшиксез язылыр дип өметләник. Чөнки бу өлкәдә эш алып баручы галимнәребез бар. Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты да әлеге проблема белән җитди кызыксына һәм бу хакта төпле хезмәтләр язуны күз алдында тота дип беләм.

Бу кыска гына кереш сүз язмам ахырында мин фронтовик галимебез Илбарис ага Надировны олы юбилее белән ихлас күңелдән котлыйм, аңа исәнлек-саулык һәм бәхетле гомерләр телим. Журналыбыз битләрендә яңа хезмәтләр белән укучыларыбызны сөендерергә язсын сиңа хөрмәтле авторыбыз!..

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

⁂



# Илбарис Надиров

## ИГЕЛЕКЛЕ ЭШНЕҢ ИРТӘ-КИЧЕ ЮК

**Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфына ун ел тулу уңаеннан**

Төп сүзгә күчкәнче, иң әүвәл Әхмәтвәли Мәңгәрнең нindиерәк шәхес булуын искә төшерик әле. Әхмәтвәли әфәнде гомеренең төп өлешен Төркиядә яшәп, зирәк эшмәкәр һәм мәрхәмәтле иганәче буларак бар дөньяга танылган абруйлы татар кешесе ул. Аның тормыш юлы мажараларга бай гыйбрәтле бер роман кебек. Язмышның ачысын да, төчесен дә мул итеп татырга туры килгән аңа, әмма ул сайлаган юлыннан тайпылмаган—халыкка, илгә файдалы санаусыз күп эшләр башкарып, табигый шөһрәт һәм олы хөрмәт казанган.

Бу урында мин сүзне Әхмәтвәли Мәңгәр белән Кытайда һәм Төркиядә якыннан аралашып, аны әйбәт белгән татар һәм төрек кешеләренең язма истәлекләренә күчерү урынлы булыр дип саныйм. Самими һәм ихлас күңелдән язылган әлеге истәлекләр (алар унбер данәдән гыйбарәт) моннан сигез ел элек Казанда чыккан "Әхмәтвәли Мәңгәр. Хатирәләр" дигән китапта дөнья күргәннәр иде. Бу нәүбәттән

шуларның кайберләрендәге аеруча әһәмиятле һәм мөһим өзекләргә күз салып узу урынлы булыр кебек.

Беренче һәм төп истәлек булып, әлбәттә, Ә. Мәңгәрнең бердәнбер кызы Сафия ханым Имренең әтисе вафатыннан соң унбиш ел узгач язылган кечкенә күләмле китабы тора. 32 биттән торган һәм фоторәсемнәр белән баетылган бу китапның тәүге басмасы 1993 елда Истанбулда төрек телендә "Әтием Әхмәтвәли Ибраһим Мәңгәр" дигән исем астында дөнья күргән иде. Ул вакытларда Казанда эш алып баручы "Ватан" җәмгыяте бер елдан соң аны татар теленә тәрҗемә итеп, "Әтием" исеме белән бастырып чыгарды (тәрҗемәчеләре—Төркиядәге милләттәшебез Фәрит Бичури һәм әлеге җәмгыять рәисе Дамир Гыйсметдинов. Шул ук елда бу китапчыкны "Казан утлары" журналы да үз укучыларына тәкъдим итте *(1994, 7 сан)*. Ниһаять, Сафия Имренең дәлилләргә бай бу истәлеге алда искә алып үтелгән "Хатирәләр" дигән китабында дөнья күрде.



*Әхмәтвәли Мәңгәр (1891—1978)*

Бүген мин фәкыйрегезнең, Сафия ханымнан гайре кешеләр тарафыннан язылган истәлекләргә таянып, атаклы милләттәшебез портретын тагы да тулырак сурәтләрдә күз алдына бастырасым килә.

Менә гомеренең төп өлешен Нью-Йорк шәһәрендә яшәп, шунда вафат булган Әмрулла Агиның 1995 елда язган истәлегеннән берничә юл: "...Әхмәтвәли абзый хакында 1933—1934 елларда Харбин шәһәрендә яшәгән мөһаҗир татарлардан күп ишеткән идем... Ерак Шәрекътагы татарлар кайда гына яшәмәсен, нинди генә җәмгыятьләр корып, яна мәктәпләр вә мәчетләр ачмасын, аларның һәркайсында Әхмәтвәли Мәңгәрнең катнашы бар...

...Танылган әдибебез вә лидерыбыз Гаяз Исхакый Ерак Шәрекъта яшәгән халкыбызны бер җепкә тезәр өчен корылтайлар оештырды. Беренче Корылтай 1935 елда Мукден шәһәрендә тупланды. Делегатлар Япониядән, Кытай вә Кореяның төрле шәһәрләреннән килгәннәр иде. Әхмәтвәли абзый шуларның алгы сафында торып, беренче Корылтайның күп утырышларында рәислек кылды...

...Тагын шуны искә төшерәсе килә. Ул бик кунаксөяр кеше иде... Татарлыкны яратканга, ул искедәге татар гадәтләрен сөйли, татар көйләрен искә төшерә, багасын, үзе дә җырлап җибәрә иде..." *(Ә. Мәңгәр.—Хатирәләр.—76-79 бб.)*. Бу урында истәлек авторы Әмрулла абзый Агиның үз язмышы турында гаҗәеп бай мәгънәле бер китап язуын һәм аның Казанда "Жизнь одного человека" дигән исем астында 2003 елда басылып чыгуын да телгә алып үтү урынлы булыр.

Хәзер исә, Төркиядә яшәп, тюрколог буларак бар дөньяга танылган мәшһүр милләттәшебез профессор Әхмәт Тимер *(1912—2003)* истәлегенә багыйк: "Әхмәтвәли бәй милләтен яратучы, Идел-Урал төрки-татар дөньясының тарихы һәм культура мәсьәләләре буенча киң мәгълүматлы, күп белгән бер кеше иде... Форсат тапканда, ул күп укый һәм туктаусыз китап җыя иде. Шул рәвешле аның сайланма әсәрләрдән гыйбарәт бай бер китапханәсе барлыкка килде. Бу коллекцияне, аның вафатыннан соң, кызы Сафия ханым "Төрек мәдәниятен өйрәнү институты"на бүләк итте...

Истанбулдагы "Казан төркиләренең мәдәни һәм ярдәмләшү җәмгыяте" озак еллар аның матди ярдәме нәтиҗәсендә эшләп килде. Ә Анкарадагы Казан оешмасы ул алып биргән бер бинада эшчәнлеген бүгенгә хәтле дәвам итә.

Истанбул җәмгыяте тарафыннан 1970 елдан башлап, янә дә Әхмәтвәли бәй ярдәме белән "Казан" исемле журнал чыгарыла башлады. Өч айда бер чыга торган бу журнал Әхмәтвәли бәйнең вафатына кадәр 23 сан булып дөнья күрде. Бу журналның чыга башлавы... ана үз хатирәләре белән бәйле вакыйгаларны кәгазьгә төшерә башлавына да этәргеч булды. Шулай итеп, беренче саныннан башлап ук, "Казан" журналында аның да мәкаләләре басыла башлады.

Милләтең, халкын һәм илен һәрнәрсәдән артык күреп сөйгән мөхтәрәм мәшһүребез Әхмәтвәли Мәңгәр бәй туып-үскән җирләрен бер барып күрә алмавына бик үзәге өзелеп яшәде..." *(Истәлек 1996 елда язылган. Шунда ук.—61-65 бб.).*

"Хатирәләр" китабында Истанбулда гомер итүче милләттәшебез, күренекле төрек-татар тарихчысы, профессор Надир Дәүләтнең "Әхмәтвәли абзый белән 10 ел бергә" дигән кызыклы истәлеге дә басылган. Түбәндәге өзекне без шуннан алдык: "Большевизм давылы байларыбызны, зыялыларыбызны тамырыннан кубарып ташласа да, аларның берничә бөртек орлыклары чит җирләрдә чәчелеп калды. Шул орлыклардан берсе булган Әхмәтвәли Мәңгәр мәһабәт кәүсәсе олы бер нарат кебек үсеп ныгыды һәм Кытайда булсын, Төркиядә булсын, андагы татарлар арасында тирән эз калдырды...

..."Казан" журналының битләрен актарганда, Әхмәтвәли абзыйның Истанбул һәм Анкарада яшәүче татарларга, бигрәк тә аларның җәмгыяви эшчәнлекләренә байтак игелекле эшләр кылганын аңлавы авыр түгел. 1970 елда "Казан төркиләренең мәдәни һәм ярдәмләшү җәмгыяте" үзенең гомуми җыелышында Әхмәтвәли Мәңгәрне татарларга күрсәткән игелекле хезмәтләре өчен җәмгыятьнең Шәрәфле рәисе итеп сайлады...

...Төркиягә килгәннән соң, Әхмәтвәли Мәңгәрнең кайбер фәнни-дини китапларны дөньяга чыгару эшендә матди ярдәм күрсәткәнлеген беләбез. Ризаэтдин Фәхретдиннең "Озын көннәрдә ураза" һәм Исмәт Бинаркның "Иске китапчылык сәнгатебез" дигән китапларын бастырып чыгаруына мин үзем шаһит. Болардан тыш, аның үз исемен язарга кушмыйча бастырткан китаплар санын төгәл генә әйтүе дә кыен. Әмма шуларның берсе белән мин соңрак җентекләп таныштым. Ул китап—төрки дөньяга киң мәгълүм тарихчы һәм сәясәтче профессор, доктор Садри Максудиның кызы, доцент, Төркиянең Римдагы илчесе, 1976 елда Төрек парламентына сенатор итеп сайланган Адилә Айданың "Этрусклар төрек идеме?" дигән әсәре... *(Истәлек 1996 елда язылган. Шунда ук.—66-75 бб.).*

"Хатирәләр" китабында әле генә телгә алган Адилә Ханым Айданың да истәлеге бирелгән. "Ул бөек эшмәкәр вә джентельмен иде" дигән бу истәлекнең Ә. Мәңгәргә багышлап язылган иң беренче истәлек булуын әйтергә кирәк. Ул искә алган "Казан" журналында 1980 елда Ә. Мәңгәрнең вафатына өч ел тулу унаеннан басылган. Менә шуннан берничә өзек: "...Көннәрнең берендә Әхмәтвәли Мәңгәрнең әтием *(сүз Садри Максуди турында бара.—И. Н.)* янына килгәнен хәтерлим... Соңыннан кичке аш вакытында әтиемнең бу кунак турында болай дип әйткәне күнелемдә тора:

—Кызым, һәр эшнең даһие була. Бу кеше исә сәүдә даһие. Кайсы илгә барып урнашса да, анда миллионер була ала ул. Аңа табигать шундый сәләт биргән...

Күп еллардан соң булган һәм "Этрусклар төрек идеме?" дигән китапны бастыруга бәйле бер күренешне искә төшереп, А. Айдә янә болай ди: "...Әтиемне сагынып искә төшергәч, Әхмәтвәли бәй сүзне үзенә күчерде, инде картаеп китүен, сиксәнгә житүен, үлемгә әзерләнә башларга кирәген искә төшерде. Аннары ул җыйган малының бер өлешен Казан төркиләренә мәдәни ярдәм күрсәтү өчен бүлеп куйганлыгын әйтте... Төркиядә гомер итүче Казан төркиләренең ата-бабадан калган гореф-гадәтләрен дәвам итүләрен теләп, казанлыларның бер мәркәзен булдырасы килүен, үзе үлгәннән соң да бу мәркәзгә ярдәм итү өчен васыятендә күрсәтмәләр бирәчәген сөйләде... Аңлавынча, әйтелгән максаты өчен ул бер вакыф кормакчы иде... Иншалла, мәрхүмнең бу изге теләге тормышка ашар дип уйлыйм...

...Әхмәтвәли Мәңгәр җәмгыяте хәйрия өлкәсендәге күркәм вә мәрхәмәтле хезмәтләре белән бергә, дөньяны аңлау дәрәҗәсе һәм тәҗрибәсе ягыннан күпләрне узып киткән бер кеше иде. Казан төркиләре үз араларыннан шундый кеше чыгуы белән һәрвакыт горурланачак *(84-90 бб.)*.

Ниһаять, тагын бер кыйммәтле истәлеккә тукталыйк. Аның авторы—Әхмәтвәли Мәңгәрнең кияве Иззәт Имре. Милләте буенча төрек булса да, ул татар хылкына гаять тә җылы карашлы һәм һәерхаһ күнелле булуы белән хәтердә калды. Олуг җанлы һәм укымышлы бу шәхес Сафия ханым белән ярты гасырга якын бергә яшәү дәверендә ярыйсы ук яхшы итеп татар телен өйрәнә, татар җырларын һәм безнең милли ашларны яратып кабул итә. Аның каенатасы турындагы истәлеге ихласлыгы һәм тормышчан бизәкләргә бай булуы белән истә кала. Без шуннан максатыбызга муафыйк бер өзек кенә китерергә булдык: "...Әхмәтвәли бәйнең тормышында ике зур теләге бар иде. Беренчесе—үзе нигез корган эшләренең аның исеме белән дәвам итүе, икенчесе—милли-мәдәни эшләр белән шөгыльләнә торган бер вакыф оештырып, шуның ярдәмендә Казан төркиләренең Русиядә һәм бөтен дөньяда югары үсешкә ирешүенә булышу иде.

Улым Эргин Имре сәүдә һәм житештерү эшләренә җитәкчелек итә башлагач, бабасы нигез салган "Мерседес-Бенц" ширкәтенең Әхмәтвәли Мәңгәр исеме белән аталып, аның эшчәнлеген киң тармакта дәвам иттерүгә ирештек. Хатыным Сафия ханым 1995 ел башында мәдәни вакыф оештырганнан соң, Әхмәтвәли бәйнең икенче теләге дә тормышка ашты *(Истәлек 1996 елда язылган. 57-60 бб.)*.

Менә шундый шөһрәтле шәхес булган Төркиядәге милләттәшебез Әхмәтвәли Мәңгәр. Урыны җәннәттә булсын!

Алда әйткәнебезчә, быел март башында Әхмәтвәли Мәңгәр исеме белән тарихка кергән мәдәни вакыф корылуга ун ел тулды. Бу урында аны кору мәшәкатьләрен һәм баштагы алты еллык эшчәнлеге белән җитәкчелек итү вазыйфаларын Сафия ханым Имре башкаруын ассызыклап билгеләп үтү гадел булыр.

Табигате белән гаҗәпләнерлек рухи көчкә һәм ихтыярга ия Сафия Мәңгәр-Имре (1927—2000) бу дөньяның күп кенә илләрендә булган, биш телдә иркен сөйләшә алучы талантлы оештыручы, сәләтле галимә, журналист һәм тәрҗемәче иде. Аның вакыф рәисе буларак башкарган эшләренә тукталганчы, фән һәм публицистикага караган аерым хезмәтләренә бер караш ташлыйк. Иң элек Сафия Мәңгәрнең Истанбул университетында немец филологиясе бүлеген тәмамлавын һәм XIX гасырда яшәгән немец язучылары Фридрих Шлегел һәм Шлаер Махер иҗатында хатын-кыз проблемасы дигән диссертация яклавын әйтергә кирәктер. Шуннан соң аны университетта калырга чакырсалар да, ул әтисе теләген искә алып, аның автомобильләр ширкәтендә мәдәни-оештыру эшләрен җитәкли. Шунда эшләгәндә һәм гомеренең соңгы елларында Сафия Имре татарлар турында төрле илләрдә, төрле телләрдә дөнья күргән мәкаләләрне Төркиядә чыга торган аерым журналларда һәм газеталарда бастыруга зур игътибар бирә. Шул басмалар үзәгендә Анкарада төрек телендә чыгучы "Кырым" журналы тора. Иҗтимагый-мәдәни рухтагы бу журнал 1991 елда чыга башлый һәм өч айга бер тапкыр басылып килә. Узган ел ахырында аның кырык җиде саны дөнья күрде. Табигый ки, журналда Кырым татарларының фаҗигаларга бай тарихы һәм бүгенге катлаулы язмышы турындагы язмалар төп урынны алып тора. Әмма журнал җир йөзендәге төрки халыклар, шул исәптән Идел буе татарлары турында да кызыклы хәбәрләр бирел бара. Журналның төрле елларда күргән аерым саннарында Сафия Имре язган яисә әзерләгән ундүрт мәкаләнең басылып чыгуы шуның бер дәлиле. Шулар арасында Казан университеты профессоры, тарихчы Искәндәр Гыйләжевның Германиядә алманча һәм Казанда русча басылган ике хезмәтеннән төрек теленә күчерелгән тәрҗемәләр бар. Алар икесе дә патша Русиясенең XVI—XVIII гасырларда Идел-Урал төбәгендәге татарларга карата алып барган мәкерле шовинистик сәясәтен күп дәлилләр белән фаш итә. Сафия Имре бу мәкаләләргә кереш сүз һәм искәрмәләр дә язган. Журналның 24, 27 саннарында Казан университеты профессоры Миркасыйм Госмановның "Каурый каләм эзеннән" (1994) дигән китабыннан "Түләк

белән Сусылу" дастанының һәм "Хан кызы" дигән борынгы жырның текстлары китерелә. Аларның төрекчә вариантын Сафия Имре әзерләгән. Журналның 25 санында фоторәсемнәр белән бизәлгән бер озын мәкаләгә аерым игътибар юнәлтәсе килә. "Риза Фәхретдин һәм Исламият" дип аталган бу хезмәттә Сафия Имре бөек татар галименең дини карашларын тасвирлый, Исламият нигезендә яткан изге әхлакый кануннар һәм кагыйдәләр турында яза. Журнал үзенең берничә санында танылган татар журналисты һәм әдибе Фатих Кәриминең "Аурупага сәяхәтнамә" исемле китабыннан аерым бүлекләрне Сафия Имре тәржемәсендә бастыра. Ә 29 санында рус миссионеры Ильминскийның татарларны христиан диненә күчерү уңаеннан патша министры Победоносцевка язган явыз ниятле, астыртын хатлары урнаштырылган. Аларны да төрекчәгә Сафия Имре тәржемә иткән. Тагын бер мисал китерик. 1998 елда Сафия ханым "Кырым" журналында күренекле язучыбыз Айдар Хәлимнең "Убить империю" дигән китабыннан Кырым татарларының хәсрәтле язмышы турындагы "Кырымда бер туй", "Варвар кем соң ул?" дигән мәкаләләрен русчадан төрекчәгә тәржемә итеп бастыра. Монда Сафия Имренең Казанда "Мәдәни жомга"да 2000 елда бер-бер артлы дөнья күргән ике мәкаләсен искә төшерү дә урынлы булыр. "Милли шәхсият һәм Кырым татарлары", шулай ук "Катнаш никах бәхет китерәме?" дигән мәкаләләрендә Сафия ханымның кайнар йөрәк тибеше ишетелгән кебек, чөнки ул гомере буе үзен төрки халыкларның азатлыгы, тигезлеге һәм бәхетле тормышы өчен көрәшүче бер зат дип санады. Шул уңайдан аның матбугатта басылган бер фикерен хәтергә алыйк: "Русиядә төрки халыклар турында патша заманында да, советлар хакимлеге чорында да бик күп ялган таратканнар. Хәзер ул ялганнарны бөтен дөньяга фаш итәргә, тарихи дөрес хәбәрләрне көн яктысына чыгарырга кирәк. Төркиләрнең борынгыдан килгән бай мәдәниятле, азатлык сөюче мәгърур халык булуы турында авыз тутырып сөйләргә кирәк. Без Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфының шигаре итеп төрки халыкларга уртак булган "берлектән куәт туар" дигән мәкальне сайладык. Мин үзем киләчәктә төркиләрнең куәтле, бердәм булуларына нык ышанам, эшләрем дә шуңа юнәлгән" *(Мәдәни жомга.—1999, 12 ноябрь).*

Сафия Имре бу мөкатдәс максатына, Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфы президенты буларак, әйтеп бетергесез зур өлеш кертте.

Сүзне шул вакыфның тарихына һәм эшчәнлегенә күчерик. Ул вакыфка нигез кору эшен Сафия ханым Имре газиз әтисе васыятенә тугрылык саклап, 1995 елның февраль ахырында башкара. Аны рәсми оештыру урыны итеп Европаның Лихтенштейн дигән кечкенә бер дәүләт башкаласы Вадуц сайлана. *(Моның сәбәбен Сафия ханымның бу илдә салым бәясе түбәнлеге белән аңлатканы хәтердә калган.)*

Вакыф уставында язылганча, аның ижтимагый-хәйрия эшчәнлеге нигезен төрле илләргә сибелгән төрки халыклар белән Төркия дәүләте арасында рухи-мәдәни күпер хезмәтен үтәү максаты тәшкил итә. Бу максатка ирешү өчен вакыф төрки халыклар тарихына, мәдәниятенә һәм теленә хас булган уртаклыкларны үстерүнығытуны, фәнни китаплар алмашуны, кириллица алфавиты белән эш итүче төрки республикаларда латин алфавитына күчүне күз алдында тота. Шул устав нигезендә Сафия Имре вакыфның идарә советы әгъзасы, тюрколог, профессор Әхмәт Тимер белән фикер алышканнан соң, вакыфка фәнни киңәшчеләр сыйфатында Казаннан өч галимне—тел белеме буенча академик Мирфатыйх Зәкиевне, тарих фәннәре буенча академик Миркасыйм Госмановны һәм фольклор буенча бу мәкалә авторын сайлап алалар.

Артта калган ун ел дәвамында вакыф ниләр эшләде соң?

Вакыф үзенең эшчәнлеген Татарстан илендә яшәүче татарлар белән элемтәләр урнаштырудан башлап жибәрде. Болай эшләү табигый да, чөнки ул Әхмәтвәли Мәңгәр хыялына тәңгәл килә иде. Алда әйтелгәнчә, Мәңгәр гомере буе үзенә кадерле булган татар халкын, татар дөньясын сагынып, жирсеп яшәгән, Татарстанны үзенең тарихи Ватаны дип санаган. Аның борынгыдан килгән ерак бабалары гомер иткән Мәңгәр авылы *(сүз хәзерге Әтнә районына кергән Олы Мәңгәр авылы турында бара)* исемен үзенә икенче фамилия итеп алуы да юкка гына түгел.

Алдарак Ә. Мәңгәрнең китапка гашыйк һәм китап җыярга яратучы укымышлы зат булуы әйтелгән иде. Аның шәхси китапханәсендә берничә мең китап туплана. Соныннан Сафия ханым аларны Анкарада профессор Әхмәт Тимер җитәкчелек иткән "Төрек мәдәниятен өйрәнү институты"на бүләк итә. Вакыф президенты буларак, ул иң әүвәл әнә шул басма мирастан татар һәм төрки халыклар тарихына, филологиясенә караган, әмма Казанда булмаган китапларны җибәрүне мәслихәт санап, безгә—киңәшчеләргә бай библиографик исемлек күндерде... Бу хәл 1995 елның май аенда булды. Без иҗтимагый-инсани фәннәргә караган 122 китапны сайлап алып, моны хәбәр итүгә, ике ай эчендә Анкарадан Казанга почта белән шул басмаларның ксерокопияләре килде. Аларның төп авторлары заманында Русиядәге милли-рухи кысанлыкка түзә алмыйча Төркиягә китәргә мәҗбүр булган татар галимнәре һәм язучылары. Арада Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Йосыф Акчура кебек бөек затлар, Рәшит Рәхмәти, Зәки Вәлиди, Абдулла Баттал, Әкъдәс Курат, Хәмит Кошай, Сәгадәт Чагатай, Әхмәт Тимер, Надир Дәүләт кебек атаклы тюркологлар бар. Бу исемлеккә Ләбиб Каран, Али Акыш, Тамурбәк Дәүләтшин, Сания Гыйффәт кебек мәгълүм шәхесләрне дә өстәргә кирәк. Телгә алган авторларның Казанга килгән китаплары нигездә төрек телендә булып, Г. Исхакый, Л. Каран, С. Гыйффәт әсәрләре генә татар телендә. Китаплар арасында 1913—1936 елларда алман телендә басылган һәм 8 томнан торган "Ислам энциклопедиясе" һәм 5 томнан торучы "Шәрык ислам классиклары. Милләтләр вә хөкемдарлар тарихы" *(төрек телендә)* барлыгын да әйтеп китик. Килгән китапларның бер данәсе Татарстан Милли китапханәсенә, икенчесе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты китапханәсенә тапшырылды.



*Сафия ханым Мәңгәр-Имре (1927—2000)*

1997 елның җәй башында Сафия Имре ире Иззәт Имре һәм Мәхмүт Әлүкәй *(вакыфның вице-президенты)* белән Казанга килгәч, вакыф җибәргән китапларны тәкъдир итү кичәсе булды. Аны Татарстан Милли китапханәсе оештырган иде. Кичәдә катнашкан гыйлем ияләре бүләк ителгән китапларга югары бәя биреп, аларның татар һәм төрки халыклар тарихын, мәдәниятен өйрәнүдә ифрат кыйммәтле чыганаклар булуын билгеләп үттеләр. Шулай итеп, Ә. Мәңгәр вакыфы халкыбызның төрле якларга сибелгән китаби мирасыннан аерым үрнәкләрне төп Ватанына—Татарстанга, Казанга кайтаруга ирешге. Олы рәхмәткә лаек игелекле бер эш бу.

Вакыфның Казанда башкарган икенче эше—латин хәрефләрендә китаплар чыгару булды. Бу эшнең соңгы ун елда үзенә күрә "көн кадагына сугучы" бер вакыйга булуын искә төшерик. Чөнки нәкъ менә соңгы елларда татар илендә латинга күчү мәсьәләсе көн тәртибенә басты. Аның унай хәл ителәсенә өмет уятып, латинның татарлар өчен яна фәнни варианты булдырылды, шуның нигезендә латинга күчү турында Татарстан президенты Минтимер Шәймиевнең указы да чыкты *(1999, сентябрь)*. Әмма латинга кире кайту юлларында кара көчләр кабат кара пәрдә кордылар... Мәсьәлә торабара Русия Конституция судына барып җитте, тик латиныбызның хәле барыбер мөшкел хәлдә, шовинистик кысанлык җәтмәләрендә калды. Бу хәл, табигый ки, халкыбызның мәдәни киләчәген кайгыртып яшәүчеләр йөрәген тырный, шомлы тойгылар уята.

Менә шундый вазгыять хөкем сөргәндә Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфының соңгы ун ел эчендә латин имлясында сигез китап чыгаруын бары тик алкышларга гына кирәк дип саныйм. Бу вакыфның матди ярдәме белән 1997 ел башында Казанда бер-бер артлы өч китап халыкара латинда дөнья күргән иде. Аларның өчесе дә Казанда соңгы елларда кириллица белән басылган китаплар: Риза Фәхретдиннең "Болгар вә Казан төрекләре", Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф"ы, халкыбызның

мәшһүр дастаны "Идегәй". Аларның титул битендә бирелгән кыскача аңлатмага күз салыйк. Анда шундый юллар да бар: "Китапның бу басмасы 1992 елда Төркия мәмләкәтенең Анталия шәһәрендә халыкара тюркологлар конференциясендә кабул ителгән уртак латин әлифбасында бастырылды. Болай эшләү бер яктан чит илләрдәге милләттәшләребез дә иркен укый алуга хезмәт итсә, икенче тарафтан Татарстан һәм Русиядәге татарларны да уртак латин әлифбасы белән якыннан таныштыруга ярдәм итәчәк". Бу максат дөрес куелган булып чыкты. Сафия ханым Имре хәбәр итүенчә, ерак чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез искә алган китапларны чын күңелдән хуплап, куанып кабул иткәннәр. 1997 елның җәендә Казанда уздырылган Бөтендөнья татарларының II Корылтаена килгән чит ил кунаклары өчен дә бу китаплар кадерле бүләк булды. "Казан утлары" журналы шушы китаплар нигезендә латин әлифбасында язуга бәйле үрнәкләр бирде. Кыскасы, Ә. Мәңгәр вакыфының бу гамәле дә халык күңеленә хуш килде, чөнки латин бик күпләр хыялында йөргән һәм туган телебез аһәненә ятышлы бердәнбер алфавит бит.

Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфы чыгарган тагын ике китапны телгә алу зарур. Аларның берсе—олуг галимебез, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани әсәре "Мостафадел-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар". Мәгълүм ки, мәшһүр тарихчының бу әсәре ике томнан торып, беренчесе 1897 елда, икенчесе 1900 елда Казанда нәшер ителәләр. Шуннан соң алар тулы хәлендә беркайчан да кабат басылмыйлар. Шуны истә тотып, Сафия Имре һәм Әхмәт Тимер бу ике китапны факсимиле *(фотокүчермә)* рәвешендә чыгару дөрес булыр дигән фикергә киләләр һәм бөек шәхеснең тууына 180 ел тулу уңаеннан ул китаплар бер-бер артлы Анкарада дөнья күрәләр. Әсәрнең I томына Әхмәт Тимер бай эчтәлекле кереш мәкалә язган. Анда Мәрҗани һәм ул яшәгән чор турында безнең тарихи әдәбият өчен яңача яңгыраган хәбәрләр дә бар. Мәрҗани китапларының бер өлешен вакыф Казанга җибәрде. Без аны фәнни китапханәләргә, Мәрҗани исемендәге гимназиягә, аның туган авылындагы музейга, Казандагы туганнарына һәм Мәрҗани иҗаты белән шөгыльләнүче галимнәргә тараттык.




*Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфының матди ярдәме белән Анкарада, Казанда, Мәскәүдә басылып чыккан китаплар. (1996—2003 еллар)*

Татарстан белән Төркия арасында соңгы елларда урнашкан тотрыклы икътисади-мәдәни мөнәсәбәтләр көн үзәгенә төрек һәм татар телләрен өйрәнү ихтыяҗын да куйды. Шуны истә тотып, вакыф игътибарын ике зур сүзлек чыгаруга юнәлтте. Аларның берсе—"Татарча-төрекчә сүзлек", икенчесе—"Төрекчә-татарча сүзлек". Беренче сүзлек 1997 елда Мәскәүдә "Инсан" нәшриятында дөнья күрде, икенчесе бер елдан соң шул ук нәшриятта басылды. Аларны тел галиме, профессор Фоат Ганиев җитәкчелегендәге авторлар әзерләделәр. Белгечләр тарафыннан уңай бәя алган ул сүзлекләр татар-төрек лицейларына, китапханәләргә таратылды, кибетләргә сатуга чыгарылды һәм тел өйрәнүчеләр өчен файдалы бер кулланмага әйләнде. Шул ук максатка хезмәт итүче янә бер китапның Казанда басылып әйбәт бәя алуын хәтергә төшерик. Сүз Казан университеты каршындагы Шәрекъны өйрәнү институты доценты тюрколог Асия Рәхимованың төрек телендә язылган "Төрек грамматикасы" дигән дәреслеге турында бара. Моннан өч ел элек дөнья күргән бу хезмәт студентлар

өчен генә түгел, төрек телен үзлегеннән өйрәнүчеләр өчен дә менә дигән файдалы кулланма булды.

Вакыф ярдәме белән Казанда һәм Истанбулда нәшер ителгән китаплар арасында татарның тарихи шәхесләренә багышланган берничәсен аерым телгә алу дөрес булыр. Алар—бөтендөньяга мәгълүм атаклы тюрколог Рәшит Рәхмәти Аратның 100 еллыгына багышлап Казанда үткәрелгән конференция материаллары *(2001)*, Әстерхан татарларының күренекле галиме, җәмәгать эшлеклесе Габдрахман Гомәри турындагы җыентык *(2003)*, бу китапның төзүчесе-авторы тарих фәннәре белгече Сөләйман Рәхимов, янә дә татар халкының бөек улларыннан берсе Йосыф Акчурага багышланган өч китап: аларның берсен профессор Әхмәт Тимер язган *(1997, төрек телендә)* икенчесенең авторы тарих фәннәре кандидаты Рафаил Мөхәммәтдинов *(1998, төрек телендә)*. Өченче китапны француз галиме Иосиф Жоржон язган: "Төрек милләтчелеге тамырлары. Йосыф Акчура *(1876—1935)*", төрек теленнән татарчага аны Рафаил Мөхәммәтдин тәрҗемә итте *(2003)*. Бу исемлектә лаеклы урынны Надир Дәүләтнең Исмәгыйль Гаспралыга багышланган монографиясе биләвен дә күрсәтик *(1996, Казан, төрек телендә)*.

Янә вакыф чыгарган өч китап шулай ук тарихи шәхесләр хакында. Ләкин алар төрки халыкларның борынгы эпик мирасы каһарманнары. Сафия ханым Имре алар турындагы сирәк кульязмаларны дөньяның төрле китапханәләре белән уртак тел табып, фотокүчермәләрен зиннәтле бер басма рәвешендә эшләтеп, төрле илләрдәге тюркологик үзәкләргә, китапханәләргә таратты. Бу очракта сүз "Огузнамә" дастанының Казан варианты, "Китабел Дедем Коркут" дастанының Дрезден һәм Ватикан вариантлары, "Тарихы Сәхиб Гәрәй хан" дастанының Париж һәм Санкт-Петербург вариантлары турында бара.

Вакыф эшчәнлегенең әһәмиятле бер юнәлешен тәшкил иткән һәм китаплар чыгаруга караган сүзебезне әле 2004 елның ахырында гына дөнья күргән бер хезмәтне телгә алып тәмамлыйсы килә. "Татарстан-Төркия: мәдәни багланышлар. 1992—2003" дип исемләнгән бу китап 600 биттән тора һәм үзенә күрә шушы темага багышланган йөзләгән мәкалә, кульязма, хатирәләрне, шулай ук бай библиографияне эченә алган бердәнбер китап булып санала ала.

Монда шунысын да әйтү кирәктер, 2001 елдан соң дөнья күргән биш китапның һәркайсы латин алфавитының бездә кабул ителергә тиеш яңа вариантында басылдылар.

Җыйнап әйткәндә, узган ун ел дәвамында Әхмәтвәли Мәнгәр вакыфы 23 китапның дөнья күрүе өчен матди ярдәм күрсәтеп, ул китапларны дөньяга тарату эшен оештырып, бу өлкәдә биниһая кыйммәтле һәм файдалы хезмәт башкарды.

Вакыф президенты буларак Сафия Имренең аерата игелекле бер гамәле—ул әдәбиятыбыз классигы Гаяз Исхакыйның архивын һәм кайбер шәхси әйберләрен сөекле Ватанына—Татарстан җиренә, Казанга кайтаруы булды. Сүз атаклы әдипнең тулы архивы турында түгел, шул архивның бер өлеше турында бара, чөнки архивның төп өлеше әле Истанбулда, башка кулларда, киләчәктә анысы да Татарстан иленә кайтыр дип өметләник.

Казанга китерелгән бу архивны 1997 елның июнь башында Сафия Имре үз кулы белән Татарстан президенты Минтимер Шәймиевкә тапшырды. Истәлекле очрашуда танылган галимнәр һәм язучылар да бар иде. Президентыбыз татар халкының иҗтимагый-мәдәни тарихында Гаяз Исхакый биләгән олы урынга югары бәя биреп, аның шәхси архивын Ватанга кайтаруда куйган изге хезмәте өчен Ә. Мәңгәр вакыфына, Сафия ханым Имрегә һәм бу архивны вакыфка биргән Сөембикә ханым Шәриповага *(Гаяз Исхакыйның бер туган сеңлесе Гайнемәрзия кызы, варис хуҗасы)* зур рәхмәт белдерде.

Хәзерге вакытта Гаяз Исхакыйның бу архивы Татарстан милли архивында саклана. Андагы кульязмалар, документлар исемлеген Сафия ханым миңа Истанбулда 1996 елның мартында ук биргән иде. Ул исемлектә 89 документ саналган. Алар арасында Г. Исхакыйның күпсанлы хатлары, аңа килгән хатлар, көндәлек дәфтәреннән өзекләр, бәйсез Идел-Урал мөселманнарының милли-мәдәни

мөхтәриятен коруга караган язмалар, Берлинда чыккан "Милли юл" журналының аерым саннары, "Жан Баевич" комедиясе буенча язылган либретто, "Олуг Мөхәммәт" пьесасы, Йосыф Акчура, Галимжан Баруди хакындагы мәкаләләрнең кульязмалары, Ерак Шәрекътагы *(Кытай, Япония, Кореядә)* татарлар арасында утызынчы елларда алып барган сәяси-мәдәни эшчәнлеге турындагы документлар, Г. Исхакыйның 50 еллыгына караган материаллар һ. б. бар. "Гасырлар авазы" журналының 1997 елда чыккан санында *(N 3,4)* бу архивтан ике документ басылды һәм документлар исемлегенең рус теленә тәржемәсе бирелде. Калганнарына да әтрафлы тасвирлама ясалды.

Гаяз Исхакый архивыннан тыш, Сафия Имре Татарстан Милли архивына XX гасыр башында татарларның һәм башка мөселман халыкларының милли азатлык хәрәкәтенә, 1906—1914 елларда үткәрелгән Мөселман Конгрессларына, Исмәгыйль Гаспралы һәм аның кызы Шәфика Гаспралыларның сәяси-мәдәни эшчәнлекләре белән бәйле кырыкка якын кыйммәтле документлар тапшыруын да рәхмәт хисе белән искә алу зарур. Ә. Мәңгәр вакыфы шулай ук Татарстан Милли китапханәсенә дә XX гасыр башында Идел, Урал, Кырым татарларының иҗтимагый вә мәдәни тормышына караган аерым сирәк китаплар һәм кульязмалар бүләк итте.

Татарлар илендә төрле вакыфлар башкарган игелекле эшләр тарихы турында киләчәктә махсус китап язылыр әле дигән өмет бар. Шул китап битләрендә Төркиядә оештырылган Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфы, аның президенты Сафия ханым Имренең татар халкы өчен, төрки халыклар өчен кылган күркәм вә шәфәгатьле эшләре хакында да рәхмәтле сүзләр үзенә лаек урын алыр дип өметләник.

Бу урында Татарстан Президенты М. Шәймиевнең республика матбугатында 1998 елның 13 сентябрендә басылып чыккан түбәндәге Указын китерү урынлы булыр: ***"Татар халкының мәдәни һәм фәнни традицияләрен пропагандалау өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әхмәтвәли Мәңгәр исемендәге мәдәни-хәйрия фонды президенты Сафия Имрегә (Төркия) "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде"***. Бу хәбәрне татар җәмәгатьчелеге хуплап каршы алды.

Инде килеп, мәкалә ахрында әйтәсе килгән тагын бер сүзебез бар. 2000 елның икенче яртысыннан башлап Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфының эшчәнлеге белән Сафия ханым һәм Иззәт бәй Имреләрнең улы—Төркиядә танылган эшмәкәр һәм фән докторы Эргин әфәнде Имре житәкчелек итә. Без аның вакыф башкарган игелекле эшләрне уңышлы дәвам итүенә ышаныч белдереп, бу өлкәдә ана яңа казанышларга ирешүен телибез.

*Роберт Әхмәтҗанга 70 яшь*

**Марсель Галиев**

# ГОМЕР УЧАГЫ

Моңаеладыр безгә дә
Мөбәрәк айлар кергәндә.
*Габделҗаббар Кандалый*

Театр фойесында бәллүр люстралардан җемелдәп таралган утларга ярашып җинелчә музыка агыла. Спектакль башланыр алдыннан мосафәхә кылу мизгеле. Төркем-төркем татар зыялылары—арада композиторлар да, әдипләр дә, җырчылар да бар. Егерменче гасыр башында туып-үсеп, иманлы тәрбия алып калган буын. Гәүдә тотышлары, кул хәрәкәтләре, бай тел белән ипле-килешле сөйләшә белү рәвешләре башка. Болар—Шаһгали дәвереннән бирле төптән киселә-аударыла килгән токымның гарасатлы-хәвефле елларда да нәсел җебен өзми саклап калган аксөякләре—милләтнең тәмен татып карый алырлык кадерле кыерчыклары (Кәбисә еллар ул могътәбәрләрне безнең арадан берәм-берәм ала торыр. Арадан тик берәү—аксөяк, морза, олуг әдип Әмирхан ага Еники гына егерме беренче гасыр бусагасын исән-имин кичеп дөнья куяр).

Менә, күпләрнең игътибарын җәлеп итеп, ишектән бер пар кереп килә. Каурыйлы эшләпә читеннән вуаль-челтәр төшеп, күзләрен серлелек томанына яшергән ханым һәм аны култыклаган егет—озын чәчен пөхтә тарап куйган, аксыл плащын җилбәгәй җибәргән, атлас кашнэ астыннан ак күлмәк якасы, шәп төенле галстугы күренеп тора. Киләләр болар,—чибәр дама һәм шагыйрь,—яшьлекнең кадерен белеп, тантана итеп... фойедагы кайсы төркем дә бик рәхәтләнеп кабул итәр боларны—шагыйрь һәм дама. Ханым әз генә дә тартынмыйча, башын горур тотып, күпме күз карашларын паркет идәнгә биек үкчәләре белән кадаклап килә. Аны култыклаган егет тә үз дәрәҗәсен белеп атлый. Фойеда һәр төркем үзенчә пышылдашып ала: "Шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов! Шулмыни инде ул?! О-о, шәп шагыйрь!..". Кайчандыр Париж, Лондон салоннарына Санкт-Петербургның бөек аристократы килеп кергәч, шулай пышылдау китә торган була: "Кенәз Юсупов!.. Кенәз Юсупов үзе!..".

Әнә шулай, үзенең яшь, кайнар шигърияте белән башкаланы тез чүктергән Шагыйрь килә. Ә бер читтә ташкаланы яуларга дип авыллардан кузгалган, табан астында камыл кытыклавы да бетмәгән студент шагыйрьләр басып тора. Үҗәт иреннәре кысылган. "Таш елады" поэмасын язган шагыйрьне сокланып та, көнләшеп тә күзәтәләр (бу шагыйрьдән көнләшү аларны гомер буе озата барачак...).

Менә фойеда соңгы звонок яңгырый. Узган гасырның истәлекле алтмышынчы еллары тамаша залының ишекләрен ача.

***

"Жыр—жанның яшел кыягы!"

Бу хикмәти юллар зиһенен ачып җибәргәнче яшьлекнең яшел аланнарында күпме адашып йөрисе бар әле Шагыйрьгә. Соклану-гамь капкалары ачылсын өчен күпме талымлы сүзләр табасы бар.

Ул ясканып яза башлаган дәвердә поэзиядә солдат рухы хөкем сөрә, әле генә тынган яу-сугыш гөрелтеләренең канлы кайтавазы колакларда чыңлап тора иде. Ауропаны гизеп кайткан дистәләрчә фронтовик-әдипләр әдәбиятның алгы сафында. Яшәүгә сусап, тыныч тормышның тәмен белеп кайткан бу кавемнең рух башка, иҗади сәләтеннән бигрәк, ихтыяр көче ташып торган, таянырдай ирләр—Әнвәр Давыдовлар, Шәрәф Мөдәррисләр, Зәки Нурилар, Мәхмүт Хөсәеннәр. Яшь шагыйрь

буларак, Роберт Әхмәтжанов аларга тартыла. Илләр гизгән ир-егетләргә кызыгып карый. Аларга да дөнья күрмәгән, үтә кызыксынучан, һәр йөгерек сүзне эләктереп алып, балкытып, шигырь тегермәненә кертеп жибәрә белгән энекәш кирәк бит! Шулай итеп, Роберт Әхмәтжанов—Кама егете, солдат-әдипләрнең яшь дустына әйләнеп китә. Шаулы редакцияләр... Тәмәке төтененнән ысланган рестораннар... Пегасларны юырттырып узган төнге Казан урамнары... Ижади бәхәсләр...

Күпмедер еллардан соң Шагыйрьнең жыр булып бөтен халыкка таралачак шигыре туар:

Озатып, вокзаллар каршында
маңгайдан үптеләр аналар.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аналар хәтере шикелле
жил йөри курганнар артында.

*"Солдатлар" шигыреннән.*

Бөтен өйләргә дә афәтле жиле тигән егерменче гасырның иң зур сугышы шаукымы әле бик озак елларга барачагын, әдәбиятның мәңгелек яшәү темасын бүлеп, жиңү тантанасы—фанфаралы, янгыравыклы бушлыкка корылган ижат алымы кая илтәсен яшьли чамалый Роберт Әхмәтжан. Ничек кызыгып карамасын, ничек якын итмәсен фронтовик әдипләрне, ул, эчтән: "болай язмаска иде", дигән үжәтлегенә бара. Яңа сугышлар иске сугышны оныттырачак. Бу—канлы куласаны кем әйләндерә, кемгә миллион корбаннар кирәк—мәкерле сер беркайчан да ачылмыйча калачак. Якты хисләрне чигереп, һаман шул сугыш фажигасе шигырьгә бәреп кергәнгә гажизләнеп, ул болай дип яза:

Сугыш күрми туган шигыреңне
соңгы кабат яз да, нокта куй.
Тик... хәтердә сакла... гүреңәчә,
нәфрәтеңне янган утка кой!..

Яу афәтеннән яра алган язмышлы уй-гамьне чаң теле белән түгел, ә жан теле белән язарга алынганга күрә ул "шинельле шигърият" иненнән соры шинельне салдырырга үреләә.

Аның хиссияте—әрфия төсләрдән тукылган кояшлы хәят. "Күнел чатларында", дип әйтә белү өчен генә дә Роберт Әхмәтжан булып туу кирәктер.

Йогынтысы—Есениннан Такташка, даһи Һадидан Әхмәт Фәйзигә күчеп, сирәк кенә чагылып киткән, бернинди вакыт жиленә бирешми торган асыл жәүһәрләр—табигать күренешенең яшьнәп киткән бизәге—шигырьне гомер буе жылытып торган утлы кузлар—Роберт Әхмәтжан әсәрләрендә тагын да нәфисрәк төсмерләр ала.

Төн аяз, тик әрәмәдә
куксел йон тетә томан,—

дип, унсигезенче язында шулай яза башлаган шагыйрьнең күнел күзе отыры үткенләнә башлый: "Гөлләрнең күзе дымлы", "Яфрак арасында яшелләнә жиле",—болар үтеп китешли генә күзгә чалынган табышлармы? Юк, палитрасындагы төсләр муллыгыннан вакыт-вакыт ул үзе дә шашып кала шикелле; телнең беркем күзе тимәгән чоңгылларына төшеп, үзе генә табып алган кабырчыкларны ачып шигърияте не асыл энжеләр сибә. Дога укыгандай, тургайның ап-ак болыт каршысында тибрәп торуы, баш очыннан карлыккан каргалар очышы, камылларда зеңләп аккан көз тавышы—болар сәнгатьле сүз остасының илаһи әфсене түгелме!

"Их, шушындый бер юл!.. Аерым юллардан эзлим мин күп вакытта шагыйрьләрне",—дигән Сибгат ага Хәким.

Үләң төпләренә төшеп, кырмыскалар янәшәсендә дөнья гөжен тыңлау, бөркетләрдән дә өскә чөелеп, галәми югарылыктан жир-әнкәнең маңгай жыерчыклары арасындагы рәшәләрне күрү, йөрәк биеклегендә калып, хис-тойгы катламнарына үтеп керү—шушы кималлеге өч яссылыкта тирбәлә шагыйрьнең сүз хәяте.

Татар шигъриятенең иненнән соры шинельне салдыру—жинел бирелмәгәндер шагыйрьгә. Талантлы шәхескә күп вакыт талантсызлар юшкынын ерып барырга туры килә...

***

Узган гасыр аборигены буларак, артка борылып карасаң, еллар офыгыннан

сүтелә-сүтелә хәтер йомгагы куа килә. Сибелеп калган каз каурыйлары кебек, хатирәләрнең яктырагы күз алдында янара...

Бервакыт шулай... Гаҗәеп эссе июль көнендә (1974 ел) самолетта очабыз. Ике канатлы "фанер" очкычыбыз (АН—2) әле өскә чөелә, әле аска убылып китә. Алдагы кабина ишеге үзеннән үзе төбенә кадәр каерылып ачыла да салонга коточкыч гөрелте ургылып керә. Мин Роберт Әхмәтҗан белән янәшә утырам. Рәдиф Гаташ алдагы урындыкта, янәшәсендәге яңа гына танышкан кызга, ярсып, шигырьләр укып бара. Мин эсселеккә түзә алмыйча, күлмәкне салып, билдән ялангач калдым. Гаташ күреп алды да: "Рөхсәт итсәгез, туташ!"—дип, әлеге кызыйга ым кагып, җәһәт кенә күлмәген салып ташлады. Күптән түгел генә Кырым кояшында кызынып кайткан тәнен күрсәтә алу форсатыннан бәхетле иде ул.

Мин бу сәяхәтебезнен җаваплы кешесе буларак (университет бетереп, Язучылар берлегенә яна гына эшкә кергәнмен), пошаманда барам. Телефоннан кат-кат сөйләшү буенча, безне сәгать өчтә Базарлы Матак аэропортында райком хезмәткәре каршы алырга тиеш иде. Хәзер кичке биш тулып килә. Тоткарлануыбыз хакында берничек тә хәбәр итеп булмады. Нишләрбез?



*Рәсемдә: беренче рәттә, сулдан уңга—композитор Хөснул Вәлиуллин, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким; икенче рәттә—Роберт Әхмәтҗан, Гамил Афзал. 60 еллар.*

Югыйсә, көндезге рейска билетлар кесәдә, бар да тәртиптә иде бит. Әле бер сәгать вакытыбыз бар, йөреп килик бераз, дип төп аэропортка таба китмәгән булсак... Аэропорт бинасының мәһабәт колонналары арасыннан Хозер Ильяс үзе чыгып киләмени! Каршыбызда—ак чалбардан, ак күлмәктән, музыкантлары арасында балкып, Илһам Шакиров басып тора. Ул елларда бөек җырчыны болай якыннан күрә алу бәхете бик тәтеми иде. Себердән ике ай буе концертлар куеп кайтып килеше икән. Кочаклашып күрешкәннән соң: "Сыйлыйм, егетләр!"—дип, ул безне ресторанга алып кереп китте.

Мул табында шактый вакыт истирәхәт чигеп утырганнан соң, Илһам Шакиров белән хушлашып, кече аэропортка килсәк, самолетыбыз күптән инде канат җилпегән икән. Безнең рейс хакында игълан бирелмәде, дип, дер селкетеп, партия кушуы буенча юлга чыгуыбызны да искәртә торгач, өстәмә самолет таптылар. Менә хәзер, соңлап булса да, шыгрым тулы шыгырдавык самолетта очып барабыз.

Тәрәзәгә карап, үз эченә йомылып барган Роберт Әхмәтҗан, кинәт кычкырып җибәрде:

—Карагыз әле, егетләр!

Аста—Кама дингез кебек җәйрәп ята икән. Үзе дә шушы борынгы елга ярында туып-үскән шагыйребез нигә болай әсәрләнә дисәк... Күгелҗем-яшькелт су киңлекләре өстеннән очкан күбәләкләр уйдыгын күреп алган бит!

—И җаныкайларым... Аргы ярга чыгып житә алырсызмы соң?..—дип сөйләнә-сөйләнә, ул хәтәр су упкыны өстеннән җем-җем килеп очкан нәзберек ак җаннарны исе китеп күзәтеп барды. Мөмкин булса, үрелер дә, учына алып, җылы сулышын сак кына өрә-өрә күбәләкләрне ул аргы ярга чыгарып куяр иде.

Мин аның дөньяга шулай җете күз белән карый белүенә, кечелекле күзәтүчәнлегенә кызыгып куйдым. Әгәр шундый игътибарлы булмаса, табигать күренешләрен ул, энә күзеннән үткәреп, тасвирлый алыр идеме. Аһәнен тыңла, балкышын күзалла, сулышын тоеп кара бу юлларның: "Суның җаны бөреләнә, орлыклана су сабагы"... "Тау янгыры ява тауларда"..." Газиз инешем минем, көмеш канлы сабыем"... "Жир чабынды Кояш ләүкәсендә, җилкәсеннән гөрләвекләр

чапты"... Очып барган торналарны ул "һава бурлаклары", кар яуганны—"Күкнен ак ясагы", дип сурәтли.

Анын акварель төсләр янгырашына байлыгы сыгылып торган шигырьләрен укыганда керләнгән жанына бер кагыну, хушлану, тел шарлавыгыннан чәчрәп киткән тылсымлы тамчыларга коену шифасы аласын.

...Ленин әйткәнчә, "бер адым—алга, ике адым—артка" талпына торгач, очкычыбыз Базарлы Матакнын чирәмле аланына төшеп утырды. Каршы алучы күренми. Барам шунда, белмим кая, дигән кебек, атлыйбыз билгесезлеккә таба. Яныбыздан бишекле мотоцикл иярләгән егет ике мәртәбә урап китте. Кунакханәне табып, мин тиз генә райкомга телефоннан чылтыратып чыктым. Бәхеткә, дежурный эләкте. Егетләр бүрәнә өстендә утыралар. Роберт Әхмәтжан тәменә кермичә генә тәмәке көйрәтә. Рәдиф Гаташ, теге кызнын өенә кайтасы барлыгын оныттырып, һаман шигырь сөйли. Томанлы Альбионнан—Байроннардан башланган шигъри бәйләме, сүтелә-сүтелә, Әнгам Атнабаевка кайтып житкән.

Баягы мотоцикллы егет тагын күренде. Төтен божралары уйнатып, килеп туктады да, кунакханәгә кереп китте. Як-ягына карана-карана чыгып, минем янга килде:

—Казаннан язучылар килгән диделәр, кая микән алар, сез күрмәдегезме?—дип сорады.

—Әнә бит язучылар!—дип мин бүрәнә өстендә утырган романтиклар ягына ымладым. Егетем бер мәлгә аптырап калды:

—Язучылар булгач, өлкән кешеләрдер дип уйлаган идем...

Ни уйласа да, бу егет безне ятимлектән коткарды. Шушы мизгелдән инде без авылдан-авылга кадерләп йөртелергә тиешле район учына менеп кунакладык.

Алдан сөйләшү буенча, якташларында кунак булып ятучы сүз остасы Әзәл Яһүдин дә безгә килеп кушылды. Бу якларга әле замана жиле кагылмаган. Иске клублар, печән жәелгән әржәле машинада юлсыз юллардан жилдереп кенә йөрибез.

Ин мөһиме—кичләрен клублар шыгрым. Рәдиф Гаташ, гадәттәгечә, чыгышын "Ирләр булыйк!"тан башлап, "Зәнгәр кое" белән тәмамлый. Чибәр кызлар, алкышларга уралып, болын чәчәкләре тотып, узыша-узыша сәхнәгә менәләр.

Сүз егәрен гажәеп төрле ритмнарда биетә алу остасы—Роберт Әхмәтжан, озынсаллы көтүче чыбыркысын сузып салгандай, кин сулышлы шигыре белән стеналарны әллә кая чигереп, туган жир кинлекләрен кочагына ала:

Саумысыз, кыр шагыйрьләре! Тургай монын
дога иткән ил картлары, эшчән ирләр!

Зал үзенә төбәп әйтелгән мәгънәле сүзләрдән, тантаналы горурлык кичереп, бер йөрәк булып тибә.

Галәм шәме—изге Кояш асларында
Сезнен ялкын белән күкри язгы жирләр!
Сәлам сезгә, Муллык жырын башлаучылар!
Төшсен орлык буразнага игелекле сәгатьләрдә.

Әнә шулай, "Игенчеләргә мәдхия" шигыре белән залны йөгәнләп алганнан сон, Шагыйрь, аяк очы белән, тып-тып басып, сүз куәсенә көч өстәп, дәртле үлчәмгә күчә:

Әйдә, бас, ныграк бас,
безнен әйткән "ас-са"га.
Безнен идән сынасы юк
ата дию басса да!
*"Бию кое".*

Егәрле шагыйрьләр чыгышыннан сон мин бөтенләй сытылып калдым. Богемачыл студент чорында язылган "йомыкый" шигырьләрем, халык күзенә карап, сәхнәдән укырлык түгел икән бит! Киләчәккә өмет баглап, йодрыгым үжәт кысыла. Хәзергә... Әдәбият, язучылар турында сөйләргә тырышам. Ин алгы рәттә йотылып тынлап утырган бер апанын: "Теленнән куан, улым!.."—диюе мина көч өсти.

Әзәл ага Яһүдин, тальянын тотып сәхнәгә чыга, заманында Фатих Кәримнен үзеннән фатиха алган поэманы ("Кынгыраулы яшел гармун") яттан сөйли башлый. Минә ул—күпме тынласан да ялыктырмый, күнелгә самими рәхәтлек бирә торган бөек мизгелгә житә; телнен искиткеч шигъри куәтеннән соклану күзгә яшь булып тәелә.

Саратский яшел гармун—
Көмеш кыңгыраулары...

Әзәл ага бу поэма белән залны әсир иткәннән соң, көлкеле шигырьләргә күчә. Бер авылда искәрәбез, икенче, өченче авылда... Такташ шигырен укыганда зал, су капкандай тып-тын утыра. Дүртенче авылда, ниһаять:

Һәр әтәчкә бүркем салып үтәм,
Совет саулык бирсен аларга.—

дигәч, Әзәл ага туктап, мәзәк кыяфәт чыгарып, үзе дә әтәчкә охшап авызын бөрештереп, коңгырт-шәмәхә тавыш белән кет-кет көләргә тотынды, шуннан соң инде, аптырагач, зал да аңа ияреп, көләргә мәҗбүр булды. Әзәл ага, дәртләнеп, шигырьне дәвам итте:

Һәрбер эткә, үзе тели икән,
Рөхсәт итәм борным яларга...

Кичә беткәч, табында мин Әзәл агага әйтмичә калалмадым. "Такташның ул шигырендә юмор түгел, ә трагедия ята. Менә совет чоры нинди хәлгә калдырды безне, дип, әрнеп язган бит ул!"—дигәч, Әзәл ага, кызып, калкына башлаган иде, Роберт Әхмәтҗан шул ук фикерне кистереп, җөпләп куйгач, үпкәләп тынып калды. Кырку холыклы шагыйрьгә ул сагаебрак карый иде шикелле...

Үргәгар авылы аеруча матур, ягымлы булып истә калган. Урамнар—яшел мәйдан. Өйләр бер-берсеннән ерак урнашкан. Иркенлек. Капка төпләрендә чалгы салырлык куе үләнлек. Авыл уртасында гаҗәеп биек итеп салынган, яшелгә буялган мәчет тора (ул елларда күрелмәгән хәл!).

Өчәүләп, изге йортның бусагасыннан атладык. Эчтә тып-тын. Баскычлардан өскә күтәрелсәк, келәм җәелгән залда чалма кигән берничә өлкән агай намаз укып утыра. Алгы бүлмәдәге киштәдә дә шундый ук чалмалар тезелеп тора. Без мондагы илаһи тынлыкны бозарга теләмичә, эчтән ниндидер дулкынлану, нәүмиз уйлар кичереп, ишеккә борылдык.

Еллар үткәч, әлеге халәтне Роберт Әхмәтҗан менә болай дип тасвирлар:

Изгелекләр кылмасам да җирдә,
булмаса да иткән савапларым,
юк канымда аккан хәрам ризык.
Ятмый җанда адәм газаплары!..
*"Дәрвиш"*

Фатир төшкән йортыбызның капка төбендә безне Әзәл ага көтеп тора иде:

—Әллә мәчеткә кердегезме?! Оятыгыз юк икән, ничек аягыгыз тарта! Сез бит совет язучылары!—дип безне ярсып сүгәргә кереште. Арада иң өлкәнебезнең мондый да дәһри, "калай коммунист" булуына шаккатып калдык.

Икенче көнне безне төбенә хуш исле печән җәелгән әрҗәле машина күрше авылга алып китте. Килеп туктадык клуб янына... Ис-акылың китәрлек, клуб дигәне—бер якка авышкан. Коточкыч иске бина. Почмакларга, кыеш тәрәзә араларына коммунизмга бару, бәхетле киләчәк турында плакатлар язылган. Буявы уңып, купшаклап, муртаеп, каралып беткән фанер аламалары өстендә ак төстәге хәрефләр генә ап-ачык күренә. Купшы ялган һәм ыштансыз чынбарлык... Мин плакатларга кулым белән ымлап, эчем катып көлә-көлә печән өстенә егылдым. Роберт Әхмәтҗан да, тынсыз калып, бөгелеп төште. Рәдиф Гаташ кына, безнең ауный-ауный көлүгә кызыгып караса да, түш кесәсендә партия билеты булу сәбәпле, тыенкы гына елмаюдан уза алмады. Кабина ишеген ачып чыккан Әзәл ага:

—Нидән көләсез?!—дип, бөердән чыккан шелтәле тавыш белән сөрән салды. Аның сорау бирүе безнең көлү өянәген көчәйтеп кенә җибәрде.

—Болай гына, Әзәл абый, мәзәк сүз чыкты да...—дип Рәдиф Гаташ, читкә борылып, авызын учына алды.

"Җәй патшалык иткән вакытлар" бит, урнашып, үзләшеп алгач, болынга, хозурлык кылырга чыгып киттек. Һәммә үлән буй үстергән, һәммә чәчәкнең таҗларын киереп, шау итеп торган мәле. Үлән арасына таянып яткан Робертыбыз кинәт кычкырып җибәрде:

—Күрми каласыз бит, егетләр! Кара әле, кара!.. Бара бит тәки, җәяүләп бара бит!..

Шагыйрь ихтыярына буйсынып, күбәләк очканны күзәтәбез. Аны оча дию кош

белән тинләп арттыру түгелме... Жилфер-жилфер килеп сары күбәләк әле алга талпына, әле өскә чөелә, әле артка китә. Аннары, арыпмы, чәчәк тажына төшеп куна. "Оча язгы күбәләк, чәчәк саен чүгәләп" дип язган Шагыйрьнең, рәхәт көлә-көлә сабыйларча соклануын, болынның тере бизәгенә шулкадәрле дә яратып каравын күзәтү—кызык иде. Менә бит, көтмәгәндә шигъри табышның шаһиты булдык: ж ә я ү л е к ү б ә л ә к...

—Син үзең дә жәяүле күбәләк бит!..

—Бу сәяхәттә бәхетен күбәләктән булды синең...

Шулай дип көлешеп алдык. Табигатьнең мондый да нәзакатьле жаны белән тинләү аның үзенә дә ошап куйды бугай. Шул мизгелдә инде аның күңелендә яна шигырь юллары бөреләнә башлагандыр...



Күңелле әңгәмә: Роберт Әхмәтҗан, Марсель Гали. Мөслим, 1974 ел.

И ул бәрәкәтле Болгар яклары! Манарасы киселгән иске мәчет-клублар. Һәр әйткәнгә ышанып, мөлдерәп карап, сагышлы шигырьдән моңаеп, шаян сүздән жәелеп көләргә әзер булып, озын эскәмияләрдә ингә ин утырган ачык йөзле, эчкерсез халык... Андый клублар да, андый халык та юк инде хәзер... Кайчандыр бабаларыбыз укыган Коръән аятләренең шифалы моңы-нуры сеңеп калган ярлы клубларда милләтнең асыл йөзен күреп калырга насыйп булды безгә.

***

Без студент чакта, житмешенче еллар башында ул университетның "Кызыл позиция" урамындагы тулай торагына килгәли иде. Гадәттә, төнге икеләр була. Бу вакытта әле мәһабәт бинабыз, бөтен тәрәзәләренә балкып, шау итеп тора. Килә, бишенче катка менә, яшь шагыйрьләр яшәгән ишекне таба. Арты белән борылып баса да үкчәсе белән шакый башлый...

Ул дигәндә бүлмә ишекләре генә түгел, күңел ишекләре дә төбенәчә каерып ачыла. Аның атаклы шигырен сөйләп, дәррәү каршы алалар.

Ятам ярда тыныч дәүләт сыман,
баш очында шаулый топольләр.
Баш очында Идел әкият сөйли,
йөрәгемне юа дулкыннар.

Менә бит, "мин!" дип, үзен дәүләти зурлыкка күтәргән Шагыйрь каршыда басып тора. Шигырь тактына дирижерлык итә!

Истәлектән сары һуннар калка,
үрә тора Чыңгыз атлары...
Кояш шаһит! Өзәнгесен тартып,
ишетелә кешнәп чапканы.

Бүлмә гөр килә. Шагыйрь бераз кызмача, сәях... Шәп пальтосын, купшы шарфын, бүреген ис китмәгән рәвештә идәнгә шудырып төшерә (шунда ук күтәреп аласыларын белә!). Яна язган шигырьләре циклыннан берничә "аккорд" биреп ала да, сүз кадерен саклап, туктап кала. Ана ничек тә килешә, ул бит монда—көтелгән кунак. Сүз пәйгамбәре, Кумир. Күпләргә—остаз.

Аннары... Крейсерга тинләп үзе мәдхия язган тулай торактан яшь каләмдәшләрен, житлекмәгән шигырь-мигырьләре белән туплап, алып чыгып китә эре-бөдрә карлар явып торган урамнарга. Яшьлек уратып алган тыгыз божра эчендә бару ана рәхәт.

Хөрмәт итәләр. Ара калдырмыйча, бик үзләшеп китсәләр дә—кичерә. Алар арасында бер "ябага коеп" алу, үзенне барлау кирәк икән шул: тоныкланмыймы шигъри тамчылар, вакытыннан алда олыгаймыймы сүз егәре, үтмәсләнмәгәнме фикер тоягы... Үз каланчаңда утырып кына шигырь кайнарлыгының "терекөмеш баганасы" нинди биеклектә торганын каян беләсең!..

Төнге Казан урамнары... Бураннарга кушылып аэропортка яисә вокзалга барып чыгулар... Кар көртенә батырып куелган арзанлы шәрап шешәсенең дөнья кендегенә әверелүе... Кабымлыкка—кыска шигырьләр... Самолет гүләүләре, борылышка кереп югалган кызыл утлы төнге поездлар—Шагыйрьнең тынгысыз, яклаучысыз, сабырсыз җанын каядыр алгысыта. Шушы кылануларның ул вакытлы гына икәнен белә. Елатып, җырлатып, юатып кала төнге Казанның карлы урамнары...

Ә ул "Карлы тәрәзәләр"дән яшьлеген эзли:

Икебезгә безнең ике ут бар,
ике сагыну, ләкин—бер бәхет.
Без мәңгелекмени? Тынса йөрәк,
икебезгә булсын—бер ләхет.

Гадәттә, мәхәббәт шигырьләре бәхетле бергәлек яисә сагышлы аерылышуга корыла; сүз тәэсире җанга кайтып куна алмыйча, бүтән киңлекләрдә адашып йөри. Бу очракта да Роберт Әхмәтҗан иҗаты үзенчә: ул кош булып очмый, яңгыр булып таммый, дулкын булып бәргәләнми: гадәти әшъялар аша күңел тойгыларын уята:

Каеннарны үт тә, сугыл миңа,
күңелем әле утсыз йорт сыман.
Анда бар да синең кулны көтә,
анда бар да сине юксына.

"Матурлык, сөю шаһинәсе"нә әле генәме, еллар ашамы эндәшеп, шигырьне ул болай тәмамлый: "...ут ал күзләремә, уз, тәртипкә китер дөньямны!" Бу—якты сагышлы сөю симфониясе...

Әгәр вакыт машинасында кирегә кайту мөмкинлеге булса, узган гасырның җитмешенче еллар азагыннан бер күренешне тасмага төшереп алып кайтыр идем мин. Ул чакта Казанның үзәк урамы—Бауманда троллейбуслар, машиналар мыжгып йөри, ике як тротуардан кешеләр ташкыны агыла иде.

Кояшлы көн. Куе кешеләр урманын каршыга ерып Роберт Әхмәтҗан килә. Ритмны бозып, ваемсыз таралып атлый. Аның кемдә дә эше юк. Ул ай буе үз мәгарәсендә, энә белән кое казып, зәм-зәм сүз чишмәләрен табып чыккан. Ул—бәхетле. Бәхете белән чәкештереп, яңа ачышларын "юарга" да хакы бар. Йөз-кыяфәтендә, рәвеш-киемендә—парижанә ыспайлык. Галстук төене генә ак яка астыннан чак кына бер якка кыйшайган (Анысы да күз тимәсен өченгә!).

...Язмасам, шигырь, үйлама:
"Сүнгән, дип, тылсым көче!.."
Язмавым—дөньяда бераз
сүзгә ял булсын өчен!

Әнә шулай тәкрарлап, бәйсез бер дәүләт булып, килә бу үзәк урамнан. Кинәт, берәр таныш каләмдәшен күреп ала да, туктап, курач гәүдәсен артка киереп, тегенә мылтык итеп кулын төби:

—Син!..

Аның усал кыяфәт чыгарып, бер мәлгә хәвефле тын калуы—хәтәр. Бу—сиңа Әмирхан Еники паузасы түгел. "Ник язып йөргән буласың, мокыт! Шагыйрь чыкмый синнән!"—дигән хакыйкатьне ярып салу мөмкинлеге булган шомлы пауза бу. Әмма ул куркып, сагаеп калудан канәгать елмая, шаркылдап көлә-көлә: "Нихәл, туганкай!" дип, тегенең иңеннән кочып ала.

Йә, син дә төш, мөтәшагыйрь, шунда—
Тукай, бәлки талант өләшер;
Тукай данына коенып яшәүчегә,
исемен атап, бәлки, эндәшер?!
*"Тукай катламы"ннан.*

Көйсез холкын көйләтер кеше таба алмасын белә ул. Шуңа күрә, үз күңеленә

берәүне дә якын җибәрми, үзе дә кеше халәтенә кереп уралмый. Ин газиз тойгыларын күз нурлары белән кушып, гомере буе тукыган шигърият келәменә көя төшерүдән сакланып ул урам теленә күчә алмый. Өзек-төтек сүзләр әйтеп, кайчакта тупас кыланышлар ясап, тизрәк араны өзеп, үз каланчасына ашыга. Аның үз яшәү кагыйдәсе: ярарга теләп, баш иеп, бил бөгеп, рухын тезләндерми. Нәкъ менә шул сыйфаты—бәйсез-горурлыгы күпме каләмдәшләрен көнләштергән, кызыктырган, ачуын кабартkандыр: "Син дә безнең кебек казна эшендә казган, кирәк икән, куян булып йөгер, кирәк чакта төлке тиресе ябын, партия кулын үп, мөнбәрләрдән үзең ышанмаган сүзне сөйлә. Манежда әнә фил булып фил дә тез чүгә, бер кабымлык өчен арыслан да аяк астында ауный... Безнеңчә уйнасаң, син дә безнең кебек дан тәлгәшләренә үрелерсең..."

Әмма Шагыйрь, кайчакта "мәгез сезгә!" дип комач-комсомол шигырьләре язып ташласа да (анда да ул сүз сәнгатен югары баллда тота), бирешми!

Әдәбиятта дан аулап йөрүче әрсезләрнең әремсез иҗаты кырмыска тезеннән дә түбән калачагын замана фаш итәсенә иманы камил булганга ул, үз мәсләгенә хыянәт итмичә, ясканып иҗат итә.

Вөҗданы—кәгазь аклыгы. Каләме—аягүрә! Үз-үзенә әмере: "Йоклама, җан!"

***

Җәй фасылын юатып, август кояшы елмая. Алданрак тулышып, тәкатен җуйган алмалар дөпелдәп җиргә коела. Ык суларын кытыклап искән Мөслим ягының ягымлы җиле баштан сыйпый. Дөнья—имин, дөнья—кин!

Шәфәкъ алсулыгы йөгертелгән тау битеннән, бер җепкә тезелгәндәй, ике тәгәрмәчле җинел арба җигүле атлар менеп бара. Борынгы Римнән яуга китеп баручы Искәндәр Зөлкәрнәйн гаскәремени!

Миражмы бу? Әкиятме бу?

Атларның тормыш сәхнәсеннән китеп, бары тик җыр-дастаннарда гына монсу хатирә булып калган бер дәвердә (1975 ел бу)—менә ул, каршыбызда—илаһи манзара! Бер төркем язучы-артистлар хәйран калып тамаша кылабыз.

Бетмәгән икән бит әле татарда ир-атның "ат"лыгы... Берничә авылны берләштергән, үзәге—Тат. Бүләр булган хуҗалык житәкчесе—Мирхаҗиян Сәлахов беркем кушмаган, күрсәтмә бирмәгән килеш, үз белдеге, үз үҗәтлеге белән атлар, чаптарлар үрчетә башлаган. "Мактанырга хакым бар, алмачуар атым бар!" дигән кебек, бу изге малкайлар хакында горурланып, таралып сөйли. Аны тынлый-тынлый утарлар тирәсенә житәбез.

—Миләүшә, Миләүшә!—дип кычкырып куя хуҗабыз. Әллә каян гына пәйда булган гаҗәп озын сыйраклы колын, шактый биек киртәне ыспай гына сикереп чыкты да болай таба килә башлады. Шаккатып карап торабыз.

—Поши малае бит бу!—дип куйды Роберт Әхмәтҗан.

—Урманнан табып алдык. Әнкәсен атканнар, кулга иялэшеп килә инде,—диде Сәлахов. Поши бозавы бик үк якын килергә базмыйча читтәрәк туктап калды.

—Бер елдан җигәргә өйрәтәм мин аны,—диде Сәлахов. —Дугасына кыңгыраулар тагып, поши җигелгән тарантаста Казанның Бауман урамыннан җилдереп узган берәү дисәләр, ул—мин булырмын!

Без бу хәлнең булачагына һич шикләнмичә, дәррәү кул чабып, аның сүзен хуплыйбыз. (Әмма тәкъдир без теләгәнчә булмый шул. Бер елдан ишетәбез. Ирекә, урманга китеп, кабат ихатага кайтып йөргән Миләүшәне ниндидер бер аучы урман аланында атып үтергән икән. Бөтен Мөслим халкының каргышын алган ул кансызны хөкемгә тартканнар).

—Атлар хакында язарга кирәк, йөрәккә үткәреп,—ди Сәлахов. —"Бардыр миндә толпар елгырлыгы, бардыр миндә дала кыргыйлыгы", дип язды безнең үз шагыйребез Зөлфәт. Аның туган авылы—Яңа Сәет әнә теге урман артында гына. Шәп яза чукынчык малай! Аны артык мактап, сезне кечерәйтмәемме, егетләр?!

Роберт Әхмәтҗан эчкерсез көлеп куйды:

—Зөлфәттән шәбрәк итеп, Зөлфәт кенә яза ала!

Янәшәдә торган композитор Зиннур Гыйбадуллин: "Зөлфәт!.. Зөлфәт!.." дип, көтелмәгән фикер әйтәсе килеп,галәттәгечә, сүз ярлылыгыннан тотлыгып калды. Риза ага Ишморат исә үзалдына елмайган да, Зөлфәтнең саллы шигырьләренә агылып керәчәк тау-үзәннәрдән хозурлык кичереп тора. Хатын-кызларыбыз—Рәисә Ишморатова, җырчы Җәваһирә Сәлахова бездән читтәрәк, сулышка-сулыш серләшәләр.

Уйлап куям: Роберт Әхмәтжанны бәлки "ат жене" читләтеп узгандыр. Аның хәяте—акчарлаклы Кама кинлекләре, су һәм күк тоташкан офыклар, кошлар юлы, канатлы хыяллар...

Мари Буләр авылында татар телле марилар яши икән. Клубта шушы авылның күз карасыдай кадерлесе—Николай белән танышабыз. Кырык яшьләрдә булыр, кыска буйлы, терсәк турлары сүсәргән күлмәк кигән, үтүкләнмәгән чалбар балаклары торбаланып тора, ямьшәйгән ботинкасыннан тишек үкчәләре күренә. Юк, боларның берсенә дә исе китми, аның бөтен вөҗүде тоташ музыкадан гына тукылган. Кулында—күпне күргән скрипка.

—Ә-ә, Риза Ишморатов агай сез буласызмыни?!—дип ул гыжылдавык курай тавышы чыгарып, скрипкасын сыздырып та җибәрде. Көйне уйнап бетергәч, аңлатып бирде:

—Сезнен, Риза агай, кырык тугызынчы елда язган спектаклегездән "Дуслык турында жыр".

Риза ага үзе дә оныткан булган ахрысы, аптырап калды.

—Ә-ә, Роберт Әхмәтҗанов сезмени?—дип Николай "Кама буе туган як", "Синең эзләр", "Кояшларың белән кил син миңа" кебек гаҗәеп җыр көйләрен бер-бер артлы уйнап та чыкты.



*Фронтовик әдипләр белән: Мөхәммәт Садри, Әмирхан Еники, Роберт Әхмәтҗан. Август, 1981 ел.*

Сәхнәдән чыгыш ясаганда: "Мин, иптәшләр, иртәгә язган яна көемне уйнап күрсәтәм", дип халыкны үзенең сәер тел хасияте белән аптырашта калдыра торган Зиннур Гыйбадуллинның да берничә көен уйнап күрсәткәч, ул гел таралып төште. "Гений, гений!"—дип, Николайны иненнән кочып йөртә башлады.

Ниһаять, музыкант-виртуозны "аяктан егарга теләп", Роберт Әхмәтжан:

—"Тукай марш"ын ишеткәнең бармы?—диде. Николай, ирен чите белән генә елмаеп куйды да, смычогын кыллар өстенә салды. Скрипка күкрәгеннән "Тукай маршы" агыла башлады.

...Айлы төн... Клубтан соң тәмле ашлар белән сыйланып кайтып киләбез. Авыл йоклый. Каядыр атлар пошкырып куя. Кунакханә ишегалды—болын кебек. Кипкән печән исе тамак төбен кытыклый. Тәндә яшь кан тибә. Артык кәефлелекне тәнжан сыйдыра алмый. Менә мин Җәваһирә Сәлахованы каерып алып күтәрәм дә... каршыдагы чүмәләгә турылыйм. Ә ул иркә тавыш белән кычкырып, егылып төшүдән куркып, муенга асылына. Каян килгән көч диген, мин аның шактый мул гәүдәсен очыртып кына алып киләм дә... икебез дә печән өстенә егылабыз. Шул мәлдә артка борылып карасак... Роберт Әхмәтжан да бинһая калын гәүдәле Рәисә ханым Ишморатованы беләкләренә салган да... Курач, юка гәүдәсе белән сыгылыпмы сыгылып килә... Кырмыска пирамиданы күтәргән кебек.

—Куй, Роберт энем! Төшереп җибәрәсең бит Рәйсәмне!—дип аның янәшәсеннән, өтәләнеп, Риза ага атлый. Менә алар да килеп житеп чүмәлә өстенә аудылар. Тәгәритәгәри көлешәбез. И ул айлы төннең рәхәт ваемсызлыгы! Алда ниләр буласын белмәгән бәхетле мизгелләр, хәзер дә искә төшеп, хәтерне иркәли.

Ак болыттай баштан сыйпап кына
узган гомерләргә—салават!

Мөслим белән хушлашабыз. Калганнарыбызны—пароходка, Роберт Әхмәтжан белән мине аэропортка озатып куйдылар. Мөслим аэропорты—офыккача җәелгән яшел чирәмле дала. Шул даланы оя-оя ак казлар көтүе чуарлаган. Биектә самолет тавышы ишетелүгә үк алар, дәртсенеп, башларын кыңгыр салып күккә карыйкарый, бергә туплана башладылар.

Гаҗәеп күренеш иде бу! Ак каз дингезен ерып, башын чөйгән, канатын җәйгән аэроплан килә. Казлар да, башын чөеп, канатларын җәйгәннәр, "Күктән олы атабыз төште!" дигән шикелле, тантаналы кыйгаклап, яфрак-яфрак тәпиләре белән марш атлап киләләр болар. Мондый да мәҗүси тамашаны тыныч-гамьсез генә күзәтү мөмкин түгел иде. Роберт Әхмәтҗанның гәүдәсе, бөтенләй авырлыксыз калып, тоташ куану, сабыйларча хозурланып, ләззәти көлүгә әверелде.

...Очабыз, Мөслим, без синнән.
Кул изәп, зәңгәр Ыгың, тугайларың,
ал таңнарың өстеннән.
*"Мөслим белән саубуллашу"*.

Көн шундый аяз. Тургай биеклегендә очабыз. Янәшәдә генә Чатыр тау күренеп калгач, мин, әсәренеп, тәрәзәгә капландым. Аста—яшеллеккә күмелгән урамнары белән Азнакай бөтерелеп калды. Ә менә үз авылым өстеннән кайчан да булса самолетта очып үтәрмен дип башыма да китермәгән идем. Әнә, Эстәрле инеше, йөзьяшәр таллар, әнә безнен олы урам, өй түбәсе... Әни! Ишегалдында күркәләргә җим сибеп утыра әнкәй. Күнелдә—кыбырсу, тәрәзәне ватып чыгып сикерәсе килә, "әни, нигә башынны күтәреп карамыйсың?"—дип кычкырасы килә. Авылым өстеннән очабыз, дип алгысынган хисләрне бүлешер кешем дә юк. Юлдаш Шагыйрем башын урындык аркасына терәп, калгып киткән, уятырга кызганыч...

Бөгелмә аэропортына төшкәч, сөйләдем дә, Роберт Әхмәтҗан:"Их, уятасың калган икән!"—диде.

Күпмедер вакыттан соң китабында күрәм, онытмаган:

Син түбәннән генә очтың...
Очкан чакта үз өегез турыннан,
аермачык күреп калдың
үзегезнең ишегалдын:
ак алъяпкыч япкан әниең
күркәләргә җим сипкәнен.
*"Мөслим белән саубуллашу"*.

"Мин—табигать улы, аерылмыйм табигатем карынынннан" дип язган Шагыйрьнең күз алдымда туган күпме хикмәти сүзләре истә калган. Бер авылда (Иске Карамалы иде бугай) юан, төз кәүсәле, искиткеч биек үрләгән өянкеләр арасыннан барабыз. Роберт Әхмәтҗан туктап, сокланып карап торды да: "Өлкән таллар урамы", дип куйды. Бу инде—туачак шигырьнең бисмилласы иде. Мин шуна төшендем: Анын "шигъри җене" һәрчак уяу-сизгер, гамьле-күзәтүчән икән: гүя бөтен терек табигать, анын илһамын уятыр өчен хезмәт итүче биләмә; очар кошлар учына каурый ташлап китә, яфраклар эч серен пышылдый, агымсулар аягына сарыла, пошилар мөгезен салып бирә, төклетуралар иненә кунып ял итә. Ул—"Кояш һәм җил республикасы"нын сулышлы, кыштырдаулы, сайраулы һәммә и я с е н ә чиксез рәхмәтле булып ак кәгазьгә иеләдер...

***

Аңа олыгаю килерме?

Тән-җәсәде генә түгел, рухияте дә олыгаеп, иҗатына моңлы чал кунар микән? Әллә инде яшьлек аланнарында, җилфердәк күбәләк булып, иркәләнеп оча-оча адашып калырмы, дип уйлый идем элек. Күпме шагыйрьләр шулай: тормыш дәрьясының өстәге күбекләрен генә алып, үзен тудырган халыкның тарихи төпкеленә, рухи коесына төшә алмыйча, ә р н ү дигән газиз тойгы катламнарын ача алмыйча, шигърият аланыннан юыртып китеп бардылар.

Хәер, матурлык җырчысы булып кына калса да ул шигъриятебезнең алтын таҗына лаек булыр иде.

Әмма... Язмыш анардан мәгънәле елларны кызганмады. "Безгә яшь гасырлар капка ачарлар" дип язган мәле фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килгәндер мөгаен. Шагыйрь яна дәверләргә олыгаеп чыкты. Шуна күрә, хәзер инде анын: "Җыр—ул кешенең кан авазы, рух сурәте" дип әйтүе дә олпатларча табигый яңгырашка ия.

Тышаулы ат иден, Татарстан,
Татар иле, изге ватаным.

Төшләремә кереп куандыра
тышауларың өзеп чапканың!

Баскан жирендә, тирәндәге тамырлар сулкылдавын тойса да, Шагыйрь дәрманы ташып торган чагында ерактагы, күз күрмәгән илләрдәге фажигаларны (Вьетнамдагы Сонгми, Япондагы Нагасакилар) үзенеке кебек кабул итәргә мәжбүр иде. Үз өендәге тарихи әрнүләргә калын йозаклы т а б у куелган иде шул...

Ирексезлек араннарына күкрәге белән бәрелгән тулпар сыман ул, фидакарьләрчә язды да язды. Күпме замандашларының күңел күзен ачкан, йокымсыраган анын уяткан, кече гамьнәрен оныттырып, дөнья матурлыгы каршында тукталырга, олы гамьгә таба бер талпынып куярга мәжбүр иткән Шагыйрь ул.

Үзеңнән элгәрләрнең бөеклеге серенә ижади табынган хәлдә генә син көч сынаша аласың. Әгәр Тукай йөгәнләргә өлгерә алмаган ритмнарны, Такташка житмәгән төгәллекне, Дәрдмәнд колачларга өлгермәгән киңлекне тоймыйсың икән, димәк, үзенә мирас итеп калдырылган бу хәятне баетырга алыну—сиңа бирелмәгән. Шагыйрьлегең бары кызыклы тәжрибәләр жимеше генә булып калачак. Күпмеләр шулай, остазга әверелә алмаган өйрәнчек икәнен сизмичә, бәхетле кинәнү белән ижат итеп, пегас иярennән егылып калдылар.

Төшегез сез Тукай катламына,
намус катламына төшегез.
Дөрләтегез сүнгән шигъри утны,
гаделлекнең кулын чишегез!
*"Тукай катламы"*.

Күпме кыйтгаларны белгән төрки телле халыкның варисы буларак, бөек татар теленен егәрен исбатлаган, поэзия оркестрында кабатланмас үз аһәнен булдырган шагыйрь ул—Роберт Әхмәтжан.

Ижатында үз мәккәсен тапкан, гомумән, әдәбиятка гомерлек яры итеп, изге гамәл итеп карауда югары кимәлдәге ижтиһадлык—аның гадел яшәү-ижат алымы.

Аның шигърияте—дүрт фасылы, дүрт тарафы булган түгәрәк—мөкәммәл дөнья. Көн вә төн ярымшарлары алышына-алышына, күз карасы кебек, үз орбитасында киләчәккә таба йөзеп бара.

"Атым үргә менә, ә мин менә, менгән саен... төшә башладым!" дип кайчакларда монсу уйларга бирелсә дә... Нахаклыктан рәнжеп, кырысланса да... шигъри сүзнең ыргымын ул затлы йөгәндә тота белә; "Кояшларың белән кил син мина!" дип, бердәнбер галәм шәмен сүз йөгереклегендә килешле итеп, төрләндереп әйтә алуы-чын шагыйрьгә—яктылык игезәгенә гөнаһ саналмастыр...

Ана туганда ук Ходай тел ачкычлары биргән.

Үзе бар иткән шигъри галәмендә ул—очар кош, биеккә чөелгән көмеш кыңгырау, кырлар догасыннан яралган тургай жырын сүзләргә салучы т ы л с ы м и я с е.

Анын тел коесы сиртмәсенә былбыллар оя корган...

⁂

*«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# АСЫЛЛАРНЫҢ АСЫЛЫ

Китап үзе бер асыл хезмәт булса, энциклопедия исә китапларның да иң асылларыннан асылы санала.

Күптармаклы гыйлем туплавын һәм халыкның барлык яшәүе көнкүреш тәҗрибәсен яктыртуын исәпкә алсак, алар чынлап та шундый зур бәягә лаектыр. Шуңа күрә да фундаменталь эчтәлекле, һәрьяктан камил, фәнни нигез эшләнгән белешмә басмалар теге яки бу халыкның социаль-мәдәни үсешенең бер этабы булып торалар.

Әмма мондый хезмәтләр һәркайда, һәркайчан түгел, фәкать билгеле шартлар җитлеккәндә генә гамәлгә ашырыла ала. Аларның беренчесе һәм иң мөһиме—гасырлар дәвамында тупланган ан-белемне, бигрәк тә халыкның үсеш тарихын, аның тарихи-мәдәни мирасын тәртипкә салу һәм системалы өлгегә салу җәмгыятьнең зарури бурычы булып өлгерергә тиеш. Аңлашылса кирәк—энциклопедик хезмәтләрнең чыганак нигезен, беренче чиратта, алга киткән тарих фәне, тарих фәненең җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелүе—историография булдыру, тел белеме аеруча тел берәмлекләре мөнәсәбәте, әдәбият, сәнгать, музыка, театр, сынлы сәнгать тарихы, китап басу һәм китапханә эше, массакүләм мәгълүмат чаралары, әлбәттә, халык хуҗалыгы тарихы һ. б. тәшкил итә.



*Татар энциклопедиясе институты хезмәткәрләре.*
*Сулдан икенче—Гомәр Сабирҗанов.*

Татар халкы тарихында мәшһүр шәхесләр һәм мөһим вакыйгалар турында билгеле бер төпле белешмәләр җыентыгына булдыру ихтыяҗын беренче тапкыр Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889) сиземләгән. Аның фәнни мирасының иң кыйммәтле хәзинәсе булып "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар ("Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр") исемле хезмәте санала. Ул автордан кульязма хәлендә калып, йөз елдан артык киштәдә яткач, 1989 елда гына хәзерге татар теленә күчерелеп, нәшер ителде һәм мәдәниятебез тарихында беренче чын энциклопедик әсәр булды.

Бу хезмәттә Болгар дәүләте, аның күршесендәге хәзәр һәм башка төрки халыклар, Казан һәм Касыйм ханлыклары, Русия дәүләте, Оренбург, Казан шәһәрләре, Казан тирәсендә урнашкан башка күп кенә торак пунктлар тарихы күзәтелә; 130га якын мәдрәсә һәм анда хезмәт иткән, бик күп күренекле мөгаллимнәр эшчәнлеге тасвирлана; халык мәгърифәтчеләренә китапның "Шәхесләр һәм истәлекле вакыйгалар" исемле аерым бер бүлеге багышланган.

К. Насыйриның (1825—1902) тел белеменә караган хезмәтләре, татар теленең

беренче аңлатмалы сүзлеге—"Ләһҗәи татари" (1895—1896), аның тарафыннан нәшер ителгән татар телендәге беренче календарьлар, татар этнографиясе, археологиясе, фольклоры һ. б. белем тармаклары буенча тупланган материаллары—шундый ук омтылыш үрнәге булып тора.

Халыкның үз-үзен танып белү юлында Академия үзәге эшчәнлеге (1921—1930) мөһим бер этап санала ала. Аңа фәнни-тикшеренү, фәнни-педагогик, музей-архив, башка тарихи-эзләнү эшләре һәм җөмһүриятебездә сәнгать иҗатын оештыру эше тапшырылган була. 1923 елның маенда Академик үзәктә татар фәнни җәмгыяте, 1925 елда Татар төбәген өйрәнү бюросы төзелә. Бу һәм башка фәнни оешмалар тарафыннан Татарстан һәм татар халкын комплекслы өйрәнү нигезе булдырыла. Соңрак бу вазифаны, ягъни 1930 еллар ахырыннан башлап Г. Ибраһимов исемендәге Тарих, тел һәм әдәбият институты дәвам итә.

Чынлыкта беренче татар энциклопедик фәнни белешмә танылган язучы һәм библиограф Исмәгыйль улы Рәмиев (1895—1969) тарафыннан төзелә. Ул татар вакытлы матбугатының "Вакытлы татар матбугаты (Альбом)" исемле аннотацияле библиографик күрсәткечен һәм үзе исән чакта кульязма хәлендә калган "Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек)" исемле хезмәтләр язып калдыра.

Мәдәниятебез тарихын тирәннән белүче Рәис Нәүширван улы Даутов тырышлыгы белән бу хезмәт әүвәл (1992—1996 елларда) "Татарстан" журналы битләрендә басылды, 2001 елда исә аерым китап булып нәшер ителде.

1960 елларда энциклопедик сүзлек нәшер итү буенча Казан педагогия институты профессоры, "Татарстанны өйрәнү җәмгыяте" гыйльми сәркәтибе Рәфкат Шакирҗан улы Таһиров (1903—1977) эш башлый. Вафатыннан соң туганнары аның архивында 22 папкадан торган "Татарстан". 11 томлы энциклопедик сүзлек" дигән гомуми исемдәге материаллар табып алалар. Ләкин Рәфкат әфәндегә башлангыч мәгълүматлар туплаудан ары китәргә язмаган булган шул.

Эшнең асылы хезмәтнең тәмамланмавында, дөнья күрү-күрмәвендә түгел, ә Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйрилар заманында ук туган милли энциклопедия булдыру идеясенең еллар, заманнар үтү белән һич сүнмичә, һаман да көчәя баруында. Шуның өчен күп кенә энтузиастлар, дәүләтнең рәсми рәвештә бу хезмәтне булдыру карарын, акчалата ярдәмен көтеп тормыйча, бу җирлектә үз көчләрен сыныйлар.

Бу, әлбәттә, татар халкының галим-голямасы катлавында үзенең милли төбәкләренең универсаль белешмәлеген булдыру ихтыяҗын тою дәлиле генә түгел, ә фән, мәдәният белеменең торышы, югары квалификацияле белгечләр өлгерүе катлаулы, фундаменталь проблеманы унай чишү мөмкинлегенең тууы күрсәткече дә.

1989 елның сентябрендә КПССның өлкә комитеты вәкаләте белән, җөмһүрият хөкүмәте фәнни җәмәгатьчелек мәнфәгатьләрен, мәдәният эшлеклеләре тәкъдимен хуплап, күптомлы Татар энциклопедиясен әзерләү һәм нәшер итү карарын кабул итте. Хөкүмәт карары универсаль фәнни белешмәне нәшер итү эшенә рәсми статус биреп, мәсьәләне гомумхалык бурычы югарылыгына күтәрде.

Ләкин бу эшнең чынлап киң колач белән җәелеп алга китүе ТР Президенты М. Ш. Шәймиевның 1997 елның 10 февралендәге "Татар энциклопедиясе программасы турында"гы фәрманнан һәм шул ук елның 4 маенда расланган бу программаны гамәлгә ашыру хакындагы хөкүмәт карарыннан соң гына башланды дияргә дә ярый.

... Инде 1999 елның көзеннән укучылар өстәлендә татар энциклопедистикасының беренче җимеше—Татар энциклопедиясе сүзлеге (рус телендә) лаеклы урын алды. Бу китап аксакал галимнәрдән, танылган язучылардан, журналистлардан башлап, гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары һәм студентларга кадәр зур канәгатьлек хисе белән кабул ителде.

Ә 2002 елда туган телебездә эшләнгән “Татар энциклопедиясе сүзлеге” (ТЭС) дөнья күрде. Эчтәлеге ягыннан ул гамәлдә яна, тулыландырылган һәм янадан эшләнелгән басма булды. Халкыбызның мәдәнияте үсешендә бу хезмәт нәшер ителүе белән укытучылар, журналистлар, студентлар, башка күп кенә белем тармаклары белгечләре кулына тәртипкә салынган фәнни терминнар, хәзерге татар теле кануннары буенча төгәлләнгән һәм төзелгән географик объект атамалары тәкъдим ителде. Аның битләрендә укучылар үткәндәге һәм хәзерге көндәге күренекле шәхесләр,

кыскача барлык мөһим тарихи вакыйгалар, мәдәният, фән, сәнгать күренешләре белән очраштылар.

2005 елда күптомлы Татар энциклопедиясенең 1 томы да нәшер ителәчәк. Бу универсаль басманың бар бүлекләре дә география, биология, археология, этнография, әдәбият, музыка, театр, сынлы сәнгатькә караган барлык төрле фотоиллюстрацияләр һәм карталар белән бизәлә. Күптомлы ТЭСнең зур күләмле мәкаләләрендә укучы төпле белешмә мәгълүматлар һәм темага караган кыскача махсус әдәбият исемлегеннән файдалана алачак. Энциклопедиянең авторлары коллективы төрле яктан тикшерелгән, төгәл фактларга нигезләнгән материаллар туплауны үзенең төп бурычы итеп саный.

Әмма еш кына тема үзенчәлекләре бер кысаларда бәя бирергә яисә аерым күренешләргә характеристика бирүне сорый. Бу хәл бигрәк тә сәнгать мәсьәләләрендә ачык төсмерләнә.

Мисал өчен әдәбият бүлеге мәкаләләре (Фольклор, Әдәбият, Проза, Поэзия, Драматургия, Балалар әдәбияты; татар төрек әдәбиятында урта гасыр жанрлары турында мәкаләләр—Васыятнамә, Газәл, Гаруз, Касыйдә, Кыйсса, Кыйтга һ. б.); татар төрек әдәбияты истәлекләре ("Бәдәвам", "Бакырган китабы", "Китабе дадән Коркыт" һ. б.) һәм дә язучылар, әдәбият белгечләре, әдәби тәнкыйтьчеләрнең тормышына һәм иҗатына багышланган һ. б. шундый мәкаләләр.

Хәтта 6 томлы "Татар әдәбияты тарихы"ннан (1984—2001), Л. Җәләй, Г. Хәмит, М. Гали, М. Гайнуллин, Н. Юзеев, Ш. Абилов, Н. Хисамов, А. Әхмәдуллин, М. Әхмәтҗанов, Х. Миннегулов, Ф. Урманче, Р. Ганиева, Ф. Мусин, Т. Галиуллин, Н. Ханзафаров, Ф. Галимуллин кебек танылган татар мәдәнияте тарихын тикшерүчеләр хезмәтләреннән файдалансалар да, Татар энциклопедиясе институты белгечләре еш кына теге яки бу мәсьәләнең, ә кайвакыт әдәбият белеменең зур, мөһим мәсьәләсенең җитәрлек дәрәҗәдә ачыкланмавы белән очрашалар.

Бигрәк тә хәзерге заман язучылары иҗатын анализлаганда зур кыенлыклар туа. Тормыш юлы һәм әдәби мирасы кабат-кабат махсус тикшеренүләр үткән күп еллар элек иҗат итүчеләрдән аермалы буларак, 1970 — 1990 еллардагы әдәби әсәрләрнең күбесе, әдәби процесс үсеше тенденцияләре һәм кануннары тәнкыйди күзәтүләрне узмаган. Соңгы елларда әдәби тәнкыйть тавышсыз-тынсыз калды, ә бу хәл хәзер нәшриятка тапшырырга әзерләнгән Татар энциклопедиясе сүзлегенең мәкаләләре эчтәлегенә кагылмыйча, аерым мәкаләләрдә каләм осталарының иҗатын төпле бәяләү, үзгәртеп кору чорына калдерге дәвердә генә күренә.

Аңлашыла ки, күптомлы ТЭС авторлары коллективы бу җитешсезлектән котылырга юл эзли, әмма ничек дигән сорау әлегә җавапсыз кала.

Соңгы 5-10 ел эчендә докторлык һәм кандидатлык фән дәрәҗәсен алу өчен якланылган диссертацияләрне барлаганда, бүгенге көн мәсьәләләренә багышланганнары юк диярлек.

1999 елда дөнья күргән рус телендәге ТЭСнең мәкаләләренә укучыларның зур шелтәләре булмады. Әш шунда ки, безнең әдәбиятыбызның билгеле теоретиклары һәм тарихчылары Н. Юзеев, Х. Миннегулов, А. Әхмәдуллин, Ф. Мусин, Т. Галиуллин, Р. Ганиева, Ф. Урманче һ. б. шул мәкаләләрнең авторлары булуындадыр.

Институт коллективы югары уку йортлары, Казан фәнни тикшеренү институтлары, җөмһүриятнең башка шәһәрләре, Уфа һәм башка фәнни үзәкләрдәге татар әдәбияты тарихын тикшерүчеләр белән ТЭСнең беренче томнарына җыелган материаллар өстендә эшлиләр. "Казан утлары" редакциясе тәкъдиме белән, беренче томнар өчен җыелган әзер материалларның бер өлешен әлеге журнал битләрендә бастырырга булдык. Бер яктан, бу мәкаләләр мәктәп һәм башка уку йортлары укытучыларына файдалы булса, икенче яктан, күптомлы Татар энциклопедиясен төзүдә милләтебез әдәбияты тарихы мәсьәләләре белән шөгыльләнүче белгечләр үзләренең тәкъдимнәрен, киңәшләрен безгә җиткерерләр дип уйланыла.

**Гомәр САБИРҖАНОВ,**
*Татар энциклопедиясе институты*
*директорының беренче урынбасары.*

# А

**АБДУЛЛИН** Ибраһим Әхмәт улы (20.9.1920 ел, Уфа губернасы Бәләбәй өязе Зирекле авылы, хәзерге Башкортстан Респ-касы Шаран р-ны), язучы, БАССР-ның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978). Башкорт телендә яза, А. кайбер әсәрләре татар телендә басыла. 1957 елда Мәскәүдә М.Горький ис. әдәбият ин-тын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945–52 елларда "Совет Башкортостаны" газетасының үз хәбәрчесе булып эшли. 1938 елда аның беренче "Көймәдә", "Вагонда" хикәяләре, "Ал яулык" пьесасы, "Гөлмәрфуга" (1953), "Розалар" (1957), "Йөрәк менән шаярмайзар" (1961) драмаларында тормыштагы кискен хәлләр күрсәтелә. "Баҗалар" (1952), "Ялкынһыз яна йөрәк" (1960), Тиле йәшлек" (1970) комедияләрендә әхлак тәрбиясе мәсьәләләренең актуаль сорауларына кагыла. А.ның күп әсәрләре—"Йыр булып кайтырмын" (1970), "Карпатта таң ата" (1985) драмалары реаль фактларга нигезләнгән. А. пьесалары Татар акад. театрында да куелалар. "Хуш, Риса!" (1969) — совет һәм италия партизаннарының фашистларга каршы көрәше, "Кош юлыннан барам" (1983) — Киевта партизаннарның яшерен эшчәнлеге турында, "Чардакка ташланган хаттар" (1965), "Меңәр йыл йәшәй кедр" (1973) исемле хикәяләре Бөек Ватан сугышы вакыйгалары турында. 1996 елда Башкортстан Респ-сының Салават Юлаев ис. Дәүләт бүләге, 1 нче дәрәҗәле Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә. Уфа шәһәрендә яши.

**АБИЛОВ** Шакир Шиһап улы (15.7.1915, хәзерге Чиләбе өлкәсе Конашак р-ны Яңавыл а.), әдәбият белгече, филол. фән. канд-ты (1961), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1964). 1938 елда Оренбург пед. ин-тын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1958–86 да СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. Мөхәммәдъярның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнә, аның "Төхфәи мәрдан" һәм "Нуры содур" поэмаларын бүгенге әдәби телгә күчерә, басмага әзерли: кереш сүз, искәрмәләр, комментарийлар яза һәм сүзлек төзи. Баласагуни, Кол Гали, Хорәзми, Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб, Мәүла Колый иҗатларына караган хезмәтләр авторы. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Борынгы татар әдәбияты. К., 1963 (автордаш); Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. 1 т. К., 1984 (автордаш).

**АБУШАЕВ** Хөсәен Йосыф улы (псевд. — Абушаев-Атлаши) (19.1.1892, хәзерге Ульянов өлкәсе, Иске Кулаткы р-ны Иске Атлаш а. — 1961 елдан соң, Казакъстан ССР), шагыйрь. "Хөсәения" мәдрәсәсендә белем ала. 1916 елдан башлап соңгы көннәренә кадәр Казакъстанда укытучы булып эшли. Шигырьләре 1909–15 тә "Идел", "Вакыт" газеталарында, "Шура", "Чүкеч" ж-лларында басыла. Аерым шигырьләре "Яңа әдәбият" хрестоматиясенә (1914, төзүчеләре Г.Ибраһимов, Г.Баттал) кертелә. "Алтыннарым" (1915) җыентыгына 22 шигыре керә. Шигырьләрендә тормыштан зарлану мотивлары, моңсу кичерешләр чагылыш таба. Татар халкы арасында мәгърифәт тарату зарурлыгы турында яза. Тукайга багышланган шигырьләре бар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Әд.: Рәми З. XX гасыр башы татар шигърияте // Мирас. 1998.N3.

*З.З.Рәмиев.*

**АВТОБИОГРАФИЯ** (грек. autos — үзем, bios — тереклек, grapho — язам), кешенең үз тормышын бәян итүе. Мемуарга якын булган әдәби жанр. А. алымнары Мәхмүд Болгариның "Нәһҗел-фәрадис" (1358), Мөхәммәдъярның "Төхфәи мәрдан" (1539–40) әсәрләрендә очрый. Лирик чигенешләрдә авторлар иҗатлары турында мәгълүматлар бирәләр. Аерым очракларда китапны күчерүче хаттат авторның үлгән елын өстәп куя. Татар әдәбиятында беренче автобиографик әсәрләр буларак авторның тормышы, аның хаж кылуы тасвирланган "Мөхәммәдәмин сәяхәте"н (1783) һәм "Рихләтел-Мәрҗәни"-не (1879) атарга мөмкин. Соңрак А. жан-

рына Г.Тукай ("Исемдә калганнар", 1909), М.Гафури ("Шагыйрьнең алтын прииска-сында", 1931) мөрәҗәгать итәләр. Бу жанрда шулай ук Х.Туфан ("Бәлки, шагыйрь булмас та идем", 1970), С.Хәким ("Үзем турында", 1971) һ.б. язалар.

*Ш.Абилов.*

**АГИЕВ** Фәхрелислам Нигъмәтулла улы (12.3.1887, Тамбов губ., Тимникәү өязе Тенеш а. — 1938), журналист, педагог, язучы. 1908 елда Казанда үзлегеннән хәзерләнеп Татар укытучылар мәктәбе курсын тәмамлау имтиханнарын тапшыра. 1908–15 тә Рус-татар уч-щесендә (Казан) укытучы булып эшли. 1907 дән башлап "Аң", "Мәктәп" ж-лларында, "әл-Ислах", "Кояш", "Йолдыз", "Бәянелхак", "Ил" г-таларында мәкаләләрен һәм хикәяләрен бастыра. 1913–16 да балалар өчен "Ак юл" ж-лы чыгара. Ә. -"Хикәяләр җыентыгы" (1926), "Кыйраәте ибтидаия" хрестоматиясе (1908), "Кызыл йолдыз" әлифбасы (1924, Г.Тимербулатов белән берлектә) авторы. 1917 дә 1 нче Бөтенроссия мөселманар съездында катнаша. 1924 тән СССР халыклары Үзәк нәшриятында (Мәскәү) эшли. Репрессия чоры корбаны (1938).

Әсәр.: Мәрхәмәт. К., 1990.

Әд.: Литературная энциклопедия. М., 1929; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986; Ибраһимова Ф. Тынгысыз шәхес // Шәһри Казан. 1997. 27 июнь.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**АГИШЕВ** Якуб Хәлил улы (28.7.1899, хәзерге Пенза өлкәсе, Кузнецк р-ны Пәлдәңге а. — 20.6.1972, Казан), әдәбият галиме, текстолог, филол. фән.канд-ты (1946). Архангельск реаль уч-щесен (1918), Казан пед. ин-тын (1934) тәмамлый. 1934–39 да Казан пед. техникумында һәм сәнгать техникумында укыта. 1939 дан СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. 1946–51 дә Казан пед. ин-ты укытучысы һәм татар әдәбияты каф. мөдире. 1951–60 та Казан ун-тында укыта. Хезмәтләре татар әдәбияты тарихын дәверләргә бүлеп өйрәнүгә, Г.Тукай иҗатына карый. Урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты дәреслекләре авторы.

Хезм.: Творчество Габдуллы Тукая. К., 1948; Халык шагыйре Габдулла Тукай. К., 1956.

Әд.: Гиниятуллина А.К. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиографич. справочник. К., 1970.

**АДНАШ** Хафиз бине Мөхәммәдхафиз (16 йөзнең урталары), Казан ханлыгының дәүләт эшлеклесе, Казан б-н Мәскәү арасындагы дипломатик сөйләшүләрдә катнашучы. Казан өчен сугышлар барган вакытта илчелек тоткын ителеп, А.шул тоткынлыкта чагында (1553) "Сиражелколүб" ("Күңелләр яктырткычы") исемле гарәпчәдән төрки телгә күчерелгән кыйссаларны үз эченә алган җыентык төзи. Сорау һәм җавап рәвешендә төзелеп, дөньяның яратылышы, ахыры, оҗмах, тәмуг, пәйгамбәрләр һәм күренекле тарихи шәхесләр, мөселман изгеләре турында язылган бу җыентыкның 16 йөзләргә караган кульязма бер нөсхәсе Лондонның Британия музеенда саклана. Җыентыкның кульязма нөсхәләре Казан, С.-Петербург, Мәскәү фәнни китапханәләре фондларында да бар. Беренче тапкыр 1863 елда Казанда нәшер ителә. Дини эчтәлектәге "Шәраигъ әл-әхкям" ("Шәригать хөкемнәре") җыентыгының да төзүчесе А. дип уйланыла. А.ның Мәскәү тоткынлыгындагы соңгы язмышы билгесез.

*Лит.:* Наджип Э.Н. Историко-сравнительный словарь тюркских языков на материале "Хосров и Ширин" Кутба. XIV в., М., 1979. Кн. 1; Средневековая татарская литература (VIII-XVIII вв.). К., 1999.

*Ш.Ш.Абилов.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ГАЗИЗЕБЕЗ БАР ИДЕ...

Ни аяныч, байтак талант ияләребез бик яшьли китеп барганнар икән! Мин үзем Аязымны сагынып искә алам да, Ходайдан сабырлык сорап: "Никадәрле талантлы каләм ияләре әйтер сүзләрен, мәгънәле фикерләрен татар халкына җиткерә алмыйча киткәннәр бит әле. Минем Аязым җитмеш бишенче яшендә китте. Шөкер итә бел, Нәкыя!"—дим. Тагын шунысы да бар: алар китү аркасында хәзерге татар әдәбиятында буыннар алмашыну режимы да бозылган булып чыкты кебек, минемчә. Алар һәммәсе дә әзмәвердәй тап-таза егетләр иде бит. Төрлесе төрле сәбәпләр белән вафат булган бу язучыларыбыз әдәбиятны яратучыларны талант ияләре язган әсәрләр уку ләззәтеннән мәхрүм итеп китеп бардылар! Шушы яшьли киткән әдипләр турында матбугат әледән-әле язып тормаса, укучы яшьләр аларны онытып та куярлар диган шигем бар. Кемнәр соң алар? Иң беренчесе, ун ел дәвамында безнең фатир күршебез булган Газиз Мөхәммәтшин (1932—1972). Кырык яшен бәйрәм итәргә теләп рухланып йөргән мәлләрендә вафат булды... Аннары, Мәсгут Шәрифуллин (1928—1966), Хәсән Сарьян (1930—1978), Фаил Шәфигуллин (1939—1982), Фәиз Зөлкарнәй (1951—1997)...

Газиз Мөхәммәтшиннар белән ун ел дәвамында күршеләр булып яшәдек, дидем. Күрше хакы—Алла хакы дигәннәр борынгылар. Әйе, без әйбәт күршеләр идек. Мин аның әсәрләрен яратып укыганмын, Аязым аның "Без әле җирдә яшибез" дигән китабына кереш сүз язып, әдипнең үзе вафатыннан соң, 1977 елда китап нәшриятында бастырып, әсәрләрен халыкка җиткерергә тырышып йөргән.

Мин урыс мәктәбендә укучы татар балаларына утыз тугыз ел дәвамында татар әдәбияты һәм татар теле дәресләре алып бардым. Дәресләр расписаниега атнага ике мәртәбә генә итеп кертелгәнлектән, балаларны әдәбият белән кызыксындыру бик кыен була торган иде. Газиз Мөхәммәтшин һәм башка язучыларның мавыгып укырлык хикәяләрен яшь үзенчәлекләренә туры килерлек сыйныфларда кулланырга тырыша торган идем. Менә шундый юл белән Газиз Мөхәммәтшинны татар балаларына пропагандалап үземә дә рәхәтлек таба идем. Аның хикәяләренең теле җанга ятышлы, укый башлагач тукталып тормыйча, беткәнче укыйсыны китерә торган. Балалар зарыкмыйча тыңларга һәм аңларга тырышалар иде.

Соңгы елларда аның әсәрләре матбугатта күренгәне булмаганга, телевизор караучыларга таныш "Ике әби бәрәңге ала" хикәясенә генә тукталып китәсем килә. Ул әсәрне Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе күренекле режиссер Әхтәм Зарипов телевизор экранына моннан берничә еллар элек чыгарган иде инде. Әмма дә ләкин ул әсәрне архивка салып куярга ашыкмыйлар, һәр елда бер-ике мәртәбә телевизор тамашачыларына күрсәтеп алалар һәм бик дөрес эшлиләр. Андагы ике әби (рольләрдә—Татарстан Республикасының халык артистлары Люция Фарсина белән Роза Хәбибрахманова һәм Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Әхтәм Зарипов) тамашачыны сәгатьләр буена телевизор экраннарыннан аерыла алмаслык итеп уйныйлар. Мин үзем аны һәр тапшыруларында да карап, рухыма ләззәт алып калырга тырышам. Спектакльне карап бетергәч, тагын күрәсе килү теләге туа. Анда картларның-карчыкларның психологик үзенчәлекләрен никадәрле тапкыр тасвирлануына таң калам. Артистларның уйнавына әдәби әсәрнең тирән мәгънәлелегә өстәлеп тамашачыны мөкиббән итә дә куя! Г. Камалның "Беренче театр" комедиясен дә телевизордан шулай кабатлап күрсәткәләп алалар. Аны да мин һич калдырмыйча карап барырга тырышам—югыйсә инде һәр сүзе ятланып беткән диярлек.

Газизнең ике әбисе дә—тормыш тәҗрибәсен туплаган карчыклар, акыллы фикер йөртүләре белән безне тәрбиялиләр. Алар барлык дөнья мәшәкатьләрен үз җилкәләрендә алып баруга карамастан, күңелләре саф, сөйләм телләре матур, инде хәлсезләнгән картка карата мөнәсәбәтләре ягымлы, халыкара хәлләрдән дә хәбәрдар алар.

Шушы хикәяне язган елда Газиз әти-әниләре янына кайтып, бәрәңге алышу эшендә катнашып килгән иде дип хәтеремдә калган. Аяз: "Ничек шулкадәр табигый матур хикәя яздың?" дип сораган иде. Газиз: "Дөрестән дә шулай ул; ике әби теттерел, бөтен дөнья сәясәтенең белгечләре булып, бәрәңге жирендә матур итеп сөйләшәләр дә сөйләшәләр, ә мин сүзләрен әләктереп алам да өйгә йөгереп кереп яза торам",— дигән иде. Нәнәсе: "Нишләп улым бик еш өйгә кереп чыгасың?"—ди икән... Газиз ана каршы нинди сүз әйткәндер—анысын хәтерләмим. Ул гажәп тә юморлы кеше иде, берәр кызыклы фикер чәчрәтеп матур итеп көлгән булгандыр...

Монда Аязның Газизгә карата язган сүзләрен искә алып китсәм дә чит булмас.

"Берәүнең кем икәнлеген, асылын аңларга теләсәк, сез аны йөргәндә түгел, сөйләшкәндә дә түгел, көлгән чагында күзәтегез",—дигән хакимнәрнең берсе. Хәтерем алдамаса, Достоевский шулай дип әйтеп калдырган шикелле. Бер уйлаганда гади генә күренгән бу күзәтүдә ифрат зур тапкырлык ята. Чыннан да, нәкъ менә көлгән чагында кешенең чынлыгын, сафлыгын, кем икәнлеген белеп була. Тегене-моны эшләгәндә, сөйләшкәндә хәйләләргә яки башка берәү булып күренергә мөмкинлек булса да, көлгән чакта кешенең уены-чыны күзгә бәрелеп тора...

Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеевлар белән бер чордарак әдәбиятка килеп кереп, кыска гына гомере эчендә якты эз калдырган каләмдәш дустыбыз Газиз Мөхәммәтшин матур итеп көлә белә иде. Без Газиз белән байтак еллар бер йортта яшәдек. Төпчек улым Рашат дөньяга килгәч, сөйләшереннән элек сызгырырга өйрәнде. Ул: "Кош ничек итеп сайрый, Рашат?"—дип сораган һәрбер кешегә, иреннәрен мәзәк кенә бөрештереп, кош булып сайрап күрсәтә, иде. Газиз бер дә иренмичә көн саен диярлек аның янына керә һәм һәрвакыт: "Яле, Рашат, кош булып сайра әле!"—дип сорый иде. Бала сызгыра башлагач, башын артка чөеп, вак-вак көмеш авазлар белән бүлмәне тутырып кетердәтеп көлеп җибәрә иде... Куанычлы итеп, үзе сөенеп һәм башкаларны да сөендереп, ямьле итеп, кинәеп, чын күңеленнән рәхәтләнеп көлә белә иде...

Уйлап карасаң, матур итеп көлә белә торган кешеләр бик сирәк очрый, алар тирәләрендәге кешеләрнең кәефен күтәрәләр, яшәргә дәрт өстиләр, тормышны бизиләр... Язучылар арасында алар тагын да сирәгрәк очрыйлар...



*Сулдан уңга: Хәсән Сарьян, Нәби Дәүли, Газиз Мөхәммәтшин, Эдуард Касыймов. 1968 ел.*

Газиз Мөхәммәтшин иҗатының да төп юнәлеше—аның кабатланмас, үзенә генә хас юморында иде дисәк, бер дә ялгышмабыз. Иҗатының икенче төп сызыгы—Газиз Мөхәммәтшин күпчелек әсәрләрен яшьләргә-балаларга багышлады.

Шул уңай белән, балалар өчен юмор әсәрләре тудыруның бермә-бер авыррак икәнлеген алдан ук искәртеп куярга кирәк дип саныйм. Балалар олыларның үзләренә нинди күз белән карауларын бик тиз сиземләп алалар. Газиз исә дөньяга да, балаларга да якты күз белән карый иде. Характерлары белән үзләре дә оптимист булган балалар, нигездә чын тормыш күренешләре чагылган шаяруны җиңелрәк һәм теләбрәк кабул итәләр. Балалар язучысыннан тапкырлык, осталык, җиңел үтемле тел һәм башка бик күп мөһим нәрсәләр таләп ителә. Газиз Мөхәммәтшинның балаларга багышлаган әсәрләре исә җиңел оста юмор белән өртелгән, аларда буш дидактика, файдасызга үгет-нәсихәт биреп маташулар бөтенләй юк, автор яшәешнең тирән фикерләрен җиңел генә, оста гына кузгата белә һәм тиешле дәрәҗәдә укучының аңына сеңдереп бара. Моның шулай икәнлегенә балалар өчен язылып, тәкъдим ителгән әсәрләрен уку белән ышанырга мөмкин. Газизнең әсәрләре ул яшәгән заманның рухын тирәнтен һәм дөрес

чагылдыралар, балалар өчен иҗат ителгән, беренче карашка шуклык-шаянлык алымнары белән язылган повестьларда да чорыбызның олы һәм кирәкле проблемалары ята. Автор балалар күнеленә бик кирәкле компас бирә, "менә, укыгыз, уйланыгыз, хәтерегезгә сендерегез" дип, борчыган мәсьәләләрне кыю рәвештә уртага сала. Әйткәнебезчә, автор ярым шаярып, сиздермичә генә укучының күнелен яулап ала һәм үзе өчен иң әһәмиятле якларны да балалар психологиясенә тәэсир итәрлек дәрәҗәдә оста итеп үреп бара. Аның әсәрләрендәге балалар ду-ду килеп быргы кычкыртып яки бик акыллы кыяфәттә тимер-томыр гына җыеп йөрмиләр, автор бик тапкыр билгеләгәнчә, нәкъ менә "җирдә яшиләр", җир проблемалары белән яналар, җир законнарына буйсынып, җир кагыйдәләрен үзгәртә-үзгәртә үсәләр, кеше була баралар. Чынлап уйлаганда, зурлар нинди дөнья белән яшәсә, балалар да шул ук тормыш шартларында яши, тик аларның теге яки бу тормыш күренешен аңлаулары гына үзгә, аңлатулары гына үзләренчә, балаларча. Әмма аларның тормышына да җирдә бара торган мөһим вакыйгалар тәэсир итми калмый, җир күренешләре аларны да уйландыра, аларның гөнаһсыз зәңгәр төшләренә керә. Олылар белән кечеләрнең тормышы бергә, бер булып тыгыз үрелеп бара. Менә "Без әле җирдә яшибез" повестена игътибар итик. Бу повесть үзенең бөтенлеге, фикеренең тыгызлыгы, теленең тапкырлыгы, геройларның образ буларак төгәлләнгән булуы белән Газиз Мөхәммәтшин иҗатында үзәк урыннарның берсен тота.

Беренче карашка мәсьәлә артык гади һәм таныш та кебек тоелырга мөмкин. Ләкин авторның көче шунда ки, ул бер темага да бер яктан гына якын килми, ул һәр темадан бай эчтәлек ала белә. Әсәр Инсаф исемле малайга багышлана, аның авызыннан сөйләнә. Әйе, Инсаф—иркә малай, әнкә баласы. Әнкәсе өф-төф итеп аны җылы почмакта гына үстерә, кирәгеннән артык иркәли, малаен җылы почмактагы зәгыйфь гөл итеп бетерә. Мондый малайны күргәнебез бармы безнең? Әйе, бар. Шигырьләр, хикәяләр байтак багышланган мондый кәнфит кортларына. Әмма Газиз Мөхәммәтшин шушы традицион малай язмышына чорыбызның байтак мөһим мәсьәләләрен кушып җибәрә, теманы кинәйтә, эчтәлекне кыю рәвештә баета, фикерен үстерә, нәтиҗәдә, тирән эчтәлекле, гыйбрәтле, яна кешеләр дөньясыннан торган кызыклы дөнья тудыра. Инсаф тормышы аша без шәһәр, авыллардагы байтак типик вакыйгалар, конфликтлар, бәрелешләр белән танышабыз. Сүз беренче карашка гына иркә малай турында бара, фикер күп тапкырлар тирәнгәрәк яшерелгән. Әгәр яраткан һөнәренә хезмәт итәсең икән, сине алда байтак газаплар, байтак бәлаләр көтә дип, искәртеп китә автор. Сүз арасында гына түгел, ышанырлык итеп, тәэсирле итеп әйтә белә! Бар булганы, күнеле, омтылышы белән чын җир кешесе булган әтинең утын складында сөрсеп ятуы—гадәти хәлме? Түгел. Тик баштанаяк әнисе йогынтысына уралган Инсаф әтисен аңлап бетерми әле, ак белән караны аера алмый. Әшләмичә, йокы симертеп өйдә генә яткан, әтисе бер сүз әйткәнгә дә "Уф йөрәгем, уф башым!" дип хәйләләп дару йотарга тотынган әнисе Инсафны нәкъ үзенең копиясе итеп тәрбияләргә тели. Өч кеше арасында кызык кына хәл килеп туа: әтисе Инсафны бер якка өнди, әнисе исә Инсафны нәкъ кире якка тарта, малай аптырашта—кайсы якка барырга, дөреслек кайда?!

Әгәр әтисе әнисенең буш, ялган капризларын җинеп, хатынын, Инсафны төяп, дөбердәтеп авылга алып кайтып китмәгән булса, ай-һай, Инсаф дөреслекне тиз генә табар идеме икән?!

Авыл, аның мохиты, кешеләре, матур табигате бу өч кешенең тормышына тирән йогынты ясый—алар һәммәсе дә уңай якка үзгәрәләр. Башта Инсафка авылда бик кыен була, мороженое юк, янгыр яуганда урамнар пычрак, ата каз талый, әмма ул монда беренче тапкыр хезмәт тәмен татый, беренче мәртәбә хулиган малай алдында җебеп төшми, егетләрчә отпор бирә, иптәшлекнең кадерен, дуслыкның бәһасен аңлый башлый. Ана кеше башта бик бирешмәскә теләсә дә, тормыш аны да яхшы якка үзгәртә, чөнки улы Инсаф та ананың үзгәрүенә билгеле бер дәрәҗәдә өлеш кертә. Яхшы кешеләр арасында начарлар да үзгәрми калмыйлар!

Газиз Мөхәммәтшин ифрат җинел, тапкыр тел белән, җитди фикерләрен дә уенкөлкегә урап, мавыктырып алып бара белә диган идек. Мисал өчен нәни генә бер эпизодка күз салыйк. Инсафлар каладагы өйләрен, алма бакчаларын калдырып, машинага төянеп авылга кайтырга юлга чыгарга торалар. Йортка фатирчылар килгән, аларның да Инсаф кебегрәк уллары бар икән. Инсаф машина кузгала башлагач кына шушы йорт белән бик озакка аерылуын тоя һәм сикереп төшеп алма бакчасына керә,

ин яраткан агачының акбурга буялган кытыршы кәүсәсен сыйпый, китап арасына куеп сакларга, истәлеккә дип ямь-яшел, шоп-шом өч яфракны өзеп ала. Моннан ары авторның үзенә сүз бирик:

"Өзеп алуым булды, баскычка атылып, кызыл ыштан кигән, миннән дә бәләкәйрәк бер малай килеп чыкты. Ул нечкә тавыш белән:

—Тимә безнең алмагачка!—дип кычкырды.

Мин ана кәҗә тоягы күрсәттем.

—Башта утыртып үстер, аннан сезнеке булыр. Кара аны, без кайтканда берәр чыбыгы гына сынсын—жанынны алырмын!

Малай мона жавап итеп телен күрсәтте. Капкадан чыкканда, минем арттан корсагын киереп, бик масаеп карап калды".

Никадәрле жанлылык, тапкырлык һәм оста күзәтүчәнлек бар бу юлларда! Баскычта корсагын киереп калган мактанчык кызыл штанлы малай да, өч яфрак өзеп алган, беренче тапкыр чын күнелдән, олыларча борчылып куйган Инсаф та, урынлы куелган "кәҗә тоягы" да безнең хәтергә жанлы сурәт булып сенеп калалар.

Бу повестьта Газиз Мөхәммәтшин балаларның байтак кызыклы образларын ижат итте. Малай гына булса да житди була белгән ярдәмче Минһаж... Ата ялганчы, үзе дә үтә кешелекле, тапкыр һәм йомры телле Гәрәй, акыллы кыз Суфия... Андый-мондый этлек эшләгәннән соң һәрчак ялган ант биреп котылырга маташучы керле күнелле Әхмәди... Бу образларны автор якты күнел, жылы, саф хисләр белән, яратып ижат итте. Шушы малайлар төрлелеге аша без заман белән танышабыз, аларның язмышы безнең күнелләрне уята, алга әйди, тәрбияли: "Тундра черкие, тәмле тамак, шәһәр чыпчыгы". Инсаф тора-бара гаделлекнең, дуслыкның ни икәнен аңлап кына калмый, дуслык, гаделлек өчен көрәшчеләр сафына баса. Авторга балалар арасындагы шушы катлаулы мөнәсәбәтләрне күзәтү гаять кызык, ул бер генә мизгелгә дә сюжет жебен кулыннан ычкындырмый, салмак кына көйгә, ипкә китерә...

Тапкыр, мәгънәле һәм әйбәт повесть! Гәрәйне генә карагыз! Сокландыргыч характер бар малайда! Ялганчы, егылып китәрсен!.. Бакчадан "бозау хәтле" кыяр урлап чыктым, ди ул... Мин урлаган кыярларны бергә жыйсан, безнең мәктәпне түбәсеннән күмеп булыр иде, дип жибәрә... Алар белән бөтен СССРны бесплатно туйдырып булыр иде, дип күкрәк кагып мактана... Хәтердә уелып кала торган тапкырлык!..

"Саумысыз аккошлар!" повесте берникадәр житдирәк тонда ижат ителгән һәм ул да заманыбызның иң мөһим, иң кискен мәсьәләләренең берсенә—табигатьне саклау, аның байлыгын арттыруга—багышланган. Кайчандыр, әле без бәләкәй чакларда гына, безгә Жир шары иксез-чиксез зур, аның байлыклары бетмәс-төкәнмәс булып тоела иде. Урманнар үз жайлары белән үсеп утыралар, чишмәләр ага, күлләргә саф көмеш сулар өстәлә тора. Умыр да ал, чумыр да эч иде кебек... Хәзер исә без үзебезнең зәңгәр планетабызның, кадерле бишегебезнең нәп-нәни шар икәнен ачык беләбез, аның һәр кисәкчәсе исәптә, байлык-муллыгы чикләнгән икән. Беләбез, ләкин белү генә аз, табигатькә кадерле дустына караган кебек карарга өйрәнергә кирәк, урман-суларны саклау, жәнлек-жанварларның яшәешен озайту, жирнең һәр бизәген исәпкә-санга алу өчен жирдә яна кеше тәрбияләргә кирәк. Нәкъ менә Яна Кеше. Бу бер көнлек, шау-шулы кампанейский бурыч түгел, бу безнең һәр көнлек яшәү формабыз, чөнки киләчәк кешесе бүгенгегә караганда да акыллы, сак, чамалый белүче булырга, табигать байлыкларын арттыру, күбәйтү чараларын эзләп табарга мәжбүр булачак. "Кешеләр жирдә төтенне бетермәсәләр, төтен аларны бетерәчәк"—диде галимнәрдән берсе. Хак сүзләр! Шушы олы, изге бурычны үтәүдә Газиз Мөхәммәтшинның повесте да мәгълүм бер дәрәҗәдә унай роль уйный. Дөрес, бу повесть үзенең эчтәлеге белән табигатьне саклауга гына кайтып калмый. Без монда үсмер малайлар белән янәшә олыларның да төрле образларын очратабыз, автор аларга да зур гына фикри бурычлар йөкли. Әсәр кискен вакыйгадан башлана: яна салынып ята торган электр станциясенең плотинасы күтәрелеп килә, Кояшлы авылы урман-күлләре, елгалары белән су астында калачак. Бу очракта кешеләр нишләргә тиеш! Бериш кешеләр моменттан файдаланып калырга, баерга омтылалар, гөрләп утырган каен урманнарын кисеп-егып запас әзерлиләр. Икенче берәүләр шушы матурлыкны, байлыкны (матурлык үзе дә зур байлык бит ул!) мөмкин булган хәтле саклап алып калырга тырышалар. Автор туган як табигатенең һәр карышына гашыйкларча күзе белән карый белә, аның монсу су-тугайларын, урман-болыннарын йөрәккә үтеп керерлек итеп, хәтердә мәңге сакла-

нырлык буяулар белән тасвирлый, табигатьне саклау олыларның да, кечеләрнең дә намус эше булып китә.

Вәкил белән Флүн исемле ике малай, ике дус, Кояшлы авылының яшь гражданнары, күп тармаклы, мажаралы тормыш белән яшиләр, алар күз алдында вакыйгалар алмашынып, үзгәреп тора, әмма малайларның дөньяларын онытырга хаклары юк, алар шушы калейдоскопик үзгәрешләр чорында да үз урыннарын табалар, шул урын өчен актив көрәшәләр. Хәйләкәр, төче ялганчы, ата карак Олыбай абый белән аралашу малайлар өчен зур бер сабак булса, үзенең сөйгән ярын сугыш кырында югалтканнан соң да мәхәббәттә тугрылык саклаган, беренче карашка сәер тормыш сөрүче Мөфәздал белән булып узган вакыйгалар алар өчен зур гыйбрәт. Малайлар Мөфәздалны тиз генә аңлап бетерә алмыйлар, аннан шикләнәләр. Мәхәббәттә шундый тирәнлек саклый белгән ир-егетнең сәер тормышы укучы күңелен кытыклый, кан тизрәк йөри башлый, яшәү зур мәгънә ала. Автор үзе сөйләгән вакыйгаларга укучыны бер чакта да битараф калдырмый. Повесть шактый гомерне эченә алса да, вакыйгалар бер-берсенә кушылып баралар, тормыш малайларны үзгәртә, чыныктыра. Без Флүн белән Вәкилнең чын кешеләр, актив көрәшчеләр булып үсүенә бер дә шикләнмибез. Яшь чагында дәртле булган йөрәк, чыныккан йөрәк, олыгайгач та нык, көчле була бит! Автор "Карт имәнне кискәннәр!" дип бәгырьне кисә торган үтә хәвефле сүзләр белән башлаган повестен тирән мәгънәле, якты өметле, күтәренке рухлы: "Әни... Аккошлар килгән!.. Ике пар!.. Олы күлгә кабат аккошлар кайткан, әни!"—дип тәмамлый...

Әйе, бу—авторның иң изге теләге. Карт имәннәр киселгән якларның күлләренә дә аккошлар кайтсын иде! Дөрес, бар урыннарда да җирнең тотанагы, тарих хәтере булган карт имәннәр киселми, мәгәр киселгән урманнар да бик күп!.. Дөрес, бар күлләргә дә пар аккошлар әйләнеп кайтмый. Әмма без барыбыз да бик нык теләсәк, теләгебезне эшебез, яшәешебез белән дә ныгытсак, безнең күлләргә аккошлар кайтыр. Тик моның өчен барыбыз да көрәшчеләр булырга тиеш. Әгәр бик нык теләсәк, без җир матурлыгын саклап кала алачакбыз!.. Без, космик хыяллар, олы планнар белән янсак та, шушы җирдә яшибез. Җир—безнеке ул. Барыннан да бигрәк—киләчәкнеке. Бүген малай гына булган Инсафлар, Вәкилләр, Флүннәр үсеп җитәр, алар баш очында да карт имәннәр шауларлык булсын өчен, аңа бик күп нәрсәләр кирәк шул!..

Роман, повестьлар, пьесалар иҗат итү белән бергә бик тиз арада хикәя остасы булып танылган Газиз Мөхәммәтшинның бу жанрдагы эшчәнлеге махсус өйрәнү, тикшерү сорый. Аның хикәяләренең кабатланмас төсмере, үзенә генә хас ароматы бар. Газиз Мөхәммәтшинның хикәя остасы булуын раслау өчен мин санап үткән берничә әсәрен укып карау да җитә. "Бал чүлмәге" хикәсенә генә игътибар итик. Формасы белән дә, бал чүлмәгенең чормада саклануы белән дә ул татар халык әкиятләрен бераз хәтерләтә. Оста корылган сюжет, тапкыр тел, ниһаять, көтелмәгән чишелеш: өч туган өчесе дә берәм-берәм чормадагы балга "һөҗүм" ясыйлар һәм чүлмәкнең төбен дә ялтыратып куялар. Җавап бирү минуты җиткәч, гаепне үз өстенә алырга җыенып йөргән Нәсим, энесе Ирек белән сеңлесе Гөлсәрия тангач, дәшми кала. Намус, әхлак мәсьәләсен автор шушы хикәясе белән оста чишә. "Автобустагы исем" дә, "Ун бәбкә" дә хикәяләр, сүз дә юк, мәгәр алар арасында "Без ничек ураза тоттык" хикәясе күзгә бәрелеп, аерылып тора. Малайларның ак мунча ләүкәсенә сузылып ятып ураза тотарга карар бирүләреннән башланып киткән кызык бер генә минутка да тукталмый. Нинди шәп итеп яза Газиз Мөхәммәтшин аларның вәгъдәләшүләрен! Нинди куе, ачык буяулар таба!

"Ләүкәдән төшкән чакта Мөбәрәкҗан:

—Чыннан да әфлисунмы соң ул, Нурлыгаян малай?—дип, тагын сорады.

Мин аның күзләренә чекрәеп карадым да, дөп итеп күкрәгемә суктым.

—Әфлисун! Билләһи газыйм, әфлисун! Тырнак очы хәтле алдасам да, шушы урында җир йотсын. Кичә ашап җибәрде, ма-ла-ай! Кетер-кетер, кетер-кетер! У-ух! Сәхәргә генә тота!

Мөбәрәкҗан иреннәрен ялап алды.

—Син онытма инде, Нурлыгаян малай. Ике ярка...

—Минем хәтер шәп, онытмам,—дидем мин, горуланып.—Таң тишегеннән торып ураза тотыйм да ди, җан дустым өчен ике ярка әфлисун эләктермим ди. Син үзең дә җебеп торма. Әбиеннең хәлвәсен әйтәм. Мина дигән кисәгең кашык чаклы... Һм... агач кашык чаклы булсын!.."

Бу өзектә һәммәсе камил, төгәл, һәммәсе үз урынында...

Сез Газиз Мөхәммәтшиннын әсәрләрен укып, бик яшьли тормыштан киткән каләм иясенен талантына сокланырсыз. Сезне мавыктыргыч яна дөнья, яна дуслар көтә. Сезнен белән кин күнелле, якты күзле һәм рәхәтләнеп көлә белә торган зирәк Газиз Мөхәммәтшин сөйләшәчәк. Яна дуслар дидем, Газиз мәрхүм кешеләрне дуслаштыра белә иде..."

Бусы Аяз Гыйләжевнен Газиз Мөхәммәтшинга карата 1977 елда биргән бәясе булды. Хәзер анын тормыш юлын күздән кичерик.

Газиз Мөхәммәтшин 1932 елнын 23 декабрендә Татарстан АССРнын Минзәлә районы Яна Бикчәнтәй авылында колхозчы гаиләсендә туа. Гадәти авыл мәктәбендәге укуын тәмамлагач, Минзәләдәге педучилищеда белем ала. Минем ишетеп һәм тоеп белүемчә, Татарстандагы педучилищелар чын мәгънәсендә шәп педагоглар әзерлиләр. Үзем мәктәпләрдә укытканда училище бетергәннәрнен балалар белән эш итүдәге осталыкларына көнләшеп сокланганымны хәтерлим. Газизгә дә бала жанына, бәгыренә үтеп керә алу осталыгы бәлки шул уку йортында салынгандыр. Аннан сон ул Казан дәүләт педагогия институтынын татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. Элек югары уку йортларын тәмамлагач дәүләт биргән юлламалар буенча ике ел срок белән чигенмәслек итеп эшкә жибәрәләр иде. Газиз дә гаиләсен алып ике елга (1956—1958) Түбән өлкәсендәге авылга укытучы булып китә. Билгеләнгән вакыт үтү белән Газизләр гаиләсе Казанга кайту ягын карыйлар, билгеле. Һәм дөрес эшлиләр. Газизнен жете зиһене, акыллы күзәтүчәнлеге кәгазь битләренә төшеп, укучыны сөендерерлек әсәрләр тудыра башлый. Шундый житезлек белән әсәрләр ижат итәргә сәләтле кешенен оештыру эшләрендә дә маһир булачагын чамалап, аны башта балалар өчен чыга торган "Ялкын" журналына, аннан сон "Совет әдәбияты" журналына баш мөхәррир итеп билгелиләр. Бу эшләрдән, билгеле булганча, үз теләкләре белән китүчеләргә караганда, теләген белдергәнче үк вазифасыннан бушатулар да була тора... Аны бу эшендә озак тотмыйлар тотуын! Газизне 1965 елнын маенда, "Совет әдәбияты", "Казан утлары" журналына әверелгән чорда, житәкчелектән читләштерәләр. Үзем хәзер фаразлавымча, күбрәк "кара тамгалы" әсәрләр бастыргандыр, дим. Мәсәлән, Аязнын "Өч аршын жир" повесте дә Газиз Мөхәммәтшин мөхәррир булганда "Совет әдәбияты" журналында 1963 елнын май-июнь айларында басылып чыкты. Әдәбият сөючеләр белгәненчә, бу әсәр шул журналда басылганнан сон унсигез ел дәвамында матбугатта чыгарылудан тыелып килендә. Бары тик Мәскәүдә телгә алына башлагач кына казанлылар "йомшарды".

Газиз Мөхәммәтшин баш мөхәррирлектән киткәч бер-бер артлы талантлы әсәрләр язды. Анын әсәрләрендә ин житди фикерләр дә, уен-көлкегә төрелеп, мавыктыргыч деталь-күренешләр, тормыш ситуацияләре аша бирелә.

Аяз белән Газиз ике профессионал язучы буларак еш кына сөйләшеп йөриләр иде. Шундый прогулкаларыннан кайткач Аязнын мина әйткән бер фикере хәтеремә сенеп калды: "Газизнен дә Шушенскоега баргач, күнеле иләс-миләсләнеп кайткан әле, Ленин юлынын тугры булуына шик уянган",—диде. Хәзер кайтып-кайтып шул фикере тирәсендә уйланам. Газизнен "Казан утлары" журналынын 1969 ел 10 санында "Шушенскоеда яз" дип аталган мәкаләсе кулымда. (Бу елларда журналнын баш мөхәррире Зәки Нури булган). Газиз—1960 елдан КПСС әгъзасы, инде "авызы пешкән", партия әгъзасы булган кешегә Ленин темасына карата шикле сөйләшү—куркыныч нәрсә. Ана ул вакытта шик-шөбһәләргә урын калдырырлык мәкалә язарга ярамагандыр, ә Аязга эчендәгесен әйтеп салган.

Әйе, ул чагында талант иясе жәмгыятькә яраклашып кына яза алды шул. Без бүген исә Газизнен әсәрләрен укып, ана рәхмәт әйтәбез, дога кылабыз. Анын максаты милләт балаларын тәрбияле итеп күрү булган. Бары тик тәрбиялелек, иманлылык белән генә жәмгыятебезнен таза, саф юлга басуына ирешә алачакбыз!

**Нәкыя ГЫЙЛӘЖЕВА**

**Адлер Тимергалин**

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***КЕРӘШЕННӘР*** *– ...*

Яңа керәшен конторасының Синодка биргән мәгълүматларына караганда, 1740 елдан алып 1749 елның беренче яртысын да керткән вакыт эчендә Казан, Нижгар, Воронеж һәм Оренбург губерналарында 295 857 кеше христиан диненә дүндерелгән, шул исәптән 1740-1743 елларда – 31 069 кеше, 1744 елда – 4 895, 1745 елда – 10 993, 1746 елда – 73 995,1747 елда – 113 392, 1748 елда – 38 140, 1749 елның беренче яртысында 23 413 кеше чукындырылган.

767 елда Зөя өязе ясаклы татарлары чукындыру сәясәтеннән күргән зыяннары турында дәүләт комитетына үтенеч белән мөрәҗәгать иткәннәр. Үтенечтә мондый юллар бар: "Безнең байтак кына татар карендәшләребез грек динен кабул иттеләр, әмма үзләре татарлар белән бергә, кайчагында бер үк йортта һәм бер гаиләдә яшиләр, шуның аркасында безгә дә, урыс динендәгеләргә дә гөнаһ; өстәвенә яңа керәшен татарларның кайсыберләре безгә зур зыян салалар. Берәр җирдә кардәшләребез ялгыз гына яисә икәү генә очрап, алар күбрәк булса, һичбер сәбәпсез кыйныйлар һәм тик торганда газаплыйлар, кайберләре әле акчабызны талап, киемнәребезне салдырып алалар. Ә андый керәшеннәр азрак булсалар, кайберәүләре безнең яклардан Уфа яки Оренбур өязләренә бакыр һәм чуен заводларына китеп, шунда бишәр ел һәм артыграк та яшиләр. Үзләре өйдә булмагач, җан башыннан түләнә торган һәм башка дәүләт салымнарын алар теркәлгән җирдә барлык авыл халкына йөклиләр. Башкалары исә, заводта булган килеш, түли алмаслык бурычка баталар, анысын да авыл халкы түләргә мәҗбүр була. Шул сәбәпле без яңа керәшеннәр аркасында тәмам бөлгенлеккә төшәбез. Шуңа күрә яңа керәшеннәр азчылык булган җирләрдә киләчәктә аларны руслар һәм яңа керәшеннәр яши торган урыннарга күчерү турында фәрман булса иде. Ә татарлар ярты халыктан да кимрәк калганнар икән, аларны да татарлар яшәгән җиргә күчерергә. Шулай, шушы ике закон буенча бик әйбәт тәртип һәм күзәтчелек урнашыр, халык бер-берсеннән канәгатьсезлек тоймас иде."

Бу үтенечтә рус "писере" кулы сизелүгә дә карамастан, урындагы хәлләрне ул бик ачык итеп күз алдына китереп бастыра.

Татар шагыйре Хәсән Туфан үзенең автобиографиясендә чыгышы белән качкын крәстиәннәрдән булуы, бабаларының моннан берничә гасыр элек чукындырылуы, ләкин авылларында яшерен төстә шәригать кануннарын үтәп яшәгәнлекләре турында сөйли (XX гасыр башлары). Алар чиркәүдә чукынмаганнар, шуңа күрә "законсыз туган" санында йөргәннәр, элементар хокуклардан да мәхрүм ителгәннәр. "Зинадан туган" дип исәпләнгәнлектән, аларга рәсми фамилияне дә әниләренең исеме буенча бирә торган булганнар. Туфан, мәсәлән, 1905 елгы инкыйлабка кадәр әнисе исеме буенча сәер "Гульзизин" фамилиясен йөрткән.

1905 елгы революция татарларга зур йогынты ясый. Уфа, Сембер, Пенза, Казан губерналарында гына да 49 мең кеше, христианлыкларын ташлап, кабат Ислам диненә кайталар.

Казан губерна статистика комитеты 1916 елда бастырып чыгарган белешмәдә күрсәтелгәнчә, 1914 елда Казан губернасында 45 529 керәшен исәпләнгән, ә христианлыктан кире мөселманлыкка кайткан татарлар саны 5 105 булган. 1913 елда Русиянең 12 губернасында һәм 60 өязендә 537 керәшен руханиы исәпләнгән, шуларның

* Әлеге мәкаләнең («Керәшеннәр») беренче өлеше 2005 елның 3 нче саныннан башлана.

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2004 елның 1нче санында.*

297 се поп, 90 ы дьяк һәм 150 се псалом укучылар булган.

XVIII гасырга кадәр чукындырылганнарны *иске керәшеннәр* дип, аннан соң ("Новокрещенская контора" ачылгач) чукындырылганнарны *яңа керәшеннәр* дип атаганнар. Хәер, мондый бүленешнең сәбәбе экономикага бәйле. Керәшеннәргә бирелгән җиңеллекләрне һәм өстенлекләрне вакыт ягыннан чикләргә туры килгән. Вакыт-вакыт яңа керәшеннәрне иске керәшеннәр исемлегенә кертеп, аларны элек бирелгән җиңеллекләрдән мәхрүм иткәннәр.

Иске керәшеннәр төрки телне саклап килсәләр дә, мөселманнардан ераклашканнар, ә әһле ислам каршында *мәкруһлар (мөкрә, мөкрән)* исеме белән йөртелгән яңа керәшеннәр үзләрен чын мөселман санаганнар. Аларга карата рус хөкүмәте каты чаралар күрә, хәтта императорның 1855 ел 29 май указы нигезендә, әгәр яңа керәшеннәр чиркәүгә йөрмәсәләр, аларның әүвәлге никахы юкка чыгарылып, ирле-хатынлы булып яшәүләре дә тыелырга мөмкин дип табыла.

Электә көчләп чукындырылган һәм чиркәүдә теркәлгән, ләкин христианлыкка ияләшә алмыйча кире үз диннәренә кайткан татарларны *солылы борайлар* дип йөрткәннәр. Вафат булгач аларны күмәргә муллага да, попка да рөхсәт ителмәгән.

Билгеле булганча, Мамадыш өязендә керәшен ирләрнең чукынмаган хатыннары белән никахларын гамәлдән чыгару турындагы патша фәрманын җиренә җиткерә башлагач, керәшеннәр арасында чак кына фетнә күтәрелмичә калган.

1835 елда яңа керәшеннәрне, привилегияләреннән мәхрүм итеп, дәүләт крәстиәннәре белән тигезләштергәч, православиедән кире Исламга кайту өчен тагы бер сәбәп була. Мәс., 1836 елда Урта һәм Югары Әлки татарлары, башка авылларга ияреп, үзләрен кабат мөселман дип игълан итәләр, ә бу ике авылда 1720 кеше исәпләнгән.

XIX гасырның икенче яртысында христианлаштыру һәм руслаштыру сәясәтен ныклы фәнни нигезгә куеп тормышка ашырырга омтылучылардан миссионер Николай Ильминскийны күрсәтергә мөмкин. Ул христиан руханиларын, миссионерларны һәм укытучыларны башка халыкларның үз вәкилләреннән тәрбияләп үстерү идеясен күтәреп чыга. Шушы максат белән Н.Ильминский рус хәрефләреннән керәшен алфавиты төзи һәм 1867 елда ул оештырган "Изге Гурий борадәрлеге" Казанда татарча христиан дине буенча китаплар бастырып чыгара башлый, кайбер керәшен авылларында дөньяви мәктәпләр дә ачыла. Казанда керәшен татарлар өчен укытучылар хәзерләүче мәктәп 1863 елда Ильминский инициативасы белән ачыла. Бу мәктәп В.Г.Тимофеев дигән кешенең квартирасында аның хисабына ачылып, беренче уку елында анда нибары өч бала укый. Ильминский Мамадыш өязе Никифоровка авылында көтүчелек белән көн күргән Тимофеевны Казанга алып килеп, башта монастырьга су ташучы итеп урнаштырган, аннары ул Казан руханият академиясендә татар теле буенча практикант булып исәпләнгән. Икенче уку елында инде мәктәптә укучы балалар саны 20 гә җиткән.

Шулай да бу мәсьәләдә миссионерлар арасында бердәмлек булмаган. 1883 елда Изге Синод христианлыкка күчкән башка милләт вәкилләренә үз телләрендә гыйбадәт кылырга рөхсәт иткән указ чыгаруга карамастан, Казан архиепискобы Палладий: "...Яковлев *(чуаш мәгърифәтчесе-А.Т.)* чуашлаштырырга тели, ә бит чуашларны руслаштырырга кирәк. Хәзергесе көндә бездә, Русь илендә, алла белсен, ниләр генә кылынмый. Грузиннар, осетиннар, татарлар һәммәсе укырга тырышыпмы-тырмаша, һәм һәркайсы үзенчә укымакчы. Русча укырга кирәк! Синод чит милләтләргә гыйбадәт кылырга рөхсәтне алар моны үзләренчә кылсын дип түгел, бәлки аларны тизрәк руслаштыру һәм шул хәлдә калдыру өчен бирде", – дип белдерә.

Чиркәүдә беренче тапкыр татар телендә православие гыйбадәтләре 1867 елда укылган *(Казандагы Гурий чиркәвендә. В.Т.Тимофеев тарафыннан).*

Ильминский хакында сүз чыккач, аңа карата да бер-ике сүз әйтеп китик. Керәшен авторларының мәкаләләреннән аңлашылганча, хәзерге вакытта һәр керәшен өендә Николай Ильминскийның фотосурәте тора икән. Әлеге авторлар Ильминскийны тәмам изгеләштереп, "керәшеннәрнең апостолы" дәрәҗәсенә күтәрәләр. Әлбәттә, керәшен халкын русча грамотага өйрәткән, аларга начармы-яхшымы әлифба төзеп биргән кеше хөрмәткә лаек инде. Әмма безгә Николай Ильминскийның яшьлегендә бер татар авылыннан икенчесенә шымчы сыйфатында йөреп, яшерен мәгълүмат туплавы һәм язма хисабын архиепископка тапшыруы да билгеле. Ихтимал, киләчәктә аның полиция

өчен "кыйммәтле мәгълүматлар" *(бу сүзләрне Ильминскийның биографы П.Знаменский куллана, без уйлап чыгармаган)* да булган көндәлеге патша эчке эшләр министрлыгы архивыннан табылыр әле. Казан руханият академиясе профессорлары Н.И.Ильминский белән "Коръән" тәрҗемәчесе, күндәм Г.С.Саблуков та кул куйган "Чукынган татарларның православиедән кире чигенүләре һәм татарларны ыграк руслаштыру чаралары турында Академия идарәсенә хисап"та Николай Ильминскийның миссионерлык юлындагы "тырышлыклары" турында сөйли. Бу хисапны чирканмыйча уку мөмкин түгел. Янә китереп, Ильминскийның Казанга авылдан килеп укытучылар семинариясендә укучы вак милләт вәкилләрен чабаталарын ташламаска, авылларына кайткач та халыкны шул ук чабата киюләрен дәвам итәргә өндәргә тиеш дип өйрәтүе үзе генә дә ни тора! Ә Ильминскийның И.Н.Ульянов гаиләсе белән даими элемтә тотуы ким дигәндә шик уята.

Тора-бара әлеге керәшен мәктәпләренең халык арасында дәрәҗәсе тәмам төшә. Мәс., "Изге Гурий бурадәрлеге"нең 1905-1906 еллардагы эшчәнлегенә күзәтү"дә Казан губернасы Чистай өязе Чуаш Елтаны авылы крәстиәннәренең, үзләрендәге миссионер мәктәбеннән риза булмыйча, авылларында земский мәктәп ачарга теләүләре хәбәр ителә. Һәм алар чыннан да үз максатларына ирешкәннәр.

1870 елда Россиянең мәгариф министры граф Д.Толстой: "Ватаныбыз чикләрендә яши торган барлык чит халыкларны агартуның ахыргы максаты, әлбәттә, аларны руслаштыру һәм рус халкына кушу,"—дип язган. Шул рәвешле, руслаштыру сәясәте ахыргы максат итеп куела һәм бу сәясәт СССР да, ягъни совет хакимияте елларында, аеруча тырышлык белән тормышка ашырыла. Мәхмүт Әхмәтҗанов үзенең бер мәкаләсендә "50 ел эчендә СССР да яшәгән 194 милләттән 93 е юкка чыкты,"—дип яза.

XIX гасыр уртасында Тубыл шәһәрендә Библия җәмгыятенең бүлекчәсе булган. Ул Көнбатыш Себер татарлары һәм казакълар арасында Инҗил иманы тарату белән шөгыльләнгән. 1900—1910 елларда Тубыл татарларын христианлыкка дүндерү эшендә миссионер Ефрем Елисеев активлык күрсәтә. Ахуннар һәм муллалар урыс миссионерлары пропагандасына каршы көрәш алып барганнар. Мәс., Мәҗит мулла христиан догматларына каршы Коръән әсасларын куеп, "Рәддия назар" *("Кире кагучы фикер")* дигән бәет тә чыгарган.

Объектив мәгълүматларга караганда, керәшеннәр үзләренең ирексезләп чукындырылган булуларын бик озак онытмаганнар. Мәс., егерменче гасыр урталарында Башкортстанда Илеш районы Нәзер авылы керәшеннәреннән мондый сүзләр язып алынган: "Безнең бабайлар кысарныкта *(кысынкылыкта)* яшәгәннәр, көчәндектә *(көчләү вакытында)* чукынып калганнар".

XX гасыр башына Рәсәйдә барлыгы 122 301 керәшен татар исәпләнгән, шуларның 42 670 е Казан губернасында яшәгән. М.Глухов үзенең "Судьба гвардейцев Сююмбеки" исемле китабында 1920 елда Совет Россиясендә керәшеннәр саны 350 мең булган дип күрсәтсә дә, 1926 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча Татарстанның хәзерге территориясендә керәшеннәр саны 99 041 булып, алар республикадагы татарларның 6,6 % ын тәшкил иткәннәр һәм бу сан, безнең карашка, ышанычлырак. Шуннан соңгы халык санын алу документларында керәшеннәр аерып күрсәтелмәгән. Кайбер тикшеренүчеләр керәшеннәр санын күрсәткәндә нииндидер "мифик" *керәшен тамырлы* кешеләрне исәпкә алып, әлеге санны 500 меңгә җиткерәләр *(мәс., А.Журавский)*. Мондый хыялый юл белән барсак, татар тамырлы кешеләр санын 50-60 миллионга да җиткереп була лабаса!

Гомумән, XIX гасыр ахырында Казан губернасында 85 ләп керәшен авылы булган, Татарстан АССР төзелгәч боларга тагын шул чама авыл өстәлгән.

Интернетта теркәлгән мәкаләсендә В.Постнова: "Татарларда һәр мең ярым кешегә бер мәчет туры килә. Керәшеннәрдә Казанда бер чиркәү һәм авылларда өч чиркәү, ә керәшен авыллары барысы 198. Ә республиканың эре сәнәгать үзәкләрендә керәшеннәр азмыни? Менә гыйбадәткә йөреп карагыз инде—һәр илле мең кешегә нибары бер чиркәү. Гәрчә хакимият һәрдаим "күп милләтле Татарстан халкы исеменнән" сөйләнсә дә, хөкүмәттә керәшеннәр юк. Халык депутатлары арасында да гел туфаннар гына (*Сүз Туфан Миңнуллин турында бара, әлеге мәкаләдә "туфан" дип, юл хәрефеннән язылган—А.Т.)*" Әйе, халык депутаты Туфан Миңнуллин массакүләм мәгълүмат чараларына "30-40 елдан керәшен калмаячак" дигән фикерне мондый формада әйтергә

тиеш түгел иде, әмма бу әле Вера Постновага мөхтәрәм драматургны үзенчә түбәнсетергә сәбәп була алмый. Туфан исемен "бәләкәй" хәреф белән язып кына аны кечерәйтү мөмкин түгел! Ә инде "керәшен инкыйразы"на килсәк, бүгенге шартларда татар милләтеннән аерылмыш хәлдә яшәсә, керәшен халкының гомере чыннан да озын булмаячак...

Татарстан республикасында керәшеннәрнең чиркәүләре бармак белән санарлык кына икән. Миңа, мәсәлән, Удмуртиядә яки Чиләбе өлкәсендә ничә керәшен чиркәве барлыгы мәгълүм түгел. Чамалап кына әйтүем, әмма бик күп булмаса кирәк. Татарстан авылларындагы мәчетләргә килгәндә исә, тәзелешкә тотылган чыгымнарны исәпкә алсак, бер таш чиркәүгә киткән чыгымнар 10 мәчет төзүгә һәм җиһазлауга җитәрлек бит. Гомумән, мәчетләрне артык нәкышьләмичә генә салу, җиһазлардагы, хәтта дин әһелләренең киемендәге тыйнаклык, гадилек Мөхәммәд Пәйгамбәр заманыннан ук килә. Хәер, католиклар да кием мәсьәләсендә хәдтин ашмыйлар. Зиннәттә чамасызлык Византия чиркәвеннән килә дип уйлыйм. Мөселманнар дини йолаларны һәм мәрәсимнәрне үтәгәндә тышкы формадан бигрәк мәгънәгә, эчтәлеккә ныграк игътибар итәләр (итәргә тиешләр). Аннары әлеге 198 керәшен авылында күпме халык яши дигән сорау да бик мөһим. Авыл халкы саны чиркәү төзүне күтәрә алырлыкмы? Инициативалы кешеләре бармы? Әгәр инде Казандагы Тихвинский чиркәүгә дә ике йөзләп кенә кеше йөри икән, чиркәү бинасының нилектән ифрат күрексез һәм зәвыксыз итеп торгызылуы безгә бик аңлашыла.

Шиһабетдин Мәрҗани керәшеннәр турында түбәндәгеләрне яза: "Инде, электә мөселман булып та, кайбер сәбәпләр белән исемдә генә христианлыкка кергән мәкруһлар һәм "керәшен" дип йөртелә торган татарлар хәленә килик. Бу таифәнең теле һәм ирләренең киемнәре мөселманнарныкы кебек булып, хатыннарының киемнәре икенче төрле булуның сәбәбе нәрсәдә икән? Әллә мөселман хатын-кызларының киемнәре дә электә шундый булып, әкренлек белән генә үзгәрү кичереп, керәшен хатын-кызларының киемнәре үзгәрмичә искечә калдымы икән, әллә бу халык асылда төрек булмыйча, фин халкыннан идеме икән?

Казан халкында финнарга охшашлык булмаса да, Казаннан ераграк урыннарда аларның йолалары, гореф-гадәтләре, киемнәре һәм башка яклары белән охшашлыклар күп табыла. Мәсәлән, илле еллар чамасы элек Сембер тирәсендәге авылларда хатыннар ак киндер күлмәкне тар гына итеп тегеп, җөй буйларына бер илле киңлектә комач тоталар иде. Җиң һәм җилкәләренә кызыл яки яшел ефәк тегә торганнар иде. Ике-өч бармак киңлегендәге ике кат киндер яки асыл чүпрәк өстенә көмеш акча тезеп, хәмаил итеп киеп, исемен "муен тамыр"дан үзгәртеп, "путемар" дип атаганнар. Аларның өйләренең эчке ягы чуаш өйләре кебек кап-кара, чөнки төтеннәре өй эченә чыга торган булган... Хәмаилне алар башка халыклардан алганнар, чөнки ул гарәп халкында да, Казан халкында да булган. Казан хатын-кызлары аны, исемен үзгәртеп, "әмайли" дип, кайберләре "бөти" дип атаганнар. Ләкин алар алтын тәңкәләр яки кыйммәтле ташлар, һич югында яхшы көмеш әйберләр һәм тәңкәләр белән бизәлгән булган."

Шулай итеп, без керәшеннәр төрле вакытларда, төрле төбәкләрдә һәм төрле иҗтимагый-сәяси һәм икътисади шартларда формалашканнар дип әйтә алабыз. Шуңа күрә дә аларга аерым үзенчәлекләр хас. Керәшен татарларының түбәндәге төркемнәре аерып карала: казан арты керәшеннәре, түбән кама буе керәшеннәре, чистай керәшеннәре, мәлки (подберезье) керәшеннәре, һәм татарларның төп массасыннан иң еракта формалашкан керәшеннәр төркеме — *нагайбәкләр*.

Этнокультура ягыннан керәшеннәрдә чуарлык күзгә ташлана, шуңа күрә алар арасында башта төркиләшкән һәм, Казан яулап алынгач, беренче чиратта чукындырылган күрше халыклар да бар дип исәпләнелә.

Мишәр керәшеннәре, информаторлар биргән мәгълүматларга караганда, мәсәлән, Тау Иле, Бахта, Керәшен Елтаны авылларында яши. Әдәбиятта Чистай ягы керәшен авылларының кайберләре чуаш чыгышлы булуы турында хәбәрләр бар. 1870 елда Казан губернасының Чуел өязендә йөреп кайткан Н.И.Золотницкий Мәлки, Большое Тябердино, Янгозино һ.б. авыл кешеләре мишәр түгел, бәлки "татардан чукынган чуашлар" дигән нәтиҗәгә килә. Татарча сөйләшсәләр дә, алар чуашлар кебек киенәләр һәм чуашларга хас барлык мәҗүси йолаларны үтиләр, дип яза ул. Аннары Золотницкий

Тәтеш өязендә дә "татардан чукынган чуаш"лар яши торган тагы биш авыл тапканлыгын хәбәр итә. Казан татарларының килеп чыгышын һәм көнкүрешен камил өйрәнгән Н.И.Воробьев ТАССР ның Кайбыч районы Иске Тябердино авылында яшәүче мәҗүси чуашларның үзләрен "чукынмаган керәшеннәр" дип атаулары турында яза. Бу оригиналь атама аларның үзләрен татар дип санаулары, ләкин керәшенгә тәңгәлләштерүләре турында сөйли.

Мәлки һәм Чистай керәшеннәре мишәрләргә якын. Көнбатыш Кама алды керәшеннәре, Алабуга, Минзәлә, Бакалы керәшеннәре һәм нагайбәкләр Казан татарларына якынрак. Чиләбе якларында яшәүче керәшен нагайбәкләрнең фольклорын өйрәнү аларның элек гомумтатар өммәтенә караганлыгы һәм һичшиксез мөселман булганлыгы турында сөйли. Мәс., "Сак белән Сок бәете"ндә пыяла ишекле "мокарлы мәчет" (Бохара мәчете) кебек башка бер җирдә дә очрамаган кызыклы терминга тап булабыз, "кыямәтлек", "талига", "ак калфак, зәңгәр шәл"ләр, "аклы ситсы күлмәк"ләр, "тутый кош" ("тотогыш") кебек уртак сүзләр дә нагайбәкләрнең татар чыгышлы булуын күрсәтә..

Керәшеннәр үлгән кешене искә алып, өч көнен, тугыз көнен, "җегерме көнен", кырык көнен, "бер җылын" билгеләп аш үткәрәләр.

Танылган этнолог С.И.Брук: "Хәзер бу төркемнәрнең кайсылары татар этносының бәхәссез өлеше булуы, ә кайсыларының үз аерымлыкларын саклап килүе турында махсус тикшеренүләр үткәрәсе бар. Һәрхәлдә Себер татарлары дигән төркемнең һәм, ихтимал, нагайбәкләрнең, керәшеннәрнең һәм кайбер башка төркемнәрнең, татарларның бер өлеше булудан бигрәк, мөстәкыйль этнос булып исәпләнергә хокуклары аз түгелдер", — дип саный. Бәлки чыннан да шулайдыр. Тик моны махсус тикшерүләр генә күрсәтәчәк. Аннары күренекле галимнең нагайбәкләр белән керәшеннәрне тәңгәлләштермәвенә игътибар итик. Хәлбуки бүген кайбер керәшен активистлары югарыда телгә алынган барча төркемнәрне, кайсы каумнән чыккан булуларына карамастан, мифик керәшен байрагы астына тупланырга чакырлар.

Элек Казан шәһәрендә керәшеннәрнең үз чиркәүләре (Тихвинский чиркәве) булган, шулай ук Казан губернасында керәшеннәр өчен ике монастырь: 1903 елда Лаеш өязе Малое Некрасово авылында ирләр өчен *Трехсвятский монастырь* (1937 елга кадәр булган, 1937 елда җимертелгән) һәм 1908 елда Казан шәһәрендә Дары заводы (Пороховой) бистәсендә хатын-кызлар өчен *Покровский монастырь* ачылган. 1995 елда Тихвинский мәхәлләсенең православный дини берләшмәсе Уставы рәсми рәвештә теркәлеп, 1996 елдан алып керәшеннәр кабат торгызылган чиркәүдә туган телләрендә гыйбадәт кыла башладылар.

20 нче елларда сирәк кенә булса да татарларның христиан евангелистлары сектасына дуңү очраклары булгалаган, ләкин бу фактлар евангелистлар пропагандасының аеруча мәкерле һәм оста, сыгылмалы булуы белән аңлатыла.

Әлбәттә, татарларның христиан диненә күчү фактлары бүген дә юк түгел. Мәс., 1999 елның мартында "Свобода" радиостанциясе (рус бүлеге) Казан университеты студенткасы татар кызы Лилия Соломонованың Исламнан христианлыкка (протестантлыкка — "пятидесятниклар" мәзһәбенә) күчүе турында хәбәр итте. Үз сүзләренә караганда, ул моны берниндн мәҗбүриятсез, үгет-нәсихәтсез, эчке инануы буенча эшләгән икән.

Ләкин кире процесс — керәшеннәрнең Исламга кайту хәрәкәте көчлерәктер, күрәсең. Әстерхан шәһәреннән Бәдретдин Әмирханов Иванов атлы бер танышының гаиләсе белән Ислам кабул итүе турында сөйләгән:

— Безнең бабайларны Иван Грозный көчләп чукындырган. Алар мөселман дине белән яшәгәннәр. Нигә Ислам дине белән яшәмәскә?! Улларым сөннәтле. Хатын белән икебез дә намаз укыйбыз. Хатынымның мәрхүмә әнисе догаларны өйрәтеп калдырды, урыны оҗмахта булсын, — дигән ул аңа.

1918 елның гыйнвар-август айларында "Керәшен" исемле атналык гәзит чыгарылып килә. 1916 — 1917 елларда Уфада "Дус" исемле ике атналык басма нәшер ителә. 1971 елда Минзәләдә "Хәбәрләр" дигән атналык керәшен гәзите чыга. 1918 елда "Иген игүче" исемле ике атналык басманың 1-4 саннары чыгуы билгеле.

Керәшеннәрнең милли-культура берләшмәләренең регионара союзы президенты Алексей Шабалин Башкортстандагы Бакалы районы керәшеннәренең 1919 елда үз

автономияләрен төзүләре турында яза. Шаһитларның сөйләвенә караганда, бу автономия берничә көн генә яшәп калган, хакимиятләр аны аяусыз бастырганнар, җитәкчеләрен атканнар, документларын юк иткәннәр икән. *("Восточный экспресс" газете, 2002, №8.)*

20 нче елларда керәшеннәрнең мәгълүм бер өлеше үзләренең аерым милләт булулары турындагы идеяне күтәреп чыкканнар иде. Бу фикер тарафдарлары әле дә юк түгел. 2002 елда Россия Федерациясендә халык санын алу буенча хәзерлек документларында керәшеннәрне аерым күрсәтү турындагы пункт татар җәмәгатьчелегендә ризасызлык уятты һәм массакүләм матбугат чараларында "керәшен мәсьәләсе" яңадан күпертелә башлады. Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәймиев: "Ата-бабаларыбызның музыкасын, телен һәм гамәли сәнгатен саклап калганнары өчен без керәшеннәргә кат-кат бурычлыбыз",—дигән иде. Керәшен лидерлары президентның бу сүзләрен тәкърарларга яратуын яраталар, ләкин шул ук вакытта бу сүзләрдә керәшеннәрнең борын-борынгыдан ук татар булганлыклары ассызыклап күрсәтелүен аңламаганга сабышалар. Чыннан да керәшеннәрдә очраган тел архаизмнары, кайбер борынгы йолаларыбыз, гореф-гадәтләр, кием-салым безгә борынгы телебезне, рухи һәм материаль культурабызны ачыграк күзалларга ярдәм итә бит. "Татар теле" һәм "керәшен теле" дип аеру да нигезсез. Керәшеннәр татар телендә сөйләшәләр. Югыйсә, аларның дини һәм гомуми терминологиясенә "пәгамбәр", "пәриштә", "әүлия", "тәмуг", сүрәт (сурәт) кебек шәрык сүзләре каян килеп керер иде? "Псалтирь" китабындагы гарәби "шөкер" сүзе дә, "иман" *(керәшеннәрдә "иртәнге иман"—"утреня")*, "каза" сүзләре дә Ислам дине аркылы, язма китап аша кергәннәр дип шикләнмичә әйтергә була. Керәшен сөйләшләрендәге *ана-кәбә* (Мәрьям-ана) сүзе дә православие терминологиясеннән ерак, бик ерак ич. Нагайбәк хатыны Алексеева Матрена Ивановна авызыннан 1966 елда язып алынган бер җырда "Асыл кошом очоп китте Бокарга" диелә. Ягъни Бохарага була инде, Мәскәүгә-мазарга түгел. Татарга Ислам дине шул Бохара якларыннан килгән бит. Димәк, Матрена Ивановна әле үзенең нәсел-нәсәбен һәм иманын онытып бетермәгән, ул аның аң төпкелендә, генетик тирәнлектә яши һәм җырларында калкып чыга... Ә шул ук "Псалтирь" китабындагы барыбыз өчен дә уртак "ни-нәстәләр" борынгы төрки телебездә үк булганнар... Бу исемлекне тагы да озайтырга мөмкин булыр иде әле. Керәшеннәр өчен чыгарылган "Инҗил" ("Святое Евангелие") һәм "Зәбур" ("Псалтирь") китапларының титул битләренә эре хәрефләр белән "На татарском языке" дип басылган лабаса! Гомумән, бу тәрҗемәләргә таянып, татар теленең үсеш баскычлары турында бик шәп диссертация әзерләргә мөмкин шикелле.

Кыскасы, керәшеннәрнең ана теле—татар теле, Тукайлар теле ул. "Туганлыгын оныткан Иван" булмасак иде! Иде дә бит, ә менә Алексей Шабалин: "Керәшеннәр беркайчан да Ислам динен тотмаганнар. Татарларның бер өлешен Иван Грозный көчләп чукындырган дигән версия рәсми төстә кире кагылырга тиеш, чөнки керәшен культурасында (гореф-гадәтләрендә, традицияләрендә, йолаларында, киемнәрендә һ.б.) исламның әсәре дә юк. Безнең ата-бабаларыбыз мәҗүси булганнар—факт шундый. Нардуган, Симит кебек мәҗүси бәйрәмнәрне керәшен авылларында хәзергә кадәр бәйрәм итәләр. Хәтта икона да керәшенчә "тәре" дип әйтелә *(күрәсең, Кояш алласы мәгънәсендәге "тәңре" сүзеннән булыр)*. Ихтимал, безнең ата-бабаларыбызның культурасы бер булгандыр, әмма Идел буе Болгарстанына Ислам килгәннән һәм аны төрки телле халыкларның күбесе кабул иткәннән соң, ситуация үзгәргән",—дип өйрәтә.

Югарыда без мондый фикерләрнең уйдырма булуын, нигезсезлеген конкрет мисалларда, тарихи документлар белән күрсәттек дип уйлыйм. Ә инде *нардуган* һәм *симек/симет/симик* көннәренә килгәндә, аларны бер керәшеннәрнеке дип тә, мәҗүси бәйрәмнәр дип тә булмый. Аларның беренчесе мөселман татарларда да календарь бәйрәм булып исәпләнә, ә икенчесе православныйларның кануни бәйрәме булган "семик" көнендә уздырыла. "Тәңре" сүзе белән "тәре" сүзенең генетик бәйләнешын да мөселманнар ачты дип беләм.

"Мишәр, керәшен "милләт"ләрен уйлап табу халкыбызга бәла-казалардан башка берни дә бирмәячәк". *(С.Алишев.)*

Тагын кара: ***КАНАШЕВИЧ ЛУКА.***

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Әбрар Сәгыйдинең тууына 110 ел*

# ДАВЫЛЛЫ ДӘВЕР ШАГЫЙРЕ

Шагыйрь һәм мәгърифәтче Әбрар Сәгыйди—егерменче еллар татар җәмәгатьчелегендә шактый ук танылган, мәгълүм исем. Аның иҗат һәм тормыш юлы да гаять гыйбрәтле.

Әбрар Сәгыйди *(Мөхәммәтәбрар Мөхәммәтзакир улы Сәгыйтов)* 1895 елның 14 апрелендә хәзерге Кайбыч районының Кече Кошман авылында туа. Башта атасы Закир хәзрәттә *(анысы—Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте)* белем алгач, аны Казанга—"Мәрҗания" мәдрәсәсенә гыйлем эстәргә җибәрәләр. Яңалыкка, белемгә омтылучы шәкерт ул чакта нәшер ителгән алдынгы карашлы гәзит-журналларны йотлыгып укый, Тукай, Гафури, Сәгыйть Рәмиевләрнең шигырьләре белән даими танышып бара, үзе дә әдәби кичәләр оештырырга керешә. Берүк вакытта егет Казанның Учительская семинариясендә дә белемен арттырырга вакыт таба.

Әбрар Сәгыйдинең тәүге шигыре Фатих Әмирхан мөхәррирлегендәге "Кояш" гәзитенең 1913 елгы апрель санында, Тукай белән хушлашу көннәрендә дөнья күрә. "Ул Г. Тукай шигырьләрен аеруча яратып укый, шуларның байтагын яттан белә иде. Шуна күрәдер, Әбрар абыйның шигырьләрендә Тукай тәэсире, Тукай стиле, аның шигъри иҗат алымнары аермачык сизелеп тора",—дип яза педагог Шәриф Сайкин.



*Әбрар Сәгыйдинең Совет төзелеше институтының эшче яшьләр факультетында укыткан чоры. Уңнан икенче—Ә. Сәгыйди. 30 нчы еллар.*

Шуннан соңгы елларда Әбрар Сәгыйдинең әсәрләре вакытлы татар матбугатында даими басыла башлый. Аның "Кояш", "Тормыш" (Уфа) гәзитләрендә һәм "Шура", "Сөембикә" журналларында дөнья күргән шигырь вә поэмаларында романтик, мифик һәм символик образлар аеруча көчле бирелгән. Дини тойгы да өстенлек итә. Аллаһыны олылау, аның илаһи кодрәтен тану, ана сөену, аның ярдәменә ихлас күңелдән ышану белән бергә милләт язмышы турында уйлану, татарның бәхетле киләчәгенә өметләнү хисләре белән дә сугарылган әсәрләр язган ул.

Октябрь инкыйлабын Ә. Сәгыйди туган авылы Кече Кошманда мөгаллим булып каршылый һәм тиздән Казанга килә, "Эшче", "Татарстан хәбәрләре" гәзитләрендә әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире булып эшли. "Үч", "Илдә", "Аерылу", "Каһарманнар" исемле поэмаларын, күп санлы шигырьләрен, публицистик мәкаләләрен бастыра.

1921 елда аның "Яшьләр иле" исемле китабы чыга. Гражданнар сугышы еллары, давыллы дәвердәге татар шигъриятенә хас үзенчәлекләр Әбрар Сәгыйди иҗатында да чагыла: агитацион рух, риторик пафос, элекке тормыш белән яңа чынбарлыкны кискен каршы кую һәм, шул ук вакытта, милләтнең киләчәгенә ышануда.

Татар совет матбугатында шагыйрь һәм журналист буларак киң танылып килгәндә генә, ул кинәт кенә Буа районындагы Киллдураз авылына китеп, мулла була. Беренче карашка, бик тә гаҗәп адым—муллаларга тискәре мөнәсәбәт шаукымы купкан дәвер ләбаса. Икенчедән, бу чорда шагыйрьләр Миргазиз Укмасый белән Нәҗип Думави да

муллалыкка кайталар. Хикмәт нидә сон? —Совет хакимиятенең партия яклы "яна совет муллалары"н эшкә жигәргә керешкән чагы була бу. Әмма дә, бернечә ел үтеп, илдә тормышлар беркадәр җанлана башлагач та, совет хакимияте дингә, руханиларга карата үтә кырыс сәяси чаралар күрә башлый, муллалар гражданлык хокукыннан мәхрүм ителә. Әбрар Сәгыйди дә шушы язмышка дучар була. 1925 елдан соңгы гомеренәчә ул байтак эш алыштыра: Зөя кантоны башкарма комитетында тәрҗемәче, Зөя балалар йортында һәм Совет төзелеше институтының эшче яшьләр факультетында (рабфагында) укытучы, татар телен гамәлгә ашыру буенча инструктор, мәгариф бүлеге инспекторы, төрле мәктәпләрдә укытучы, "Гаҗур"да корректор—кая гына урнашса да, аны тиз арада эшеннән китәргә мәҗбүр иткәннәр. Мулла нәселеннән һәм үзенең дә мулла булуы, нишлисен, гомеренең азагына кадәр эзәрлекли, аның "кара сакалына" әверелә. Утызынчы елларда ул әдәбият мәйданыннан да читләштерелә: әсәрләре, төрле сылтаулар белән кире кагыла, хәтта нәшриятка тапшырылып, "басарга карар бирелде" дип кул куелган кульязмалары да кире борыла. Заманында Галимҗан Ибраһимов тарафыннан уңай бәяләнгән иҗаты да фәкать тискәре тәнкыйть унае белән генә телгә алына башлый. Ул заманнарның әдәби "киллеры" Ф. Мөсәгыйтьнең: "әсәрендә сыйнфый көрәш юк"—дигән ише мөһерләренә күп юлыга ул.



*Мөгаллимәләр әзерләү курсында укучы кызлар. Икенче рәттә сулдан өченче—Әбрар Сәгыйди, янәшәсендә—Кәрим Әмири. Казан, 1918 ел.*

Әмма дә ләкин Әбрар Сәгыйди бу давыллы-авыр елларда да ихтыярын сындырмаска, кулыннан каләмен төшермәскә тырыша. Ул "Әбү Сәгыйть" имзасы белән балалар өчен ике шигырь китабын—"Умарта бакчасы" һәм "Эш курае"н бастыруга ирешә. Тик аның бик күп әсәрләре кульязма хәлендә генә калган. Әдипнең өлкән улы Марат Сәгыйтовта саклаучы шәхси архивына караганда, аның бу дәвер иҗатында хикәяләр һәм пьесалар өстенлек иткән. Мәсәлән, егерме жиде драма әсәренең фәкать берсе генә сәхнәләштерелә: "Сахра кызы" дигән биш пәрдәле пьеса фаҗигасе 1928 елда Татар дәүләт академия театрында, соңрак исә Мәскәү үзәк татар эшче театрында уйнала. Әдипнең әлегә кадәр дөнья күрмәгән "Кирпеч базларында" повесте, "Лашман" поэмасы, "Фәрһад-Ширин" һәм "Сак-Сок" пьесалары—бүген дә кызыксынып укырлык, сәхнәгә куярлык әсәрләр.

Үзенең көчен шагыйрь тәрҗемә өлкәсендә дә сынап караган. Әле егерменче елларда ук ул Шәрыкнең бөек шагыйрьләре Имрү-әл-Кайс белән Рабиндранат Тагорны, Америка шагыйре Уолт Уитменның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә. Болары да бүгенге көн укучысында зур кызыксыну уятыр иде. Әдәби мирасыбызны халыкка кайтару җәһәтеннән байтак кына эшләр башкарылган бу заманда Әбрар Сәгыйдинең дә бай вә колачлы иҗаты үз укучысын табарга тиеш!

...Әбрар Сәгыйди 1939 елның 1 апрелендә, нибары кырык дүрт яше тулыр-тулмас, туган авылы Кече Кошманда вафат була. Язгы җепшек карларда, көзге салкыннарда барлы-юклы өс киеменнән ерак авылларга балалар укытырга йөргән мөгаллим шагыйрь, әнә шулай, үпкәсенә салкын тидереп, бакыйлыкка күчә.

Биредә янә шунысын да әйтү бик тә урынлы булыр: шагыйрьнең өлкән улы профессор Марат Әбрар улы Сәгыйтов—гомере буе Казан дәүләт педагогика университетында укытты һәм укыта. Әдипнең олы кызы Зөмәррә, кече кызы Илһамия, кече улы Фоат Сәгыйтовлар да, югары уку йортларында татар теле һәм әдәбияты, тарихы буенча белгечлек алып, озак еллар дәвамында мәктәптә укыткан фидакарь затлар. Бабаларының, әтиләренең изге хезмәтен дәвам иттерүче чын мәгънәсендәге мөгаллимнәр алар.

**Марат ЗАКИР**

# ЯКТЫ ҺӘМ ҖЫЛЫ БӨРКЕЛӘ...

Бу әдипнең исемен әйтү белән минем күз алдына якты, кояшлы җәй көннәре — Аккош күлендәге иҗат йортында аның белән бергә, янәшә яшәлгән бик тә матур көннәр килеп баса... Һәм ул шәхес үзе дә хәтердә әнә шундый кояшлы җәйге көн кебек булып сакланып калган.

Әйе, Мәҗит ага Рафиков — чын-чыннан зыялы зат, югары тәрбияле һәм бик тә укымышлы шәхес иде. Аның белән икәү генә калганда ул сине үзенә дә сиздермичә генә тормыштагы, табигатьтәге, әдәбияттагы гүзәллекнең иң нечкә хасиятләре хакында гаҗәеп мәгънәле әңгәмәләргә алып кереп китә. Андый чакларда синең әңгәмәдәшең булган бу кешенең дөньяны һәм матурлыкны шундый да нечкә тою, шундый да тирәннән аңлау талантына сокланасың. Аның белән бергә үзең дә матурлыкның яңа үрләренә күңеленнән генә өр-яңа сукмаклар саласың...

Менә ул татарның иң затлы шагыйрьләре язган әсәрләрне сөйли. Алардагы эстетик байлыкка, фикри тирәнлеккә ушы китеп, дөньясын онытып тора... Менә ул русчага күчеп, Иван Бунин шигырьләрен яттан укый. Афанасий Фет әсәрләреннән күпләп-күпләп өзекләр китерә... Шулай ук чит илләр әдәбиятын да бик яхшы белә иде мәрхүм Мәҗит ага.

Аның үз әсәрләре дә дөнья әдәбиятының бөек әсәрләренә хас булган әнә шул кыйммәтле сыйфатларга ия иделәр. Аларда да кеше җанының, кеше рухының югары яшәеше гаҗәеп табигый булып һәм тәэсирле чагылды. Мәҗит Рафиковның күләм ягыннан әллә ни зур булмаган әсәрләре кеше күңеленең кадерле һәм изге мизгелләре хакында укучы белән ихлас әңгәмә алып баралар.

Мәҗит Рафиковның 1966 елда “Илһам авазы” дигән хикәяләр җыентыгы, 1973 елда “Төлке улы Хәйләпүш” дигән шигырь китабы, 1975 елда “Су башы” исемле повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы дөнья күрде.

Бу әдип бердәй осталык белән рус телендә дә иҗат итте. Аның русча басылган “Родник Хабира-Соловья” (1972), “Ишкильды” (1975) һәм “Школа на взгорке” (1981) китаплары бар.

Әдипнең “Шарлама”, “Сиңа ничә яшь” һ.б. әсәрләре чит илләрдә дә басылып чыкты. “Безнең авыл мәктәбе” повесте исә 1977 елда “Волга” журналының еллык бүләгенә лаек булды.

Ул бик тә шигъри җанлы әдип иде. Проза әсәрләре язып бетереп “хәл җыйган” арада үзе дә байтак кына әйбәт шигырьләр язды. Алар 1985 елда “Гүзәл мизгелләр” дигән исем белән Татарстан китап нәшриятында басылып та чыктылар, матбугатта яхшы бәя алдылар.

Сүзгә гаять сизгерлеге Мәҗит Рафиковның тәрҗемә эшчәнлегендә дә күренде. Аның тәрҗемәсендә Г. Тукайның прозасы, Ш. Камал, Н. Дәүли, М. Әмир, М. Гази, Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, Р. Төхфәтуллин, Х. Сарьян һ.б. татар язучыларының күп кенә хикәяләре русча дөнья күрде. Гомеренең соңгы елларында ул бик тә бирелеп һәм ихлас күңелдән мавыгып Тукайның чәчмә әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итте. Ул бөек шагыйребез язган һәр сүзнең тулы мәгънәсе бөтен тирәнлеге, саллылыгы рус укучысына һәм бу тел аша дөнья халкына аңлашылсын дип тырышты. Бу эшкә үзенең поэтик һәм фәлсәфи көчен салды, кызганмады. Мәҗит Рафиковның вафатыннан соң дөнья күргән китап, көченең юкка сарыф ителмәгәнлеген раслый.

Әйе, Мәҗит Рафиков дөньяны, тормышны киң колачлап һәм киң күңел белән яшәүче әдип иде. Әнә шуңа күрә аның әсәрләрендә безгә Олы Хакыйкать юлдаш

булып бара. Бөек Матурлык көнелләрне жылытып тора. Аның иҗаты турында язган тәнкыйтьчеләр дә бер дә юкка гына менә мондый сүзләр кулланмаганнардыр: "Фәлсәфи калыптагы әдип" (И. Ахунжанов), "Матурлык эзләүче" (Ф. Миннуллин) һ.б.

Мәҗит Рафиков — Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм авыр яраланган кеше. Әнә шул яра соңгы елларда бигрәк тә үзен сиздерде, аның хәрәкәтләнүенә нык комачаулады.

Әдип Сталин системасының җәзаларын бик иртә татый — аны студент чагында ук кулга алалар һәм Себергә сөргенгә сөрәләр. М. Рафиков 1950–55 елларда Иркутск өлкәсендә, Тайшет-Братск тимер юлы төзелешендә эшли.

Совет лагерьларын кичергән кеше булса да, аннан үзенең кешелеклелеген, нечкә күңеллелеген җуймый кайткан, саф йөрәкле зат иде ул. Матурлык һәм гаделлек ахырга кадәр аның төп таянычы булды.

Шулай ук аның сугыштан яраланып кайткач туган ягында һәм сөргенгә сөрелгәч Тайшет—Братск трассасында фельдшер булып эшләве дә бу шәхеснең якты образын тагын да тулыландыра, аны тагын да кешелеклерәк итә.

...Җәйнең ямьле, матур, кояшлы көннәре "Аккош күле"ндә хәзер дә була... Һәм гаять монсулатып, җаннарны серле билгесезлеккә төреп, андый ямьле көннәрнең энгере дә килеп җитә... Әнә шундый кичләрдә, Мәҗит ага белән икәү яшәгән өйнең кояш баешына караган верандасына чыгып утырам да — дөньяның, дөньялыкның, тормышның Олы Хакыйкатен, Олы Матурлыгын тоеп һәм күреп яшәгән, әнә шуларга йөз тотып яшәгән олы җаннарны чын-чыннан сагына башлыйм... Һәм кичке эңгердә утырып үз эчемнән, үз күңелемнән генә алар белән башланган әңгәмәләрне дәвам итәм...

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

---

# КИЛӘСЕ САНДА УКЫГЫЗ:

Менә тагын җылы язлар җитте. Һәр елны халкыбыз бөтен кешелек дөньясы белән бергә Икенче бөтендөнья сугышында фашистик Германияне җиңү көнен билгеләп үтә. Инде байтак еллар узган, байтак сулар аккан, әмма кеше хәтеренә ил язмышындагы ул аяныч көннәрнең афәтле хатирәләре канлы юллар белән язылган. Беркем дә, бер нәрсә дә онытылмый. Журналның май санында Башкортстанда яшәп ятучы сугыш ветераны **Мөҗип Имамов**ның "Сугышның мәрхәмәтсез йөзе" дип исемләнгән документаль повесте тәкъдим ителә. Автор үз башыннан кичкәннәрне гаҗәеп бер төгәллек белән сурәтли, каһәрле сугышның әлегә киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм булмаган серле һәм аянычлы сәхифәләрен күз алдына китереп бастыра. Бу сандагы күп кенә башка әсәрләр дә, хөрмәтле укучылар, сезгә сугыш елларының кайнар кайтавазын алып килер. Шундыйлар исәбендә шагыйрь **Шамил Маннапов**ның лирик парчалары, майда үзенең 75 яшен билгеләп үтүче аксакал әдибебез **Мәгъсум Хуҗин** хикәясе дә кызыксыну уятыр, дип ышанабыз.

Шигырь сөючеләр **Әдип Маликов, Фәрит Габдерәхим, Әхмәт Гадел, Резеда Вәлиева** шигырьләре, яшьләр поэзиясе үрнәкләре белән танышыр.

Журналның бу саны да, гадәттәгечә, әдәби тәнкыйть мәкаләләренә, публицистик язмаларга, халык һәм сәнгать тарихының төрле катламнарын күтәргән гыйльми язмаларга бай.

*Юмор-сатира*

**Тәлгат Нәҗмиев**

# САБА МӘЗӘКЛӘРЕ

## Хата тоту

Газетада хаталар әледән-әле чыгып тора инде ул. Аны махсус җибәрмисең бит, объектив йә субъектив сәбәпләре була.

Газета укучыга барып җиткән көнне үк ул хатаны табалар, кош тоткан кебек сөенә-сөенә телефоннан шалтыраталар, урамда очратып әйтәләр, олы хуҗаларга житкерүчеләр дә юк түгел.

Сәяси хата өчен, илле биш яшьлек башымны кая куярга белмичә борчылып йөргән монсу көзге көннәрдә, хакимият башлыгыбыз Рәис Миннехановның өряна тәкъдим керткәнен һич тә онытасым юк.

—Бернечә махсус приз әзерләп, газетада иң күп хата тапкан кешене бүләклик әле, акчасын үзем бирәм,—дигәч, минем ачылган авызым ябылмыйча калды, шактый вакыт шул килеш йөреп тордым...

## Торып басу

Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында уза торган әдәби ел йомгаклары бик эшлекле үтә. Башта Язучылар берлегенең классик әдипләр исемен йөрткән махсус бүләкләре тапшырыла.

Жанрлар буенча докладлар барышында елмаеп алган, йә зал белән дәррәү кычкырып көлгән мизгелләр дә булмый түгел.

2002 елның шигърияте турында Ркаил Зәйдулла ясаган доклад күнелемдә уелып калды. Татарстан матбугатында басылган поэзия үрнәкләрен һәм төрле нәшриятларда дөнья күргән җыентыкларны санап китте дә: "Күләм кайчан да булса сыйфатка күчәргә тиеш бит, дип күнел юатасың. Шундый канун бар шикелле. Ләкин татарның бөек мәкален дә онытмыйк әле: ком җыелып таш булмас, кол җыелып баш булмас!"

Оста трибун икәнен дә үзенә генә хас тел осталыгы һәм юмор белән күрсәтеп ала Ркаил. Текстының чираттагы кәгазь битен ачкач, ике кулын да чалбар кесәсенә тыгып куя.

Менә оратор Лена Шагыйрьҗанның поэзия сөючеләр тарафыннан олы бәяләнгән Нью-Йорктагы Сәүдә үзәген шартлату унаеннан язылган "Дөнья базары яхуд яңа Америка фаҗигасе" дигән лирик-публицистик поэмасын анализлый. Шагыйрәнең Америкага юллаган хатыннан өзекләр дә укый:

...Барып житеп кулыгызга
Керсә ошбу хатыбыз,
Тышына ук язып куям:
"Курыкмыйча ачыгыз!..."
Әнә килә ак парахут,
Төягән ак парашук.
Сездә дә "шок", бездә дә шок,
Тик торабыз карашып...
USA=АКШ дип язылган
Сәмәлүт канатына.
Теләктәшлек белдермибез
Террор аппаратына...

Билләһи, кабереннән Тукай торып чыкса, Лена ханымның кулын үбәр иде",—диде дә, бераз пауза ясады Ркаил һәм: "Курыкмаса..."—дип өстәде.

Тагын су салып эчте ул. Кыскасы, докладын әзрәк укыды да су эчте, укыды да су эчте. Кемнәрнедер мактады, тәнкыйтьләде.

—Күп кенә шигырьләрне укыгач, гажизләнеп тә куясың. Автор, көндәлек эш эшләгәндәй генә, тезмә сырлап куйган сыман тоела. Йокыдан торгач юынасың, теш чистартасың ич... Рим Идиятуллин хәтта бер тезмәсенә "Аптыраганнан язылган шигырь" дип исем дә куйган. Шулайдыр. Аптыраганнан кайчак кәҗәкәйне дә суялар. Аз булса да ите чыга...

Тагын су эчеп куйды Ркаил Зәйдулла. Аннары, янәдән, байтак каләмдәшләренең исем-фамилияләрен атый-атый, иҗатлары белән таныштырды, тәнкыйтьләде, ат уйната торган шагыйрьләрне мактады. "Поэзия ул—музыка",—дип тә җибәрде. Тагын бер тапкыр тамагын су белән чылатып алды да:

—Бөтен кешене дә әйтеп бетереп булмый, исемегез чыкмаганнар торып басыгыз!—диде.

## Кырыйга карау

Университеттагы мөгаллимәләребез арасында һәр җөмләсен, сүзен уйлап кына әйтә торган бик тә сабыр холыклы морфология укытучысы Фәһимә апа Хисамованы хөрмәт итә идек.

Аның сабырлыгын раслау өчен бер мисал китерим әле.

—Минем ин яратмаган ике нәрсә бар,—диде бер вакыт сабакташыбыз, булачак язучы Газиз Кашапов. —Берсе—морфология, икенчесе—кабартма!

—Икенчесе нәрсә?—дип кайтарып сорады да, җавапны кабат ишеткәч, шундый матур итеп елмайды Фәһимә апабыз—үзебезгә дә уңайсыз булды.

Тора-бара ул докторлык диссертациясе яклап, профессор дәрәҗәсенә күтәрелде. Без баштарак аның әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамовның җәмагате, игезәк рәссамнар Айдар белән Ниязның әнисе икәнен бөтенләй белми идек.

Алга узып шуны әйтергә кирәк, малайлар башта Казан сәнгать училищесын, аннары Санкт-Петербургта Е. Репин институтын тәмамлаганнар. Икесе дә реалист рәссам. Иҗатлары туган якка мәхәббәт, татар халкына олы хөрмәт белән сугарылган. Хәзер Айдар—Казанда, Нияз Берлинда яшәп иҗат итә.

Әни кеше дә, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры булып эшләүче Нурмөхәммәт ага да рәссам уларының уңышларына бик сөенә.

Якташыбыз, профессор Азат Әхмәдуллинның башкалабыздагы юбилей кичәсе Казан милли-мәдәни үзәгендә булды. Сәхнә түренә юбилярның читкәрәк каратып ясалган портреты урнаштырылган иде. Филология фәннәре докторы, профессор Гомәр ага Саттаров шуны күргә:

—Нурмөхәммәт, бу рәсемне синең малайлар ясадымы әллә?—дип сорап куйды.

—Юк!—диде әти кеше, үзенә генә хас катгый тавыш белән.—Әйе. Минем малайлар ясаса туры каратып ясаган булырлар иде...

## Чуан гына бушка чыга

Каләм тибрәтүчеләр арасында журналистларның мэтры, "Советская Россия" газетасының элеккеге үз хәбәрчесе, язучы һәм публицист, бик күп китаплар авторы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марсель ага Зарипов турында да кызыклы сөйләкләр йөри. Янәсе, аңа Татарстан Журналистлар берлегенең бик әз суммадагы бүләге бирелгәч, ул профсоюз комитетына: "Мина Хөсәен Ямашев исемендәге премия бирелү сәбәпле, бераз матди ярдәм итүегезне сорыйм", дип гариза язган, имеш...

## Арт белән—алга

Вакыт уза торды. Капитализм һәм социализм чорлары артта калып, демократия еллары башланды.

Сабантуйлар соңгы елларда шимбә көнне уза башлады Сабада...

Ә дүшәмбедә барыбер җыеп алалар. Минем күңелем тыныч хәзер, чөнки йөзем чиста—якшәмбе көнне үк "Ватаным Татарстан", "Шәһри Казан" кебек газеталарга репортажымны язып, эшемне бетереп куям.

—Главага ничекләр итеп кирәсе,—дип уфтана икән Саба җирле үзидарә Советының ул чактагы рәисе Равил Гасыймов, тәмәке тарткан җирдә,—чыраем да әйбәт түгелләр инде...

Район хастаханә кассасы директоры Рөстәм Сафиуллин үзенчә тынычландыра икән Гасыймовны:

—Бер дә аптырама, Равил. Чыраең начар булса, артың белән кер син главага...

## Авызыңа май да бал...

Туган авылы Көекне саклап калган Фәнис Хурамшин да ярты гасырлык юбилеен билгеләп үтте.

1986 елда ул республикада иң беренче итеп оештырылган “Агропромснаб”ның район предприятиесе директоры итеп билгеләнә. Иң башта “Сельхозтехника” берләшмәсенең элеккеге конторасы, гаражлар ремонтлана, өч типовой склад, күпкатлы административ бина, җылы гаражлар салына. Бер үк вакытта туган авылы Көекне 1500 гектар җире белән ярдәмче хуҗалык итеп рәсмиләштерәләр. Сыерлар өчен ике торак, ат абзары төзи башлыйлар. Тора-бара дүрт склад, ябык ындыр табаклары, контора, тегермән, автоулчәгеч, пилорам, нефтебаза, кыскасы, агрошәһәрчек коралар. Сыерларның баш санын туксанга, атларны йөз егерме башка җиткерәләр. Умарталык, балык күле булдыралар. Көеклеләрнең фидакарь хезмәте Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының күчмә Кызыл Байрагы белән бәяләнеп, мәңгелеккә истәлеккә калдырыла.

...Ә инде Фәнис Шәйхеразый улының юбилей кичәсенә туктасак, бик матур үтте ул. Азат Хөсәенов җитәкчелегендә концерт төркеме дә килгән иде. Мәҗлесне танылган юмор остасы, сатирик язучы, “Ком сәгате”, “Сакау күке” романнары авторы Камил Кәримов алып барды. Башта үзе белән таныштырды.

—Без нәселебез белән язабыз,—дип фикерен башлады ул. —Әни йон язган, әти май язган, абый летчик була язган...

Мине дә кыстырып, колак кызарырлык итеп мактап алды. Аннары:

—Һәр районның үз алфавиты бар. Сездә ул “М” хәрефеннән башлана икән. Беренче сүзне Миннеханов Рәис Нургалиевичка бирәбез,—диде.

Юбилей тантанасы гөрләп барды. Җырлап та күрсәтте инде Азат!..

Ә Камил сүзне бирә торды.

—Һәркайсыбызның әнисе бар. Без тугач, алар изге теләкләрен индергәннәр,—дип сөйләп китте ул.—Минеке язучы булуымны теләгәндер инде. Ә менә хәзер микрофонны тоттырасы кешегә анасы, авызы гел майда йөзсен,—дигәндер, күрәсең... Сүз—Саба май заводы директоры Миннеислам Зариповка...

## Көзгегә үпкәләмә!

Бездән ераграк бер районда булган хәлне кыска гына итеп тасвирлыйм әле. Озын-озак сөйләмим, гомер болай да кыска.

Бер-берсен күрә алмый торган ике хатын җитәкче урыннарда эшлиләр икән. Боларның мөнәсәбәтләренә чатнау кергәнгә шактый еллар үткән. Лев Толстой әйтмешли, үзара тату булып, бер-беренә ярдәмләшеп кенә яши алмаганнар болар.

Чираттагы КПСС райкомы пленумы докладында берсен мактап та җибәрә район хуҗасы. Бу хәлгә тегенең дошманы күлмәгенә сыя алмый, гомер буе күрә алмаган җәбәхәердән үч алу юлларын эзли. Төн буе үз-үзе белән сөйләшеп, психланып чыга һәм таң алдыннан гына черем итеп ала.

Уянып китеп, сәгать телләренә күз салса, сигезгә якынлашып килә икән. Үч иткәндәй, әбисендә кунып калган оныгын да бакча дип атала торган саклау камерасына илтергә тиеш була.

Кабалана-кабалана яхшы мехлы тунын киеп, сабыйны җәһәт кенә ясле ишегеннән кертеп җибәрә дә туп-туры райкомга йөгерә бу. Бәхетенә күрә, сәркатип кыз да каядыр чыгып киткән була. Дуамалланып килеп керә ул беренченең эш бүлмәсенә һәм төн буе репетиция ясап яткан җөмләләрен, төкереген чәчә-чәчә, пулеметтан аткан кебек сибә дә башлый. Кыскасы, тетмәсен тетә теге докладта макталган “спиральле чәйнекне”.

Бик игътибар белән тынлый инсафлы беренче. Бүлдерми. Аннары, шикаять белән керүчене җайлап кына тынычландыра, ишек төбенә кадәр озата килә. Соңыннан болай дип әйтеп куя:

—Мөшәрифә Имамовна, кабул итү бүлмәсенә чыккач, көзгедән карап алырсыз әле, яме...

Эче “бушаган”, сулыш алулары җиңеләеп киткән ханым, үзен коточкыч мандраж көтәсен чамаламый әле башта. Көзгегә караса—оятыннан җир тишегенә кереп китәрдәй була...

"Тефаль" үтүге дә рәткә кертә алмас дәрәҗәдә бөгәрләнеп беткән эчке күлмәктән басып тора икән бит ул, мескенкәй!

## Әллә тешләп куясы?

Зәйдән ирле-хатынлы Динира һәм Равил Вафиннар белән "Бәкер суы" дип исемләнгән ресторанда бер өстәл артында утырабыз. Равил әфәнде белгечлеге буенча инженер икән. Хуҗалыкта да эшләгән, соңгы елларда Зәй ашлык кабул итү предприятиесендә баш инженер вазифасын үти. Җәмәгате Динира ханым, тумышы белән Самара өлкәсенең Камышлы авылыннан булып (шагыйрьләр Әнвәр Давыдов, Рөстәм Мингалим, һәм атаклы полиграфист Мөҗәһит Шәйхетдинов та шул төбәктә дөньяга килгәннәр), гомер буе балаларга белем биргән, район мәгариф бүлегендә—сигез, мәктәп директоры булып унике ел эшләгән. Ул сөйләгән кызык хәл дә тәрбия темасына, әлбәттә.

Камышлыда булган әлеге вакыйга.

Йорт хуҗасы көн буе яңгыр астында эшләп, лычма су булып, арып-талып өенә керсә—җәмәгате ике буш чиләк тотып, каршысына килеп баскан:

—И матурым, аш салырга су юк, барыбер чыланган инде син, шул килеш кенә су алып кереп бир инде,—дигән.

Тумыштан ук караңгы чырайлы, авыр холыклы, аз сүзле Ир-ат (зур хәрефтән языйм әле) суны алып кайткан да, берьюлы ике чиләк белән хатыны өстенә койган, аннары:

—Менә син дә юешләндең инде, хәзер үзең дә алып керә аласың!—дигән.

## Иң нечкә җир

Әйтергә дә оят—биш кило чамасы арткан мын санаторийда. Шул "Бәкер суы" дип аталган ашханәгә көйләнгән "швед өстәле" сәбәпче булды мона. Кырык төрле салат, җиләк-җимеш, бавырлы, итле, балыклы "второйлар" тезеп куялар да... Күзгә күренгәч, аласы килә. Өйгә кайткач, киметәбез ашауны,—дип үз-үзебезне юаткан булабыз. Корсак үстерүнең иң зур дошман икәнен дә бик яхшы беләбез, югыйсә. Шуның аркасында йөрәк май белән каплана бит... Үзем эчтән генә сөенеп тә куям, ярый әле сыер булып тумаганмын, беренче люцерна басуында ук күбенеп үләр идем, дим.

"Бәкер"дән кайткач, әнинең хәлен белергә сугылдым.

—И улым, син ул кешенең корсагын күрсәң,—дип коточкыч итеп сөйләп китте бер авылдашым турында,—синеке кадәр була язган!

Аңламаганга сабыштым. Әнигә үпкәләп булмый бит инде. "Авторитетың" авырлы хатынныкы кадәр булгач. Әллә фамилиядән дә килә инде?!.

Мина гына түгел, заманында Сталин премиясен алган язучыга—алаш бабайга—Кави Нәҗмигә дә төрттергәннәр бит әле...

...Татарстан китап нәшрияты корректорлары әбәт вакытында чәй эчеп утыралар икән. Бүлмәгә Кави Нәҗми килеп кергән.

Кызлар ана карап-карап торганнар да:

—Кави абзый, нигә инде сез шундый олы корсак үстереп йөрисез, ә?—дигәннәр.

—Их, кызлар,—дигән Кави ага,—сез минем иң нечкә җиремә кагылмагыз инде, зинһар!

## Ашау сәнгате

Татарның байтак интеллигенты белән очрашырга насыйп булды. Аларны, яктылык алып килүче һәм яхшылыкны дөньяга, кешеләргә иңдерүче, дип хак әйтәләр. Интеллигент кешенең сәламләве, күрешүе, кызмыйча, ашыкмыйча сөйләве, киенә белүе, машинага утыруы һәм төшүе, хәтта ашавы да үзенчәлекле...

Мәскәүдә яшәп иҗат итүче композиторыбыз, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Алмаз ага Монасыйпов белән бер мәҗлестә утырырга туры килде.

Алданма, укучым! Юк—бу син уйлаган һәм күз алдына китергән эчү мәҗлесе түгел. Рәсми кабул итү ашы турында барачак сүз алга таба.

Алмаз ага Монасыйпов, беренче эше итеп, сихри моңнар тулы әсәрләрен уйный торган нәфис бармаклары белән ап-ак салфетканы алып, килешле күлмәк якасы өстенә кыстырып куйды. Ул салфетка шул кадәр унайлы ятты ки, кабул итү

тәмамланганчы төшмәде. Аннары, уң кулына пычак, сул кулына чәнечке тотып, бик нәзберек итеп ризыктан авыз итә башлады. Шәрабны башта әйләндерә-әйләндерә карады, озаклап түмен татыды. Яхшы икәненә инангач кына рюмкасына өстәргә рөхсәт итте.

Кыскасы, Алмаз аганың табында ризык жыюы (ашау дип язсам, тупасрак булыр кебек тоела)—үзе бер сәнгать. Минем аны тасвирларга, беренчедән, сүз байлыгым житми, икенчедән, яхшы түгел...

Бик мәгънәле, әмма кыска итеп тост әйтте дә Габдулла Тукайның "Безнең авыл" шигыренә ижат иткән жырының бер куплетын жырлап бирде:

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы түмен беләм,
Шуңар күрә сөям жаным-тәнем белән.

Сүз жегәре, тел тәме, көйнең аһәне белән искитмәле итеп жырлап күрсәтте ул. Табындашларның күзләре яшьләнде. Билләһи, рәхәт менә шундый кешеләр белән аралашу. Бер утыру—үзе бер гомер ич...

## Кошларның сөте буламы?

1967 елда, Казанда Бөек Октябрь Социалистик революциясенең 50 еллыгына багышланган укучылар слеты булды. Икенче көнне һәр районнан берничә делегатны КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Табеев кабул итте.

Менә без, гади генә итеп әйтсәк, обкомда. Очрашу башланыр алдыннан, пионер хәрәкәте ветераны, ап-ак чәчле Ш. Сидаев: "Кукмарадан иң кыю бала кем?"—дип сорап куйды. Мине күрсәттеләр. Ни өченме? Моның сәбәбе үзешчән сәнгатьтә актив катнашуым, кечкенәдән концерт алып баруым, юмористик шигырьләр сөйләвем белән бәйле булгандыр. Очрашу башлангач, Шамил ага миңа урысчалатып: "Во всех районах Татарии был ли дождь?"—дигән сорау бирергә кушты.

...Менә зал алкышларга күмелде. Ф. Табеев белән бергә С. Батыев, Г. Усманов һәм башка бюро әгъзалары күренде.

Безне алдан ук ниндидер залга кертеп утырттылар. Күңелдә шунысы уелып калган: андагы өстәлләргә фамилияләр язылган иде. Очраклылык булдымы икән, әллә киләчәк язмышымны сиздерү өченме—анысын әйтә алмыйм, мин "Хамматов Ш. Х." дип язылган урынга туры килгән идем...

ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре А. Василец очрашуны ачып, Ф. Табеевка сүз бирүгә, мин сикереп тордым да, яттан өйрәнгән русча соравымны "чәпәдем".

Шуннан хут алып сөйләп китте Беренче. Аның чыгышы егерме-утыз минутка сузылып, юбилей елы игененә барып тоташты. Мин "төпле" сорау бирүемә чиксез шатланып утырдым. Житмәсә, оратор чыгышының уртасында мактап та өлгерде: "Кукмара егете жиргә дым кирәген дөрес аңлый, анардан яхшы агроном чыгар әле",—диде. Мин дә аптырап калмадым утырган жирдән генә: "Так точно, товарищ Табеев!"—дип жавап бирдем.

Ә үзем эчтән генә: "И, иптәш Тәбиев, колхозыбыз председателе Миңзифа апа Гыймадиева паспорт алырга белешмә бирсә, авылдан ычкыныр идем әле",—дип уйлап утырам. Кечке мәктәптә укып алыр идем әле белемне... Әти, әни—колхозчы, мин—алты баланың олысы. Яшәүләре бик авыр шул. Ипи булмаган көннәр дә юк түгел...

Алга узып шуны әйтергә кирәк, дөрестән дә шуннан кайткач Миңзифа апа паспортка рөхсәт язуы бирде. Рәхмәт яугыры. Кызгангандыр инде. Үзем дә әйбәтләп сораганмындыр, бәлки. Әллә Ходайның "амин" дигән вакытына туры килдеме?!.

Кыш буе бергә концерт куеп йөргән Шәмәрдәндәге дуслар промкомбинатка эшкә дә урнаштырып куйдылар, 67 сум 50 тиен хезмәт хакы ала башладым, 13 сум 70 тиенгә "шевиот" дигән материалдан концерт костюмы тектердем.

Ә теге очрашу күңелле үтте. Өстәлләргә тәм-томнар да куелган иде. Матур итеп киенгән официант апалар безгә чәй ташып торды. Залдан чыкканда берәр тартма конфет та бирделәр. Аның тышына "Птичье молоко" дип язылган иде. Ул көнне безне, авыл малайларын, тагын бер сорау борчыды: "Кошларның сөте була микәнни?.."

## YAZDAN AYIRIP BULMIY TUQAYNI

### KITAP

Hiç tə künlem açılmaslıq eçem poşsa,
Üz-üzemne küralmıyça, ruxım təşsə,
Cəfa çiksəm, yədəp betsəm, bu başımnı
Quyalmıyça canğa cılı hiçber təşkə;

Xəsrət sonra xəsrət kilep almaş-almaş,
Kunelsez uy belan təmam əylənsə baş,
Kuzləremda kibep tə citməgən bulsa,
Xəzer genə sığılıp-sığılıp yılağan yəş,—

Şul waqıtta min qulıma kitap alam,
Anın izge səxifələren aqtaram;
Rəxətlənep kitə şunda canım, tənem,
Şunnan ğına dərtləremə dərman tabam.

Uqıp barğan hərber yulım, hərber süzem
Bula minem yul kürsətüçe yoldızım;
Səymi başlıym bu dənyanın waqlıqların;
Açıladır, nurlanadır künlem, küzem.

Cinelləņəm, məğsumlanam min şul çaqta,
Rəxmət əytəm uqığanım şul kitapqa,
Işanıçım arta minem üz-üzemə,
Əmit berlən qarıy başlıym bulaçaqqa.

**Ğabdulla TUQAY**

* * *

"Şağir kem?" digən sorawğa cawapnı citmeş əç yəşemə citkəndə Tuqaydan taptım. Şağirlekne şağir üze yəşəgən cəmğiətkə kertkən ruxi kəçenen miqdarı belən ülçəgənlegen Tuqaynı uqıp anladım. "Bette kəç, sındı qılıç.–Şul buldı eş" menə qayçan əytelə ikən. Tuqay mində üzenen milli ruxı belən yəşi. Şul yazdıra, şul eçke energiəgə əylənə. Yəş çaqta alğa-artqa qaramıy yarışa-yarışa çapqan kiləçək şağirlərə də, minem şikelle qartaya təşkəç, ələge sorawğa cawapnı barıber Tuqaydan ezləyəcəklər. "Şağir kem?" Taqtaş, Tufan, Cəlil dip kilerlər də Tuqayda tuqtalırlar. Şuna bik nıq inandım. Ə şağirgə cawap tabarğa kirək

ikən. Qısqası, ikençe zamanda yəşəsəm də, dənyağa ike qatlı tərəzə aşa qarap yəşədem–Tuqay aşa. Bətenesen teoretik nigezli alsam, min şağir də bulmas idem. Tuqay–borçu. Tuqaydan ayırılasım kilmi…

**Sibğət XƏKİM**

* * *

…Hər bəyek zatnı tanır, bəyələr əçen çorına layıq zamandaşları bulu, ilahi ruxnı kiləçəktə də saqlap baru əçen zirək onıqları–yaņa buınnar bulu kirək. Sanduğaç tawışın ayırır əçen bixisap qoş sayrawın belü kirək… Bu cəhəttən də Tuqay bəxetle şəxes. Çənki anıņ icat çorı ğəcəyep dəwergə–1905 yıllardağı bəyek kütəreleş çorına turı kilə. Xalıq bəyeklegenen ruxi mayaqların təgəl açıqlaw, barlaw zamanı. Annan soņraq dəwer buınnarı ruxi bəyeklekne tanu, bəyələw buyınça tağın da zirəgrək buldılar–Tuqaynı bəyek itep tanıp, kiləçəkkə ilttelər.

Əlbəttə, ni genə dimik, bu oçraqta bəyekleknen təp səbəpçese–Tuqay üze, ğəcəyep icatı, XX yəz başında Rossiə kinleklərendə berdənber diərlek unikal' şəxes. Yətim üsep, dəwlət uqu yortları kürmiçə tərbiələnep, bik az ğəmer yəşəp, yətimlek həm yalğızlıq kiçerep, biş-altı tomlıq ülməs əsərlər yazğan keşe dip ul çorda tağın kemne atap bula soņ?

**Rawil FƏYZULLİN,**
*Tatarstanniņ xalıq şağire*

* * *

Tuqay şulay uq ədəbiat dənyasında da bəten yaxşılıqqa mərxəmətle bulu belən bergə, bəten mətəşağirlərgə, yəğni şiğer yazıp mataşuçılarğa, şağir bulırğa tırışuçılarğa da (anıņ "Mətəşağirgə" digən şiğere də bar) bik ayawsız. Ədəbiatqa, icatqa dənya ədəbiatı bəyeklegennən qarap, zur taləplər quyıp, bəten buldıqsızlarğa qarşı kərəş aça. Bu da bəyekleknen ber missiəse. Mondıy missiəgə ədəbiat hərwaqıt, hər zamanda moxtac bulğan. Ə xəzer? Xəzer bigrək tə! Beznen ədəbiatlarda əlege şul mətəşağirlek, atalanmağan, subtil', ruxi cenessez şiğerlər ürçep barğanda, citməsə, şundıy əsərlərnen avtorları üzlərenə-üzləre ədəbiat həm poeziə xaqında cəmğiət fikere tudırırğa mataşqanda, ədəbiatta Tuqaylarnın bulmawı, Tuqay dəreslege bulmawı ütə qızğanıç.

Beznen küplərebez, beznen üsüebezgə qomaçawlağan ütə citdi citeşsezleklər belən kərəşkəndə Tuqaylıqtan, yəğni qiyulıqtan waz kiçep barabız. Ə bit Tuqay hiç nərsədən, doşmanı ettən kübəysə də, qurıqmağan.

**Nacar NƏCMİ**

* * *

Qazanğa berençe kilüemdə ük min ataqlı xalıq şağire Gabdulla Tuqay turında işettem. Anıņ turında bezgə professional' yazuçılar belən jurnalistlar ğına tügel, bəlki zavodlardağı həm təzeleşlərdəge eşçelər də, studentlar həm məktəp balaları da səylədе. Tatar xalqınıņ bu bəyek ulına uquçılarnıņ məxəbbəte nindi samimi bulğanın, küp ğasırlardan birle dəwam itep kilgən bay kul'tura traditsiəse həm sovet epoxasında şul tikle unışlı üsə barğan bu xalıqnıņ poeziəne şundıy nıq yaratuın min açıq aņladım həm bəten yərəgem belən sizdem.

**Jovanni JERMANETTO,**
*italyan şağire.*

* * *

Tuqaynın progressiv həm ğorur poeziəse bəyek Puşkinnın irek səyüçe poeziəsenə yaqın tora.

Tağın şunısı da əhəmiətle: Puşkin realizmın qabul itkən Tuqay şul çor cəmğıətenen yaraqsız yaqların həm tarixi qarşılıqların açıp sala aldı. Tuqay çın xalıq şağire ide.

**Moxtar AUEZOV,**
*qazaq yazuçısı.*

* * *

Min, əle poeziə əlkəsendə qulıma qələm almastan elek ük, Tuqaynın dulqınlandırğıç, tirən əsərləndergeç şiğerləren küp uqıdım…

Ğabdulla Tuqayğa bulğan burıçımnı ütəw teləge belən, min anın ike men yullap şiğeren tərkmən telenə tərcemə ittem…

**Berdı KERBABAYEV,**
*tərkmən yazuçısı.*

* * *

İskitkeç talantqa iə bulğan Ğabdulla Tuqaynın şiğri mirası ul barı tik tatar şağirləre milke genə tügel, ul barlıq tuğandaş millətlər şağirləre əçen də qəderle həm ğəziz...

Ğabdulla Tuqay kebek iskitkec talantlar citeştergən tatar xalqına dan!

**Soləyman ROSTƏM,**
*əzerbaycan şağire.*

* * *

…Tuqaynın əsərləre qırğız xalqına bik küptənnən tanış inde… Qırğız ədəbiatının aqsaqalı əlkən aqınıbız akademik Aalı Toqombayev, kürenekle ədiplərebez K. Bayalinov, U. Abduqaimov, N. Cantəşev, M. Toqobayev, K. Malikov, M. Abdukərimov, T. Əmetaliev həm başqalar əle ğərəp xərefləre belən çıqqan basmalarınnan Tuqay əsərləren uqıp əyrəngənnəren səylilər…

**Qamçı CUNUSOV,**
*qırğız yazuçısı.*

* * *

Ğabdulla Tuqay–tatar xalqının bəyek şağire, səyekle ulı. Ləkin Gabdulla Tuqaynı fəqət tatar xalqının şağire dip əytü genə citmi. Ul tatar xalqının ğorurlığı, əmma şunın belən bergə Tuqay–Rossiədə yəşi torğan küp kenə başqa tərki xalıqlar arasında, in elek alarnın uqımışlıları arasında kin tanılğan, yaratıp uqıla torğan zur ədip tə.

Ğabdulla Tuqaynın isemen telgə alğaç uq, tatar ədəbiatının üzbək ədəbiatı belən elemtəse, alay ğına da tügel, ğəmumən tatar xalqı belən üzbək xalqının tarixi elemtəse küz aldıbızğa kilə.

**Ğafur ĞƏLƏM,**
*üzbək şağire.*

## *«Казан утлары» архивыннан*



*"Кемнәр бар да, кемнәр юк!.." Каләмдәшләр әлегә бер өстәл тирәсендә. Сулдан уңга—Мәдинә Маликова, Кояш Тимбикова, Рәшит Гәрәй, Фәрваз Миңнуллин, Рафаэль Мостафин, Илдар Юзеев, Барлас Камалов, Абдулла Сәләхетдинов, Әхәт Гаффар. 1976 ел.*



*Шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин. 2001 ел.*



*Татарстанда яшәп иҗат иткән бер төркем чуваш язучылары. 1973 ел.*



*Шәриф Хөсәенов "Әни килде" спектакле премьерасыннан соң. Арткы планда Камал театры артистлары—Р. Таҗетдинов, А. Шамуков, Г. Ибраһимова, М. Миңлебаева.*
*1970 ел.*



*Татарстан суверинететы өчен көрәш еллары. Казан. Азатлык мәйданы. 1991 ел.*



*Язучы Ләбибә Ихсанова I нче татар гимназиясендә. 1998 ел.*

*Берлекнең яңа әгъзалары*

## Әлфәт Закирҗанов



Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы 1959 елны Мамадыш районы Югары Яке авылында туа. Башта үз авылында башлангыч мәктәптә, аннары Кече Кирмән сигезьеллык һәм Урта Кирмән урта мәктәбендә белем ала. Хезмәт юлын 1976 елда Түбән Кама шәһәрендә төзүче-плотник буларак башлый.

1978—1983 елларда Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетында укый. Шул елларда әдәбият һәм аны мәктәптә укыту, әдәби процесс үзенчәлекләре белән тирәнтен кызыксына. Институтны тәмамлагач, Мамадыш районы Урта Кирмән урта мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп билгеләнә. 1984—1987 елларда Уразбахты урта мәктәбендә директор вазыйфаларын башкара.

1987 елны гаиләсе белән Казанга күчеп килгәч, мәктәптә укытучы, директор урынбасары булып эшли. 1989 елны Мәскәүдәге Милли мәктәпләр институты каршындагы аспирантурага укырга керә һәм әдәбият укыту мәсьәләләре белән фәнни нигездә шөгыльләнә башлый. 1903 елда "Татар мәктәбенең өлкән классларында драма әсәрләрен өйрәнү" дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.

Мәгарифнең милли проблемалары институтының Казан филиалында фәнни хезмәткәр, гыйльми сәркатип вазыйфаларын башкара. 1995 елда Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасында өлкән укытучы, ә инде 1997 елдан доцент булып эшли.

Мәктәптә һәм вузда татар әдәбиятын укыту проблемалары белән ныклап шөгыльләнү нәтиҗәсендә, рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең 5 һәм 11 классларында укучы татар балалары өчен әдәбият дәреслекләре төзүдә актив катнаша. Моннан тыш татар теле, әдәбияты укытучылары һәм укучылар өчен дәреслек-әсбаплары басылып чыга: "Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре (1997), "11 сыйныфта татар әдәбиятын укыту" (2001), "Сыйныфтан тыш уку дәресләре" (2002). Хезмәттәшләре белән берлектә "Татар әдәбияты: теория, тарих" (2004) китабын чыгаруга зур өлеш кертә.

Татар әдәбияты тарихы, бүгенге әдәби процесс белән якыннан кызыксынып яши. Әдәби тәнкыйтькә, проза торышына, драматургия мәсьәләләренә караган мәкаләләре "Казан утлары", "Фәнни Татарстан", "Фән һәм мәктәп", "Мәгариф", "Шәһри Казан" һ. б. газета-журналларда даими басылып килә. Ә. Закирҗанов 50 дән артык фәнни хезмәт авторы. 2004 елда хәзерге татар драматургиясендәге һәм театрындагы эзләнү-табышларның идея-эстетик үзенчәлеген ачуга йөз тоткан тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы—"Заман белән бергә" исемендә дөнья күрде.

2005 елның 28 февралендә, Кабул итү комиссиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә язучылар: Х. Миңнегулов, А. Әхмәдуллин, З. Хөснияр), Язучылар берлеге Идарәсе Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улын Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул итте.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен" ордены белән бүләкләү турында

Татар милли музыка сәнгатен үстерүдә гаять зур хезмәт куйган өчен Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе сәнгать житәкчесе **ШАКИРОВ Илһам Гыйльметдин улын "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен"** ордены белән бүләкләргә.

**М. ШӘЙМИЕВ,**
Татарстан Республикасы Президенты.

*Казан, Кремль,*
*2005 ел, 11 февраль.*

## ИЛЬҺАМЛЫ АЙ

***

Февраль — мәшһүр жырчы Илһам Шакиров туган ай. 15 февральдә аңа 70 яшь тулды. Шул уңайдан Г. Камал театрында жырчы хөрмәтенә зур тантана булып узды. Зал тулы тамашачылар легендар жырчыны аягүрә басып озак алкышладылар. Аннан соң сәхнәгә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев күтәрелде. Ул болай диде:

"Илһам Шакиров сәхнәдә күренгәч, безнең шулай дәррәү күтәрелеп, озак кул чабу, тәбрикләү ул — артист өчен зур бүләк. Илһам ул — легенда, тере килеш мәңгеләштерелгән шәхес.

"Сәнгать кешеләре тиешенчә бәяләнәме?" — дигән сорау күпләрне борчый. Хәзер без авыз тутырып "әйе" дип жавап бирә алабыз. Бер ел элек Дәүләт Советында кабул ителгән "Татарстан Республикасы бүләкләре турында"гы Закон нигезендә безнең үз орденыбыз булдырылган иде. Шушы дәүләт бүләгенең — "Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен" дигән орденның беренчесе Илһам Шакировка бирелә".

Бәйрәм кичәсе югары дәрәжәдә үтте. Юбилярны бер-бер артлы сәнгать осталары тәбрикләде. З. Сөнгатуллина, Г. Ибушев, Р. Маликов, Р. Ибраһимова, А. Фәйзрахманов, Татарстан дәүләт жыр һәм бию ансамбле, фольклор ансамбле. Юбиляр жырчы үзе дә репертуарыннан байтак жырлар башкарып тамашачыларга рәхмәтен белдерде.

***

Моннан 17 ел элек оештырылган "Татар жыры" конкурсы 2003 елдан мәшһүр жырчыбыз исемен йөртә. Мәдәният министрлыгы һәм Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе оештырган әлеге ярыш 16-20 февральдә булып узды. Быел ул И. Шакировның — 70, Казанның 1000 еллыгына багышланды. Конкурста 14 яшьтән алып 35 кә чаклы Россиянең төрле төбәгеннән йөздән артык башкаручы катнашты. Аларны Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Зилә Сөнгатуллина рәислегендәге жюри бәяләде.

Конкурста беренче бүләккә — Казаннан Айгөл Сагынбаева, Илшат Вәлиев, Алсу Зәйнетдинова, икенчегә — Казаннан Эльвира Сәлахова, Альберт Валиуллин, Алмаз Нургалиев, өченчегә Казаннан Венера Шәмиева, Эльвира Гафурова, Артур Исламов, Чувашстаннан Илдус Шәйдуллин лаек булды. Жиңүчеләргә акчалата бүләкләр һәм "Илһам" дип язылган кош сыны тапшырылды.

## ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР

Муса Жәлил исемендәге республика премиясенең быелгы лауреатлары итеп "Татарстан" журналы баш мөхәррире Рифат Фәттахов, С. Өметбаев исемендәге Минзәлә дәүләт драма театры коллективы һәм "Бәхетле балачак" хореография ансамбле билгеләнде. 30 яшькәчә булган яшьләргә яисә яшьләр белән һәм яшьләр өчен эшләгән затларга ике елга бер тапкыр бирелүче әлеге премиягә быел 12 кандидат тәкъдим ителгән иде. Алар арасында әдәбият, сынлы сәнгать, музыка, хореография, театр, кино сәнгате вәкилләре бар иде.

## МАТБУГАТ ҺӘМ ЯЗУЧЫ

Язучыларнын Г. Тукай исемендәге клубында әдәбият һәм көндәлек матбугат мәсьәләләренә багышланган җыелыш булды. Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин ачты. Аннары ул шагыйрь Рәдиф Гаташка — Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге, ә шагыйрь, прозаик һәм драматург Ркаил Зәйдуллага Ф. Хөсни исемендәге бүләкләре дипломын тапшырды.

Җыелышның көн тәртибендә каралган мәсьәлә буенча филология фәннәре докторлары Илдар Низамов һәм Дания Заһидуллинаның махсус әзерләнгән докладлары тыңланды.

Фикер алышуда язучылар Рабит Батулла, Равил Фәйзуллин, Зиннур Мансуров, Рашат Низами, Җәүдәт Дәрзаман, Зиннур Хөснияр, Наис Гамбәр һ. б.лар катнашты. Алар үзләренең чыгышларында бүгенге татар матбугатының киләчәк язмышына кагылышлы көнүзәк мәсьәләләргә, газета-журналларда тагын да кинрәк яктыртылырга тиешле аерым темаларга игътибар юнәлттеләр, әдәбият һәм көндәлек матбугатның уртак бурычларын үтәүдә каләм әһелләрен активрак булырга чакырдылар.

## ӘДӘБИ ФОНД ХИСАП ТОТА

Татарстан язучылары Әдәби фондының отчет-сайлау җыелышы булды. Анда хисап доклады белән Әдәби фонд идарәсе рәисе Гәрәй Рәхим чыкты. Оешманың финанс эшчәнлеге турында контроль-ревизия комиссиясе рәисе Нәҗибә Сафина чыгыш ясады.

Докладлар буенча фикер алышуда язучылар Данил Салихов, Айдар Хәлим һ. б. катнашты. Алар берничә ел элек финанс кыенлыклары аркасында авыр хәлдә калган Әдәби фондның яңадан тернәкләнеп китүен, кайгыртуга мохтаҗ каләм әһелләренә акчалата ярдәм күрсәтелә башлавын канәгатьләнү белән билгеләп үттеләр, оешманың Татарстан интеллектуаль милек агентлыгы, шулай ук Халыкара Әдәби фонд белән дустанә хезмәттәшлектә эшләвен, әдипләргә булышлык күрсәтергә теләгән иганәчеләрне табарга омтылуын бердәм рәвештә хупладылар.

Отчет-сайлау җыелышында Татарстан язучылары Әдәби фонды идарәсе рәисе итеп яңадан Гәрәй Рәхим, ә фонд директоры итеп Данил Салихов сайланды.

## ИДАРӘ УТЫРЫШЫНДА

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булып үтте. Анда ике идарә арасында башкарылган эшләргә йомгак ясалды. Аннары Казанның 1000 еллыгын, Җиңүнең 60 еллыгын лаеклы каршылау буенча язучылар алдында торган бурычларга игътибар юнәлдерелде. Рус телендә язучы яшь каләм ияләре белән эшләүнең торышы турында урыс әдәбияты остаханәсе җитәкчесе Лилия Газизова һәм әдәби консультант Владимир Корчагин хисабы тыңланып тикшерелде.

Январь аенда үткән утырышта драматургия остаханәсе җитәкчесе итеп Мансур Гыйләҗев билгеләнгән иде. Шул уңайдан ул идарә әгъзаларын остаханәнең 2005 елга эш планы белән таныштырды. Аннары Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясен бирү мәсьәләсе каралды. Ябык тавыш бирү юлы белән ачыклау өчен бюллетеньнәргә премиягә дәгъвалык итүче биш кандидатның исеме-фамилиясе кертелгән иде. Шулар арасыннан күпчелек тавыш җыеп, әдәбият галиме Хатыйп Миннегулов һәм драматург Данил Салихов җиңеп чыкты. Аларның беренчесенә әлеге бүләк Г. Исхакыйның иҗатын җентекләп өйрәнүе һәм аңа багышланган "Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты" (ТНК, 2004) дигән китабы өчен бирелсә, икенче автор исә соңгы елларда драматургия өлкәсендәге казанышлары өчен лаек булды. Татарстан Язучылар берлегенең әдәби тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтләр өчен тәгаенләнгән Җамал Вәлиди исемендәге премиясен идарә әгъзалары бертавыштан танылган әдәбият тәнкыйтьчесе Фоат Галимуллинга бирделәр. Авторның үткән ел Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән "Табигыйлеккә хилафлык" дигән китабы һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге шулай югары бәяләнде. Идарә утырышында яшь шагыйрь, прозаик Салават Юзеев һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә нәтиҗәле эшләүче Әлфәт Закирҗанов Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

## ПЕН-ҮЗӘК БОРЧЫЛУ БЕЛДЕРӘ

Татарстан Милли китапханәсендә Татар ПЕН-үзәгенең киңәйтелгән утырышы булды. Халыкара Туган тел көне уңаеннан оештырылган әлеге очрашуда танылган язучылар, галимнәр, хокук белгечләре, иҗтимагый оешмаларның вәкилләре, журналистлар катнашты.

Киңәшмәне кереш сүз белән ПЕН-үзәкнең президенты, Татарстан халык депутаты Туфан Миңнуллин ачты. Ул үз чыгышында төп игътибарны ана телебезнең республикада чын мәгънәсендә дәүләт теле дәрәҗәсендә күтәрелүе өчен кичекмәстән башкарылырга тиешле мөһим бурычларга, шулай ук латин им-

лясына кайту мәсьәләсенең бүгенге торышына юнәлтте, бу җәһәттән һәр халыкның үз телен файдалану, шул исәптән үзенең язу графикасын билгеләү буенча халыкара оешмалар раслаган үз хокукы булуын искәртеп үтте.

Бөтендөнья Татар конгрессы Башкарма комитетының чит төбәкләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе Фәрит Уразаев "латин проблемасы" унаеннан ЮНЕСКО Генераль директорына, тиешле документлар белән бергә, мөрәҗәгать җибәрелүе турында әйтте, утырышның төп тәртибенә куелган мәсьәләләргә республикадан читтә яшәүче милләттәшләребезнең мөнәсәбәтен бәян итте. Хокук эксперты, юридик фәннәр кандидаты Борис Пантелеев (Мәскәү) исә үзенең махсус әзерләнгән чыгышында РФ Конституция судының татар язуында латин графикасын куллануны тыю турындагы карарына (16 ноябрь, 2004 ел) җентекле рәвештә анализ ясады, кеше хокукларының Европа судына мөрәҗәгать итү процедуралары хакында сөйләде.

Аннары утырышта туган телне Россия күләмендә һәм милләттәшләребез яшәгән чит илләрдә саклау һәм яклау мәсьәләсе каралды. Бу унайдан язучылар Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Әхәт Мушинский, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Гәрәй Рәхим һ. б.лар үзләренең тәкъдим-фикерләре белән уртаклашты.

Татар ПЕН-үзәге әгъзалары "Татарстан" дәүләт телевидениесе һәм радиотапшырулар компаниясе, бигрәк тә Татарстан радиосының киләчәк язмышы унаеннан тирән борчылуларын белдерделәр.

### ФАКУЛЬТЕТТА ӨЙ ТУЕ

Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультеты яңа уку бинасына күчте. Әлеге вакыйга унаеннан факультетта фәнни-гамәли конференция дә булды.

Факультет деканы, профессор Васил Гарифуллин әйткәнчә, әлеге фәнни-гамәли конференциядә "Сәяси лоббизм", "Тележурналистның имиджы", "Санлы фотографиянең иҗади процессы" һ. б. темалар тикшерелгән.

Журналистика һәм социология факультеты — университетта иң яшь факультет, ул 1992 елда ачылган иде. Моңа кадәр студентлар берничә кысан аудиториядә генә белем алды, ә хәзер шартлар бик уңай.

### МИЛЛИ КИТАПХАНӘ БАЕДЫ

Мәскәүдән Татарстан Милли китапханәсенә күренекле тюрколог-галим Әдһәм Тенишевның 2 меңнән артык китап һәм документ исәпләнгән шәхси китапханәсе кайтарылды. Академик, СССР һәм РФ Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире булган Әдһәм Тенишев төрки телләр тарихы һәм тарихи-чагыштырма тел белеме буенча күпсанлы хезмәтләр авторы, Идел-Урал һәм Үзәк Азия төрки халыкларының хәзерге замандагы тел үзенчәлекләрен тикшергән галим, борынгы төрки тарих һәм мәдәни һәйкәлләр буенча зур белгеч иде.

### ҖӘЛИЛ МУЗЕЕНДА

Герой-шагыйрь Муса Җәлилне искә алу көне уңаеннан, 15 февральдә аның музей-фатирында "Моабит дәфтәрләре" күрсәтелде. Тамашачылар шулай ук әдипнең көрәштәшләре Р. Саттар һәм А. Алишның кулъязмаларын, шәхси әйберләрен карадылар.

Бу күргәзмәдә тагын бер фронтовик шагыйрь Ф. Кәримнең сугыш чоры шигырьләре, хатлар белән бергә пуля тишеп бетергән шинеле дә урын алган иде. Бирегә М. Җәлил премиясе лауреаты Рафаэль Мостафин һәм язучы Вакыйф Нуруллин белән очрашу булды.

Әлеге музейда фронтовик рәссам Мансур Рәхимовның шәхси күргәзмәсе дә ачылды.

### "КАЮМ НАСЫЙРИДА КУНАКТА"

Каюм Насыйри музеенда "Олуглык гакыл белән, әдип белән..." исемле тантаналы кичә узды. Ул татар халкының күренекле мәгърифәтчесе, галим-энциклопедист, язучы, педагог Каюм Насыйриның тууына 180 ел һәм музейга нигез салынуга 10 ел тулуга багышланды.

Анда галимнәр, Мәдәният министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгыннан вәкилләр, К. Насыйри исемендәге премия лауреатлары, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

Кичәдә "Габденнасыйр улы Габделкаюмда кунакта" исемле театральләштерелгән тамаша күрсәтелде. Аның авторы — Каюм Насыйри музее директоры Рушания Хөснетдинова. Рушания Салих кызы алып барган әлеге тамашада К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры актеры Илгизәр Хәсәнов, 80 нче мәктәп укучылары катнашып, үз осталыкларын күрсәттеләр.

Бөтенроссия, халыкара бәйгеләр җиңүчесе "Ак калфак" балалар фольклор ансамбле исә "Сак-Сок" бәетен сәхнәләштерде һәм татар халык көйләрен уйнады. Киров районы каршындагы "Елга аръягы" балалар иҗат үзәгенә йөрүчеләр "Кыз елату" дигән татар халык йоласыннан күренешләр күрсәттеләр.

## КАҺАРМАН ГАЛИМГӘ БАГЫШЛАП

Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Вил Мирзаяновның 70 яшьлегенә багышланган кичә булды. Аны татар милли һәм дини җәмгыятьләрен берләштергән "Милли шура" оешмасы үткәрде.

Мәгълүм булганча, Вил Мирзаянов Башкортстанның Дүртөйле районы Иске Кәңгеш авылында туган. Мәскәүнең органик химия һәм технология фәнни-тикшеренү институтында эшләгәндә ул сәяси темаларга мәкаләләр бастырып чыгарды. Аларда галим Россиянең халыкара килешүләрне бозып, химик корал житештерүен дәвам итүе хакында бәян итте. Шуның өчен эзәрлекләүләргә дучар ителеп, ул 1995 елда Америкага китәргә мәҗбүр булды. Бүгенге көндә Вил Мирзаянов Принстон шәһәрендә яши, Принстон һәм Вашингтон университетларында лекцияләр укый.

## КАРАБАШТА АТЛАСИ МУЗЕЕ

Бөгелмә районының Карабаш авылында истәлекле вакыйга булды — анда тарихчы Һади Атласи музей-китапханәсе ачылды. Шунысы игътибарга лаек— Карабаш авылында яшәүче милләтпәрвәр Фазыл Вәлиәхмәтов үзе туып үскән йортны бина итеп бирә. Милләт тормышында сирәк очрый торган бу вакыйганы авыл һәм район халкы бик югары бәяләде.

Һади Атласи музей-китапханәсен ачарга Бөгелмә һәм Карабаштан хакимият вәкилләре, милли зыялылар, мәктәп балалары килгән иде. Шушы тантана барышында язучы, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмовага Һади Атласи исемендәге премия тапшырылды. "Мәгърифәтче" дип язылган билге һәм диплом бирелде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Язучыларның үткән съездында шигърият өлкәсендә Һади Такташ премиясе булдыру турында карар кабул ителгән иде. Татарстан Язучылар берлеге гамәлгә куйган бу премиянең беренче лауреаты— хезмәттәшебез, танылган шагыйрь Рәдиф Гаташ булды. Каләмдәшебезгә яңа иҗади уңышлар телибез.

***

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен "Чаян" журналы редакциясенең әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөхәррире Гәрәев Мәгъсүм Гәрәй улына "Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелде.


## ТАТАР КИТАПЛАРЫН — ПОЧТА АША

Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез, тарихи Ватаннарыннан читтә яшәүчеләр, республикабыз мәдәнияте һәм әдәбияты белән кызыксынып торалар. Ләкин аларның һәрвакыт Казанга килеп, китап сатып алырга мөмкинлеге юк.

Шуңа күрә Татарстан китап берләшмәсенең 13 нче китап кибете ("Почта аша китап җибәрү" бүлеге), түләп алу шарты белән, Татарстан китап нәшрияты, "Мәгариф", "Заман", "Рухият" кебек республика нәшриятларының татар һәм рус телләрендә чыккан китапларын җибәрү белән шөгыльләнә.

Адресы: **420039, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 3 нче йорт.**
Телефоны: **(8432) 92-46-47.**


## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Тәфтиләү». ***И. Әхмәдиев рәсеме.***

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Марат Закир.**

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Балачак әдипләре**: Biобиблиографик белешмәлек / Рәис Даутов. Икенче китап = Писатели нашего детства: Биобиблиографический справочник / Раис Даутов. Вторая книга.— Казан: Мәгариф, 2004.—286 б. Тиражы—2000 данә.

"Мәгариф" нәшрияты хәзерге заман татар язучыларының тәржемәи хәлләре, иҗат эшчәнлекләре, әсәрләре турында матбугат бәяләмәләре, һәр язучының бала чагы белән бәйле хатирә-язмалары урын алган китап-белешмәлекләр чыгаруны дәвам итә. "Балачак әдипләре"нең беренче китабы 2002 елда дөнья күргән иде инде. Әлеге сериядән бу китапта утыз татар язучысы хакында татар һәм рус телләрендә мәгълүматлар бирелә. Белешмәлек мәктәп укучылары, укытучылар, балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр һәм, гомумән, әдәбият белән кызыксынучылар өчен файдалы булыр.

Нәшрият редакторы—Л. Гыйззәтуллина.

❊




Рафаэль МОСТАФИН. **И Казан, серле Казан...**—Казан: "Мәгариф" нәшр., 2004.—143 б. Тиражы—3000 данә.

Әлеге китап башкалабыз Казанның меңъеллык олуг юбилеена багышлана һәм шәһәрнең барлыкка килүе, төпләнгән урыны, халкы белән таныштыра. Шәһәр төзелү тарихы борынгы риваятьләр, татар, рус елъязмалары һәм чит ил авторлары истәлекләрендәге мәгълүматлар белән бәйләп аңлатыла. Басма шулай ук Казан хөкемдарлары турында, каланың архитектура һәйкәлләре хакында бәян итә.

Кереш сүз авторы—тарих фәннәре докторы Равил Әмирхан. Рәссамы—Нияз Хажиәхмәтов.

Нәшрият редакторы—Илсөяр Кадыйрова.

Индекс 73210



Марат Закир

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)